www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Роберт МИҢНУЛЛИН. Дәверләргә китеп барышы. *Шигырьләр*. ....3
Әхтәм ЗАРИПОВ. Әманәт. *Бәян*. ....7
Ләбиб ЛЕРОН. Бер яшисе иде кешечә. *Шигырьләр*. ....69
Сирень ЯКУПОВА. Ятим йорт. *Хикәя*. ....73
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Һәр сүзнең үз моңы, үз көе. *Шигырьләр*. ....79
Айзирәк ГӘРӘЕВА. Ни һоу! Яки нихәл? *Хикәя*. ....83
Булат ИБРАҺИМ. Кайнарлык бөркелсен рухыңнан. *Шигырьләр*. ....95

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Рифат СВЕРИГИН. Тургайларның туган ягы. ....99
*100нче бит:* Фоат УРАЗАЙ. Милләтне хәтер вә рух яшәтә. ....100

ТУКАЙ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Рифә РАХМАН. Тукай очырган карлыгачлар: «Бездә юк, булса да бик аздыр, беләм, тәнкыйтьчеләр». ....109

ЮБИЛЕЙЛАР

Фәния ГАЛИЕВА. Гомер — бер мизгел *(Миңгол Галиевкә 75 яшь)*. ....114
*Харрас Әюпның тууына 70 ел:* Фәридә ХӘСӘНОВА. Шигъри дога остасы иде ул... ....121
Харрас ӘЮП. Авырткан җир. *Шигырьләр*. ....125

СӘНГАТЬ

Юныс САФИУЛЛИН. Сәхнәдән нур чәчеп. ....127

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Театр — тылсымлы учак *(Оренбург рус драма театрының баш режиссёры Рифкать ИСРАФИЛОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе)*. ....134

ТАРИХ

Фәүзия БӘЙРӘМОВА. Соңгы туранчы... *(Һади Атласиның тууына 140 ел)*. ....140
*Юбилейга барышлый:* Зәкәрия АХМЕРОВ. АБ-225. *Очерк*. ....167
*Бәләкәйләр:* Мәсгут ИМАШЕВ. Бәләкәй Мәсгут. ....170

АК ҖИЛКӘН

Хикәя яза аласызмы? Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ хикәяләре. ....180
Илүзә КАШАПОВА. Серле кунаклар. *Хикәя*. ....184
*Табигать һәм мин:* Вакыйф НУРИЕВ. Җиңүче кем? ....185
*Шаян сәхифә*. Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....187
«Казан утлары» архивыннан. ....112
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*
**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер)**.**

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.1268).*
: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*


: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 29.07.2016, график буенча 29.07.2016.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ М-1907. Тираж 4016.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210, П2365 (физик затлар өчен), 16262, П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе иркле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2016 ел



Роберт
Миңнуллин

# ДӘВЕРЛӘРГӘ КИТЕП БАРЫШЫ

## Хөррият

Без булырга тиеш азат халык,
Без булырга тиеш хөр милләт!
Тик хөр милләт булып яшәр өчен
Кирәк безгә ирек, хөррият!
Йөрәкләрдә дүрт гасырлык максат,
Күкрәкләрдә безнең бер ният!
Халкым сине гомер буе көтте –
Өметләрне акла, хөррият!
Без хөрлеккә әле өйрәнмәгән,
Хөр яшәргә безне дә өйрәт!
Сине безгә бүләк итмәделәр,
Яулап алдык сине, хөррият!
Тибәме соң безнең күкрәкләрдә
Хөррияткә лаек хөр йөрәк? –
Сине әле якларга да кирәк,
Сакларга да кирәк, хөррият!
Хөрриятне яулап алган икән,
Татар җаны әле хөр, димәк!
Татарстан, Казан өсләренә
Канатларыңны җәй, хөррият!
Оч син, талпын, и азатлык кошы,
Үз артыңнан безне дә иярт!
Тик Ватанның биек күкләреннән
Очып китә күрмә, хөррият!

---

Роберт МИҢНУЛЛИН (1948) – *Татарстанның халык шагыйре; Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Җиде томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китап авторы. Казанда яши.*

## Кол Шәрифкә мәдхия

Син гөрселдәп ауган идең,
Син дөрләп янган идең.
Син бары тик күңелләрдә,
Хәтердә калган идең...
Күңелләр сыкрый бүген дә
Шул чордагы ярадан.
Торып бастың аягүрә –
Егылмассың яңадан!
Безне яңа заманнарга
Син дәшеп тор, Кол Шәриф!
Халкыбызның күңеленә
Нур чәчеп тор, Кол Шәриф!
Нур чәчеп тор! Син үзең дә
Нурга күмел, Кол Шәриф!
Без кол түгел, без кол түгел,
Без кол түгел, Кол Шәриф!
Тарихларның төпкеленнән
Күтәрелдең, терелдең.
Терелдең дә күккә аштың
Һәм җиһанга үрелдең.
Күтәрелдең син күкләргә,
Күтәрдең син безне дә.
Бөтен дөнья күреп тора:
Көчле дә без, эзле дә!
Тарихыбыз – гыйбрәтле дә,
Тарихыбыз – бөек тә!
Башларыбыз – иелмәгән,
Карашыбыз – биектә!
Күңелләрне рухландырып
Кайттың безгә яңадан.
Кайтты безгә яңа шөһрәт,
Кайтты безгә яңа дан!
Безне яңа заманнарга
Син дәшеп тор, Кол Шәриф!
Халкыбызның күңеленә
Нур чәчеп тор, Кол Шәриф!
Нур чәчеп тор! Син үзең дә
Нурга күмел, Кол Шәриф!
Без кол түгел, без кол түгел,
Без кол түгел, Кол Шәриф!

## Алып булып кабат калыкты!

*2013 елның 10 октябрендә Уфада Башкортстанның
халык шагыйре Мостай Кәримгә һәйкәл ачылды.*

Ятим булып калган иде Уфа,
Мостай киткәч безнең арадан.
Яңа дан һәм яңа шөһрәт булып
Кайтты безгә Мостай яңадан.

Мостаебыз Уфа уртасында
Алып булып кабат калыкты!
Рәхмәт сиңа, Келәш, халкыбызга
Биргән өчен мондый Алыпны!

Уфаларда бигрәк моңсу иде,
Нидер көтә иде күңел дә...
Бүген безне тагын Мостай җыйды!
Бик моңсу да кебек, түгел дә.

Бөтен шагыйрьләр дә һәйкәл булып
Кайта алмый безгә киредән.
Андый бәхет сирәкләргә генә,
Бөекләргә генә бирелгән.

Мостай берәү генә! Һәр халыкта
Берәү генә була андыйлар.
Берәү генә булган өчен дә бит
Бөекләрне шулай данлыйлар.

Килдек менә, тик һәйкәлгә түгел,
Мостаебызга баш иягә!
Минем өчен Мостай исән әле! –
Телем бармый һәйкәл диягә.

Булгангамы әллә замандашы,
Белгәнгәме әллә якыннан,
Минем өчен Мостай һәйкәл түгел,
Койсалар да аны алтыннан.

Биек иде аның урыннары:
Язганы да, әйткән сүзе дә;
Бөек булды кылган гамәлләре,
Бөек була белде үзе дә.

Озын-озак юлга чыккан Мостай, –
Офыкларда аның багышы...
Халкы белән яңа гасырларга,
Дәверләргә китеп барышы!

Киләчәккә китеп бара Мостай,
Шагыйрь һәрчак безнең арада...
Юк, Мостайны берни туктаталмый,
Мостай гына шулай барала!

Мостай безгә иртәгә дә кирәк!
Мохтаҗ идек аңа элек тә...
Мостай гына шундый була ала:
Үзе җирдә, үзе биектә!

## Пушкин бәйрәме

*Шагыйрь Сергей Малышев рухына*

Килмәдең син Пушкин бәйрәменә...
Тиеш идең шигырь сөйләргә.
Барыбыз да көттек... Килмәвеңне
Юрадык без әлләниләргә.

Юкка булмаган шул борчылулар,
Юкка булган безнең көткәннәр:
Пушкин туган көнне сине, Сергей,
Больницага алып киткәннәр.

Без Пушкинга шигырь укыганда,
(Вакытларын каян тапкансың?!)
Йөрәгеңне кысып, үлем белән
Яшәү арасында яткансың...

Дөньядагы гаделсезлекләргә
Ничек түзсен шагыйрь йөрәге?!
Түзәр иде – җәмгыятькә әгәр
Шагыйрьләрнең булса кирәге...

Тик шагыйрьләр алар әле һаман
Әйләндерә шигырь чыгырын...
Пушкин бәйрәмнәре синсез үтә,
Җитми анда синең шигырең.

Укымыйсың инде син шигырьне,
Берчә каушап, берчә тотлыгып.
Синең шулай шигырь укыганны
Тыңламыйлар инде йотлыгып.

Сагындырып искә төшәсең син,
Сагынмасын инде сине кем?!.
Пушкин бәйрәмендә шигырь укыйм...
Үземнекен түгел, синекен.

## Казакъ акыннарына

Сезнең хакта никтер бик еш уйлыйм,
Бик еш укыйм сезне, акыннарым, –
Бик борынгы һәм бик алыстагы
Аркадашларым һәм якыннарым!

Ул якынлык килә ераклардан,
Ул уртаклык килә гасырлардан...
Безнең уртак тарихыбыз бит ул
Асыллардан асыл, асыллардан...

Урдаларның алтын дәверләрен,
Данлы далаларның давылларын,
Тарих битләренең авырларын
Бергә кичтек, төрки бауырларым!

Бөек Жамбулларым, Абайларым –
Акыл ияләре, агайларым!
Сез бит безгә бик тә якын кавем, –
Шулайлыгын күптән абайладым.

Мин һәрвакыт сезгә тартыламын,
Сагынамын сезне, аһ, җаннарым! –
Казакъ шигыренең даһилары –
Мукагалиләрем, Магжаннарым!

Яшьтән таныш Кеңшеликләрем һәм
Чордашларым – Галым, Нурланнарым! –
Очрашканда һәрчак күреп торам
Якты йөзегезнең нурланганын!

Күтәрелеп, төбәп бер караргa
Ярый әле бар, дим, Олжасларым!
Батыр җанлы казакъларны күрсәм,
Күтәрелә рухым, чал башларым!

Акыннарым, сездә дә бит уйный
Казакъ ханнарының кайнар каны.
Сез – казакъның рухы, җыры, җаны,
Казакъ Иленең сез сайрар таңы...

Сезнең омтылышлар олырактыр,
Сезнең йөрәк утрак-ялкынрактыр!
Сезнең үзегезнең Илегез бар...
Сез Ходайга, ахры, якынрактыр!

Куанам мин күреп казакъларның
Ирекләләрен һәм азатларын!..
Мең яшәгез Азат Илегездә,
Бауырларым минем, казакъларым.

## Талдыкорганда да татарлар бар...

Талдыкорганда да татарлар бар.
(Ә татарлар кайда юк соң алар?)
Талдыкоргандагы татарлар да
Туган туфракларын юксыналар.

Шуны белеп мин дә килдем менә
Татарларым белән күрешергә,
Тормышлары белән танышырга,
Татарларның хәлен белешергә...

Алар мине тотып-тотып карый,
Мин аларга күктән иңгән кебек.
Алар өчен минем монда килү
Казаннардан бер хан килгән кебек...

Җырлый әле алар татар җырын,
ТНВны карап бара алар.
Бер карасаң, ак сакаллы картлар,
Бер карасаң, сабый бала алар.

Картлар гына монда... татарларның
Әбиләре монда, бабалары.
Кемдер, белмим, Талдыкоргандагы
Татарларыбызның балалары?..

Күзләрендә – сары сагыш кына,
Телләрендә – истәлекләр генә!
Талдыкоргандагы татарларга
Телим бары исәнлекләр генә!

Талдыкорганда да татарлар бар.
Тормышлары менә дигән икән.
Тик күзләре сагыш белән тулы...
Шунсы гына менә нидән икән?

Нидән булсын? Сагынудан инде,
Сагынудан туган тамырларны.
Табарлармы, юкмы? Тапсалар да
Тамырларын алар таныйлармы?

Сыенганнар ерак далаларга
Безнең күпме татар балалары?
Якынаеп беткән инде күптән
Казакъ белән татар аралары.

Йөзләрендә – казакъ чалымнары,
Сүзләре дә казакъ белән катнаш.
Үзем аралашам, үзем уйлыйм:
«Ни сөйләрмен Казаныма кайткач?»

Сагыналар алар яшь чакларын,
Сагыналар алар Ватаннарын...
Картайганнар инде, картайганнар
Талдыкоргандагы татарларым...

## Нигә кирәк сиңа Казан?

*Татарның Казакъстанда яшәүче*
*мәшһүр рәссамы Камил Муллашевка*

Нигә кирәк сиңа безнең Казан?
Ник киләсең килә Казанга?
Ерактагы кояш җылыгамы?
Сусадыңмы әллә азанга?

Тамырларың тартып китерәме
Бабаңнарның ерак иленә?
Кан авазы сорап тормый бездән...
Киленә шул инде, киленә.

Безнең үзебезгә кирәк синең
Татар рухың, татар талантың...
Безгә килеп таба алмасаң да
Талантыңа лаек дан, алтын,

Синең рухың безнең өчен үзе
Алтын бәясенә торырлык!
Талантыңа, Камил, табынырлык,
Сокланырлык һәм баш орырлык!

Синең иҗат – татар җиһанындыр...
Иҗатыңа шаклар катарлык!
Каян иңә сиңа милли хисләр,
Каян килә сиңа татарлык?

Югыйсә бит сиңа рәхәтләнеп
Кытай яки казакъ булырлык...
Кытайдагы ерак борынгылык,
Казакътагы төрки горурлык!

Юк шул, үзең – казакъ даласында,
Күзең һаман – Казан ягында.
Бик сагынсаң, Камил, Казаннарга
Син килерсең әле тагын да!

Безгә кирәк синең татарлыгың,
Чакырганны көтми килүең:
Кытайларча матур елмаюың,
Казакъларча ихлас көлүең.

Дөресрәге, безгә кирәк синең
Килүләрең түгел, кайтуың.
Сөембикә дә сиңа пышылдыйдыр:
«Казаннарга ешрак кайт, улым!»

Нигә кирәк сиңа шәһри Казан?
Ник Казан дип тибә йөрәгең?..
Болай гына сорыйм, Камил дустым,
Мин бит беләм нигә кирәген.

Әхтәм
Зарипов

# ӘМАНӘТ

БӘЯН

## 4 БҮЛЕК

### Көрәш баскычлары

Куркырлык сәбәпләр булмаса да, шомлануым тагы да артты. Беркая чыкмый, беркемгә шалтыратмый «сам»ның чакыруын көтеп ятам. Тагы температурам уйный башлады. Йә күтәрелә, йә төшә, кан йөрешен җиңеләйтеп, нервларны йомшарту өчен мунчада кызынырга киңәш бирделәр. Күрше подъездда яшәүче пенсионер белән парлашып, парланырга йөри идек.

– Кичә генә мунча кергән булсам да барам! – дип ризалашып кына калмады. – Үзем куганны күпме алыйм? – диде ул.

– Миндә аның кайгысы юк, күрше, рәхмәт.

– Ә нинди кайгың бар?

...Мин аңа кыскача, Коръән «тикшерү» вакыйгасын, Зәкәрия абзый белән танышуны, аннан заказлар кабул итүемне, «Религии мира» журналының хәбәрчесе белән булган әңгәмәне, шәхесемә кара яккан шикаять хаты килүне, «зам»ның янавын – барысын да кыска-кыска гына сөйләп:

– Нинди чара күрелү ихтималы бар? – дидем.

– Әгәр хат Диния нәзарәтеннән булса, пүчтәк эш түгел бу. Андагы халык грамотный: нәрсә язарга да, кемгә, кайчан язуны да беләләр. Хакимият белән бер йөкне тарткач, курку кимеде аларда.

– Диннең дәүләттә, дәүләтнең диндә эше юк ич.

– Юк иде. Хәзер бар, – диде күршем, бик яшерен сер чишкәндәй.

– Син мәсьәләне артык куертасың кебек.

– Син анда аңламаганыңны аңлату сорагансың. Мин дә сорар идем. Сорауларым тел очымда йөри. Мин шунысын нык беләм: саф күңелгә гөнаһ ябышмый. Иман ныклыгы шунда.

– Күңелең сафлыгына ышандыру авыр шул.

– Ә син аңа ышандырырга тырышма! Үзеңчә яшә!

– Буш имезлекне көчләп авызга каптырганда нишләргә?

– Татардан азган философ Чаадаев Рәсәйгә карата: «Её прошлое позорно, настоящее малосимпатично, а будущее более чем сомнительно», – дигән. «Сомнение» – «шикле», «шөбһәле» дип тәрҗемә ителсә, мин Чаадаевка

*Ахыры. Башы узган санда.*

ышанмыйм. Киләчәк шикле дә, шөбһәле дә булсын! Әмма булсын гына ул, килсен генә! Аның нинди булуы безнең үзебездән тора ич! Синнән, миннән! Әгәр сиңа буш имезлек каптыралар икән – син аны авызыңа капканчы, шикләнүеңә шатлан: һәр ачыш, һәр белем шикләнүдән башлана. Хафаланма, әйдә, киттек!

– Әләккә каршы дару юклыгын беләм.

– Әләкнең идәне черек, түшәме ачык!

...Мунча чыккач, термоска төрле үләннәр салып пешерелгән хуш исле чәй эчеп утырганда, үзенә-үзе каршы килеп: «Шикләндермәгән хакыйкать бар дөньяда. Мәсәлән – үлем. Ул, шиксез, килә торган хакыйкать», – диде күршем.

– Үлем турында сөйләшәсем килми.

– ...Теге кара елларда атылгач, безнең мулла бабайны «Архангельское зиратына Туганнар каберлегенә күмелде», дигәннәр. Урынын тапмасак та, чәчәк илтергә әни мине бер тапкыр алып барды. Бәлки, эзләнүләреңне шуннан башларсың? Анда кемнәр генә күмелмәгән?! Кәрим Тинчурин, Галимҗан Ибраһимов та шунда ята, диләр.

– Зәкәрия абзыйныкылар гади тимерчеләр булган бит...

– Тимерчеләрне дә сәясәт җинаятендә гаепләп атканнар.

– Анысы шикләндермәсә дә, рәхмәт... соңрак барырмын.

...Рәхмәт дисәм дә, эзләнүләрне Архангель зиратыннан башламадым. Зәкәрия абзый үзе язып биргән фамилияләрнең нәселләрен табып сораштырырга булдым. Бәлки, алар ни дә булса хәтерлиләрдер...

Гомере буе Зәкәрия абзыйлар эшләгән заводтан пенсиягә чыккан Әнвәр абзый сөйләгәннәрдә өметләндерү чаткылары бар иде:

– Ничәнче елда икәнен хәтерләмим – Брежневны күмеп, кәнәфигә Черненко утырган көз иде бугай. Җылы яклардан җирән чәчле бер әфицәр кайтып, анасын хәтерләүчеләрне эзләп йөрде. Фотосын күрсәтеп сораштырса да, очраткан марҗам түгел иде.

– Фотодан марҗалыгын белеп буламыни?

– Исемен «Люда» дигәч, сары чәчле булгач – марҗа булмый, кем булсын? Хикмәт шул блондинка улының һәйкәл куйдырырга кайтуында! Менә, ичмасам, бала дисәң дә бала! Ә безнекеләр... үзеңнән калган акчага да таш куйдырмаячаклар... тәүбә...

– Бала үзе үк ата-анага һәйкәл.

– Анысы да дөрес. Бу җирән кешенең янында улымы, оныгымы сөйләшүне тыңлап торды. Күрәсең, әбиләре аның өчен дә кадерле кеше...

– Һәйкәл турында тагы ни дә булса беләсеңме? Куелдымы ул?

– Үлгән кешегә дога гына кирәк дидем дә, шундый бала табып калдырган Ана рухына дога кылдым. Моны оныттым, дияр идем, отдел кадрдан бермәл Флүрә шалтыратты: заводта эшләп, шәхес культы чорында корбан булганнарга һәйкәл ачу тантанасына кил, ветераннарга күчтәнәч бар, шул Люда малае акча җибәргән, диде. Баралмадым, чирли идем. Минем өлешне кемгә биргәннәрдер.

– Һәйкәлен күрдегезме соң?

– Завод идарәсе янындагы стенага беркетелгән мәрмәр такта икән ул. Шунда язылган фамилияләр арасында «Людмила Александровна Терентьева» дигәне җирәннең анасы булгандыр инде.

– «Людмила»мы, «Любовь»мы?

– Анысын һәйкәлне ясаучыдан сорап дөресли аласың! Чөнки хәзер ул заводның хуҗасы нindiдер «ООО» ди.

...Идарә бинасы да, андагы мәрмәр такталар да каядыр күчкән булып чыкты. ...Рәссамнар берлегендә мин эзләгән сынчының вафат булуын, сәнгать әсәре дип саналмаган эшләрнең документлары сакланмавын әйттеләр.

...Генрихның, Казанга килгәч, кайда, кемнәрдә тукталуын белү зарурлыгы туды. Яшьтәш-танышларыннан кем дә булса берсе исәндер, алар белән очрашкандыр, дигән фикер мине кайчандыр Зәкәрия абзыйлар яшәгән бистәгә китерде. Бистәнең исеме сакланса да, бараклар урынындагы 9-12 катлы йортлардан Рыжий Генрихны хәтерләүчеләрне табу нерв бозу гына булачагын күргәч, сорашып та тормадым – киттем.

...Өмет Шаршада балалар йортында тәрбияләнеп таралышкан егет-кызларның берәрсен табып, сораштыруга күчте.

Министрлыкларда Шаршада балалар йортының инде күптән ябылуын, авылының да бетеп баруын, кемнәрнең кайдалыгы турындагы мәгълүматларнең сакланмавын әйттеләр. Бу эшләрне отпускадан соң эшкә чыккач, телевидение исеменнән эшләү нәтиҗәле булачагына өметләнеп, Генрихны эзләүдән Зәкәрия абзыйның әтисе кайда күмелүен белеп, тартмадагы туфракны «җирләү» хәстәренә керештем. «Ритуальные услуги»га шалтыратып, кем белән сөйләшергә, аларның эш вакытларын белдем. Ландыш Радиковнага килергә куштылар, мондый мәсьәләләрне ул гына хәл итә ала, диделәр.

«Коры кашык авыз ерта»дан чыгып, аңа «Александрит» кашлы көмеш беләзекне бирергә булдым. (Бәхеткәме, бәхетсезлеккәме, алып кайткан бүләкләрне хатын: «Торсын әле, сәбәпсез өләшми тор», – дип тараттырмаган иде.)

Исеме Ландыш булса да, тигәнәккә тартым кыяфәтле мадам, бик мәрхәмәтле күренергә тырышып, «хуш киләсез, көтә идек, кемне озатабыз?» дип каршылады, кәгазь салфетка белән урындыкны сөртеп: «Утырыгыз!» – диде.

– Рәхмәт илтифатыгызга.

– Игътибар белән тыңлыйм – сөйләгез! – диде ул, кемгәдер телефон шалтыраткан арада. Күземә карамый гына ул номерлар җыя, мин «гозеремне» сөйлим.

Зәкәрия-Самуэль тарихының хаҗдагы очрашуларга кадәрен сөйләдем дә, тартманы күмү мәсьәләсенә күчкәч, тукталдым. Чөнки Ландыш Радиковна мине тыңламый, кем беләндер телефонда сөйләшә иде – ул да туктап калды.

– Прекрасная легенда, – диде ул, күзләремне бораулап, – кызганыч, Иске зиратка күмү, вообще юк; мәрхүм бик дәрәҗәле кеше булса, югарыдан күрсәтмә кирәк. Күрсәтмәсез күмү түгел, зиратка керү дә чикле. Яңа зиратка күмегез! Почётный гражданин булса, нибары кырык мең сум...

...Шунда мин, вакыт җиткәнен чамалап, кыйммәтле беләзекне чыгардым да, туфрак салган тартма күмеләчәк урынның шушы җиһазларны эшли торган фабрикалар хуҗасы өчен икәнен (аңларга теләгән кеше аңларлык), «җырлап», «буш итмәс» дип тә өстәдем...

...Ландыш Радиковна тагын телефон номерлары җыеп, бик тә җаваплы урын биләүче «вечный» депутатның исемен атады да: «Киңәшмәне башлый торыгыз, мине монда бүлдерделәр», – диде. Аңлашыла: бу аның үзен бик кирәкле «кишер яфрагы» булуын күрсәтүе иде.

Аннары ул, бер сүз әйтми, беләзекнең проба саннарына карап, «Александрит»ын тикшерде дә, «мәҗбүр иткәч, тыңламый булмый инде» кыяфәтендә, аны сул кулына киеп тә куйды. Шуның белән, «операция тәмам»лануын аңлатып, тагы телефонга үрелде. Һаман чыгып китмәвемә

гаҗәпсенгәндәй, нәрсәдер әйтмәкче иде дә, ялгыш туфрак салган тартмама күзе төште.

– Күпме тора инде бу безнең акчага?

– Сатылмый бу, күмелә!..

– Беләзекнекен сорыйм.

– «Жигули» шестёркасыннан ким түгелдер.

– Кемегез була үләчәккә претендент?

– Хажда таныштык... Аның байлыгы Австралиядә – җиденче, дөньяда йөз илле алтынчы урында.

– Кеше кесәсендәгене санамыйк...

– Әйттем исә кайттым...

– Сез мине уенчык биреп алдамакчы булсагыз – нык ялгыштыгыз; мин бирегә эксперт чакыртып, аның чын хакын тикшертә алам бит...

– Чакыртыгыз! Миңа да кызык булыр...

– Әтәчләнмик! Ул сезнең исәпкә булачак. Ә мин сезнең белән үзем уртак тел табарга телим. Мөмкин булса...

– Ә миңа тел түгел, урын кирәк.

– Үзегезгәме?

– Кулыгыздагы тартмага дип сөйләдем ич...

– Махсус шушындый операцияләр өчен эшләнгән тартмамы бу «иномарка» тартма?

– Бу тартмада диңгезгә чумганда медуза тешләмәсен өчен сөртенү мае булган. Зәкәрия абзый анда балчык салган. Чөнки бездә монда медузалар юк дип уйлаган.

– Тартмада чын балчык булуын раслаган нинди документыгыз бар?

– Соң... шул балчык үзе! Ягъни, туфрагы! Ачып карагыз!

– Исеме ничек?

– Австралия туфрагы.

– Урын туфракка кирәкме?

– Тартмасы белән күмәргә кирәк аны, урын биләр өчен.

– Кабер ташына «тартма» дип кенә куярсызмыни?

– Самуэль Конапацкий дип...

– Яһүдмени ул?

– Польша татары дип сөйләдем ич.

– Алласы кем?

– Алла һәммәбез өчен дә бер – Алла!

– Шулай икән, нигә католиклар зиратыннан урын эзләмичә, безгә килдегез? Польша кертмиме?

– Чөнки мөселман ул.

– Аларда мөселманнарны күммиләрмени?

– Ул күмелгән инде. 1945 елдан анда ята.

– Шулай булгач, нигә аңа Казан зираты кирәк? Ике җирдә ятмакчымы? Хи-хи-хи!

– Аңа түгел – урын Зәкәрия абзыйга кирәк, ягъни документ-тәзкирәсе буенча Конопацкийга. Тегендә Конопацкий Зәкәрия абзый исемендә ята. Монда Зәкәрия абзый Конопацкий булып ятачак.

– Урын кайсына кирәк?

– Зәкәрия абзыйга. Документ буенча Конопацкийга.

– Димәк, ике урын?

– Мин сезгә сөйләшүебезнең башында ук аңлаттым: бер урын кирәк! Авансом!

– «Аванс» сүзен әйтсәгез, күптән аңлаган булыр идем: әйтмәдегез. Нәрсәдер сөйләдегез дә сөйләдегез... Главное калган.

– Зәкәрия-Самуэль тарихын сөйләдем.

– Миңа тарих түгел, факт кирәк!

– Ә миңа әнә шул тартманы Зәкәрия абзыйның әтисе каберенә янәшә күмү кирәк. Факты бары шул гына.

– Ә авансы?

– Урын!

– Каберен таптыгызмы соң?

– Шуңа сезгә килдем.

– Сүзне шуннан башлау кирәк иде. Ә сез «ике исемле поляк», «Самуэль», «Зәкәрия» легендалары белән баш катырасыз. Конкретика кирәк! Натура!

– Хәзергә Австралиядә яшәүче Зәкәрия абзыйның әтисе белән янәшә Казанда җирләнәсе килә. Натурально.

– Аның мөселман яисә Польша татары булуын раслаган нинди документыгыз бар?

– Ул Польша татары түгел, ә казанлы! Хаҗда бергә булган казанлылардан шаһитлык белешмәләре яздырырга мөмкин.

– Аларны кем раслый?

– Кирәк дисәгез, Диния нәзарәтендә раслый алалар. Шаһитлар бар. Зәкәрия абзый өчен иң мөһиме – атасының каберен табу.

– Ничек табарга җыенасыз?

– Сезнең ярдәм белән!

– Казан зиратларында күмелүе турында документы бармы?

– Сездә булырга тиештер дип уйлыйм.

– Ә мин «бу абзый мине ни өчен шантажировать итә икән?» дип уйлыйм.

...Җитмеш ел элек күмелгәннәрнең түгел, җиде ел элек үлгәннәрнең дә данныйлары яңа зиратларда гына саклана, сакланырга тиешле булса.

...Мондый «иномарка» тартмаларны күмү өчен Диния нәзарәте рөхсәте белән крематорийдан белешмә язуы кирәк. Крематорий Казанда юк. Аның өчен мәетне Мәскәүгә алып барып яндыру кирәк. Әгәр Диния нәзарәтеннен һәм крематорийдан язуларың булмаса, бу тартманың эчендәгеп махсус лабораториядә тикшертеп, зарарсызлыгын раслатырга кирәк. Бәлки анда Сибирская язва микроблары тулыдыр?

– Туфрак кына, символ гына анда...

– Нинди символ, нинди туфрак?

– Туфрак – туфрак инде: карагыз.

– Барыбыз да туфрактан яралган. Кайсы Зәкәрия туфрагы, кайсы Конопацкийныкы булуын белергә кирәк.

– Ник аларны белү кирәк?

– Һаман аңламадыгызмы?

– Сез аңлагыз: Зәкәрия абзыйның атасы янында күмеләсе килә! Мин монда бер йомышчы гына, ягъни, акча – аннан, эш – бездән!

– Алайса тартманы калдырасыз. Анализлар үткәрү безнең оешма өстендә булыр. Рәсми заявка белән тикшертсәгез – илле биш мең, танышлык аша, квитанциясез эшләтсәгез, кырык биш меңгә төшәр.

– Минем бу өлкәдә танышларым юк.

– Мин сезнең танышыгыз булырга риза. Кайсы юлны сайлыйсыз?

– Кайсы тизрәк эшләнә?

– «Тизрәк» дигәндә, күпме вакыт сезне канәгатьләндерә?

– Сезнеңчә күпме?

– Максимум кырык көн. Минимумы бер ай.

– Риза. Тик мин өйгә кайтып, акча күчерү мәсьәләсен хәл итәргә тиешмен.

– Танышлык белән эшләнгән эшләр өчен банк яки почта аша түләнелми, ягъни квитанциясез генә. Алдым – бирдем и... вәссәлам.

– Миңа квитанция түгел – рөхсәт язуы кирәк.

– Менә сезгә пропуск. Шуны Иске зират администраторына биреп, озатучы алырсыз. Кая барып, нәрсә күрсәтүне ул белә. Эзләгән мәрхүмегезнең сезне көтеп ятуы бик ихтимал.

– Рәхмәт...

– Мин сезне иртәгә иртәнге сигезгә шушы бүлмәдә көтәрмен. Билетны урын тапкач алырсыз. Сөйләшкән шартларда, дигәнем...

...Икенче көннең иртәсендә хатыннан әҗәткә илле мең алып, кайбер нәрсәләрне ломбардка тапшырырга ниятләп, юлга чыктым. Трамвайга барганда, юлымны кара мәче кисеп узгач, такси тотып, ломбардка таксида илттердем.

...Акчаны Ландыш Радиковна кулына тотмады, гөл чүлмәге астына куярга кушты. «Куюны» күрүгә телефонга тотынды, кемгәдер утыз алты көннән дигәнне аңлатты да, миңа тагы бер билет бирде. Аннары күземә карамый гына:

– Уңышлар телим! – диде дә журналын актарырга кереште.

Бу инде миңа «эшең бетте, китәргә мөмкин» дигәнне күрсәтү иде. Гөл чүлмәге белән хушлаштым да Иске зиратка юл тоттым.

...Зират конторасына Ландыш Радиковна шалтыраткан булып чыкты – Әбелнәгыйм исемле егет көтеп тора иде. Бераз салмыш булса да, фикер йөртүенең ата-анасы бар:

– Син, абзый, ак болыт астындагы бозавыңны эзлисең. Аны күптән суеп ашадылар инде (сөяген дә таба алмассың). Иркенрәк бер буш урынны билгелә дә: «Таптым!» – диң. Мин шуңа чын шаһит! Өч шаһит дисәләр, өчне табам! Барысының да яше сиксәннән узган булыр. Олы мәчеттә язуын грамотно яздырып, мөһерен бастырып бирәм. Казу, күмү расходларына җәмгысы унбиш бөтен дә, плүс миңа чәйлек.

– Аңладым шикелле.

– Ризалык сүземе бу?

– Рөхсәт ителгән мөмкинлекләрдән файдаланып, әүвәл үзем эзләп карарга телим.

– Аны эзлисе юк. Андый урыннар, күп булмасалар да – барлар. Килешеп эшләгәндә...

– Хәзергә эшнең шушы этабында аерылышыйк. Татулык белән.

– Татулыкны тотып кибеткә кереп булмый. Аванс калдыр. Барыбер киләчәксең бит...

– Янымда наличный акчам юк, энем, ышан. Кыйммәтле муенсам бар, шуны калдыра алам. Кызларыңа шәп бирнә булыр...

– Минем кызым юк.

– Хатыныңа...

– Хатыным ялтыравыкка кызыкмый.

– Анаң исәндер?

– Мин детдом баласы.

– Кайсы детдомда үстең?

– Хәзер юк инде ул.

– Ничәнче елларда?..

– Армиягә киткәнче... Мин соңгы потоктан. Безне Иж-Бубыйга кушкач бетте Шаршада детдомы. Хәзер инде авылы да беткән, диләр.

– Кызганыч...

– Син үзең дә шуннанмы әллә? Ник кызганасың?

– Анда тәрбияләнгән Генрих исемле кешене эзлим мин... Хәзер өлкән яшьтәге пенсионер булыр иде ул җирән малай. Исәнме-түгелме – белүче, күрүче юк.

– Безнең группада Генрих исемле җирән удмурт малае бар иде. Бик кыю, булдыклы иде – корт чагудан үлде ул.

– Детдомда медперсонал да юк идемени?

– Урманда була ул хәл. Карт юкә агачының куышында корт оясы табалар. Кояш баегач, балын алмакчы булып, агач түбәсенә менеп китә бу. Күзлек урынына битен майкасы белән генә каплый, аркасы ачыла... ...Үзем күрмәгәч, дөресен белмим. Кулын тыгып, кәрәзнең кайдалыгын белүе була – икенче тишектән чыккан күч моңа сарыла... ...Тәненнән йөздән артык корт угы алганнар. Бәлки, исән дә калган булыр иде – шешенмәс өчен дип, Иж суына чума ул. Кич бит, төн. Су салкын. Күрәсең, көзән җыерган мәрхүмне. Гәүдәсен икенче көнне күпер турыннан табалар. Бик кыю егет иде...

– Кыюлыкның урыны башка эштә кирәк шул.

– Чаңгы ярышларында ул гел беренче килә иде. Сабантуйларында баганага менү – аныкы.

– Бәлки аның исеме Генрих булмагандыр? Милләте дә удмурт түгелдер? Бакыр чәчле «рыжик»лар башка милләтләрдә дә бар ич.

– Ул кадәресен белергә мин бит кечкенәләр группасында идем. Аның чын дөресен детдомда тәрбияче булып эшләгән Мөслимә апа белергә тиеш. Генрихны күмгәч, аны гаепләп тә маташтылар; янәсе, карамаган, күздән ычкындырган... Син аның үзен күреп сораштыра аласың! Туксанны узган булса да, исән әле ул, Казанда, улларында яши. Аның белмәгәне юк. Казанга килгән-киткән белән очрашып тора. Ул белми калмас.

– Адресын әйтә аласыңмы?

– Аның улы театрда рәссам. Кәшфи атлы.

– Син миңа бик зур ярдәм күрсәттең, энем. Кызганыч, бүләгемне алмыйм, дисең...

– Хакын да белмәгән нәрсәне алудан ни мәгънә?! Килерсең әле. Зират – очрашулар урыны бит ул... Монда килми калган кеше юк. Килгәннең һәркайсына мин кирәк. Бигрәк тә мәрхүмнәргә...

...Мин бу Әбелнәгыйм атлы егетне дә Хызыр галәйһиссәламдер дип кабул иттем. Ул миңа Генрихны эзләүдә туры юл күрсәтте.

...Рәссам Кәшфине Минзәлә театрында спектакль чыгара, диделәр. Адресын бирделәр.

Комиссионкага кереп, муенсаны тапшырдым да, күчтәнәчләр алып, Мөслимә апага киттем...

Ул ачык йөзле, үз көчендәге бик пөхтә әби икән. Күрешүгә торып утырды да, күчтәнәчләремне алып, дога кылгач:

– Сине хәтерләмим... Кем соң син? – диде.

Мин аңа Генрих исемле неместән туган малайны эзләвем турында сөйләдем.

Ул: «Беләм, бугай», – дип кенә әйтте дә, онығыннан фотолар тутырылган катыргы тартмасын китертте. Аннан сугыштан соңгы унъеллыклардагы «воспитанниклар»ның чыгарылыш-озату мәҗлесендә төшертелгән рәсемнәрне сайлап:

– Шушылардан, шәхсән, сине кем кызыксындыра? – диде.

– Мин аларның берсен дә күргән-белгән кеше түгел бит, апай. Зәкәрия абзый әманәте буенча, арадаш-эзләүче генә мин. Шулай да, «берсен дә танымыйм» дияргә, менә бу ак чәчле малай рәсеме белән миндәге аның атасы Ян Роммель фотосы арасында охшашлык бар.

– Эзләгәнең турында тагын ниләр беләсең?

– Атасы – Казанда укыган нимес-танкист, анасы Люда – шәхес культы корбаны.

– Барысын да беләм. Малайны детдомга китерә килгән хатын төн буе сөйләде: нимес шпионы дип гаепләгәннәр. Шуңа күрә, малаен нимес дип җәфаламасыннар өчен, без аны «татар» дип яздырдык. Гөнаһмы бу? Саклап калу өчен бит!.. Ул заманны хәтерләсәң...

– Рәнҗетүләр була идеме?

– Аны безгә китергәнче, «Правда»да, Эренбург дигән язучының «нимесне кайда очратсаң да үтерергә» өндәгән мәкаләсе чыккан иде. Шуны өйрәнергә мәҗбүр ителдек. Идел буе нимес автономиясеннән булган сабыйларны тәрбиягә алмаска, дигән яшерен боерык та бар иде...

...Нәкъ шул чорда безгә бакыр чәчле малай китерелде. Чын исеме Генрих булса да, «Гәрәй» дип яздык. Китерүчесе Югары Барҗыдан Казанга күчкән татар хатыны иде.

– Зәкәрия абзыйның анасы.

– Без аның белән ачыктан-ачык сөйләштек: малайның атасы Казанда укыган нимес курсанты икәнен, пожар булуын, малай анасының нимес шпионы түгеллеген, хөкем карары көтеп төрмәдә ятуларын – барысын шул чакта ук белдем. Төне буе серләштек. Шулардан чыгып, без баланың фамилиясен (анасының атасы Александр булудан чыгып) – «Искәндәров», Генрихны – «Гәрәй», отчествосын «Рәмилевич» дип яздырдык. Шулай тәрбияләнде, паспорт алды. Ялгыш-моңгыш берәрсе «нимес» дисә – сугыша иде. Җирән иде бит, бакыр чәчле, нимес кебек...

– Нигә «иде» дә «иде»? Үлдемени?

– Паспорт биргәч, аларны ФЗУга озаттылар бит. Ә ул укуга бик әвәс, ушлы, башлы иде. ...ФЗУны да бетергән, академияне дә. Эзләп тапты ул мине, килде!..

– Шулай булмыйча... Сез бит аны коткаргансыз...

– Мине эзләп табуының сәбәбе күрешү өчен генә түгел. Атасы анасына фамильный герблы алтын балдак калдырган була. Бала шуны онытмаган, хәтерендә саклаган. Аны миңа китерүче, әманәт буларак, Гәрәй егет булганчы саклауны йөкләде.

– Ул балдак аңа кайтарып бирелгәндер бит?

– Бирелмичә! Балтач врачлары биргән мөһерле белешмә кәгазен дә, нимес биргән истәлек фотосын да, хатларын да саклаган идем – барысын да Гәрәйгә тапшырдым. Бик шатланып, рәхмәт белән кабул итте. Акча да бирмәкче иде – әманәткә хыянәт итмәдем. Шуңа шатланам.

– Балдакны Гәрәй кидеме?

– Киеп караган иде – шуып чыгарлык зур булды. Күрәсең, нимес олы

гәүдәле, калын кеше булган. Балдакның кашында ниндидер тамгасы да бар иде; аңламагач, ни икәнен әйтә алмыйм.

– Хат алышмыйсызмы?

– Израильдән бер хаты килде. Хатынының туганнары шунда икән. Менә кара: фотоларын салган: бусы хатыны белән үзе, бусы кияве белән кызы. Ә менә монысы үлгән улының улы, оныгы Эмиль – студент.

– Уллары үлгәнмени?

– Машинада бәрелешеп улы белән килене вафат, онык боларда үскән... ...Кызлары балага уза алмый икән. Динен алыштырырга кушканнар, шуңа «Матильда»дан Мәликә булган, хаҗга да барган – тик һаман балалары юк, ди, Гәрәй, соңгы кайтуында кергәч сөйләде.

– Кайтып йөримени?

– Уллары Энгельс шәһәрендә җирләнгәнлектән, аны ташлап китә алмыйбыз, ди.

– Кызлары Матильда-Мәликә атасына да, анасына да охшамаган икән.

– Холкы да үзгә, ди, Гәрәй әйтә. Берәр сере бардыр, әйтәсе килмәгәндер. Әйтмәсә тагы, миңа аның кирәге дә юк... Әйе... Кияве дә, кызы да врачлар, үз поликлиникалары, дару сату әптикләре бар, ди.

– Бу фотоларны миңа биреп тора аласыңмы, Мөслимә апа?

– Алалар да кайтармыйлар шул.

– Ә мин фотографиягә төшертеп алам да бүген үк кайтарам.

– Күрдең ич инде. Нигә кирәк булыр алар сиңа?

– Мин шушы кияү тиешле кеше белән Хаҗда очраштым. Хатыны мин эзләгән Гәрәйнең кызы булгач, аның белән дә сөйләшергә кирәк булыр...

– Кайтарылуы кайчан? Улыма ни дип әйтермен? Өч йөз грамм кәнфит белән чәй салган кучтәнәч пакеты алып кереп алдыйлар да ядкарьләремне алалар... Мин бит шулар белән генә яшим! Алып тор, хәерле булсын!

– Детдом тормышыннан бүтән фото юкмы?

– Ул чакта фотога төшү дә олы бәйрәм, сирәк була иде... Болары өчен рәхмәт димисең...

– Рәхмәт кенә түгел, мин сиңа бүләк тә китерәм, Мөслимә апа, хафаланма.

– Хафа-җәфаларны күп күрдек инде. Нимеснең шушы бер хатын таптырып кына да Казанга ничә чакыртып сорадылар. Имеш, анда ниндидер шифр язылган! Пүчтәк! Нинди шифр булсын! Баланы табарга кушкан, кайчан булса да килеп алам, дигән. Әнә – укы: утыз сүзгә кырык хатадан торган гыйшык хаты! Шулай да, теләсә кемгә күрсәтмә аны. Бүген болай, иртәгә тегеләй дөньяда ышаныч юк.

– Миңа ышан, Мөслимә апа.

– Бар, тиз йөре. Бүләк көтмим. Тозлы кәбестә ашыйсым килә.

– Тозлысын да, төчесен дә алып керермен. Бик зур рәхмәт сиңа...

– Артык төчеләнми генә сөйләш.

– Ничек инде? Булды, табылды ич!

– Югалган нәрсә генә табыла. Ә мин берсен дә югалтмадым – сакладым. Син дә сакла!

«Гәрәйнең» «Генрих» булуына йөз процент ышансам да, аның үзен күреп сөйләшмичә Зәкәрия абзыйга хәбәр итү дөрес булмас.

Иң элек кызы белән киявен күрергә, күрешү мөмкинлеге булмаса, телефонда сөйләшеп, Гәрәйнең бу көннәрдә кайдалыгын ачыкларга кирәк. Сәламәтлекләре ничек? Үзенең Гәрәй түгел, ә Генрих булуына, Роммель нәселеннән булуына ничек карый?

...Дөнья очраклы хәлләргә бәйле, очраклы вакыйгалар белән тулы. Зәкәрия абзый белән очрашу да, Гәрәйнең кияве белән Хаҗда очрашуым да, Мөслимә апаны табуым да – барысы да очраклылык «җимешләре». Әллә соң очраклылык үзе бер канунлык микән?

...Кайсыдыр акыл иясе әйткән, имеш: алфавиттагы хәрефләрне шакмакларга язып, күккә чөйсәң, җиргә төшкәч, алар шигырь юлларын тәшкил итсә – бу очраклылык түгел, ә чөюченең чыга ашкан хыялы, дигән. Минем табышларым – табышмы, әллә шул хәреф чөюче теләгән язылмаячак шигырь юлларымы? Күңел «Генрих» дисә дә, әлегә тапканым «Гәрәй» бит?!

...Өйгә кайткач, докторның визиткасын эзләп таптым. Сәясәтчеләрчә сөйләшергә сорауларым әзерләп, телефон номерларын җыйсам – трубканы алучы юк, «автоответчик» кына язылырга куша.

Әгәр дә Гәрәй башка берәүне әтисе дип ышанып үскән булса, мин тапкан Гәрәй табышыммы, ялгышыммы?

Күзгә йокы керми әйләнә-тулгана ятканда, төн уртасында «междугордка» звоногы! Гадәттәгечә, трубканы хатын алды.

– «Родничок»ка сез шалтыраттыгызмы? – ди еракталагы хатын-кыз тавышы.

– Нинди «Родничок?» – диде хатын, миңа карап.

– Мәскәүдәге безнең «ООО», – диде телефон.

– «ООО»лар белән эшебез юк безнең.

– Телефонда сезнең номер чыга.

– Ә минем сезгә ачуым чыга: сәгатькә карагыз!

– Без егерме дүрт сәгать эшлибез.

– Сез кем соң?

– Фирманың хуҗасы идек, рөхсәт итсәгез...

– Фирмалар белән дә эшебез юк безнең.

– Простите... «пип-пип-пип»...

– Моңа кадәр фирмалардан шалтыратучы юк иде. Кемең ул? – диде хатыным.

– Үзеннән сорарга иде.

– Тагы ни сорарга кирәк иде?

– Һич югы исемен, – дидем мөмкин кадәр сак кына.

– Аның исеме миңа ник кирәк? – диде хатыным, бөтен өйне уятырлык кычкырып.

– Бәлки миңа кирәкле кешедер, – дидем, кроватьтан төшеп.

– Трубканы үзеңә алырга иде, – диде хатын, мендәрен алып, башка бүлмәгә күчешли.

– Синнән узыпмы? – дидем, Мәскәү номерларын җыя-җыя.

Бүлмә ишеге «шак» итеп ябылды, хатынымның, өйрәнгән гадәте буенча: «кем уйлаган, кем уйлаган», дип еларга тырышуын, телефондагы җавап оныттырды:

– Опять сез?

– Гафу итегез, ханым әфәнде, миңа доктор кирәк иде.

– Доктор тыңлый.

– Хаҗи доктор кирәк иде, дигәнем.

– Мин хаҗия.

– Бу сезнең исемегез түгелдер бит?

– Мин ир хатыны. Исемемә дә, җисемемә дә ул хуҗа.

– Хуҗагыз белән сөйләшергә ярыймы?

– Сез кем соң?

– Мин аның белән бергә Хажда булган «Казан ятиме».

– Аның приём сәгатьләре иртәнге тугыздан...

– Миңа сәгать түгел, минут җитә.

– Дарулар мәсьәләсендә булса, миңа әйтегез, сорагыз...

– Әтиегез хакында иде соравым.

– Әти үлгәнгә өч ел тула инде.

...Шунда мине ток суккандай булды. Күз алларым караңгыланып, башым әйләнеп китте, телефон трубкасы кулдан ычкынды. Тыңлый да, дәшә дә алмыйм. Кыска гудоклар ишеткәч кенә ушым кайтып, миллионнардан баш тартуыма үкенүемне тойдым. Кабат Мәскәү номерларын җыйдым. Бу юлы трубканы алучының тавышы миңа таныш докторныкы иде: «Слушаем»...

– Әссәламегаләйкем, хаҗи әфәнде, исән-сау яшисезме?

– Бу... теге кем... сезмени әле?! Как говорится, «вагалайкумсалям».

...Исәнлек-саулык йоласын үтәүгә, әзер соравымны бирергә ашыктым:

– Гафу үтенәм, хаҗи, әтиегезнең кайда җирләнүен белергә иде. Авылдамы, шәһәр зиратынамы күмелде?

– Ул бит шул якның Чишмәле авылыннан иде. Үз васыяте буенча, без аңа кремация ясатып, көлен Иж елгасына сиптек. Аңа тәрбия биргән Шаршада детдомы да якын, туган авылы да күренеп тора.

– Димәк, Матильданың әтисе исән булып чыга? Сезнең әти үлгән?!

– Мәликәнең әтисе әлегә табылмаган. Тереме, үлеме – белүче юк. Эзлиләр.

– Гәрәй абзыйнымы эзлиләр? Ачыкласагызчы...

– Мәликәнең әтисен дим ич.

– Гәрәй абзый Мәликәнең әтисе түгелмени?

– Документ буенча әтисе. ДНК анализы буенча юк. Анализларны Гәрәй бабай үзенең кем улы булуын Казанда яшәп ятучыда сакланган документлардан белүгә ясатты. Параллельно Мәликә дә. Туры килмәгәннәр. Чужие друг другу.

– Болар хакында Хаҗда чакта ук белә идегезме?

– Даже раньше! Хаҗга кадәр үк.

– Сез бит миңа Зәкәрия абзый нинди әманәт йөкләвен беләсез. Нигә дәшмәдегез? Моны яшерү сезгә ни бирә?

– Мин фашист фельдмаршалы оныгының ире дип кычкырырга кирәк идемени? Һәркемнең үз миссиясе...

– Ян Роммель фельдмаршал оныгы түгел бит...

– Исбатлый аласызмы? Юк!

– Тырышабыз.

– Исбатласагыз, «Мерседес» бездән.

– Ярдәм итегез. Сезгә олы бөтен мирас Роммельдән, әлбәттә.

– Ничек ярдәм итеп була? Әйтегез!..

– Гәрәй абзыйны Мәскәүгә чакыртып, ДНК анализы ясатсагыз, ярты эш эшләнә дигән сүз.

– Бабай кабат бу эшкә бармаячак, килмәячәк.

– Кызы сораса?

– Ул аның үз атасы түгеллеген исбатлады инде. Алар конфликтта. Әмма конфликтта булу бабайның бала каршында җаваплылыгын киметми. Мирас мәсьәләсендә төп документ – туу турында таныклык! Анда «Матильда Гараевна Искандарова» дип язылган. Без инде төрле консультацияләр уздык, беләбез... Так что...

– Бу очракта да, барыбер, ДНК анализы кирәк булачак, хаҗи...

– Мең анализ булса да, бер якныкын гына исбатлау материалы була алмый. Законы шулай.

– Нигә хатыныгыз сүзгә катышмый?

– Шулай бүленгән: беребез сөйләшкәндә, икенчебез... язып бара. Әнә микрофон. Стенография... Үзебез генә калгач, мин Мәликә Гәрәевнага ситуацияне аңлатырмын. Процесс реаль нәтиҗәгә илтә торган булса, бездән концессия көтә аласыз. Булмаса – сюжетыгыз хыялда килеш калыр... Пока... «Пип-пип-пип...»

...Авыздан аш, кулдан эш китте. Эзләгәннең табылуы шатлык булса, аны исбатлау кирәклек тәмам уйларымны чуалтып, эзлеклелегемне югалттырды. Мәскәү белән сөйләшүнең дүртенче көнендә тагы «междугородка» звоногы:

– Тыңлыйбыз.

– Хәерле иртә! Эшкә киткәнче сөйләшергә булдык...

– Ханым әфәнде! Минем белән сөйләшүдән эш алга бармас... Сез әтиегез белән телефон аша сөйләшергә тиеш идегез. ДНК буенча.

– ДНК анализы поликлиникада бармактан кан бирү генә түгел. Мәсьәләнең социаль-мораль аспекты, экономикага, репутациягә, сәясәткә кагылышлы яклары, шәхес ирке, абруй саклау проблемалары – барсы да ДНК анализының кеше язмышында хәлиткеч гамәл икәнен тануны сорый. Сез шуны аңлыйсыздыр?

– Аңлыйм шикелле.

– Шулай икән – бу эшне кем финанслый?

– Нинди финанслау ул?

– Кем акчасына?

– Әгәр финалы без уйлаганча килеп чыкса, ягъни мирас сезгә булса...

– Легендадагы мираска таянмыйк. ДНК анализы автоном эш ул. Күп чыгымнар сораучы эш. Сез шуларны күтәрергә ризамы?

– Бу бит сезгә кирәк, ханым... Чыгымнарын нигә мин күтәрергә тиеш икән? Абсурд түгелме бу?

– Муссолини үтенече белән Африкага җибәрелеп, англичаннарга каршы сугышып, Ливияне буйсындырган танк дивизияләре фельдмаршалын – Гитлерның ышанычлы офицерын атамның туганы дип исбатларга тырышу абсурд түгелме? Бүген мине «кызым» дигән кешене Роммель нәселеннән дигәнгә куануны сорасалар, иртәгә Гудериан оныклары дигәнгә ышанырга кушсалар – абсурд түгелме? Абсурд!

– Татарда бер үк фамилиядә берничә нәсел булганны, немесләрдә дә Роммель берәү генә микәнни?

– Сез бит кычытмаганны кашучы, процессны сез башлагансыз, кем заказы белән икәнен тикшертмичә. Әгәр очына чыксагыз – без каршы да, шат та түгел – битараф.

– Миңа сезнең шатлану да, кайгыру да түгел – әтиегезнең ДНК анализы гына кирәк.

– Яшермим – бездә бар ул. Әлегә копиясе.

– Шулайдыр дип уйлаган идем.

– Сезгә аның хакы турында уйларга кирәк иде...

– Сез әйткәч уйларбыз: күпме тора?

– Копиясе өчен мең доллар! Оригиналы миллион!

– Миндә андый акчалар юк. Ханым әфәнде, сез алданасыз, яисә алдаганнар сезне.

– Заказ бирүчеңнән сора: реквизитларым язылган карточкамны кулыңа бирәм. Бүген күчерелсә – ДНК копиясе иртәгә сезнең кулда булачак.

– Мин уйлармын. Уйлый алсам... Нәтиҗәсен шалтыратып әйтермен. Сөйләшербез. Сез дә уйлагыз.

– Мин кешеләр белән кешеләрчә генә, заманча гына сөйләшергә күнегеп киләм. Аңлыйсыздыр? Мәҗбүрмен.

– Безнең телдә булмаса да, «заманча сөйләшкәч» аз-маз аңлыйм кебек.

– Заман үзгәрә, заманга буйсынып тел дә үзгәрә, кеше дә. Башкача мөмкин түгел.

– Әмма кешелеген җуймый кеше булган кеше.

– Демагогия.

– Мин аңлыйм сезне. Шикләнмәгез...

– Ярый... сезнең эзләнүләрегез нәтиҗәсендә безнең әтинең атасы Роммель атлы немец булуы расланды, ди. Шуннан?

– Сезнең өчен бу зур шатлык китерәчәк.

– Нюренберг суды карарлары һаман үз көчендәме? Аброгациягә эләкмәдеме?

– Сез миңа нацизм адвокаты тамгасы сугарга җыенмыйсыздыр, шәт?

– Аны сез үзегезгә үзегез сукмагыз! ...Зурмы, кечкенәме – безнең көйләнгән бизнесыбыз, абруебыз бар. Барсыннан баш тартып, шикле мираска алданыргамы? Халыкара трибунал хөкем иткән партия әгъзасы исеменә күчәргәме? Никогда!

– Аталары гөнаһы өчен балалары җавап тотмый.

– Ә без үз атабыз Гәрәй өчен җаваплылыктан качмыйбыз. Аралар суынса да... бәйләнеш ныклы. Ул да баласын ташламас дип өметләнәбез. Амин.

– Өметсез – шайтан, диләр. «Пип-пип...»

...Мәликә-Матильданың «тел төбендә» үзен саклау инстинктымы, әллә башка төр сәбәпләре дә бармы? Кем белән киңәшләшеп, эзләнүләремнең юнәлешен тикшертергә? Бармы күзгә-күз, ачыктан-ачык сөйләшер кеше?

Гомере буе органнарда эшләп, подполковник дәрәҗәсендә ялга чыккан Хәйдәр хәзрәт белән киңәшләшергә җомга көн Иске бистәнең яңа мәчетенә киттем. Үз рөхсәте белән.

...Репродуктордан намазга чакырган тәкъбир яңгырый. ...Агылып булмаса да, намазга килүчеләр күренә. Койма буендагы эскәмиягә утырып, хәзрәт килгәнне көтәм. Килүчеләрдән берсе мине таныды, ахры, «әссәламегаләйкем»енә миннән җавап та көтмичә, намазга чакырды.

– Тәһарәтем шикле, – дидем шаяртмакчы булып.

– Тәһарәт бүлмәсендә җылы суы да, сөлгесе дә бар. Авыруың булса, шунда ук хәләл дарулар сатып алырга мөмкин. Мәчет – гыйбадәт урыны, зал ожидания түгел.

– Хәйдәр хәзрәт шушында көтәргә кушты. Килгәнен күрми калдым, ахры.

– Аның киткәне дә юк. Кәсебе дә, яшәве дә шушында.

– Гаҗәп икән...

– Гаҗәпләнәсе юк. Ул инде төрмәдә эшләгәндә үк ялгызак яшәүгә өйрәнгән.

– Ә менә үзенә мөритләр сайларга өйрәнмәгән. Беренче очраткан кешегә хәзрәтегезнең серләрен ачтыгыз да бирдегез. Бәлки мин аңа компромат эзләп йөрүче тикшерүче яки журналистмындыр?!

– Әгәр шулай булса, күбрәк тә сөйли алам: җинаятьче ул.

– Үзегез кем?

– Мин – ике ел Бохара мәдрәсәсендә укыган гыйлем иясе! Өлкән муллада

икенче сәркатип идем. Бу подполковник килгәч, «үзсүзле» дип вазифамны кыскарттырды, кансыз...

– Бик кызганыч...

– Кемне кызгану кирәген намаздан чыккач сөйләшербез. Мин фактларга таянып сөйләү яклы, гайбәткә түгел.

...Намазны гадәттәгедән озаграк укыдылар. Китмәкче дә булган идем, көткән вакытымны әрәм итәсе килмәде, вәгъдәсез булып күренергә дә теләмәдем. Ике сәгать чамасы вакыт узуга, җомгачылар мәчеттән чыга башладылар. Кайберләренең кулларында «серле» флаконнар. Чыгалар да, ялт-йолт каранып, кемнедер эзлиләр: күзләре минем күзләр белән очрашуга, флаконнарын яшереп, сүзсез генә узып та китәләр.

«Гыйлем иясе» чыкмады. Ә Хәйдәр хәзрәт, озак көттерде, өч кеше озатуында яныма килеп туктады да, гафу үтенеп, сөйләшергә вакыты юклыгын, кемнеңдер баласына исем кушу мәҗлесенә ашыгуын, очрашуны якшәмбе көн сәгать унда шушы урында көтәргә кирәклекне әйтте дә сакчылары белән иномаркада китеп тә барды. Ничек кенә итәгатьле булырга тырышса да, подполковникта Хаҗда очраткан мөселманнан берни дә калмаган иде.

Ул китеп, булганнарны аңлап, анализ ясап өлгермәдем, «Гыйлем иясе» күренде.

– Синең белән сөйләшеп тору зур гөнаһ икәнен белсәм дә, вәгъдәмдә торып, чыктым.

– Нигә минем белән сөйләшү гөнаһ?

– Хәйдәр хәзрәт барын да сөйләде: Коръәнгә ревизия ясаучы икәнеңне, эшеңне Диния нәзарәте тикшерәсе икәнен, синең яклау эзләп килүеңне, үзеннән яклау сүзе чыкмаячакка ант итте.

– Гайбәттер болар...

– Мин дә аңа ышанмадым.

– Ә мин сиңа ышанмыйм: ялган сүз сөйлисең.

– Коръәнгә ышанмаган дәһринең миңа ышанмавы табигый.

* * *

...Өйгә кайтсам, хатын тузына:

– Җомгаң шимбәгә ялганды. Өч мәртәбә Мәскәүдән шалтыраттылар: әүвәл хатыны сорады, аннары ире, өченчегә тагы марҗасы.

– Марҗа түгел – хаҗия ул.

– Сизмәдем хаҗиялеген.

– Ни әйттеләр?

– «Пусть сам позвонит», диделәр.

– Миңа аларның позициясе ачык. Тагы шалтыратсалар, мәчеттә диярсең.

– Өйдә булсаң?

– Намазда... диярсең.

...Якшәмбе көн килешенгән вакытка килеп, Хәйдәр хәзрәтнең «хөтбәсен» тыңлыйм.

Башта ул эше күплектән, «хәләл эптик» ачканлыгын, Мәскәүдән дарулар кайтартуын, кыйммәтчелекне җиңә алмавын, конкуренция зурлыгыннан, чыгымнар күплектән зарланды. Тыңламавымны күргәч, кинәт, үзгәреп:

– Үзеңдә ни хәлләр? Табышларың бармы? – диде.

...Мин Ландыш Радиковна аша эш итүемне, тартмадагы туфракны анализга бирүемне, Мөслимә апа Гарифуллинаны очратып, аннан шикләнмәслек

мәгълүматлар алуымны, Мәскәүләрнең ДНК анализы өчен мин түләргә тиеш дигән ялгышуларын сөйләдем. Хәйдәр хәзрәт:

– Мин боларның барсын да беләм бит, – диде.

– Каян? Ничек? Мөслимә Гарифуллинаны күреп сөйләштегезме?

– Мин күреп киткән Мөслимәләрне саный китсәң – алар күпләр. Иң мөһиме: без Мәликә хаҗия белән бәйләнештә. Алар минем партнёрларым; бизнеста, әлбәттә. Инде аның атасы белән конфликты мәсьәләсендә... Киңәш бирә алмыйм. Аларның хаклы булуына шигем юк.

– ДНК алар өчен кирәк бит.

– Алар аны кайчандыр эшләткән инде.

– Нинди эш өчен икәнен белмисезме?

– Белсәм дә әйтмәс идем. Коммерция сере.

– Бәя күтәрәсез.

– Ачышларга галимнәр төрле юллардан килә... Мәликәгә ачыш түгел – табыш кирәк икән – гаепмени? Бизнес!

– Ул бит эзләнүдән баш тарта.

– Кемгә кирәк – шул эзләсен. Без үзебезне үзебез тапкан, ди ул.

– Ничек инде тапкан? Исбатлый аламы?

– Зәкәрия абзыйга Роммельнең токымын табу кирәк. Мәликә кем оныгы документына ия булуын белә. Кирәк кеше исбатласын, ди ул. Мирас, һәрхәлдә, аныкы.

– Шантаж бу, наглость...

...Хәйдәр хәзрәт белән сөйләшү минем күзләремне ачып, тәвәккәлрәк адымнар ясарга этәрде. ...Мәскәүләр белән аның «партнёр» булуы гаҗәпләндермәсә дә, «барсын да Мәликә белә» дигәне интрига өчен генә әйтелгән сүзме? Әллә, чынлап та, кем оныгы булуын белеп тә (Мөслимә ападан Гәрәй абзыйга ирешкән хәбәрдән соң), рәсми белдерергә куркып яшиме? Фельдмаршал оныгы булуын дәгъва итү аны бизәмәүдән генә түгел, ни көткәнен белмәүдән булса? Ян Роммельнең, чыннан да, фельдмаршал белән туганлыгы юклыкны хәзер ничек раслап була?

Ял көннәрем беткәнлектән, «зам»га кереп, «үз исәбемә ял сорарга булдым.

– «Зам» да, «сам» да командировкада, реорганизация буенча чабалар, ике-өч көнсез кайтмаслар, – диде секретарь.

Шимбә-якшәмбе ялларын да кушкач, аларны атна узмый күреп булмаячак, дигәннән чыгып, гаризамны, «сам»нан яисә «зам»нан кул куйдырып, кадрлар бүлегенә тапшыруны секретарьга калдырдым да расписаниеләр белешергә аэропортка киттем. Бер атнада урап кайтырмын, дип исәпләдем.

Сәмәркандка Казаннан рейс юк. Ташкентка бу айга билетлар беткән, тагы ун көнсез сату булмаячакны белдем. Дүшәмбе шәһәре аша очып, Сәмәркандка поезд белән бару ихтималы бар икән, әмма Таҗикстанга хәзергә һава юлы ябык, кайчан ачылуы – халыкара хәлләрдән тора, диделәр.

Рәшит Нуриевның визиткасын эзләп табарга туры килде. «Миграционная служба, наркоконтроль» дигән сүзләр аны миннән ерагайтса да, визиткада күрсәтелмәгән хаҗилыгы самолётка билет алуыма ышаныч тудыра иде. Рәшит Нуриевичка шалтыратсам, ул шикләнүләргә урын калдырмыйча:

– Паспортыңа ике билетлык акча кыстыр да иртән нәкъ тугызынчы яртыга алтынчы кассага килеп, Элеонораны сора, миннән сәлам тапшыр. Рейсыңны әйт, – Дүшәмбегә очарсың, –диде.

– Мин үзем генә ич! Нигә ике билет?

– Син үзең генә булсаң, кассир үзе генә түгел бит.

...Әйтелгән вакытына килсәм, «Әфган вакыйгаларына бәйле, Ташкент, Дүшәмбе юнәлешләре пассажир рейсларына билетлар аерым күрсәтмә булганчы сатылмый», дигән игълан эленеп тора. Аптырап, каңгырып йөрүдән дә, Элеонораны күрүдән дә эш чыкмаячак иде. Кабат Рәшит Нуриевичны күрергә булдым.

– Син бит Элеонорага әйтелгән вакытка килмәгәнсең...

– Белдерүне укыгач... килмәдем шул.

– Белдерү синең өчен түгел ич ул, хәзер инде көтәргә туры килер...

– Озак көтәсеме?

– Шалтыратып белешергә кирәк булыр.

– Кайчан?

– Өч көннән.

Бу көннәрем бушка узмасынга, Ландыш Радиковнадан туфрак анализы нәтиҗәләрен барып белергә булдым.

– Ландыш Радиковна Таиландта ял итә. Кайчан кайтуы билгесез, – диде аны алыштырган Ревекка Львовна атлы мыеклы ханым, тәмәке төтенен миңа таба өреп, көлен өстәлендәге савытка өч алтын балдак кигән юан бармагы белән чиртә-чиртә.

– Миңа Ландыш Радиковна үзе кирәк түгел, тикшерергә калдырылган туфракның анализ нәтиҗәләрен белергә кирәк. Менә шушы, ул биргән квитанция буенча эзләгез...

– Что за чепуха?! Безнең фирма, вообще, туфрак анализы белән шөгыльләнми, без ритуаль хезмәтләр күрсәтәбез, поминка, юу, күмү, кырыгын, елын уздыру, исем кушу, сөннәткә утырту, никах мәҗлесләре... Сезнең нәрсә: исем кушасызмы, сөннәткә утыртыргамы?

– Ханым әфәнде! Без инде тиешлесенә күптән утырган да, утыртылган да...

– Чем и поздравляем.

– Мин анализга калдырган туфрак әнә шул сез тәмәке төпчеге салган медуза сурәтле тартмада иде...

– Пепельницадамы?

– Пепельница түгел ул! Сибирская язва микроблары юклыкны тикшертергә калдырган туфрак иде анда! Австралиядән!

– Мин эшне кабул итеп алганда, монда Ландыш Радиковнаның тәмәке көле генә иде. Бернинди сибирская корона күрмәдем.

– «Корона» булса, күргән булыр идегез – «язва» турында сүз бара! «Сибирская!»

– Монда язвенниклар була алмый. Әнә – санэпиднадзорның күрсәтмәсе – укыгыз!

– Туфрак кая?

– Позвольте: зачем безгә австрийский туфрак? Түктем, разумеется.

– Кая түктегез?

– Сезгә туфрак кирәкме, справкамы?

– Икесе дә.

– Только что язва таптырдыгыз, инде справка, дисез. Конкретно: что вам?

– Анализ результаты, резюме!

– Уже третье... да нет – четвёртое... Вот это и есть язва...

– Где язва? Минме?

– Сезгә әйтмим – эзлим... Вот тут пыяла астында Ландыш Радиковна имзасы

белән странная бер язва, то-есть, справка ята... Пожалуйста... Бик кирәк булса, туфрагын әнә шул фикус гөле чүлмәгеннән алыгыз, не жалко... Только без шума и скандала?

– Рәхмәт, мадам.

– Пожалуйста, без иронии.

– Ирония генә коткарса икән...

– А ведь Ландыш Радиковна тартма турында да, язва хакында да кисәтмәде. Так что! Мин сезгә добровольно благосклонность күрсәтәм. Бесспорно, заслуживаю адекватности.

– Анысы нинди язва тагы?

– Мин пөхтәлек яратам. Ничего лишнего не терплю на столе: только кофейница, сигареты и зажигалка. Сезнең бәхет җиңгән: пыяла астындагы справка сакланган – вернее, кул җитмәгән...

– Рәхмәт сезгә, мадам.

– Джентльмен җавабыгыз шушымы?

– Минем сезгә соравым да, җавабым да юк. Сез бик тә аңлаешлы субъект.

– Только без оскорбления! Мине «субъект» дип атарга сезнең ни хакыгыз бар?

– Ә кем соң сез?

– Объективно хотя бы... объект! Только серлесе.

– НЛО? Котлыйм!

– Миңа сезнең коры котлавыгыз түгел, ә «башкарылган эш буенча жалобам юк», дип, менә шушы журналга кулыгызны кую кирәк. Пожалуйста, будьте милостливы.

– Кайсы графага?

– «Поминка» дигәнгә, плюс, консультация өчен. Ничә минутымны ашадыгыз...

– Афёра бу, рэкетның бер төре.

– Күрәм: сез крупный мелочник икән. Куймагыз кулыгызны, калмасын заразный туфрагыгыз да, эзегез дә! Әнә – туфракны фикусы белән алыгыз!

...Эреләнми, вакланмый өч көнемне бушка уздыргач, телефон аша тагы Рәшит Нуриевич белән сөйләшергә булдым.

– Алло! Җиденче бүлек тыңлый, – диде ир тавыш.

– Сезне кем дип белик, энем?

– Наркоконтроль. Лейтенант Кәбиров. Ә сез кем?

– Мин – телевидениедән. Рәшит Нуриевич белән очрашырга иде. Срочно.

– Бүген аның кабул итү көне түгел. Кайчанга, сәгать ничәгә языйм?

– Миңа ул, күп булса, бер минутка кирәк, язылусыз, сорау бирер өчен генә: бүген.

– Полковник спецоперациядә. Сәгать өчтән соң гына бушавы ихтимал. Хәбәрегезне миңа әйтә аласыз. Наркотикларга бәйле эш булса, журналда теркәлергә тиеш.

– Теркәтер хәбәрем юк.

– Аны сез үзегез бәяли алмыйсыз. Әйтегез: нәрсә беләсез, ни күрдегез? Кайда?

– Туктагыз әле, лейтенант, без аның белән Хаҗда бергә булган идек... танышлар... йомышым бөтенләй башка юнәлештә.

– Андый танышлары күп аның. Приём өчен сәбәп түгел бу. Закон есть закон. «Пип-пип-пип...»

...Телефон өзелде. Калдым «калтаеп». Сәгать өч тулганчы ук аэропортка барып, эш урынына кайтуын сагалап торырга булдым. Килүем әрәм узмасынга, кассирша Элеонораны да күреп кую артык булмас, ятып калганчы – атып кал, дигәндәй... Ләкин Элеонора мине танымады. «Рәшит Нуриевичтан кайнар сәлам», дигәнемә каршы: «Дүшәмбегә самолётлар аерым боерык белән генә очалар, билетлар сатылмый», – диде дә форточкасын «шап» япты.

Урамга чыгып көтәргә булдым. Йөри-йөри уйлана торгач, кайдадыр укылган: «катлаулы эшне ялкауга тапшыр, ул аны җайлы гына эшләү ысулын табар», дигән фикерне хәтерләдем. Шуннан чыгып, «полковникны» түгел, берәр «сержантнымы», «ефрейторнымы» табып, йомышымны йомышларга ниятләдем. Андыйлар грузчиклар арасында табылуга өметләнеп, ангарга таба барганда, милиция машинасы очрый. Мин тукталуга, машина да туктала. Узып китмәкче булам, ишеге ачылып, аннан полковник Рәшит Нуриевич төшә дә, машинаны озатып, мине култыклап ала:

– Бирәм дигән колына, чыгарып куяр юлына, ди. Сәлам «ревизорга!» Мин сагынганны белдеңме, үзең сагынып килдеңме?

– Шул инде, Дүшәмбегә билет алып булмый. Ярдәмең кирәк.

– Рейслар Казанда формировать ителми хәзер. Безнең аэропорт арадаш пункт кына. Булмастыр, абзый, Мәскәү аша оч!

– Мин, ничек тә, Сәмәркандка барып, Зәкәрия абзый эзләткән Генрих-Гәрәй Рамилевич Искәндәровны күреп, бу эшкә нокта куярга телим.

– Табылдымыни? Котлыйм.

– Почти!

– Ничек таптың?

...Очраклы бер очрашудан соң Мөслимә апаны – Гәрәйнең детдомдагы тәрбиячесен табуымны, анда сакланган метрикәнең Гәрәй-Генрихка кайтарылып бирелүен, Мәскәүдә яшәүче кызлары Матильда-Мәликә белән сөйләшүләрне, аларның ДНК анализы ясатуга каршы булуларын – барысын-барысын сөйләдем дә, бары син генә ярдәм итә аласың Гәрәй-Генрих Рамилевичны табуда дип, сүземне төгәлләдем.

– Син дөрес юлда. Миңа Мәликәнең бунты гына аңлашылмый: ник ДНК анализына каршы алар?

– Йә ул фельдмаршал оныгы булудан курка, йә мирасны үзләренә генә үзләштерү өчен вакытны суза.

Без Рәшит Нуриевичның эш бүлмәсендә. Кәбировка беркемне дә кертмәскә, чәй әзерләргә боерды да, телефон номерлары җыярга тотынды ул. Ниһаять, берсен эләктерде, сөйләшүе яшерен төс алды. Бу мине гаҗәпләндерсә дә, игътибарны чәй белән бергә тәм-том керткән лейтенантка юнәлткән булдым.

– Шикәр салдыңмы?

– Ике шакмак.

– Миндә диабет. Алыштырсагыз иде.

– Рәхим итегез...

– Лимон ярый.

– Лимонны полковник үзе кисәргә ярата.

...Рәшит Нуриевич сөйләшүен ишеттермәскә бик тырышса да, сүзнең минем турыда баруы аңлашыла иде. Соңгы «игра свечи стоит» дигәнен генә әлегә кадәр аңлый алмыйм. Нинди уен, нинди «шом» турында әйтте ул?

Таможнячы полковник, берара үзенең кем булуын, ничек сөйләшергә кирәген уйлап утырды. Аннары трубканы куеп, өстәл янына килгәч, кулына

иң элек пычак алды, лимон турады. Аны берәр генә телем икебезнең бокалга да салып болгаткач, бер йотым чәй эчеп куйды. Әйтерсең, шушы цейлон чәе аның өчен яшәү эликсиры иде.

– Син тотынган бу эш чәй кебек кенә болгатылмаган. Иң читене – нәрсәләр салынганын белеп булмый. Безнең чәйне күрәсеңме? Лимон салгач ничек ачылды! Ә синең Сәмаркандка барып, картны күрүгә, эшең ачыклануга ышанычың ныкмы?

– Әйе.

– Әгәр Гәрәй абзый «не признаю Роммеля» дисә? Бу вариант – версияне дә исәпкә алырга кирәктер, коллега.

– Менә син чәй белән безнең ситуацияне чагыштырдың. Безнең «чәй» дигәнебезгә салынган нәрсәләр эреп тәмам болганганчы мин синдә утырам да инде.

– Телефоннары җавап бирми, диден.

– Үзәк телеграфлары «өздерелгән». Тоже серле.

– Менә нәрсә, хаҗи әфәнде...

– Әфәндесез генә инде.

– Әфәндесез ярамый. Син безнең өчен финанс министры бүген!

– Ә син минем өчен транспортныкы. Ха!

– Илне законсыз килгән эмигрантлар басты. Меңәрләп киләләр, йөзәрләп озатабыз. Әле менә тагы чираттагы группаны оештырдык. Шуларны махсус аэрорейс белән Дүшәмбегә озату мөмкинлеге чыгып тора. Кабул итүче ягыннан хәбәр көтәбез. Әгәр шуларны озатучылар составына сине тәкъдим итсәм – ризамы?

– Кем булып инде мин?

– Үзең буласың!.. Оператор!

– «Үкенәбез» дигән интервьюлар алыргамы?

– Әгәр җае чыкса, кирәк дип тапсаң... алырсың.

– Аларның күбесе – чарасызлыктан эш эзләп килгән, күп балалы мескеннәр.

– Әйе, чарасызлыктан. Но – нелегально. Законсыз.

– Кыскасы, алар – сәясәт тоткыннары.

– Шул тоткыннардан берсе, озын юллар узып, Термездан кырык капчык лавр яфрагы алып килә. Безнеңчәсе – дәфнә. Берничә капчыкта яфракка яфрак беркетеп марихуана яшерелгән.

– Тотылдылармы?

– Проблема үлем порошоклары яшерелгән капчыкларны адресатларына ирештерүнең серен ачуда. Шунысы авыр.

– Яфракка яфрак беркетелгәнен белгәч, нинди проблема булсын инде ул?

– Һәр капчыкка төрле цифрлар язылган. Әйтик, берсендә «15.VII.40» дигән саннар, ди. Бу «1940 елның 15 июле» дигәнне аңлатмый, капчыкта «157194 порция наркотик» дигәнне күрсәтә. Пароль бу! Капчыкларны тегеннән озаткан хуҗасы, оптовый базарга килеп, үзе капчык сатып мәшәкатьләнми – парольне генә сата. Пароль һәр кырык капчыкта да түгел. Алары өчен башка пароль. Тулы бер система.

– Мин ул системаны фаш итүдә нинди хезмәт күрсәтә алам?

– Самолётта Дүшәмбегә кайтып төшкән «нелегалларны» каршы алучыларны видеога төшерәсең. Инструктаж үткәргәндә, кемнәр каршылау ихтималын аңлатырлар. Фотоларын да күрсәтерләр. Бернинди катлаулылыгы юк, синең өчен таныш булган «кеше эзләү» процессы. Эшең беткәч, озата барган безнең майорга кассетаны биреп, үз юлыңны дәвам итәсең. Бары шул!

– Кыскасы, җай гына шпион статусына күчәм.

– Самолётка башкача утыру мөмкинлегең юк.

– «Стукач» кына түгел – «шпион»! Булмас эш тәкъдим итәсез, полковник әфәндем! Кем инде «менә без» дип видеога төшәргә аэропортка килсен?! Французларда: «Гаепсезне хөкемгә тартканчы, гаеплене яклау хәерлерәк» дигән әйтем бар.

– Без – татарлар – башкача уйлыйбыз.

– Белмәгән, күрмәгәнне гаепләүдә катнашырга хакыбыз бармы безнең? Бер хатаны төзәтергә йөргәндә, зуррак хата ясаргамы?

– Сиңа беркем дә гаепләргә кушмый. Дөрес аңламыйсың.

– Бер сатылгач – сатлыкның башкача кирәге калмый. Артык кашыкка әверелә ул.

– Сиңа тәкъдим ясалды. «Риза» дисәң, тиешле документлар тутырту өчен өске каттагы 403 нче бүлмәгә менәргә кирәк, булмасаң – хуш.

– Мин, сиңа мөрәҗәгать итеп, төзәтеп булмас хата ясавымны аңладым. Ләкин Сәмәркандка барырга кирәк. Самолётта булмаса – җәяүләп. Баку, Каспий аша...

– Хәсән Туфан мәвәрәэннәһергә җәяү барган. Үз исәбенә! Ә сине «акча чире» йөртә. Масаюың сине хакыйкать корбаны итми. Очсызлы комедиянең персонажы булуыңны гына күрсәтә. Үпкәләмим. Киңәшем: «Кеше эзлим» циклы алып барам, дигән идең. Син аны таптың. Ул – син үзең.

Чарасызлыктан гына ризалашуымны укучым кичерер дип өметләнәм.

Рәшит Нуриевичның җайлап, майлап, 403 нче бүлмәгә алып менеп, мине инструкторга тапшырды, эшкә урнашырга гариза яздыртты.

...Инструктор үз эшен яхшы белүче аз сүзле, мәгънәле һөнәрмәнд – белгеч иде. Бурычларымны аңлатып, саклану чараларына өйрәтте дә сораулар бирергә кушты. Ә нәрсә сорыйм? – Кеше эзләү минем төп эшем. Аерма нинди кеше эзләүдә генә!

– Шулай да бер соравым бар иде, яраса...

– Ярамаса, җавап бирмәм.

– Мин полковник белән Хаҗ кылырга баргач таныштым. Анда ул чукрак иде. Хәзер күрәм – пышылдап әйткәнне дә ишетә. Дәвalandымы? Колак аппараты әйбәтме?

– Кирәклесен генә ишетеп, кирәген генә күрә белү – безнең эшнең иң төп, иң кирәкле үзенчәлегедер...

...Үземә-үзем хуҗа булып, кирәк кадәр генә үзгәреп, кирәклесен генә ишетеп, кирәклесен генә күреп, тапшырылган эшне тиешенчә эшләп, видеокассетаны озатучы майорга бирдем дә, кабат элекке хәлемә кайтып, үз юлымны дәвам иттем. Кызыклы очрашуларга тарыдым. Алар минем төп сюжетыма сыймый да, кирәге дә юктыр.

## 5 БҮЛЕК

### Көндәшләр

...Ниндидер бер спектакльне әзерләгәндә, рольнең төрле якларына артык игътибар бирә башлагач, мәрхүм артист Гали ага Надрюков: «Портрет ясаганда аның колагы белән күп маташсаң, кешенең сурәте югала», – дип кисәткәне хәтердә. Әгәр бу «мәвәрәэннәһер» сәяхәтендә очратып, күргән-

ишеткәннәремне бәян итүгә күчсәм, төп хикәям онытылыр, аларга тими тору дөрес булыр.

Дөресен дөрес... Сәнгать юлында дөреслек кенә хәл итмәстәйләр дә очраштыра. Талантлы рәссам буларак танылса да, режиссёрлык һөнәренә өстенлек биргән артист Празат Исәнбәтнең әйткәннәре гыйбрәт булырлык: «Кеше образын сурәтләү өчен аның бөтен гәүдәсен ясау кирәкми. Күзенә, борынына гына карап та кемнең кем булуын танып була. Менә – карагыз: кем борыны бу?»

«Шририяздан Сарымсаков!» – дип куя иде янындагылар.

...Сюжет, фабула кагыйдәләренә буйсынмыйча, «колак», «борын», «күзләр» белән мавыгып, финалны сузуым өчен, укучымнан гафу үтенеп, очрашуларымның кайберләре турында язмый чарам юк.

...Мәккә каласында актык тешен суыртырга чират көткән Сәлим бабаны хәтерлисездер?! Шул хаҗины Дүшәмбе-Термиз поездында очраттым. Сакал-мыегын чын мөселманча җиткезгән, калын бишмәте өстенә укалы чапан бөркәнгән, башында чалмалы бүрек. Карлыккан булса да тавышы, Коръән сүрәләрен көйләгәндә, Сәлим «баба» икәнен таныта иде.

Кемдер авыруыннан котылу өчен, кемдер ташлап киткән ире кайтсын, кемдер балага узу өчен дип, сәдакасын кызганмый. Гарәп телен белгән кеше тыңласа, бу көйләвенең Коръәнчә булмыйча, гарәпчә дә түгеллеген җиңел әйтер иде.

Мин дә, эзләп барган кешемне очрату өчен юл догасы кылырга дип, сәдакамны суздым. Ышанырсызмы, юкмы – алмады!

– Андый сүрә барлыгын белмим мин, – диде ул.

– Башкаларга гел бер үк аятьне укыдыгыз ич, миңа да шул ярыйдыр?!

– Ә сезгә укымыйм. Чөнки сезне мин таныдым, хаҗи.

– Мин дә танып эндәштем. Әссәламегаләйкем...

– ...Сезнең өченгә танымавыгыз хәерлерәк булыр иде. Мин монда үзем генә түгел. Миннән бигрәк алар сезне күзәтәләр.

– «Алар» дигәнегез кемнәр?

– Болай сөйләшеп торуны артыкка санаучылар.

– Сөйләшергә түгел, хаҗиларча күрешергә дә өлгермәдек бит әле.

– Сез мине, мин сезне белмәү кирәк. Аллаһу әкбәр...

**6 БҮЛЕК**

## Әсир кыз әсирлегендә

...Сәмәркандка өченче төнгә кергәндә генә барып җителде.

Таңны вокзалда каршыладым. Шәһәр уянуга, такси яллап, үзәк кунакханәгә киттем. Россия наркоконтроленең Казандагы бүлеге кулга биргән маршрутта кайсы шәһәрләрдә, нинди кунакханәләрдә тукталасы күрсәтелеп, тиешле оешмаларга хәбәр дә ителәчәк дигәннәр иде.

Кызганычка каршы, чакырылмаган кунак булып чыктым: урын юк, диде дежур администраторша. «Урын юк» дигәнне күп ишеткән мосафир буларак, урын табылуы ни хак торганлыгын сорадым да:

– Командировочное удостоверениегә дә күңел биреп карагыз: мин – хөкүмәтләребез килешүе белән дәүләт мәнфәгатьләрен кайгыртып йөрүче, – дип тә өстәдем. «Батты» сүзем!

...Администраторша, күзлеге өстенә тагы бер күзлек киеп, тәзкирәләремне

тикшерде дә, янында әмер көтеп торган ханымга: «К нам пожаловал ревизор!» – диде.

Мин: «Гогольдә башкачарак», – дидем, «радиодулкынны» тотканлыгымны аңлатмакчы булып. Бу сүзем дә «батты»:

– Сезнең кебек «особаларга» саклаган люксым бар... Әгәр безнең шартларга ризалашып, ике тәүлеккә алдан түләсәгез – оештырырга өстемә алам – урнашасыз.

– Мин бит ялгызым гына килдем, нигә миңа ике урынлы бүлмә?

– Ялгыз килгән – ялгыз кунармы? Аппетит приходит когда?

– Анысын сезнең госкомитет хәл итәр, – дидем комарланып.

«Госкомитет» сүзе үз вазифасын үтәде – администраторша, счёт-фактура тутырып, кулыма бирде дә:

– Беренче кат, дүртенче бүлмәгә урнаштыр, – диде тын да алмый көтеп торган хәдимәгә.

– Дүртенче ике урынлы бит, – диде хәдимә, – ә аңа бер урынлы кирәк!

– Нәрсә кирәген ул үзе дә белми...

...Озын коридор буйлап бүлмә карарга барганда, бер урынлы өч буш бүлмәне ачып күрсәтте дә:

– Катырак торсагыз бер урынлы бүлмәләр икенче катта да бушлар, – диде хәдимә.

– Ә нигә әле сез мине якларга булдыгыз, сеңлем?

– Документларыгызга күз салгач, сез миңа якын булып киттегез. Мин Кукмара кызы ич! Исемем – Гөлназ! Йомышларыгызны үтәргә әзермен.

– Рәхмәт, Гөлназ, шул дүртенче бүлмәдә генә калырмын инде мин, хафаланмагыз.

...Счёт буенча түләп, ике урынлы люкска урнашып, буфетларында тамак ялгап алгач, адреслар бюросында белешеп, Гәрәй Рамилевич Искәндәров белән очрашуга киттем. Иңемдә фотоаппарат, уемда шатлыклы хәбәрләр алмашу.

Тик... Гәрәй Рамилевич... хатыны Әлфия белән Саратов өлкәсе Энгельс шәһәренә киткән булып чыкты.

– Атна узды инде, кайтыр көннәре җитә, – диде аларның фатирына күз-колак булырга калган күрше кызы. – Кирәк дисәгез, ачкыч авырып яткан көндәшемдә.

– Миңа ачкыч түгел, үзләре кирәк иде шул, кызым.

– Зәйтүнә атлы татар хатыны мин, «кызым» димәгез, кырнак, ягъни әсир кыз мин.

– Кызганыч...

– Минме, алармы кызганыч?

– Үзем.

– Рәсәйдән бирегә кадәр аларны күрер өчен генә килмәгәнсездер бит?

– Шуның өчен генә...

– Ышандырмыйсыз...

– Эш сезнең ышану-ышанмауда гына булса икән...

– Ә нигә алдан хәбәрләшмичә килдегез?

– Телефоннары эшләми, диделәр телеграфта...

– Кызлары Матильда белән кинәт аралары суынгач, өздерделәр шул.

– Сез Матильданы яхшы беләсезме?

– Хәзер кабат Мәликә булып йөри, диләр. Бу арада очрашканыбыз юк. Аларның тарихы үзе бер кинолык. Әлфия апа белән Гәрәй абзый кызганыч.

– Ник кызганыч алар?

– Улларын югалтудан һаман аңга килә алмаганда, кызларын да югалту фаҗига ич.

– Үлдемени?

– Бу хакта бер-ике сүз белән генә әйтү сорауларыгызны гына арттырачак. Аннары... сез минем өчен әлегә күршеләрне сорап килгән юлаучы гына бит... Гәрчә, очрашулар булса да... Бер генә дә түгел.

– Алайса, танышыйк: мин Казаннан, телевидениедә «Кеше эзләгәндә» дигән цикл алып баручы журналист-режиссёр. Шул эзләнү мәшәкатьләре бирегә китерде, сезнең белән таныштырды.

– Безнең бу беренче генә очрашу түгел. Күзегезне ачыбрак карагыз: бәлки хәтерләрсез?

– Кояшка туры карый алмаган кебек, артык чибәр кызларга күз тутырып карый алмыйм.

– Дөрес эшлисез дип әйтер идем, сезнең миңа күз тутырып каравыгызны күрмәгән булсам. Кызганыч, мин пока ир хатыны шул... кома – кырнак.

– Шушы йорт хуҗасының әсиреме?

– Кайчандыр киленнәре идем. Элекке каенанам – хәзерге көндәшем урын өстендә, минем бала табуымны көтеп ята. Оныкк кирәк аларга.

– Төшенмим: «каенанам», «көндәшем», дисез... ирегез уртакмыни?

– Беренче ирем – аларның уллары – Әфганда шәһид китте. Икенче ирем, ягъни беренче иремнең атасы Тәмирлан хаҗи үз эшләре белән Термизякларында йөри. Тагын өч-дүрт көннән кайтыр дип көтә көндәшем.

– Сез көтмисезме?

– Мин сезгә тиешлесеннән артыграк та әйтеп ташладым шикелле. Эзләгәнегезне табу насыйп итсен Ходай.

– Бик кызыклы ханым белән очраштыруына мин Ходай Тәгаләгә рәхмәтлемен.

– Сезнең халыкка йә бик кызыклы, йә бик кызганыч язмышлар кирәк шул. Кибәргә эленгәннәр сезне кызыксындырмый. Ә андыйлар биредә күпчелектер...

– Сезнең бәхетегез йөзегезгә чыккан. Кибәргә эленгәннәр мондый булмый.

– Мин бу иремнең улына чыгып, туебыз узгач, туксан бер көн генә бәхетле яшәп калдым. Кайтуына малай табып көтәргә вәгъдә биреп озаттым үзен. Кырык көннән буш табутын кайтарып күмгәндә, «выкидыш» булып, бала имезү бәхетеннән дә мәхрүм. Инде менә «мең ел», ирле килеш тол булып, калым хакын чыгарып, «оҗмах» дигән «тәмугта» көн уздырам. Сез мине кояшка тиңләдегез. Эчемдәге ялкын шулай күрсәткәндер шул.

– Сез әле яшь, дәртле күренәсез. Сездәге чибәрлек белән тиңегезне табу проблема булмас. Ә инде бу «александрит» алкагыз, «фенакит» беләзегегез, «рутил» төймәгез сезгә күз тидермәү өчен генә тагылган.

– Сез – ирләр, барыгыз да калку күкрәкләргә генә күз атасыз шул, ачыккан сабый кебек. Ялтыравыклы тәтәйләр кыйммәт. Күкрәк астындагы йөрәкне күрмисез... Анда көйрәгән утлы күмер дә пешерми сезне.

...Мин ундүрт яшемдә «шәрык гүзәле» ярышында икенче урын алган... тоткынмын. «Милләтең кем?» дигәнгә «татар» димәсәм, беренче урын минеке иде. Татар – тартар кебек теленнән табар дигәнгә бер мисал бу, елау түгел. Әнием башкорт татары, әтием – пуштуннан азган үзбәк фанаты иде. Хәзер мин ялгызлардан да ялгызмын. Кырнак, ягъни әсир кыз. Кома – наложница.

– Бала табу, дидегез. Ә көндәшегез моңа ничек карар?

– Алар икесе дә шуны көтә. Табып биргәч, калдырып китсәм дә риза-бәхилләр.

– Табып бир дә котыл бу зинданнан!

– Тәвәккәлләр очрамый шул, абзый. Акыллылар күп, ә менә хыялыйлар юк.

– Үзеңә дә реалист булу кирәк.

– Хыял әнә – тәрәзәләргә капланып, безне күзәтә. Һәркайсында бер тамашачы булса да, йөз күз. Икенче бер чынбарлык – кемгә кем керүен тикшереп утыручы «шымчы».

– Эше шулмы?

– Төп эше, имеш, зират сакчысы... Әнә ничек күзәтә безне...

– Күзәтерлек гамәл кылганыбыз юк, сезнең бизәнү әйберләрегезне карыйдыр.

– Берне биш итеп, юкны бар итеп сөйләргә сылтау кирәк.

– Алайса, фатирыгызга керик, күрмәсеннәр.

...Бу сүземә ханымның җавабын ишетеп өлгермәдем, йортның ихатасындагы эсселектән шиңгән төрле чәчәкләрне йокыларыннан уятырлык кыңгырау шалтырады. Юлына кергән җәяүлегә трамвай йөртүче шундый сигнал бирә...

– Каенанам – көндәшем чакыра. Рөхсәт иткәненнән артыграк торуны күтәрә алмый. Үзе һаман «чык, йөре, эзлән» дип колак итемне ашый. Аңламассың, көнчелләрнең холкын.

– Киш-миш яфраклары арасыннан кояш нурлары да узмый. Йөри дә алмаган сырхау ничек күзәтә безне? «Курыкканга куш» түгелме бу сезнең?

– Гайбәтчеләре җиде кат җир астындагыларны да ишетеп җиткезәләр. Ирем кайткач килерсездер бит?

– Миңа сезнең ирегез түгел, әнә шул җиде кат җир астындагыларны күреп, ишетеп торучыларның берәрсе белән күрешеп сөйләшү зыян итмәс иде.

– Аларның тел ачкычы көндәшемдә. Әүвәл аның белән сөйләшегез.

2 нче кат, 16 нчы фатир. Сезне куркыткан трамвай звоногын шушында гына көтегез. Ике кыска, бер озын шалтырау – керергә рөхсәт дигәнне аңлатыр. Хушлашмыйм...

...Үлгән кешеңне дә уятырлык кыңгырау тавышын көтеп күпме утырылгандыр – шалтырау булмады – калтырау булды. Серле чибәрне бүтән күрә алмам дип күңелем калтыравы иде бу. Ниләр генә уйланылмады да, нинди генә хыялларга бирелмәдем! Җан картайса да, тән картаймавы идеме бу, әллә киресенчә – тән картайса да, җан картаймавы идеме – мин үземдә көч артуын, җиңeлəю сиздем. Шунда ук үземә үзем: «Җиңеләймәскә, онытылмаска, азмаска, шайтан коткысына бирелмәскә», – дип, яшерен боерык бирдем. Кабынуымны, кәрәчине бетеп сүнәр алдыннан сукыр лампаның «леп-леп» итеп, яктырак балкып куюына тиңләдем, «җитте, булды, бетте!» – дидем.

Кыңгырау шалтырамады, беседка түбәсендәге репродуктор, пытыр-пытыр килде дә: «Керегез!» – диде. Бөтен нәрсә техникага көйләнгән икән монда!

Празат абый хаклы: кеше образын тудырган сурәт ясар өчен, аның бөтен сыны кирәкми. Мәхәббәттә дә шулай, күрәсең: кырнакның «керегез» сүзе миңа мәхәббәт монологы булып ишетелде. Шунда ук «тәҗрибә авазы» бер колагыма: «Әйдә, синнән генә калганмы, бер яшьлектә, бер картлыкта», – дисә, икенче колагыма: «Барсы ялган, уен, алданма, ышанма», – дия иде.

Шулай да керергә булдым. 16 нчы фатир, диде. Аскы катта «14» белән «15». Өстә бер генә ишек. Димәк, ике фатирны бергә кушып ясаганнар. Хуҗасының

Обком кешесе булганлыгы сизелә. Гаҗәпләндергәне фатирның эчендәгеләр иде.

Елаудан алсуланып калган килен кеше – көндәше – каенанасына нидер әйтте дә каядыр китте. Чыгышлый миңа бер генә җөмлә пышылдады: «Мин сезне үзем табармын!»

Бу җөмлә монолог кына түгел, тулы бер сценарий, фильм-спектакльгә бәрабәр яңгырады.

Кая килеп эләгүемне белергә тырышып, ишек төбендә чакыру көтәм. Тыңлыйм. Күзәтәм.

– Керегез! – дигән чакыру сүзен ишетәм. Кереп, авыру хатын яткан караватны эзлим – күренми.

– Әссәламегаләйкем... Хәерле көн! – дим.

– Сәлам, якташ, сәлам бездән сезгә мул итеп. Узыгыз, әнә шул кәнәфигә утырыгыз да сорауларыгызны җиткерегез. Мин чаршау артыннан гына җавап бирергә тырышырмын.

– Кешенең күзенә карамыйча сөйләшә алмыйм шул, ханым.

– Көндәшем әйтүе буенча, сезне 14 нче фатирда яшәүчеләрнең кызлары Матильда кызыксындыра икән. Моның өчен минем күзләремә багуның ник кирәге бар?

– Дөреслек күзләрдә чагыла.

...Ни булса – шул, дип чаршау артындагы ханымга Роммель-Зәкәрия мирасына варислар эзләвемне, Матильда-Мәликәнең Гәрәй Рамилевичтан ДНК анализы ясатуга нигәдер каршы булуын, таныклыгы буенча гына эш йөртергә теләвен сөйләдем.

Әгәр дә Роммельнең токымын табып исбатлый алсам, алар өчен дә, үзем өчен дә мөлкәт-хәзинә чыганагы ачылачагын, булдыра алганча үтемле телдә тасвирлап (үземдәге документ күчермәләрен дә күрсәтеп), монда килүемнең төп сәбәбен аңлатырга тырыштым. Сөйләвемнең тәэсирен күрә алмасам да, «биш миллион доллар» дигән сүзләрдән соң максатыма ирешүемне «дөп» итеп идәнгә ауган тавыштан чамаладым.

Ханым йөрәге ярылып үлгәндер, дип куркуымны язмасам да аңлыйсыздыр. Һушым китеп, үзем егылудан ханымның: «Фу, шайтан», – дигән сүзе коткарды.

Ни булуын карарга чаршауны ачсам, каршымда көндәше-киленнән ким булмаган сөйкемле ханым басып тора иде. Паралич дигәннең төсе дә, исе дә юк.

– Култык таягының идәнгә бәрелү тавышы куркыткандыр сезне. Үземнең дә котым очты. Нервлар. Гафу итегез...

– Сүзем, озынга китеп, арытканмындыр дип курыктым.

– Арытмадыгыз, терелттегез. Хәер, мин авыру түгел бит. Авыруга сабышуым ирем белән аны аздырган киленемә үч итүдән генә. Аларның мине күтәреп бәдрәфкә йөртүеннән ләззәтләнәм.

– Ышана алмыйм. Сез андыйга охшамаган.

– Бар рәхәтем – мәрхүм улым фотосына карап, хыянәтчеләрне үз кубызыма биетү.

– Кубызда шәп уйныйсызмы?

– Минзәлә педучилищесында укыганда, мандолинада уйнарга өйрәнгән идем, хәзер инде дошманнарымның нервларында гына уйныйм. Көндәшем әйтүенә караганда, сезгә Матильда-Мәликә турында чын дөреслек кирәк.

– Дөреслекнең дә ялганы буламыни?

– Бөтен дөнья ялган дөреслек белән тулган. Матильда да шуның бер буыны. Сөйлимме?

– Көтәм.

– Ишекне эчтән бикләү хәерле булыр

– Кунак – хуҗаның ишәге. Рәхим итегез.

– Хуҗаны буйсындырып яшәүдән тәм табучы кол мин.

– Сезгә буйсынган ир үзен бәхетле саныйдыр.

– Төчеләнмәгез. Миндә диабет. Татлыны яратмыйм. Ризыкта да, телдә дә.

– Гафу итегез...

– Без Әлфия белән институт торагында бергә яшәдек.

– Әлфия кем ул?

– Кемне эзләп килсәгез, шуның хәләле. Бу исемне аңа детдомда татарлар кушкан. Чын исеме – Альба. Ак, якты, чиста дигәнне аңлата. Энгельс шәһәрендә туган немка ул. Калинин указы белән иленнән күчерелгәндә, авырып, әнисе поездда үлгәч, апасын бер яһүдә медичка үзенә ала, ә сабый Альбаны Әгерҗе детдомына тапшыралар. Гәрәй абзый белән алар шул детдом чорында танышалар. ...Паспорт биргәч, төрлесен төрле якка җибәрү сәбәпле, алар тиз аерылышалар. ...Берчак безнең торакка курсант авиторлар ияләште. Шунда алар кабат очраштылар.

– Шунда өйләнештеләрме?

– Диплом алгач, Әлфияне нимес теленнән укытырга Кәттә-Курган ягына җибәрәләр. Гәрәй исә хәрби авиаполкта, адресы саннар белән генә язылa. Мин, укуымны дәвам итеп, Ташкентка киттем.

Шунда кияүгә чыгып, Сәмәрканд өлкәсе Ыштыханга кайттык. Ирем, мамык совхозында баш агроном булып бер ай эшләүгә, авыл хуҗалыгы идарәсенә күтәрделәр. Докладларын мин язып бирәм. Ул шуларны трибунадан укып, дәрәҗәсен үстерә, бүләк ала. Ике ел дигәндә, мамык планын арттырып үтәгән өчен, үзен Обкомга алдылар... Бер күтәргәнне бездә гел күтәрделәр бит, йә ефәк корты үрчеткән өчен, йә мамык өчен дип, иремнең түшенә орден арты орден тактылар. Түрәләрнең хатыннары да, ирләреннән калышмый, һаман үргә үрмәләде. Мине дә мәгарифне җитәкләү түрәсе иттеләр. Көлке булса да көлмәдем: түздем, эшләдем.

...Берчак хезмәтем буенча Кәттә-Курганга барсам, Әлфияне очраттым. Мамык сазлыкларында бизгәк эләктереп, озак кына больницада яткан икән. Торыр урыны – ишле үзбәк гаиләсенең чоланы, ди. Председательне таптырып, торак мәсьәләсен хәл итәргә вәгъдәсен алып, Әлфия белән елашып аерылышабыз.

...Булдырды, эшләде рәис. Үзегез беләсез, бу заманда бер эш тә коры рәхмәткә эшләнми...

...Туганнары юк, круглый ятимә, дусларыннан аерылган нимес кызы – блондинка кая барсын, ни белән түләсен? Колхоз рәисе Корбанов аннан хак сорамый, үзен сорый. Әлфия бирелергә мәҗбүр. Корбанов алдакчы булмаса да, яшь хатын белән качып аерым яши алмый – коммунист, алты баласы бар...

...Гәрәй Рамилевич отпускасында Сәмәркандка курсташлар очрашуына килгәч, Әлфиясе турында ишетеп, ялгышын төзәтергә, язмышын үзгәртергә карар кыла. Ирем ул чак Обком кешесе, өлкәнең мамык басуларына самолёттан агу сиптерү авиаотрядлары белән мәшгуль иде. Гәрәйне, штурман итеп, вакытлыча эшкә урнаштыра.

Беренче очуда гына Әлфияне «качуга» күндерә алмыйлар, билгеле. Җан кергән көмәнен югалтудан да, тугач аны ятим итүдән дә курка ул.

РОНО белән сөйләшеп, райздравны җигеп, баланы саклап калу сылтавы

белән, Әлфияне райком машинасында алып килеп самолётка утырталар да – озаталар. Гәрәй Рамилевич, эз югалтыр өчен, Әлфияне үзе хезмәт иткән хәрби частька алып киткәч, кайда, ничек яшереп асрагандыр – бер мәл инде. Үзбәкстанның астын өскә китергән Рәшидов процесслары башлана. Шул зил-зиләдә ханның мөритләре дә, хурлык тамгасы сугылып, хөкемгә тартыла. Рәис Корбановны да эләктерәләр. Әлфияне эзләүче дә, эзәрлекләүче дә булмый. Вакыты җиткәч, нәкъ атасына – Корбановка охшаган кыз таба ул. Аңа Матильда дип исем кушалар...

...Ирем ярдәмендә монда күченделәр, фатир алдылар. 14 нче фатир аларныкы. ...Гәрәй Рамилевич, табигый, баланы үз кызы итеп яздыра. Уртак уллары тугач та, кызга игътибар кимеми, артыграк та булмаса... Төрле түгәрәкләргә йөртү димме, музыка, бию репетиторлары яллау дисеңме – күп тырыштылар. Шул артык игътибар «бозмадымы» икән Матильданы: үзсүзле, көйсез булып үсте ул. Ата-анасына каршы дәшә башлады, сәбәпсезгә энесеннән көнләште. Әмма, ни хикмәттер, унынчыны медальгә тәмамлады. Мәскәүдә, ике институтта укып, врач һәм юрист һөнәрләрен үзләштерде. Эшкә дә Мәскәүдә урнашып, бергә үскән егетенә кияүгә чыкты... ...Фатир проблемасы тугач, акча кирәкте. Энесе үлгәч, оныклары эти-әниләре өстендә. Аны да, укытып, кеше итәргә, йорт-җирле итәргә кирәк. Моңа Матильданың «җене» чыга.

...Шул чордамы, соңракмы – Рәшидовчыларга караш-мөгамәлә йомшара башлады. Матильда, кемнәндер ишетеп, Гәрәй Рамилевичның үз атасы түгеллеген белә, алдагансыз, дип баш күтәрә.

Бермәл үзбәкләрдә бензин сибеп үз-үзләрен яндыру мордарлыгы таралды бит. Ирләреннән җәбер күргән хатыннар шулай үч алалар, янәсе. ...Матильда да ата-анасына: «Әгәр үз атамның кем булуын әйтмәсәгез, мине тере килеш озатмассыз», – дигән ультиматум куя. Аңа дөресен әйтергә мәҗбүр булалар: «Корбанов». Газеталарда миллионер Корбановның яшерелгән хәзинәләре турында берсеннән икенчесе уздырып ялган үрчегән чор иде. Матильдага эш арты эш чыга: ДНК анализлары ясатырга кирәк. Гәрәй абзыйдан ваз кичү, үз атасын эзләү, исемен үзгәртү мәшәкатьләре. Тик мәсьәлә бик тиз арада чишелә: Корбановның миллионер дигәне төрмәдә корбан булган: икенче бер Корбанов, рәис булып эшләсә дә, байлыгы юк фамилиядәш кенә икән, өченче Корбановның тугыз баласы өстенә, унынчыга тагы бер кызы табылу шатлык булса да, Матильдага хәсрәт кенә китерә: бу Корбанов үпкә чире белән ярдәм көтеп ята икән. Әлфияне белми, Кәттә-Курганда булганы да юк икән...

...Гәрәй абзый Казанга баруының берсендә үз ата-анасы турында дөреслекне белеп, документ табып кайта. Көлсәң – көлерлек, еласаң – еларлык «сәхифә» башлана: Матильда-Мәликәдән кабат Матильдага әверелә. Тик күңел бит пыяладай: Гәрәй абзыйның кызына рәнҗеше тирән, гафу итми кызны.

– Һәр сугыш солых белән бетә, килешерләр әле.

– Сугышның яңасы башланмаса... Израильдә йөреп кайткач, нык үзгәрделәр. Гәрәй абзый да, Әлфиясе дә нимесне мактыйлар. Ирем белән дә гел шул милләт турында бәхәсләшәләр. Минеке: «Барыбыз да Алтын Урдага бурычлы», – дисә, Гәрәй абзый: «Елизаветадан соңгы урыс патшаларының һәммәсендә нимес каны», – ди. Шуннан бәхәс китә, үпкәләшү белән бетә.

– Икесе дә хаклы булса кирәк...

– Икесе дә бәхетсез: бердәнбер улларын югалткан бәхетсезләр. Безнең улыбыз югалуга атасы үзен гаепли: мөмкинлеге була торып, Әфганнан алып калмады. Үрнәк күрсәтә, янәсе. Обком, имеш!..

– Улыгыз кем иде?

– Математик, яшь белгеч. Сорамагыз, елап, кәефегезне бозармын. Чынлап кызыксынсагыз, бүлмәсенә кереп әйберләрен карарсыз. Музей иттердек без аны. Ташкенттан килеп бизәделәр. Узганыбыз шул бүлмәдә, каршы бүлмәдә – иремнең бүгенгесе.

– Киләчәк башка бүлмәдәме?

– Киләчәгебез узганнарда гынадыр инде безнең... Карагыз, күрегез.

...Музей бүлмәсенә күчтек. Түрдә – уллары Вильдан почмагы. Тууы, ЗАГСта язылышуы турында таныклыклар, грамоталар, фотосурәтләр, көндәлекләр... Табут фотосына беркетелгән үлем хәбәре. Сабый чак киемнәре белән янәшә эленгән өр-яңа кителе, «Мастер спорта» значогы.

– Нинди спорт белән мавыга иде?

– Боксны гына яратмады. «Мордобойство», дия иде. Иң яратканы – шахмат уены.

– Грамоталары да күп күренә.

– Атасын отканда, аннан гафу үтенә иде. Шатланасы урында, атасы шуңа хурлана иде. Әнә фотода улына грамота тапшыралар, атасы кире якка борылган.

...Музейның каршы яктагы экспонатларын карауга күчтек. Бүлмәнең бу өлеше нәкъ Обком секретарьлары кабинетыдай җиһазланган: почмакта Кызыл байрак, Ленин бюсты, Рәшидов сыны. Ни сорасаң, шуны «юк» дип утырган «секретутка» гына юк.

Диварларда грамоталар белән аралаш фотолар эленгән. Күбесендә орден кадау мизгелләре. Кайсы ни өчен бирелүен ачыкламакчы булып борылсам, хуҗабикә гөлләргә бу сибү белән мәшгуль, үзе тавышсыз гына елый иде. Соравымны «соңыннан»га калдырып, кием шкафына күз салмак булдым. Анда эленгән пиджаклардагы орден-медальләр телсез калдырды. Ничәү булгандыр – колодкасы гына бишәү иде бугай.

– Герой исемен алырга җитмеш кило мамыгы җитмәде; Нәмәнганныкына биреп: «Чиратың киләсе елга!» – дигәннәр иде, киләсе ел килмәде.

«Килмәде» сүзен ишетүгә, ханымга таба борылсам, ул инде иренең «бүгенгесенә» күчкән. Монда күчү белән күзгә ташланган нәрсә «Батулла бүреге» булгандыр. Аны аерым элгечкә элгәннәр. Шикләнәсе юк: мин Мәккә-Мәдинәдә очраткан хаҗи-хаҗияләр «хозурына» килеп эләккәнмен. Ышаныргамы моңа? Очраклылыкның мондый ук «оятсызы» очрау очраклары буламы? Әгәр башка берәр автор язмасындагы персонажлар шундый хәлгә юлыкса, бу мине ышандырмас, уйлап чыгарылган ясалма күренеш булып тоелыр иде. Инде менә үземә шундый сәер, көтелмәгән очрашу турында язарга кирәк. Ярый, язуын да язармын. Тик үзең ышанмаганга ничек укучыны ышандырырга?! Бер генә юл кала: укучыдан ышанычны әҗәткә алып, эшемне дәвам итәргә.

...Бу карарым чибәр ханымның, ягъни көндәш-киленнең «җан тартмаса – кан тартыр, кан тартмаса – җан тартыр», кебек кинаяле сүзләрен хәтерләп, үземне-үзем юатсам да, шикләнүләрем бар иде.

Бүреккә таянып кына фикер йөртү дөрес булырмы? Кая мин күргән, камыт бөяте кебек чыраен каплаган сакал-мыеклы мөселман фанатигының һич югы бер фотосы? Диварларда гел орденлы коммунист абзый сурәтләре генә.

...Бүлмәне тутырган комган, келәм, паласлар йорт хуҗасының диндарлыгымы? Әллә яңа төр «театр»ның реквизитлар цехымы бу?

Пыяла шкафның аерым бер шүрлегендә җиде китап ята. Берсеннән икенчесе

матуррак бизәлгән тышлыклы Коръән нөхсәләре икән. Кайсы – ерак Мисырдан, кайсы – Әнкара бүләге! Ә берсе, әйе – анысы үземдә дә бар... Сораулар бирергә җай чыгып:

– Ирегез Хаҗда булган икән, – дигән идем, ханымның «тел тегермәне туктамый тарта» башлады:

– Ике ел рәттән үз ишләре төркемен хатыннары белән алып барды. Минем көндәшкә Хаҗ кылу кирәкмени? Бүләк кирәк аңа! Ике баруында алдырган бүләкләрен саный китсәң, мәктәп тотарлык чыгым. «Ияртмә!» диеп күпме ялварсам да, тыңламады карт алаша», – дип, тамагы карлыкканчы сүкте картын мәгариф ветераны.

...Бер тукталышында барасы җирләрем, күрәсе урыннарым күплекне сылтау итеп, китәргә кирәк, дигәч: «Ничек инде, килмәс борын китү ди ул? Шулкадәр юл узып, расходланып кил дә – кит, имеш! Мин бит әле сез көткән хәбәрне әйтмәдем. Нәкъ менә шул хәбәр сезгә реаль ярдәм булачак. Юк, юк – китмисез! Җибәрмим! Чәй эчә-эчә сүзне шунда дәвам итәрбез». Шуннан соң электр чәйнүгендә чәй кайнатылды, тәм-томнар чыгарылды, күлмәк алышынды, яңа монолог башланды...

...Агыйдел буе кызы икән, әти-әниләре белән бәхилләшергә кайта алмавына иренә рәнҗүен әйтүгә, кинәт, кулымны тотып: «Коткарыгыз мине бу тәмугтан! – диде дә ул, кулындагы кыйммәтле беләзеген, никах балдагын салып, алдыма куйды. – Болар сезгә, сүзләремнең чынлыгына дәлил дә, гарантия дә. Акчам да бар. Зинһар, җаен табып, ияртеп, илгә алып кайтыгыз!»

– Минем өчен иң кирәкле хәбәрегез шушымыни?

– Башка җай чыгуына ышаныч юк. Илемә бик тә кайтасым килә.

– Гәрәй абзыйның атасыннан калган балдак булса, табышыма гарантия дияр идем, ә болар сезнең шантаж элементлары! Алыгыз, ханым, киегез үзегез! Ирегез алып кайтсын! Адресым бирәм. Каршылармын!

...Ханым тырышлык белән генә тамызуга ирешкән күз яшьләрен сөртеп, тынычланган кыяфәт алды. Чәй йотып куйды. Аннары, партком карарын укыганда күнеккән рәсми интонациядә:

– Бүдәнә базарында «Һөд-һөд» дигән ломбард бар. Хуҗасының исеме Шпигельме, әллә Штигельме – «Шәкә» дип йөртәләр. Ул да теге чакта Казакъстанга куылган немес токымыннан. Ятим калгач, уйгыр гаиләсендә үскән, татар кызына өйләнгән. Телен белмәсә дә, үзен «немес», ди. Гәрәй Рамилевичнең дусты... Матильдалары белән мөнәсәбәтләре какшагач, ул-бу була калса, оныгына тапшырырга балдак белән таныклыкны «Һөд-һөд»тә саклыйлар.

– Оныгына ышанычы юклык түгелме бу?

– Курсант бит әле, югалтуы да ихтимал... Аннары: курсант өчен нәрсә соң ул балдак? ...Тел ачкычы тапсаң, Шәкә сөйләр.

– Йөзек белән таныклык турында сез каян беләсез?

– Әлфиядән! Ахирәтләр ич без.

– Бүлмәгез саен утта янмас, суда батмас сейфыгыз бар. Нигә сездә генә калдырмадылар икән?

– Аларның берсендә – депутат мандаты белән партбилет. Икенчесендә – орден-медаль документлары.

– Кайсыгыз депутат!

– Теге чакныкы. Дөньялар үзгәрсә, кирәге чыгар дип саклый.

– Үзгәрдек бит инде! Дөньясы да, үзебез дә башка.

– Эшегез барып чыкса да, чыкмаса да, хәбәрләрем хакына сез миңа бурычлы.

– Балдак тарихын ирегез беләме?

– Минем ирем һаман «көтү баш» булырга омтылучы. Башында балдак түгел, ә мин. Көтүдән качарга телим, сер саклый белмим: хыялым – ялгызлык.

– Елгалар гел кушылырга омтыла... Кешеләр гомер ахырында аерылырга... качаргамы?

– Сез мине аңларга теләмисез.

– Аңласам да, яклый алмыйм, ханым. ...Гәрчә, минем өчен яңалык әйтмәсәгез дә, хәбәрегез өчен рәхмәт.

– Рәхмәтегезгә рәхмәт белән, исемем – Зөлхиҗә.

– Илгә кайтырга, дисез... Күчереп утырткан чәчәк корый бит, ялгышмыйсызмы?

– Минем бөтен гомерем ялгышлар төзәтү белән узды. Күнеккән дә, чыныккан да.

– Анда да, мондагы кебек: көтүләр элекке «көтүбашлар» куеп калдырган көтүчеләр кулында. Иярмим дисәгез дә, бер көтүгә иярми яши алмаячаксыз.

– Сезгә иярермен.

– Үз язмышына һәркем үзе җаваплы. Ләкин без алдануыбызда кемнедер гаепләргә яратабыз.

– Алданабыз шул. Мин дә, сезгә күңелемне ачмакчы булып, алдана яздым. Бүдәнә базары ахшамнан ясигъ намазына чаклы гына эшли. Әтәч-бүдәнә сугышларыннан башланып, эт сугыштыру белән тәмамлана.

– Миңа ул сугышларның кирәге юк.

– Ломбард шул вакыт эчендә генә ачыла. Үзбәкне ничек, кайчан алдарга белә нимес.

– Анда үзбәкләр генә җыеламы?

– Калинин указы белән куылган һәр милләтнең вәкилен очратырга мөмкин, имеш, диләр.

– Бәйнәлмиләл икән.

– Үзем барып күрмәгән. Гәрәй абзый сүзе. Греклар да, абиссиниялеләр дә очрый дип... Менә, бу сезгә иремнең теге чактагы визиткасы. Бәйләнә-нитә калсалар, күрсәтерсез. Чебен дә кундырмаслар. Абруй билеты.

...Күңелгә шом салынса да, киттем «Һөд-һөд»кә таба... Ахшамга иртәрәк. Борынгы кала Сәмәркандның тарихи истәлекләре – Регистанны, Биби-ханым мәчетен, Гүр-Әмир, Ишрәт-хан, Шаһи-Зинда мавзолей ансамбльләрен театрыбызның Үзбәкстанга 1963 елгы гастрольләре вакытында күргәнлектән, бу юлы мәшһүр каберстаннарын карарга ниятләдем.

...Экскурсиям тәэсирле булса да, ахырдан чыгу юлын табалмый адашып йөрүем шомландырып кына калмады, үземне-үзем белешмичә, кинәт: «Коткарыгыз, чыгарга ярдәм итегез!» – дип кычкырырга да мәҗбүр итте.

Шуны гына көткәндәй, артымда кисәтү яңгырады: «Зиратта кычкырып сөйләшергә дә ярамый. Әрвахлар рәнҗи».

– Трамвайга чыгу юлын югалттым.

– Юл табылыр, иман югалмасын.

– Күрсәтмәссезме?

– Син инде чыккан, трамваең гына күренми... Бүдәнә базарына барасыңдыр бит? – диде өстенә ак җилән, ак түбәтәй кигән ак сакаллы абзый, мине куып җитеп. – Читтән килгән татар шунда бара, мәзәк эзләп...

– Миңа «Һөд-һөд» кирәк иде. Ломбард...

– Зират кылгач, әүвәл мәчеткә бару тиеш, син адашкансың, бәндә.

– Адаштым шул.

– Адашуыңны тану – дөрес юлга басу.

– Гөнаһым шул гына булса.

– Дөнья – адашу урыны. Ахирәттә генә тыныч, – диде дә сул кулы белән уң кулымны тотты бу, – әйдә!

...Мәет кулы тотканым булмаса да, бу сәер кешенең кулы үлгән кеше кулыдай тоелды миңа: үзе суык, үзе юеш.

– Рәхмәт сезгә. Кая килеп чыкканымны аңладым шикелле, – дидем дә кулымны ычкындыруга ирештем. – Мин бит сезне күптән түгел генә күрдем шикелле.

– Кешеләр кыямәт көнендә очрашу өчен дөньялыкта аерылышалар. Бер-беребезгә догада булыйк.

– Аны кемнеңдер көткәнлеге сизелә иде.

– Бераз гына көтсәгез, мәрхүмнәр рухына дога кылырга сәдака бирер идем, вагым юк, йөз сумны алыгыз, зинһар.

Шулай да, сәдакамны алды бу. Әмма, сул кулы белән алды. Җиң эченә яшерелгән уң кулының бармаклары юклыгын шәйләдем.

Ай күрде, кояш алды, дигәндәге кебек, әллә берәр төрбә эченә керде, әллә инде җиргә сеңде... Юк! Югалды кеше.

Үзем мистикага ышана башласам да, укучымны да шуңа ышандырырга тырышу – «колак ясау» булыр иде. Бүдәнә базарына ашыктым.

...Мин ашыга дип, трамвай ашыкмаса да, этәч сугышына өлгердем...

...Базар дигәннәре метр ярым киңлектәге арыкның ике як ярындагы ярты гектар чамасы мәйданда икән. Уртада ашханә корылмасы, казан аскан урдалар; киез палас япкан сәкеләрдә төрле самавырлар кайный; дивар чөйләренә эленгән тимерчыбык читлекләрдә сатлык бүдәнә, этәчләр сүгенә. Яр буендагы алыча агачларына дөя-ишәкләрне ялган бау белән генә бәйләп, алларына кукуруз сабаклары ташлаганнар, хуҗалары сәкеләрдә «чәйләп» утыра. Яңа килүчеләр исә арыкка иелеп, болганчык суда кул чылатып, «гөсел коенгач», чапан итәкләренә сөртенәләр дә, танышлары белән күрешеп, сәлам алмашалар. Шуннан соң кәвешләр салынып, кая утырырга, кем сәкесе отышлы булуны юрау, сайлау башлана.

Сәкедәгеләр авызларындагы яшел боламыкны, утырган киез паласларын күтәреп, төкерәләр дә, шул ук киез белән аны каплагач, яңа килүчегә, кыйммәтле бүләк биргәндәй, урын тәкъдим итәләр. Тамашаның «хуш килдегез, котәбез, мәрхабә!» өлеше икән бу. (Монысын соңыннан сорашып белдем.)

...Мең мәртәбә ишетелгән бер үк төрле сорауларга бер үк төрле җаваплардан соң, сәкедәге чынаякларның ниндие, кемнеке булуын тикшереп тә тормыйча, яшел чәй эчү тантанасы башлана. Бусы үзенә бер аерым «спектакль». Гадәттә, яңа килүченең янчыгы буш түгеллектән, чәйдән соң, кальян белән сыйлашу «уены»на (кысташу) чират җитә.

...Төрепкәнең кем авызларында булып чыкканын тикшереп тормый, аз-маз «төтәсләнгәч», диварга эленгән читлекләрдәге «гладиатор»ларны сайлау иң җаваплы эш. Сайлауның нәтиҗәсе сатучының сата белү осталыгы белән алучының «гладиатор» кошлардан гаеп таба белүеннән чыгып билгеләнә.

Ниһаять, сугышчы мәхлуклар сайлана, «аренага» күчәргә вакыт җитә. Боларын мин ишетеп түгел, үз күзләрем белән күрдем.

...Җәтмә белән капланган читлектә сугышып канга баткан ике бүдәнә ята. Икесенең дә хәле беткән. Тамашачылар аларны җанландырырга теләп кычкыралар, аты-юлы белән сүгенәләр, икмәк-нан ыргыталар.

«Гладиаторлар»ның хәлләре нан калҗаларыннан гына терелерлек булмый шул...

...Мин икесенең берсе үләчәк бу мескен кошларны калдырып, каршы як яр буйлап тезелгән насвай тәмәкесе сатучылар хозурына күчтем.

Алучыларыннан сатучылары күп бу базарның кәсепчеләре ят кеше булуымны күреп, насвайларын чама югалтып мактауларын фотога төшермәкче булган идем, өлгермәдем, кокардалы сакалбай: «Ярамый!» – диде дә фотоаппаратыма кулын сузды.

Инстинктив рәвештә чигенеп, тиз генә, Зөлхиҗә ханым биргән визитканы күрсәттем. Мин кунак, дип тә өстәдем.

Кокардалы карашын бер визиткага, бер фотоаппаратка юнәлтә. Нинди карарга килгәндер:

– Боларны сурәткә төшерү сезгә нигә кирәк булды? – диде ул, һәр сатучы каршында өелеп торган каз тизәге өеменә күрсәтеп.

– Миңа ул өемнәр түгел, телләре телгә йокмаган сатучыларның йөзләре кирәк иде. Типажлар бит.

– Антисанитария типажлары! Убрать!

...Шул сүз чыгуга, насвай сатучылар, кунаклаган каз «ояларыннан» калган яшел өемнәрне, җирдән алып, арыкка аттылар да, шунда ук, кулларын чайкап, кокардалыга бактылар.

– Дәвам итегез! – диде тәртип сакчысы. Миңа әйттеме, насвай сатучыларгамы – сорамый гына күрсәткән визиткамны алырга кулым суздым.

– Бу визитка сезгә каян килеп эләккәндер – тикшереп тормыйм. Тәмирлан әкә әле тиз генә кайтмас, йомышыгызны Шәкәгә әйтеп калдырыгыз. Ул мондагы иң ышанычлы связной... Кем булуыгызны да, каян һәм нигә килүегезне дә сорап тормыйм, чөнки оперативкада әйттеләр, кунакханәдә, 4 нче бүлмәгә урнашуыгызны да беләбез. Мәгез, бу катыргы кисәген, алыгыз!

...Базар шау-шуыннан, саз исеннән, чебен болытыннан котылырмын дип, күперчектән чыгып, ломбардка керим дисәм, чүкеч тоткан берәү:

– Күпер ябык, монда хәзер эт сугышы башлана, – дип, чинаган этләр ябулы ике тимер читлеккә күрсәтте.

Нәкъ шул мизгелдә, дөнья бетүгә хәбәр салгандай, дөя үкерде, сәкедә утырган голәмәнең үтә дә канәгатьләнү хисе белән көлү тавышы яңгырады. Баксаң-күрсәң, борынына җикән сабагы тыгып кытыклауга хурланып, дөя «бичәсе» көнозын чәйнәгән чүбеген сәрхуш хуҗасының йөзенә чәпәгән икән... Голәмә «ха-ха-ха»сына сәбәп шул иде.

...Бу мәрәкә базар халкына, зур вакыйга итеп сөйләр өчен, айдан төшкән кешене күрүгә бәрабәр иде.

Әйдә, алар көлә торсыннар. Без, «колак» ясауны калдырып, «Һөд-һөд»кә керик.

– Әссәламегаләйкем!

...Җавап ишетелмәде, электр лампасы кабынды. «Ломбард» дигәннәре вокзалдагы саклау камераларын, авыл кибетләрен, хуҗалык әсбапларын төзәтү остаханәсен хәтерләткән тимер рәшәткә тәрәзәле таш келәт иде.

Сәламемә җавап булмагач, аны кычкырыбрак кабатладым. Бу юлы җавап көттермәде:

– Ут кабызу сәлам алынуны күрсәтәдер, кардәш. Ни китердек? Бездә пашпорт белән әйберне күрсәтеп сөйләшү төп шарттыр...

Мәгарә хуҗасы, шушы сүзләрне әйтә-әйтә, шкафлар артыннан чыгып, өстәле янына килде, бер күзлеген салып, икенчесен киде, журналын ачты, каләмен тотты. Мин исә, сүз ялгансын өчен, үземчә, бик саллы сорау бирдем:

– Биредә Генрих Роммель атлы нимес карты нард уйнарга йөри дигәннәр иде. Бүген ул юкмыни?

– Ә кем соң ул?

– Гитлер фельдмаршалы Роммельнең туганы түгелме икән – шуны белешмәкче идем.

Җавабым үземә эффектлы тоелса да, ломбардчыга ошамады. Ул сүзне дәвам итәргәме-юкмы дигәндәй, урынында таптанды да, күземә карап:

– Төп һөнәрем химик-технолог минем. Хәтерем ялгышмаса, Менделеев таблицасының өченче төркемендә Бериллий дигән элемент күрсәтелгән. Исеме бар, чынбарлыкта күргән кеше юк. Алтыннан да кыйммәтлерәк металл булса да, аны табигатьтә саф килеш очрату мөмкин түгел. Шуның шикелле монда чын нимес эзләү – мамык басуында Бериллий эзләү кебек. Бизгәк эләктерүең ихтимал... Бусы – мәсьәләнең бер ягы. Икенчедән, нигә кирәк сиңа нимес карты? Әллә Идел буе нимесләре автономиясен тергезергә йөрүчеме син?

– Булса, ни?

– «Аве Мария» дигән җырны җырлау автономиясенә генә ирешәчәксең. Анысы да лагерь үзешчәннәре хорында.

– Ә нигә лагерьда? Сездә җырлар идек. «Аве, Мария»ны гына түгел, нимес композиторларының операларыннан арияләрне, романсларны. Музыка коралларыгыз бар күренә. Әйтик, Бетховен әсәрләрен, – дигән булдым, каяндыр бөек композиторның фамилиясен хәтерләп.

– Сәйдәшнең «Хуш, авылым»ы белән Мозаффаровның «Син кайтмадың»ын яңгыраткалыйбыз.

...Әйткәннәрен расларга теләгәндәй, ломбард хуҗасы киштәсеннән курайга охшаш бер нәрсә алды, авызга каба торган мөштеген кульъяулыгы белән сөрткәләп, тын өрүе булды, шуннан чыккан моңлы көйне генә көткәндәй, базарда котырып этләр өрә башлады. Шәкә каушады. Каударланып, уен коралын шүрлегенә куйды да кулына бохар түбәтәе белән намазлык алды.

– Шушы кәләпүшне ки дә, намазга утырыгыз. Монда хәзер эт сугышы фанатлары керер, – диде, «син»гә күчеп. ...Мин намазлык җәеп утырырга өлгермәдем – өстендәге һәр киеменең сәдәфләре ычкындырылган (әллә өзелгәнме?), авыз-борыны корымланып, суга чумып чыккандай тирләгән «берәү» керде дә, сәлам дә бирмичә, Шәкәнең өстәленә, «шап» итеп, «Хезмәт Кызыл байрагы» орденын салды.

– Үтермә! Тиз генә тиешле хакын бир дә, сугып егыйм тегеләрне. Отыштан соң икеләтә түләп алырмын.

– Дүкәмитләрең күрсәт, Хәйдәрхан.

– Кереп алам дим ич.

– Кайчан?

– Откач!

– Син «мая» салган эт җиңмәсә?

– Ышанмасам, салмас идем.

– Теге юлы да «отам» дип оттырдың. Әнә ята медалең. Сораучы да юк, үзең дә кирегә алмыйсың.

– Ул чакта судья сатлык булды. Бүген үзебезнеке.

– Мондый нәрсәләрне дүкәмитсез алу ярамый, Хәйдәрхан. Тарих өзелә.

– Әткәй мәрхүмнеке икәнен беләсең ич инде.
– Законы юк.
– Алайса, мә ал. Институт значогын корбан итәм. Үземнеке.
– Дипломыңны күрсәт: нумеры туры киләме.
– Хәйруштән диплом сорамагансың бит, алгансың...
– Дипломсыз значокның хакы яртылаш кына була.
– Бир миңа да яртылык!
Шул сүзне ишетүгә, Шәкә миңа карап алды, аннары ишетелер-ишетелмәс кенә:
– Ярый, сиңа бөтенлек бирәм. Әмма кире алганда икеләтеп кайтарырсың. Алмасаң – утыз көннән сатуга куела, – диде.
– Бүген үк сатсаң да бәхил!
...Китте дәрте кабынган фанат (эт сугышына!) бер яртыга ромбасын да, атасыннан калган истәлек орденын да сатып. «Орденыңны онытасың!» – дип кычкыруын көтсәм дә, дәшмәде Шәкә, сейфына бикләде. Ә ромбаны исә өстәл тартмасына гына салды. Карамыйм дисәм дә, күзем төште: тартмада төрле ромбалар ята иде.
– Сораучысы бармы шуларны?
– Һәр товарның үз алучысы, үз вакыты.
– Кыйммәт йөриме?
...Бу сорауның кинәт булуы шикләндердеме – Шәкә сагаеп калды:
– Сиңа да кирәкмени?
– Зыян итмәс иде...
– Дипломы белән булганда, кайсы ВУЗ, нинди һөнәр сайлавыңа карап хакы.
– Диплом да эшлиләрме?
– Чыннан ялганны аерып булмас бу бозык заманда ни генә эшләмиләр! Доллар ясап саталар!
– Туу турында таныклык ясыйлармы?
– Машина хакы бирсәң, патша заманы мөһерен басып бирәләр.
– Чәч машинасымы, тегүнекеме?
– Син нәрсә миннән көлеп утырасың? Дөресен әйт: каян син? Кем син? Миннән ни кирәк сиңа?
– Миңа Гәрәй Рамилевичнең алтын балдагы белән, бала тугач бирелә торган белешмә язуы кирәк иде, ягъни вәсикасы.
«Һөд-һөд» хуҗасы миңа ни кирәген ишетүгә, башта «ха!» диде; аннары, аптечкасыннан дару алып, аны су белән эчеп куйды. Нидер эзли башлады. Нәрсәләрдер тапты. «Ревизия» дип язылган катыргыны чыгарып элгәч, ишеген эчтән ике йозакка бикләп, кулына газ баллоны алды. Мин инде «каравыл» кычкыру хәлендә идем.
– Нигә сорауларның баштагы икесеннән качып, өченчесенә генә җавап бирдең?
– Баштагы икесенә – мәгез, паспортыма карагыз...
– Кем җибәрде сине монда? Мәскәүләрме?
– Австралия капиталисты! Миллиардер!
Бу җавабымны ишеткәндә, «Һөд-һөд» хуҗасының күзләре алышынды, йөзеннән кан, җаныннан миһербан качты, сулышы сизелми башлады. Үлә дип торам. Чын курку белән куркып калдым. Чыгып китү җае да, сүз үзгәртү мөмкинлегем дә юк. Ирексездән, Роммель-Зәкәрия кыйссасын сөйләргә керештем. Каушадым, буталдым, әмма финалга җиттем:
– Әгәр Гәрәй Рамилевич Искәндәровның Ян Роммель улы булуы расланса,

аңа күчерелачәк мирасның документлары әзер, Зәкәрия-Самуэль Австралиядә миннән хәбәр генә көтә.

Ышанырсызмы-юкмы – ломбардчының йөзенә кан йөгерде, күзләре минем күзләр белән очрашты, тирән итеп сулыш алды, әмма сөйләшүе юк. ...Утыра да утыра. Мин, тын алырга да кыймыйча, аннан хөкем карары көтәм. Бик озак булып тоелган ун секундтан ул күз карашын минем күздән күчерде. Мин дә урындыкка утырырга кушуы дип аңладым. «Үл» дисә, үләрлек хәлдә һаман хөкемен көтеп утырам. Ни әйтер?! Әйтмәсә, нишләргә? Чү! Башын калкытты. Ниһаять, кабат күзләр очрашкач, авызын ачып, «эн...» диде дә... тотлыкты бу.

Мин, хөкемдарга ярарга тырышып, «эн»га башланган сүзләрне тезәм, ягъни суфлёр булдым:

– Эндокринология? Энциклопедия? «Эндшпиль?»

– Энтропия! – диде ул, Менделеев таблицасына өстәргә яңа элемент тапкандай. – Мөмкин булган эшне башкару ихтималы юк, дигәнне аңлаткан очрак бу. Энтропия!

– Миңа ышанмыйсыз, димәк?

– Сөйләгәннәреңә ышанам, башкарып чыгуыңа ышанмыйм. Чөнки син ялгыш юлда.

– Тәүбә...

– Күрдең: миңа орден-медальләр китерәләр. Ата-бабаларыныкын яисә туганнарыныкын. Алам. Очраклы табылдыклар да килгәли... Төрлесе бар. Алам. Югалмасын өчен алам.

...Шулай диде дә сейфыннан йолдыз тотып килде.

– Менә бу Алтын йолдыз Әмирханов Хәтемҗанга бирелгән булган. Аны миңа теш кою остасы сатты. Ә ул үзенә кем сатуын, кем китереп тапшыруын хәтерләми, сораган хакын биргән дә алып калган. Ә мин, тикшертә торгач, эзенә төштем: «Хәтемҗан» дигән батырҗан бер ялгызы егерме сигез фашист офицерын әсир иткән өчен Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган уйгур егете икән! Отпускамда Казакъстанга кайтып, уйгур авылыннан аның үзен эзләп барсам, «Әмирханов Хәтемҗан»ның сугышка китәр өчен чит кеше исемен алган немец булуын белдем. Сугыштан соң, чын исемен әйтеп, Жуковка хат та язып караган, тик җавабы килгәнче, мәрхүм булган. Ялгызлыкта, ярлылыкта үлгән батырҗан.

– Нигә үз исемен яшергән ул?

– Немецләрне сугышка алмаганнар бит, трудармиядә генә җиккәннәр.

– Сугышта булган немецләр дә күп ич...

– Күп булмаса да бар. Кагыйдәдән качып, алдап-җайлап киткәннәр, ватан өчен батырларча һәлак булганнар. Мин сиңа исключительный очракларның берсенә бер мисал күрсәттем. Инде Роммельнең балдагына килгәндә... Әйе, сиңа Зөлхиҗә ханым дөрес әйткән – балдак та, бала тугач бирелгән белешмә вәсика язуы да миндә саклана. Ләкин аларның кемнеке булуын исбатлау ихтималы юк. Ә менә бу Алтын йолдызның чын хуҗасы кем булуын номеры буенча юллатып белдек. Номер – күп сорауларга җавап чыганагы ул.

Балдактагы вензельдән без аның Роммель атлы кешенеке икәнен белсәк тә, Роммельнең кем булуын белә алмыйбыз. Номеры юк!

Гәрәй абзый Израильгә баргач, вензельләр каталогы табып, махсус белгечләрдән тикшертеп, бу вензельдә нинди фамилия күрсәтелүен ачыклаган. Әмма шуннан уза алмаган. Чөнки узу мөмкин түгел. Хәзер инде безнең

бурыч – Роммельләр шәҗәрәсенең чишмә башын табу. Кемнәр алар? Ни белән шөгыльләнгәннәр?

– Анысы да энтропия түгелме?

– Түгел! Тыңлатмакчы булып флейта күрсәттемме?

– Флейта идемени ул?

– Роммель дигән оста тарафыннан 1760 елда эшләнгән флейта ул. Немесләр Рәсәйгә мылтык тотып түгел, флейта тотып килгәннәр. Вензель шул ук: Роммельнеке.

– Иң мөһим сер чишелә түгелме соң? Мәсьәлә ачык!

– Адаштыра торган гына ачыклык ул.

Ломбард хуҗасы кыза барып, арттагы бер шкафыннан һава өрдергеч тире күрекле корал тотып килде дә, бик кыйммәтле табышын күрсәткәндәй:

– Менә моны нидер дип беләсең? – диде.

– Балдак-беләзекләр ясаганда күмергә өрдереп, металл эреткеч җайланма түгелме?

– Портатив орган бу! «1784 ел» дигән, шул ук әби патша чоры! Лейпциг дигән немес шәһәреннән Идел буена алып киленгән, 1941 елдан Казакъстан даласына сөрелгән, хуҗалары үтерелгәч, чүплеккә чыгарып ташланган могҗиза бу. ...Киң диапазонлы, кул мануалы белән уйналучы флейталар ансамбле – орган! Виктор Гюго яза: «Орган концертында яңгыраган тылсымлы яңгырашу авазыннан изрәп, күктәге йолдызлар еларга җиргә төшәрләр», – ди. Безнең өчен аның кыйммәте органның музыкаль мөмкинлекләрендә түгел – ясаган остасында. Кара: «Alt goidschmied Meister» – «Золотых дел мастер Роммель» дигән. Менә кем нәселеннән килә Гәрәй Рамилевич Искәндәров – яки оксидлашкан Генрих Янович Роммель! Инде Гәрәйдә немес каны акканны исбатлыйсы гына кала.

– Мөмкинме бу?

– Аның өчен һәр ике якның ДНК анализы булу кирәк. Балдак та, музыка кораллары да, каннар туры килүе ачыклангач, уйнар өчен генә ярый!..

– Миндә Ян Роммельнең анализ күчермәләре бар. Зәкәрия абзый биргән иде.

– Ә миндә Гәрәй абзыйныкы саклана. Ләкин мин аны сиңа күрсәтә дә, бирә дә алмыйм. Саклауның төп шарты шулай. Вәгъдә – иман.

– Миңа нишләргә боерасыз?

– Һәрнәрсәгә әзер булып, сабыр итәргә, көтәргә! ...Әгәр рөхсәт итсә, мин аларны сиңа күрсәтергә дә, бирергә дә риза. Урыс әйткәндәй, «овчинка выделки стоит».

– Аның кайтканын көтеп ятаргамы?

– Мин аңа телеграмма сугам, адресы белән телефонга чакырып та заказ бирәм. Иртәгә җавап булыр дип өметләник тә көтик.

Киртәдән чыкмый гына хакимнәрне сүгеп, «тегеләрне» мактый-мактый, кипкән инжир кабып чәй эчәргә утырдык. Никадәр генә шакысалар да, ишекне ачмадык; Гәрәйдән уңай хәбәр килсә, «ничек-ничек нитәргә, ничек дөнья көтәргә» мәсьәләләрен бергәләп чишәргә килештек.

– Уңай хәбәр килмәү ихтималына сәбәп бармыни? – дидем мин, өченче чәшке чәемне ясатканда.

Шәкә әфәнде җавап бирергә ашыкмады. Җавапсыз калуы да аның холкында түгел, ахры. Шулай да, җавабына бик урау юлдан килде ул.

– Эшләр сез сөйләгәнчә, без теләгәнчә барса, Гәрәй Рамилевич Искәндәровка «Генрих Янович Роммель» исеменә паспортын алыштырырга кирәк булачак.

Мирасны монда торып кына кабул итеп булмаячак, Австралиягә барырга кирәк булачактыр бит?

– Әлбәттә.

– Шунысы куркыныч шул.

– Әгәр паспортны монда эшләмәсәләр, Россиядә эшләтер. Роддом справкасы белән, ДНК анализлары булгач, шикләнәсе юк.

– Гәрәй абзыйның үзеннән шикләнәм мин: исемен алыштыруга бармаса ни булыр?

– Принципиальномы?

– Анысы да, монысы да мөһим аның өчен. Кирелеге дә бар, чыгымы да...

– «Монысы» дигәнең нәрсә?

– Бу яшькә җиткәндә, немескә әверелү өчен госпошлина түләү генә җитмәячәк бит аңа.

– Эш акчага гына терәлеп калса, миндә рутил кулон бар... Менә ул... муенга аскан.

– Күреп торам...

– Шуны синең ломбардка салып – аңа!..

– Кулон хакы гына торса икән... пашпорт...

– Алтын чылбыры белән! Мин аны кирәге чыкса дип кенә алган идем, биркасы бар, «Зәкәрия» фирмасыныкы, ягъни затлы нәрсә, кыйммәтле җиһаз.

– Миндә нәкъ шундый уенчык бирәү ята. Шул ук «Зәкәрия» фирмасыныкы. Чит илләргә чыгу пашпорты алу өчен, Роммельгә мондый кулон ничәү кирәк булыр икән?

– Яхшылап кара: чын рутил бу, ясалма түгел. «Башлаган эш – беткән эш», дисәләр дә – гомер чикле. Ашыгырга кирәк, Шәкә әфәнде. Сүз түгел, гамәл кирәк.

– Минем чын исемем Шпейдель. Гитлерга каршы фетнәчеләрнең берсе шул фамилиядә булган, имеш. «Шәкә» монда кушылган кушамат кына. Тулысы – Шакирҗан. Мин аңа күнеккән, хурланмыйм да, кимсенмим дә. ...Минем бабамнар Идел буена күчеп килгәч, иң беренче булып су тегермәннәре төзегәннәр, сугару системасы керткәннәр. Хәзер ул урыннарда тегермәне түгел, елгалары да юк. Булдырабыз дип бетерделәр.

– Аңлашыла торган метамарфоза.

– Ә без Гәрәй абзый белән мылтык тотып түгел – музыка кораллары алып килеп, урыска мәдәният тараткан милләтнең йотылуын аңлый да, кичерә дә алмыйбыз. Шул борләштерә безне.

– Аңламау борләштерми, аңлау кушылдыра, Шпейдель әфәнде...

«...Шпейдель әфәнде» дигәнемне ишеткәч, Шәкә «ялт» итеп миңа карады да, елмаеп:

– Дөрес әйтәсең – «Шпейдель»; юкса, «Шпигель» дип бутыйлар, – диде. Аннары гаиләсе тарихын, бай тормыш юлын, ирешкәннәрен, югалту-табышларын – барысын-барысын бер тын алуда сөйләп бушангач, кинәт тынып калды.

Гомере буе саклаган серен беренче тапкыр очраткан чит кешегә сөйләвенә үкенә иде булса кирәк. Әйе, ул сөйләде, мин бүлдермәдем. Тыңлавым – арабызда дуслык җепләре пәйда булудан түгел, ә серен саклап йөргән ир-егеткә сабырлыгы, түземлеге өчен хөрмәтемнән булгандыр.

Әнә – утыра ул хәзер тавышсыз уйланып. Иртә картайган яшь кешегә дә, яшьлек кыяфәтен җуймаган картка да охшаган... әбине дә, бабайны да

хәтерләтә... ...Аның бердәнбер куанычы... куанычы? Юктыр, булмагандыр аның куанычлары... Ә юанычлары? Очсызга алганны кыйммәткә сатудамы?

...Әгәр дә «Кеше эзләгәндә» дигән исем белән чикләнгән булсам, хикәямдә Шәкә минем бик тә үзенчәлекле табышым булыр иде. Хәзергә мин аны калдырырга тиешмен.

– Шпейдель әфәнде, мин сезне арыттым, ахры. Транспорт тукталганчы китим инде... Кунакханә телефоны аша элемтәдә торырбыз.

– Монда күргән, монда ишеткәннәр шушында калса иде. Сакланган сер үзен аклый.

– Сәмәркандта Шәкә-Шпейдельдән башка бүтән серләшер танышым юк.

– Ә зиратта очраткан кешең? Кунакханә хәдимәсе? Сине миңа җибәргән Зөлхиҗә ханым белән көндәше? Менә алардагы сер грамм белән үлчәнми, тонналап кына. Акча исен сизсәләр, әтисеннән кызын биздергәнне – алар безне тиз тешләрләр...

– Эш берләштергәнне тешләп кенә аерып булырмы? Аннары Гәрәй белән кызы Матильда тарихы бөтенләй башка... кыйсса.

– Сәбәбе шул ук – акча, мирас.

– Эшебез уң булсын, Шпейдель әфәнде, акчасы булыр.

– Амин! Шулай булсын дип юрыйк.

...Шпейдель-Шәкә, авыз эченнән нидер укып, битен сыйпап куйды.

– Карале, Шәкә әфәнде, син католик түгелмени, ислам дине тотасыңмыни?

– Аллага ышансам да, дини йолаларга илтифатым мактанырлык түгел... Бөтенләй үк ваемсыз булмасам да, азартым юк. Кем белән утырсам, шуның кәефе өчен тегеләй дә, болай да булгалый. Үпкәләмә тагы. Ә Алла бардыр, бердер. Ышаныч кирәк. Көч – ышанычта.

Кунакханәгә такси яллап кайтсам да (икеләтә хакка), сәгать төнге уникене сугып узганлыктан, ишекләре бикләнгән, каравылчы ир дә, кизү торучы администратор ханым да йокларга ятканнар иде. Аларны уятканчы кат-кат кыңгырауга басып, ишек шакырга туры килде. Кырык сүзгә җитеп, ачкычларын тотып, ишек ачарга килгән бывший «КГБ»шник, мондый очракларда тиешле булган «чәйлек» күрсәткәч, сүгенүдән туктап, ишекне ачты.

Администратор, ятагыннан башын күтәрми генә:

– Ничәнче нумер? – диде.

– Дүртенче.

– Дүртнең ачкычы монда юк.

– Кая киткән?

– Анысын сездән сорарга кирәктер, мөхтәрәм казанлы. Кемгә бирдегез?

– Беркемгә дә бирмәдем... шикелле. Бәлки хәдимә алгандыр? Җыештыручы?

– Хәдимәләрдә запас ачкыч бар-барын. Тик алар иртәнге сигезсез эшкә килми.

– Миңа бүген керергә кирәк бит.

– Бик үтенеп сорасаң, каравылчы Әхмәдиша җаен табар. Табарсыңмы, Әхми?

– Ачкыч ясау хакына ризалашса, тәвәккәлләрбез, – диде сөйләшүебезне ишетеп яткан каравылчы.

...Риза булмый кая барам? Баскан урынымнан кузгалмый гына көтеп торырга боерып, китте йөзләгән ачкычны бер бауга тезеп муенына аскан коткаручым дүртенче «бастионны» алырга.

...Сулыш алырга да куркып, бер сәгать булып тоелган бер минут чамасы

узуга, килә бу. Хәйләле елмаюдан «авызы колагына» җиткән, күзләрендә очкыннар уйный.

– Бар, кунак, рәхәтен күр, безне дә онытма – оҗмах ишегең ачык!

– Шул арада ничек ачтыгыз?

– Без бит хакны вакыт сарыф иткән өчен дип түгел, нәтиҗә өчен алабыз.

– Күпсенеп әйтүем түгел. Рәхмәт илтифатыгызга... Йөз аклыгы өчен алыгыз.

– Йозаклык булды инде бу... Сдачам юк.

Сак кына атлап, номерыма кереп, ишекне эчтәм элим дисәм, ачкыч эчке йозак тишегендә мине көтә! ...Әхмәдишаны гаепләмим, «ачкыч юк»ны ишетүгә, үзем килеп тикшерәсем калган. Бәлки, шулай ишектә онытылып калгандыр ул?

«Видеокамерам очмаганмы?» дигән шик эчкәреге бүлмәгә уздырды.

...Бүлмә ишеген ачуга... ни булганын язар өчен минем урында физиолог, психолог, тикшерүче һөнәрләрен камил үзләштергән белгечлекләре өстенә ялангач хатын-кыз фигуралары ясап дан яулаган Алексей Кравченкодан остарак сынчы-рәссам да булырга кирәктер. Саналган һөнәрләрнең берсенә дә ия булмагач, ир кеше буларак кына күргәнемне тасвирлап карыйм. ...Әйе, килеп керүгә... юк – булмый...

...Ир-егетләр минем хәлне аңлар, хатын-кыз, мыскыллап, елмаер гына. Ни-нәрсә булуын, битараф күзәтүче «күзлеге киеп», тасвирларга җөрьәт итәм. Франц Базен: «Мәхәббәт уенында тәннең кирәкле бер әгъзасын гына күрсәтеп, бик күп нәрсә аңлату – бар булган мөлкәтеңне күрсәтеп, бер фикер әйтмәүдән кыйммәтрәк», – ди мәгълүм формуласында.

Назлану фонында фикер хөрмәт ителмәсә дә, булган фикерне (зурмы, кечкенәме) үтемлерәк әйтү отышлырактыр. Ә үтемле әйтергә осталык белән кыскалык кирәк. Ул мәлдә миндә, гомумән, бер фикер дә юк иде. Кыскасы, мин шок хәлендә. Шик диңгезендә, сихри дөньяда, тылсым тоткынлыгында идем. Ә ул... ул ята, ята йокыга талган гүзәл...

...Өстәлдә бик аз гына салып эчелгән бер литрлы шешәдә затлы шәраб, сындырылган шоколад кисәкләре, печеньелы тартмалар, суы суынган электр чәйнүге, тиелмәгән «Липтон» чәе пакетлары ята. Барсы да ята...

...Шунда ук ятучы пластик флакондагы ниндидер дару шикләндерсә дә, язуын укыгач, тынычландым: йоклата торган «сәдәфләр» икән. Күрәсең, көткән-көткән дә номер хуҗасы кайтуга үзе «номер» күрсәтмәкче булган. Тик, түземлеге җитмәү өстенә, Базен формуласын белмәве көчсезләндергәч, шәраб салып эчкәндер дә, шул җиткәндер – ауган гүзәлбикә. ...Әгәр мин бу хәзинәне күрүгә «нәфсем уянмады», «кызыкмадым» дип язсам, моңа беркем дә ышанмаячак. Кыскасы, минем ихтыярым аның ихтыярында иде. Башка сүз табалмыйм. (Хәзер инде укучым теге анекдоттагы кебек, «дальше-дальше», диячәк. Ләкин «дальше было раньше» җавабы булмаячак.)

...Уятып, мең соравымның һич югы берсенә җавап алу турында уйларлык түгел: гүзәл – татлы йокыда. Әнә аның ир-егетләрне кол иткән хәзинәләре, горурлыгы – барысы да якында гына. ...Уянгач, үз хәленнән үзе оялмасынга, ефәк җәймә белән кайбер «детальләрен» күздән яшердем дә, уянганын көткән арада, бәллүр фужерга шәраб салып, эчмәк булдым. Салдым, кулыма алдым... Тукта... чү... ни бу?

...Шәраб түгел икән – ниндидер мин күрмәгән, мин эчмәгән коньяк исе килә, ни булса – шул дип, эчтем бу «иномарка»ны. Таныш түгел нәрсәнең ничек тәэсир итүен белгән юк, «Восток – дело тонкое» дигәннән чыгып кабатламадым.

(Әлегә кадәр булган вакыйгалар эзлекле һәм өзлексез тасвирланса, хикәямнең шушы урынында аерым бер бүлекне язмый узуыма укучымнан гафу үтенергә тиешмен. Язсам, анда яңа фикер дә, адәм балаларына ят гамәл дә булмас иде.)

**7 БҮЛЕК**

## Ирнең үгие булмас

...Яткан караватымның шыгырдап тибрәлүеннән уянып киткәндә, сәгать ничә булгандыр, әмма тышта яктырган иде инде.

Янымда яткан гүзәлнең йөзе нурлы да, бәхетле дә булу, мине дәртләндереп, көч тә өсти кебек. Без тагы ләззәт диңгезендә йөзәбез.

Кем караватына кайсыбыз башлап күченгәндер, хәзер инде ятакларыбыз гына түгел, җаннарыбыз кушылганлыктан, безне бернинди көч тә аерырга җөрьәт итмәс дигән ышанычта хозурланабыз.

Аның һәр әйткәне миңа хакыйкатьнең үзе булып тоела. Минем белән булып узганнар да, бүгенгем дә аны җилкендерми, аның өчен бары тик киләчәк кенә кирәк, кирәкле булганга, киләчәк кенә әһәмиятле аңа.

Аңа ияреп, миңа да хыялга бирелеп яту – рәхәт.

...Шагыйрь Илдус Гыйләҗев: «Ышаныч яулап алына, мәхәббәт үзе табыла», – дип яза. Безнең очракта башлап мәхәббәт (күз аша) безне сүзсез таныштырып, күңелләрне кавыштырды, шул кавышу бер-беребезне эзләргә этәрде; тапкач, ышаныч уятты. Шушы яшькә җитеп, шашып ярату барлыгын да, мәхәббәтнең һәрнәрсәдән көчле булуын да белмәгәнмен, тоймаганмын. Бар икән, дөрес икән, яши икән... Яшәсен мәхәббәт!

Бу – һич кенә дә гомер иткән хатынымны сөймәгәнмен икән, дигән сүз түгел. Әмма мин аны күбрәк аның үзе өчен, аңа рәхәт булсын өчен дип яратканмындыр. Аның янында мин ышанычлы, бәхетле тормыш тапсам да, ләззәтле гомер кичердек дип әйтә алмыйм. Матур булганга яхшы күрендеме ул, яхшы булганга матур күрендеме – өзеп кенә анысын да әйтү кыен. Һәрхәлдә мин хатынымның хосусый милке булып саналсам да, күңелем биләүле түгел иде. Аңа хыянәтсез гомер кичерүемне көчле холыктандыр дип тә санамыйм. Кирәге булмагач, кызыгын тапмаганмын, кызыксыз нәрсә кызгануны уята. Мөгаен, шуннан куркылгандыр. Яшәлгән, яшибез, яшәлер. Яшьлектәге бер күңел дәфтәремә кемнеңдер дүртьюллыгын язып куйганмын:

Вчера давно уже умчалась,
Завтра может не придёт.
И лишь в одном сегодня
Радость, бесспорно, человек найдёт.

Кем шигыре булса да, фикере белән килешәм.

Шул ук вакытта куркам да: җәйдән соң кыш килгәндәй, шатлыкны кайгы-хәсрәт алыштырмаса иде, дим...

* * *

...Бүген ул гомере буе йола-кагыйдәләр тыеп килгән теләкләрен, сүнү хәленә җитеп, тумыштан килгән дәртен, комарлыгын, азгынлыгын, үз ихтыяры белән әрәм-шәрәм ителмәгән хис, тойгыларының калган көчен сынап карау мөмкинлеге чыгуга язмышына рәхмәтле булып, теләгәнчә рәхәтлек кичерергә тырыша. Мин аны аңлыйм һәм ул теләгән ир булырга тырышам. Ахыры хәерле булсын.

Шатлыктан изрәп, хаталарны танып, беркая чыкмый, мәхәббәт, «иномарка» һәм шоколад белән генә туенып, өч тәүлек яшәдек.

Ниһаять, минем өчен бөтен дөнья рәхәте, баксаң-күрсәң, хатын-кызда икән, дигән фикерем оеп килгән мәлдә генә телефон шалтырады. Шатлык дәвамлырак булсын өчен, трубкага ашыгып ташланмадым, майкамны, чалбарымны кидем. Шуннан соң гына телефонга. Мин көткән Шәкә-Шпейдель тавышы түгел, ә дежур администраторныкы иде:

– Әгәр номерны бушатмасагыз, акча түләргә тиеш буласыз. Бүген көндезге сәгать унбергә кадәр түләмәсәгез, бер тәүлеккә артык яшәлгән исәпләнә... «пип-пип-пип»...

– Гаҗәп икән... «бер тәүлеккә артык яшәлгән», имеш. Кем миңа күпме яшәүне билгели? Нинди серле кисәтү бу?

– Мин ишетмәдем.

– Карале, кем, исемең исемнән чыккан...

– Безнең халыкта исем белән эндәшү юк. Ир дә, хатын да бер-берсенә «син» дип кенә дәшә. Син дә миңа «син» диң.

– Син бит минем хатыным түгел.

– Ә кемең???

– Бәлки «сөяркәм»дер? Ләкин бу сүзне кычкырып әйтмиләр, сер итеп саклыйлар, яшерәләр.

– Ә минем сөяркә булуым белән горурланасым килсә?

– Бу оятсызлык дип атала түгелме?

– Табигате сораганны канәгатьләндергәч, ни өчен хатын-кыз гына оялырга тиеш? Теләкләренең табигый юлына аркылы төшмәү нәтиҗәсендә нәсел калдыру мөмкинлеген ир дә, хатын да тигез бүләләр икән, нигә аның өчен хатыннар гына оятлы? Ни өчен теләкләре тигез булса да, хатыннар карышкан атлы булырга тиеш?

– Оялчанлык – хатын-кызның иң көчле коралы. Күз карашының яшеренлеге, тәненең нәфислеге, тавышының йомшаклыгы, сүзләренең серлелеге – барсы да ирләрне буйсындыру коралы. Әмма шунысы бар: корал кирәк чакта гына кулланыла.

– Хатын-кыз өчен аларның кирәкмәгән чагы юк. Чәчәк ни өчен һәрчак матур да, хуш исле дә була? Күбәләкләр, бал кортлары еш кунсын, серкәләнсен, җимешләнсен өченгә! Кызыктыру исәбе үсемлекләрдә бар!

– Төссез, иссез дә гөлләр була. Алары да чәчәк ата, орлык сибә...

– Син мине нинди гөлгә тиңләмәкчесең?

– Лотоска! Ул матур да, хуш исеннән башлар әйләнә, имеш. Һиндстанда булган егетләр сөйли: лотос күле төн буе «гөж» килә, ди. Ширбәтенә рәхәтләнгән бал корты туену белән очып китмәгән. Ә, төн җиткәч, суынгач, чәчәк ябылган – зинданга әверелгән, кояш чыкканчы нечкәбил тоткын җырын җырларга мәҗбүр.

– Кызганыч. Нечкәбиле дә, лотосы да. Мәхәббәткә лаек түгел, алар – тамак-нәфес коллары.

– Хәзер бу турыда сүз куертырга вакытым юк. Син давай, кызый, тор, юын, киен дә, өеңә кайт. Көндәшең көтеп зарыкмасын. Мин «Һөд-һөд»кә барып нинди хәбәрләр килүен белешим.

– Ә минем кайтыр юлым киселгән, өем – шушы, ирем – син.

– Шаярырга моменты ул түгел. Әгәр хәбәр килмәгән булса, нинди чара күрү турында уйларга кирәк миңа. Минем бит әле кайтыр юлга билет та алынмаган.

– Качу турында уйласаң – ялгышасың... Мин сине җибәрмәячәкмен! Китсәк – бергә!

– Саташма, кызый!..

– «Сөяркәдән» «кызыйга» әвереелдекмени? Хәмергә нәрсәдер салып эчереп миңгерәүләткәч, «кызыйга» түгел, кәҗәгә дә әверелерсең... «Наркоконтроль», имеш... «Бар-бар, тик озак юанма, тизрәк йөре. Мондагы халык үшән булса да, эшне тиз тота, каты тота. Тотканын ычкындырмый... Бигрәк тә минем Тәмирлан кулына эләккән эшнең эш булмый калганы юк.

– Нинди эш турында сөйлисең син?

– Ярый. Син аның хатынын алдалап, азындырырга ирештең, ди. Ә... эшеннән тыя алмыйсың бит?! ...Ул инде былтырдан бирле «инюрколлегия»дәге дуслары аша әнә шул нимес Ян Роммельне эзләтә... Синең кебек теләсә кайда, теләсә кемгә сер таратып, күләгә куып йөрми.

Бар, бар – аптырама... Ишеткәнеңнән бигрәк әле ишетәселәрең алда... Син кайтуга мин монда никахыбызга шаһитлар әзерләп көтәрмен. Хәер, алар һәрчак, һәрнәрсәгә әзер...

* * *

– Синме соң бу? Ни сөйлисең син? Мин ялгышаммы? Синме?

– Икебез дә ялгышабыз. Шул безне таныштырды, кавыштырды. Кая минем киемнәрем? Чишендергәнсең икән – киендерә дә бел!

– Мин каравылчыдан ишекне ачтырып кергәндә, син шушылай йоклап ята идең...

– Йокыга сабышып!!! Ишекне дөбердәткәндә генә чишенеп яттым әле мин. Сынар өчен! Ә син мине өемә озату урынына...

– Шантаж!

– Әнә шул таблеткалар шантаж түгелме? Тикшертикме? Чакырам!

– Кирәкми! Беркемне дә чакыру кирәкми! Сөйләшербез, аңлашырбыз. Үзебез, үзара... Уф... Шулай булырсың дип курыккан идем. Уйлаганым алдымда калтырап тора. Шаяруымны аңламас ир-егет! Шуны гына бел: миннән качып котылу ихтималың юк. Чөнки, чөнки син миңа бик тә ошыйсың. Әлегә җитте. Бар, эшеңне бел.

...Бу сөйләшүдән соң тагы ниләр булганын язып, кәеф бозасым килми. «Колак ясау» дип узып китү дә дөрес булмас. Чөнки «инюрколлегия» аша Роммельнең нәселен эзләтү ихтималы булу – игътибарсыз үткәрердәй хәбәр түгел. Шпейдель белән киңәш кылырга кирәк. Видеокамерамны алып, киттем таныш ломбардка. Бүдәнә базары эш көннәрендә ябык булса да, «Һөд-һөд» ачык иде. Хуҗасы гына «бикле» кебек. ...Шәкә-Шпейдель әфәнде үпкәләгән кебегрәк каршылады:

– Беркемем дә юк дигән идең, ике көн буе телефонга да килмисең, «кунагы бар», диләр. Кеше өч көн буена кунак булмас – кемең иде ул? Әллә тегеләрнең берәрсеме?

– Ялгышыммы, язмышыммы, табышыммы, югалтуыммы? – әлегә әйтә алмыйм. Бәлки синдәге хәбәр айнытыр: әйт тизрәк.

– Гәрәй Рамилевич белән сөйләштек тә, телеграммасын да алдым. Мә, үзең укы. Ул синең Саратовка килүеңне көтә. Ә бусын менә бирергә кушты. Балтач больницасы биргән белешмәнең күчермәсе белән вензельдәге тамганың зурайтылган фотосы. Калганын үзе белән сөйләшкәч хәл итәрсез... Ул каршы түгел, барсына да риза.

– Миңа калса, буласы булды, буявы сеңде дияргә түгелме?

– Гәрәй Рамилевич «күчерелгән милләтләр мәдәниятен саклау» фонды оештыру мәшәкатьләреннән аерыла алмау сәбәпле, үзе кайта алмый. Сине көтә. Ничек тә сузмый барырга, күрешергә тырыш. Сунарчылар син генә түгел.

...Беренче очрашуымда күзем төшкән гүзәлне монда тагы очратуымны, аның да миңа күңеле төшкәнлеген, кунакханәгә кайтуыма көтеп ятуын, хәмер эчеп гөнаһка керүебезне – барсын-барсын бөтен нечкәлекләре белән сөйләдем дә Шпейдель әфәнденең күзләренә багып хөкемен көтәм: ни әйтер?

– Монда хәмер гаепле түгел, – диде ул, бераз тын утыргач.

– Үзебезме?

– Гаепле юк. Барысы да чарасызлыктан. Аның чынлап та коллыктан котыласы килә.

– Котылабыз дип тотылсак? Прощай, карьера, эш, иҗат, гаилә – барысы, барысы оча.

– Син инде тотылган. Бу проблеманы чишәм дип баш вату – мәгънәсезлек. Шул проблема белән яшәргә кирәк.

– Ягъни?

– Ягъни аны үзең белән алып китәргә кирәк. Анда акча җитәрлек, аерым фатир табып урнаштыруда ярдәм итәрсең.

– Саташма!

– Ул – монда бала чагыннан Тәмирланның колы хәлендә яшәүдән туйган хатын. ...Башта үзе файдаланып, аннары, малаен өйләндереп... хуҗабикә ясап... Барысын да күрмәсә дә, белеп, сизеп яшәде халык.

Хакимияттән китсә дә, хакимлеге һаман көчле аның. Шунысы куркыныч: кая карама ул һаман хуҗа.

– Шулай булгач?

– Без «халыклар иреге, милләтләр иреге» дип барабан кагарга яратабыз. Ә бер кешене коткарудан куркып качабыз. Тәвәккәллек кирәк!..

...Аласыларын алып, бирәселәрен биреп, әйтәселәрне әйтештек тә, мин Шпейдель-Шакирҗан белән хушлашып, билет алырга вокзалга киттем. Ул Гәрәй Рамилевич белән сөйләшергә телеграфка юнәлде.

...Эшләремнең барысы да теләгәнчә барып чыкса да, җаным тыныч түгел, тагы нидер булыр һәм алары куркынычрактыр кебек тоела иде.

Күңелем сиземләве алдамаган: Ташкенттан Саратовка оча торган самолётка түгел – Ташкентка кадәр поездга да билет юк иде. «Бу белешмәне күрсәтүчегә һәрьяклап ярдәм итегез!» – дигән көчле язуны сузсам да, кассир хатын аңа карарга да теләмәде, «юк» диде дә, билетларын кире тапшыручыларны көтеп торсагыз, сез беренче булырсыз, дип тынычландырды.

Инде ничәнче тәүлек нормаль йокы күрмәгәч, эскәмиягә утыру белән изрәп киткәнмен. Сыбызгы тавышына күзләремне ачсам, каршымда үзен маршалдан да өстен санаучы старшина басып тора:

– Гражданин пассажир, тут спат нилҗә, эс вас штраф! – ди. Бәхәсләшеп тормыйча, көткәнен алса да, тәртип саклаучы икенче залга чыгарга боерды.

– Билетын кире тапшырырга килүчене шушында утырып көтәргә кушты бит...

– Сәфәрең кай якка?

– Ташкент аша Саратовка, аннан Казанга иде.

– Кая, китер акчаңны.

– Ничә сум кирәк?

– Ничә сум җәл түгел.

– Билет бәясе күпме торса, шул суммадыр инде? Ике билет.

– Билет хакы бездә кешесенә карап, көне белән – җомга, шимбә, якшәмбе бер бәя, эш көннәрендә – башка хак.

– Прейскуранты бардыр бит? Безнең акча белән ничә сум кирәк?

– Сиңа прейскурант кирәкме, билетмы?

– Билетның хакын белү кирәк. Чөнки миндә доллар түгел, ә рубль. Ике билет!

– Алайса, утырасың инде, абзый, рублеңне саклап, прейскурант карап... билетларын тапшырырга килүчене көтеп...

– Билет миңа бүген, хәзер кирәк иде бит, старшина.

– Ә безгә монда ничек тә үлми яшәргә кирәк. Кассирга да, миңа да.

...Китте старшина, калдым аның «тел төбен» төшенмичә. Күпмедер утыргач, видеокамерамның «эшчәнлеген» тикшерергә теләп, саквояжымда актарына башлауга, каян күреп, нәрсә сизенгәндер – очып дигәндәй, тагы каршыма килеп басты бу:

– Тут снимат нилҗә. Стратегик объект, органнардан аерым рөхсәт язуы кирәк.

– Миндә рөхсәт язуының төрлесе бар. Рәхим итеп танышыгыз...

– Ә нигә аны баштан ук күрсәтмәдегез? Монда мин бит... Мин...

– Кассир да, администратор да язуны укымадылар.

– Миңа күрсәтергә кирәк иде! Закон сагында мин! Менә ич – язган: «Местные отделения правоохранительных учреждений должны содействовать», – дигән. Киттек кассага! Бүлмәсенә керәбез! Ач, Дөркәй. Мин бу – старшина Байтирәков.

– Бикле түгел ишек – ач та кер, Байтирәк Черекбаев.

– Син нигә бу иностранецка билет сатмадың?

– Сорамагандыр...

– «Билет бармы?» дигәч, «юк» дидегез ич, ханым.

– «Билет бармы» соравына бездә һәрчак стандарт җавап: «юк». Әгәр кая кирәген әйтеп сорасалар: «бераз сабыр итегез, эзләргә кирәк», дигән булыр идек. Кирәк кеше көтә дә, көттерми дә. Ә бу Казан татары шунда ук сиңа чапкан... Куркыта, янәсе!..

– Хәзер үк оформляй!..

– Уже пишу. Сезгә ничә билет, әфәндем?

– Ике.

– Нинди урыннар кирәк?

– Ике кешелек купе бармы?

– Күпме кирәк – шулкадәр. Паспортларыгызны һәм ике билетлык...

– Миндә паспорт үземнеке генә. Минем исемгә языгыз.

– Алай ярамый. Үз паспорты белән килеп алыр. Кем дип языйк?

– Паспортым алдыгызда.

– Аңа дигәнен бронялау өчен фамилиясен әйтегез, дим!

– Кайчандыр «шәһәр гүзәле» конкурсында икенче урынны алган.

– Кая бара Тәмирлан хатыны сезнең белән?

– Эш буенча...

– Тәмирлан әкә риза булып җибәрәме?

– Анысын үзеннән сорарсыз.

– Мәҗбүрбез! Кайсы хатыны? Аның хатыннары... күп.

– Конкурста җиңгәне!

– Байтирәков, ишетәсеңме?..

– Старшина булганыма ике ай тула бүген.

– Старшина Байтирәков! Көек исе сизмисеңме, дим?

– Көек исе дә, киек исе дә бар бу эштә. Чыгып торуыгызны сорыйбыз, әфәндем. Бүлмәне җилләтеп алырга кирәк булыр. Ишетмисезме әллә?

– Паспорт, билет, акчам?

– Алар вакытлыча кассада калып торыр. Ситуация ачыклангач килеп алырсыз. Тиене дә югалмас.

...Аларга ситуация ачыклангандырмы, юкмы, әмма минем өчен катмарланды гына: кичкә кадәр утырсам да, билет та булмады, акча да кайтарып бирелмәде, паспортка өстәмә командировка документларын да сорап алдылар. Имеш, Сәмәркандта буласым анда атап күрсәтелмәгәнлектән, Үзбәкстан шәһәрләрендә генә диелгәнлектән, нинди учреждениедә булсам, шул оешмалар аны үз мөһерләрен сугып, расларга тиешләр икән. Командировочныйда ул графа буш. Ни өчен буш? «Һөд-һөд» госучреждение түгел, шәхси сату-алу урыны гына икән... «Уф, Алла!» дими, ни диярсең?!

– Иртәгә иртәнге сәгать унга килерсез, – дигәнгә ризалашмасам да, сүз куертмыйча, кунакханәгә юл тоттым. Бу юлы ачкыч үз урынында, ә гүзәлнең урынында калдырган язуы гына ята иде: «Ачкычыңны алып, бүлмәңдә үземне монафикъларча тотуым өчен гафу үтенәм. Без, кешеләр, барыбыз да артистлар ич – тугач та уйный башлыйбыз. Сөйләшү-алдашу, ялган өчен уйлап табылган чара ул. Кунакханә хәдимәләренә ачу, үпкә тотма, алардан гафу көтмә, ни дә булса дәгъва итмә. Алар мине яхшы белгәнлектән, ни теләсәк, ничек теләсәк, кайчан теләсәк – ничек кирәк, шулай үтәргә сүз биргән халык... Кыскасы, аңлагансыздыр: бу кунакханәнең хуҗабикәсе мин булам. Чәчтараш, матурлык салоннарын санап, әйтеп тормыйм. Матурлар анда йөрми. Мине эзләмә. Сине үзем табармын. Бу язуны укыгач, яндырып, көлен унитазга агыз да суыткычта көткән «Наполеон» белән таныш. Аннары, узганнарны төшеңдә күреп йокла».

«...Йокла», имеш! Йокларсың монда! Мәрхәмәтле хуҗабикә булып күренәсе килгәч, «Йоклама!», «Уян!» дисә иде... Мин бит болай да, тегеләй дә, менә ничәнче тәүлек инде, гел йокылы-саташулы халәттә йөрим.

Мин, һаман саен, авырткан башны тарарга тимер тарак эзләгәндә, проблемага юлыгам икән бит! Проблема өстенә проблема. Әгәр дә ул, чынлап та хуҗабикә булып, «очрашу»дагы сөйләшүләр диктофонга яздырылса? Яшерен микрофоннар булыр урыннарны эзли башладым. Мин табарлык булса, яшерен булмаслыгын уйлап кына, эзләнүдән тукталдым.

Хуҗабикә булуына шикләнәсе юк. Үзебезнең Казаныбызда да, байлыгын «хуҗабикәләре» исеменә яздырып, миллиардерга әверелгән чиновниклар азмыни? Ә кем соң бездә «бу завод минеке», «бу кунакханә минеке», «бу урман минеке» дип йөри?

Ишеткәннәргә ышансаң, илдәге җирләрнең генә түгел, җир астындагы хәзинәләрнең дә, күлләр, елга-чишмәләрнең дә «хуҗабикәләре», халыкка кушылып, хуҗаларны сүгешә, зарланган була.

...Микрофон-видеокамералар күз-колагыннан саклану йөзеннән, суыткычка таба борылып та карамыйча, йокларга булдым. Хәлем чыннан да авыр иде, ярдәм көтәр кешем юк. Бердәнбер өметем Хызыргаләйһиәссәламдә дияр идем – аны гөнаһлы кешедән читләшә, диләр...

Шулай уйланып күпме ятканмындыр, ишегемне шакуга уянып киттем. Дөрес уйлыйсыз: бу ул иде. Тик бу юлы ул тәненең бер өлеше дә күренмәслек

итеп ефәк чадрага төренгән, мин уема да китерә алмаслык ярсыган, җилкенгән, ашыга.

– Киен, – диде ул, бөркәнчегеннән котылуга, – менә сиңа заказың буенча самолётка ике билет, болары Ташкентка кадәр поезд билетлары – иртәгәгә. Ә бусы калдырган акчаң.

– Иртәгәгә самолётка билет юк дигән иде бит...

– Такси белән китәсең. Шунсыз өлгерә алмыйсың.

– Нигә ике билет? Син дә минем беләнме?

– Мин әлегә калам. Җиңәр өчен вакытлыча җиңелү тактикасы бу. Аңа мине «китте» дигән хәбәр барып ирешүенә шикләнмим. Тикшерәм дип кайтса, мин өйдә... Сиңа очарга кирәк. Әгәр тоткарлансаң, ул синнән котылу чарасын күрәчәк.

– Куркытма, зинһар...

– Кисәтү бу. Наркоконтроль инспекторы икәнеңне белгән булыр ул. Бусы сиңа көтелмәгән юл чыгымнарыңа.

– Сатып алуның бер формасы инде бу. Рәхмәт. Мохтаҗлыгым юк.

– Кирәге чыгарын беләм. Мине эзләмә. Сине үзем табармын. Хәбәр көт.

– Нинди хәбәр?

– Шатлыкка булыр дип өметләнәм.

– Мин сине аңламыйм, кызый: без ике телдә сөйләшәбез. Чынында кем соң син? Хаҗияме? Тылсымчымы? Сихерчеме? Уйнашчымы? Интриганкамы? Нәфес колымы? Артисткамы? Кем син? Язмышыммы? Ялгышыммы?

– Чынында санаганнарыңның һәркайсы һәр хатын-кызда бардыр.

– Ә минем сине генә беләсем килә? Кем син?

– Мин синең коткаручың – Хызыргаләйһиәссәлам!

– Мин хәзер чынбарлыкка гына ышанам шул.

– Үзеңә ышанычың бетмәсен! Иң мөһиме – үзеңдәге көчтә, абзый. Кил, киләчәк өчен дип, кирәкмәгәнен онытып, кирәген онытмаска вәгъдә биреп, кочаклап үп тә, хушлашыйк.

– Һөнәрем актёр булса да, тормышта уйный алмыйм, матур төшем, сиңа да уяныр чак җиткәндер... Хуш, сау бул!

## 8 БҮЛЕК

## Яхшыга тиң юк, яманга им юк

...Юл газаплары тоймыйча, таксида да, самолётта да йоклап кына баргач, кунакханәгә урнашканчы туры Гәрәй Рамилевичка илттердем. Өч бүлмәле «хрущёвка»ның бер бүлмәсенә – Әлфиянең ерак туганнарына урнашканнар икән. Киләсемне Шәкә-Шпейдель шалтыратып әйтүе буенча белсәләр дә, бүген килер дип көтмәгәннәр; хатыны кунак каршыларга ризык алырга дип базарга киткән, Гәрәй Рамилевич нотариуска җыена иде. Очраштык, шатлык һәм саклык белән генә сынашып, «эшлекле сөйләшүгә күчтек».

...Кинәт кенә Сәмәркандтан китүемнең сәбәбен үземчә йомшартыбрак сөйләсәм дә, Тәмирлан гаиләсе белән бәйләнешемнән канәгать түгеллеге сизелә иде абзыйның:

– Хатыннары үзләренчә яшиләр. Күрмәскә, ишетмәскә тырышсак та, без капчыкта ятмый бит... Ут күршеләребез буларак, конфликтка кермәскә, күрмәскә тырышабыз. Сер сөйләүдән, ачылудан сакланабыз. Һәрнәрсәдән үзләренә файда эзлиләр.

– Хатыннары дамы?

– Хатыннары Тәмирланның кайларда нинди «чишмәләре» барлыгын да белми булыр. Булсын да, кесә тулсын... ...Бер туганы Термезда загранпаспортлар бирү буенча ниндидер түрә, шул эше аның чабыш аты да, җигүлесе дә. Дөньяны читтән килгән килмешәкләр белән тәэмин итү алар кулында. Шулардан чыгып әйткәндә...

– Гәрәй Рамилевич! Сез мине бик кирәк дип чакыргансыз. Тәмирлан турында гайбәт сөйләр өчен түгелдер, шәт?! Минем вакытым бик аз. Мөмкин булса, чакыруыгызның сәбәбенә күчсәгез иде.

– Шул сәбәпләр турында сөйлим бит инде мин.

...Эш болай тора: Мөслимә ападан әти турында мәгълүматлар алып кайткач, шатлыгымны күршем Тәмирлан белән уртаклаштым. Ул шунда ук инюрколлегия аша этине эзләтү хәстәренә алынды. Язды, шалтыратты, сөйләште. Анысы хак. Нәтиҗәдә, минем әтинең фельдмаршал туганнарыннан берсе булырга тиеш, кайда һәм ничек үлүе турында хәбәрләр юк дигән язу кайтарып тоттырды. Бу кәгазь кисәге безгә бик кыйммәткә төште. Без моңа ышанмадык. Шуңа күрә эзләнүләребезне үзебезчә дәвам иттек.

Хатыным Әлфиянең апасына кунакка Израильгә баргач, алар ярдәмендә эзләнүләребез шундый нәтиҗә бирде: Роммельләрнең шәҗәрәсе күп тармаклы. Бер тармагы – рыцарьлар – сугышчылар, икенчесе – галим – уйлап табучылар, өченчесе – музыкаль кораллар ясау осталары. Вензель тикшерү белгечләре безнең шул тармактан булуны раслады. Илгә кайткач, мин шул юнәлештә эзләнүләр алып барып, шактый табышларга ирештем. Күчерелгән халыклар музее оештыру буенча рөхсәт артыннан йөри башладым.

Тәмирлан каршы төшеп, миңа «фашист туганнары исемен мәңгеләштерергә йөри» дигән тамга суктырды. Рөхсәт бирмәделәр. Мин сүнмәдем, сүрелмәдем. Роммель фамилияле немесләрнең адресларын эзләтә башладым. Израильдәге белгечләр ярдәмендә табышлы булдым. ...Фельдмаршалның 1928 елгы бердәнбер улыннан беркем дә калмавын, Аргентинага барып чыккан энеләре Карл белән Герхардның опера җырчылары һәм стоматолог, сеңлесе Хеленаның музыка укытучысы булганлыкларын, балалары калуын белдем. Алар белән бәйләнешкә кереп, Рәсәйнең Энгельс шәһәрендә музей ачарга теләгем барлыкны, спонсорлар эзләвемне белдердем; фондыбызның реквизитларын җибәрдем...

Кыскасы, безнең фондыбызга юмартларча акча килә башлады. Читтә яшәүче немесләрдән генә түгел. Уругвайдан, Чилидән, Боливиядән – төрле милләтләрдән: ассириецлардан, греклардан, босниецлардан – ягъни, Советлардан җәбер күргәннәрнең токымнарыннан. Хәзер безнең фондыбызда музей яки кирха төзетергә генә түгел, кунакханә йорты, парк төзетергә дә хәлебездән килә. Проблема урын алуда. Саратов түрәләре бу мәсьәләне чишүне, төрле сылтаулар табып, юри сузалар. Идел немесләре автономиясен тергезүнең башы булмасын дип куркудан, элекке немес колонияләреннән бушап калган (әрем баскан) җирләрдән урын таба алмыйлар. Көләр идең – елыйсы килә. Янәсе, федераль органнардан рөхсәт әмере кирәк. Аның кайчан булуы билгесез. Без газеталарга да яздык, имзалар җыеп та җибәрдек. Берсеннән дә җавап юк...

...Синең эзләнүләрең хакында ишетеп белгәч, без сине попечительский советыбызга керттек. Фонд белән идарә итү составына кертү өчен дә, Мәскәүләр белән сөйләшү алып бару группасына кертү өчен дә ризалыгың кирәк. Аның өчен син фонд идарәсенә гариза кебек нәрсә язып бирергә тиешсең.

– Әгәр сезгә шулай кирәк икән – кертерсез. Әмма, дөресен әйтергә кирәк,

минем Мәскәүләр артыннан чабарга вакытым да, теләгем дә юк. Андагы чиновникларның һәр демократик чыгышта милли азатлык өчен көрәш чаткылары күрәчәкләре «ярылып ята». Ә нигә кызыгыз Матильданы бу эшкә җикмисез? Киявегезне? Аларның мондый эшләргә тәҗрибәсе дә, белеме дә җитәрлек.

– Анасы шалтыратып сөйләште. Фондның уставын җибәрегез, нигез капиталыгызның суммасын, функцияләремне әйтегез, уйлашырбыз, – дигән. Ризалашмавыдыр.

– Ничек тә бу эшкә аларны җигәргә кирәк. Матильданың таләпләре урынлы. Аны гаепләмәгез...

– Без бит партия түгел. Нигә кирәк гади максатлардан чыгып оешкан фондның уставы?! Без фондыбызның төп капиталын Израиль банкларында саклыйбыз. Максатчан суммада гына монда күчереләчәк. Шулай булмаганда, без бер кило кадак алырга да мондагы бюрократларга ришвәт бирергә тиеш булабыз. Төзелеш башланса, кадак белән генә эш бармас бит... Бу мәсьәләдә Рәсәй белән Сәмәрканд кануннары игезәкләрдәй охшаш.

– Гәрәй Рамилевич! Сез хаклыдыр. Минем Зәкәрия абзыйга биргән сүзем – әманәтем сезне табып, «таптым» дип аңа хәбәр итүдән гыйбарәт. Ниһаять, мин сезне таптым, таныдым, сөйләштем. Табылган документларның күчермәләре дә, фотолары да бар. Сездән дә нидер булыр, нидер өстәрсез дип өметләнәм. Безгә, әтиегез фотосы белән чагыштырып, охшашлыгыгызны дәлилләр өчен, сезнең фоторәсемне нотариуста раслатып җибәрсәк, минем миссиям – әманәтем үтәлгән була. Музей ачу мәшәкатьләрегезгә килгәндә, миннән әлләни ярдәм була алмас. Андый эшләргә катнашыр маһирлыгым да, җорлыгым да юк. Аннары... вакытым да юк. Болай да төп эшемне калдырып, күп йөрергә туры килде.

– Мәскәүдә Матильданы күреп, вазгыятьне аңлатсагыз, бәлки, акылга килеп, йомшарыр, безнең гадәләтне яклашыр иде.

– Әйе, аңа ситуацияне аңлату зыян итмәс. Әмма мирас турындагы фикерен үзгәртүне өстемә ала алмыйм.

* * *

Саратовтан Мәскәүгә самолёт билеты өч көннән соң гына булыр дигәч, поездда китәргә булдым. Анысын бер тәүлек көтсәм дә, үкенерлек түгел: Гәрәй абзый музейларын ачу өчен җыйган антиквариатларын күрсәтте, аларны кайлардан, ничек табуы турында сөйләде. Төрле тегү-чигү машиналарын, дивар сәгатьләрен саклар өчен гараж һавасының зарарыннан зарланды, аларның күпчелеге бердәнбер булуы белән мактанды. Күзгә күренеп торган шушы гамәлләре өчен генә дә мактауга лаек иде алар. Әмма мактау түгел, музей ачу өчен рәсми вәсика-документ кирәк иде аларга.

Китәр алдыннан дәстархан әзерләп, якын кешеләрен җыеп, мәҗлес үткәрделәр. Миннән кабат Зәкәрия – Роммель тарихын сөйләткәч, зәвык белән киенгән зыялы бер карчык, музей ачу өчен иганә йөзеннән, Америкада яшәүче улының фондка мең доллар акча җибәргәнен игълан итте. Кунаклар таралышкач, Гәрәй абзый бу карчыкның медицина фәннәре докторы Броун булуын, улының химия өлкәсендәге ачышлары өчен Нобель бүләге алуын сөйләде.

Үзебез генә калгач, Әлфия ханым миңа рәхмәт әйтеп: «Шундый мәҗлесләрдән соң, шундый милләттәшләр булуын белгәч, тагын бер гомер яшисе килә. Сезнең тырышлык белән табылган бу бәхет чынга ашса, ихтимал, яшәрбез дә», – диде.

– Ташламагыз безне, – диде, хатынының сүзен куәтләп, Гәрәй абзый, – эти белән очрашкан кебек булдым, рәхмәт сезгә.

Казанга Мәскәү аша кайтырга сүз биргән идем.

Поездларның Сызрань-Рязань юлы белән барганына билет хакы Тамбов аша йөргәннекенә караганда кыйммәтрәк тә, юлы да ураурак, әмма тиз йөрешле, имеш. Кайсына билет алырга белми икеләнеп торганда, кассирша, ашыктырып, сүгенә башлагач, чираты миннән соң булган тәкъва татар: «Сызрань аша барганы соңрак китсә дә, Мәскәүдә иртәрәк була», – дип икеләнеп торуымнан коткарды.

Киңәше белән кыенлыктан коткарган бу мосафирның билеты минем поездга булуы, баскычлардан менә-төшә буталмыйча, тиешле платформаны җай гына табуда да ярдәм итте.

Аның бу юлларда йөрү тәҗрибәсе һәр адымында күренеп тора. Әлбәттә, һәркем үз вагонына утырды. Минем билет купейный вагонга иде.

Кузгалып киткәч, өч сәгатьләр вакыт узуга, йокларга дип урын җәйгәндә, купема шул юлдаш мосафир килеп кермәсенме! Ресторанга чакыра.

– Сәгать ничә соң?

– Ничә булса да ачык.

– Миндә диабет. Ресторан ашы ярамый.

– Аларда кемгә нинди ризык кирәк – барсы бар.

– Соң бит инде. «Ятыр корсак ятыр, озакламый таң атыр», дигәндәй...

– Борчылмагыз, барысы да минем исәпкә.

– Мин намазга баскан, хәмердән баш тарткан кеше, – дидем, чалбарымны сала-сала, – сездән шикләнүдән түгел, йомышларым бик күп. Мәскәүгә аек барсаң да, йөри-йөри исерәсең.

– Мин бит сезгә исертәм димәдем.

– Ресторанга кергәч – эчми булмый, эчкәч – исерми булмый.

– Куркасыз?

– Мин – сәнгать кешесе. Фильм төшерү буенча килешүләр төзисе бар, мирас юллау мәсьәләсендә юристлар белән җитди сөйләшү көтелә, – дидем, сыйдан баш тартуыма сәбәпләрнең «важныйлыгын», үземнең дә «вип персона» булуыма ишарәләп. Тәкъва татар ялганыма ышанды кебек, ә минем аңа карата нindidер шигем уянды. Тавышы таныш тоелдымы, әллә кыяфәтеме – әйтә алмыйм. Әмма шигем уяну рас.

– Әрсезлек дип уйламагыз, тагын бер үтенечем бар иде, – диде ул, якыная төшеп.

– Нинди үтенеч?

– Саксофонымны сезнең карамакка калдырырга ярыймы?

– Ни өчен минем карамакка? Кондукторга калдырыгыз. Алар обязаны...

– Сезнең ышанычлы кеше булуыгыз йөзегезгә чыккан. Юл озын. Кондуктор урынында гына утырмый. Үзегез әйткәндәй, ресторанга кергәч, бераз «чирттерми» булмас... Алла «саклanganны саклармын», дигән. Калдырыйм, зинһар...

– Сез кем соң? Мин бит сезнең кем икәнегезне дә белмим.

– Минем сезне белүем җиткән. Сез Казанга кайтасыз. Кайчандыр мин дә Казанда Лундстрем оркестрында эшләп алдым, Кытайдан кайткач...

– Сез Кытайда булдыгызмы?

– Кайда гына булмадык икән без?!

– Хәзер кайда яшисез?

– Хәзер без – гражданин мира. Ирекле! Кавказы да, Мәвәрәеннәһере дә минеке. Җәйләрен туристлар белән теплоходта йөзәм, кышын рестораннарда биетәм.

– Ялгышмасам, без хәзер, җәй булса да, поездда барабыз, шикелле?! Теплоходта түгел, – дидем, сүзне беткәнгә санап.

– Теплоходка мин югарыдан түбәнгә акканда гына утырам. Кесәләре бушаган халыкка музыка түгел, тизрәк кайту кирәк.

– Арыган кешегә йокларга кирәк.

– Гафу итәсез. Сез «ит изгелек, көт явызлык» кешесе икән, абзый.

– Кайда сез миңа изгелек иттегез? Билет алгандамы?

– Адашкан чагыгызда, Сәмәрканд зиратында.

– Минем адашканым юк. Туры юл сорау адашу түгел.

– Шулай да саксофонымны калдырып торырлык танышлыгыбыз бар бит?!

– Кайда төшәсез?

– Бәлки әле сезнең белән Казанга кадәр барылыр. Анда да турист теплоходларының маршруты башлана ич.

– Кызыксынганым юк.

– Сезнең һәрнәрсә белән булмас, тик күп нәрсә белән кызыксынучан кеше икәнегезне күзләрегез сата.

– Ярый. Сатса сатадыр. «Бәладән башаяк», диләр. Калдырып торыгыз саксофоныгызны. Тик, рестораннан чыккач, йокыдан уятып йөрмәгез, иртән килеп алырсыз. Өстәл астына куегыз.

– Зинһар өчен, астыгыздагы багаж сандыгына! Үз тиңнәре арасында виолончель тавышлы Джерри Мюллиган эше бу саксофон.

– Миңа барыбер.

– Страдивариус скрипкасына тиң саксофон ясау остасы Мюллиган эше сезнең өчен барыберме?

– Кадерле нәрсә булса, иске капчыкта йөртмәс идегез. Беркем тимәс, ишекне эчтән бикләп ятармын.

– Рәхмәт, коллега.

– Мин сезгә коллега түгел, ә очраклы юлдаш. Әйткәнемчә, иртән килеп алырсыз.

– Аңладым.

Ә мин – ахмак, күземә ышанмыйча, алдануымның сәбәбен әлегә кадәр аңламыйм. Имештер, гел миңа гына кайчандыр, кайдадыр күргән кеше очрармы? Сызлаганчы тешләрен суыртучы да, чибәр Зәйтүнә белән бу музыкант та сюжет сырлансын өчен «махсус очрыйлар», диярсез. Юк шул, укучым. Шул очраклы очрашулар тәэсире кулдан каләмемне төшерми, язмамны дәвам итәргә этәрә...

Йокыга китеп, күпме ятканмындыр – купе ишеген ачарга маташуны сизеп:

– Мин бит сезгә уятып йөрмәскә куштым, – дидем.

– Откройте, милиция! – диделәр коридордан.

«Моя милиция меня бережёт» дигән ялганга ышанып яшәгән кеше буларак:

– Мне никто ничем не угрожает, я сплю, – дигән булдым, урынымда яткан килеш.

Шул арада мин аңламаган-белмәгән тылсым-кодрәт белән бикле ишек ачылып, пистолет тоткан ике милиционер купега керде; кондуктор белән янәшә баскан пижамалы пассажир: «Это вероломство, вы не имеете право ворваться в чужую квартиру», дип күкрәк кага башлады. Милициянең дүрт йолдызлысы,

пистолетын миңа төбәп: «Где саксофон?» – диде дә саный башлады: «Раз, два, три...» Өч йолдызлысы: «Если до тридцати не дадите – предупредительный выстрел, а тридцать один – на поражение!» – диде.

Пижамалы һаман «не имеете право!» дигәнен кабатлады. Мин исә, анымоны уйламыйча:

– Спросите у хозяина, он в ресторане, – дидем.

– Хозяин в мешке. Где его саксофон?

– Тоже в мешке, – дигән булдым, тавышымны акрынайтыбрак.

– Должен быть в футляре, – диде кондуктор, икеләнүле тавыш белән.

Тынлык урнашты. «18» дип әйткәч, санаучы офицер тукталып калды да кондукторга:

– Откуда вы знали, что в футляре саксофон?

– Из радиограммы, вашей...

– Значит, самого саксофона не видели?

– Если он в футляре закрыт, а футляр в мешке... как?

– Я тоже не видел, хозяин сказал, что инструмент как скрипка Страдивариуса.

– Но вы же утверждаете, что видели только мешок?

– Было темно, электричество выключили, вагон спал.

– Значит, не видя лица незнакомца, вы взяли от него мешок?

– Лица я его видел у кассы в Саратове.

– Предъявите ваши документы.

Документларның Рәшит Нуриевич биргәне шикләндердеме, нинди эш белән йөреп кайтуыма ышанмадылармы:

– Одевайтесь, вы арестованы, – диде дүрт йолдызлы офицер, – проверим.

Шуннан соңгы узган мизгелләр онытылган төш кебек кенә хәтердә.

«Саксофон» дигән җиз торба мини пакетларга салынган порошок белән тулы иде.

Аларның һәркайсын кечкенә бизмәннәрендә үлчәп, «пүнәтәйләр» алдында акт төзеделәр дә, һәркайсыбыздан кул куйдыргач, кондукторга:

– Сообщите вашему бригадиру – в Саранске вылезаем, – диде дүрт йолдызлы.

– У меня билет до Казани, – дисәм дә, мине ишетүче булмады.

Саранскка килеп төшкәндә, кояш күтәрелгән булса да, минем кояшым болыт астына кергән иде: сорау бирергә ярамый, тәкъдим кабул ителми, документлар алынган.

Милиционерның сул кулына богауланган «саксофонист»ны – аерым машинада, мине үзләре утырган «УАЗ»икта каядыр алып киттеләр. Тимер ишекләр ачылып, бер бүлмәгә кергәч, анда басып торган «музыкантка» күрсәтеп: «Бу кешене таныйсызмы?» – диде микрофон тоткан өч йолдызлы. Дүрт йолдызлысы дәфтәргә язып барырга кулына ручка алды.

– Кабатлыйм: бу кешене таныйсызмы? – диде татарча.

– Нигә баштан ук татарча сөйләшмәдегез? Үз телегездә сөйләшү хурлыкмыни?

– Ответьте только на вопрос: кто перед вами?

– Минем купега саксофонны сакларга калдырган музыкант. «Гражданин мира», диде, исемен әйтмәде. Туристлар теплоходында йөзәм, диде.

– Знаем мы его где он плавает: то в Термезе, то в Самарканде, иногда в Саратове и в Казани.

– Моңа кадәр очрашканыгыз бар идеме? Булса, кайда? Нинди шартларда?

Шунда музыкантның күзләре белән минем күзләр очрашты. Кайда очратуны әйтсәң, ни булыр да, әйтмәсәң ни була? Дәшмим. Сорау тагы кабатланды.

– Һич хәтерли алмыйм.

– Күрдегез, әмма кайда күрүегезне хәтерләмисез?

– Күрүемне хәтерләмим.

– Хәтерләмәгән дә, белмәгән дә кешенең әйберсен сакларга алып калгансыз. Ул сезгә нәрсә вәгъдә итте?

– Иртәнгә кадәр уятмауны вәгъдә итте.

– Димәк, беренче мәртәбә күрүегез поездда, купеда булды?

– Беренчесе дә, соңгысы да.

«Музыкант» «ха» дип куйды. Көлүе идеме, хуплавымы – аңламадым.

Шундый ук сораулар «музыкантка» да бирелде.

– Бу кешене таныйсызмы?

– Ялган сөйләүче булуын таныйм. Ул мине «музыкант», саксофонын сакларга калдырган «гражданин мира», диде. Карагыз минем кулга: саксофонда түгел, барабанда да уйный алмыйм мин!

Шунда мин аны, чынлап та, Сәмәрканд зиратында күрүемне хәтерләдем. Әйе! Биргән хәерне сул кулы белән алды. Әйе, уң кулының бармаклары юк иде! Бу турыда әйтергәме, юкмы! Әйтсәм ни була да, әйтмәсәм ни көтә? Баткакка кереп бата баруымны тоеп, курка калдым.

– Ярый, саксофонда уйнамыйсыз, ди. Башка вагоннан күчеп, капчык тотып килүегезне кондуктор күргән, – диде дүрт йолдызлы.

– Капчык тотып йөрү җинаятьме?

– Наркотик таратып йөрү җинаять.

– Сез «саксофон» кемнеке булуын, аны сакларга кем куюны ачыклагыз. Монда кондукторның кулы уйнавына шикләнәсе юк. Махсус оештырылган эш бу, – диде музыкант.

Сорау алу сәгатьтән артык вакыт дәвам итсә дә, музыкантның «уйный башлаган көе бозылмады», һаман «минеке түгел», «үзегез оештыргансыз»ны кабатлады. Бирелгән өстәмә сорауларга җавапларымда мин дә: «күрмәдем», «белмим», «белмәдем», «ишетмәдем» киртәсеннән чыкмадым.

Допростан соң «саксофонист»ны ябык машинада каядыр алып киттеләр. Мине тәрәзәсез бүлмәгә бикләп, тикшерүче килгәнче дип, хыялларым белән генә калдырдылар. Ә хыялларым исә «су бирерләр микән», «йокларга ярыймы икән» дигән уйлардан ары узмады.

Буяу исе бетмәс бүлмәдә унике көн «кыл иләктән иләнеп» «ял иттем». Сорауларга бирелгән җавапларның дөреслеген тикшерү шулай озакка сузылдымы, тикшерүчем тәҗрибәсез идеме – таможнячы Рәшит Нуриевич йомышы белән Дүшәмбе шәһәренә очканнан башлап, Саранскка төшкәнче ниләр булган, кемнәр белән очрашып, ни турында сөйләшенгәннәр язылган дәфтәрнең һәр битенә кул куйдырып, мөһерен басты да, дипломатына салып бикләгәч, миңа карап: «Наконец», – диде тикшерүче. «Наконец, эш бетте», дигәнне аңлата идеме, әллә «наконец, эләктең», дигән сүзе идеме – ничек аңларга белми икеләнгәч:

– Бу дәфтәргә язылганнарның күчермә нөсхәсе миңа бирелмимени? – дидем.

– Хөкемгә кадәр беркемгә берни бирелми. Эчтәлеге белән танышкач, «барсы да дөрес» дип раслап кул куйдыгыз – безгә шул җиткән.

– Миңа да суд булачакмы?

– Сез – төп «участник операции». Ә кем буларак катнашуыгызны хөкем карарыннан соң белерсез.

– Катнашым юклыкны сөйләдем ич инде.

– Шулардан баш тартмакчымы хәзер?

– Булганнарыннан ничек баш тартыйм?.. Бухгалтериядә тоткарлануымның чын сәбәбен сорасалар, ни диярмен?

– Анда барысын да беләләр. Билетыгызга сугылган штамплардан да аңларга була. Кирәксә, белешмә җибәрелер.

– «Музыкант»ны кабат очрату ихтималы бармы минем?

– Повторно эләгүе. Егерме елдан да ким бирмәсләр.

– Кызганыч...

– Рецидивист кызганычмы?

– Минемчә, гаеплене хөкем итүгә караганда, аны аклау юлларын эзләү саваплырактыр. Уникаль талант иясе ул.

– Сез аны милләттәш дип кызганасыз. Кем белән утырса, шуның телен өйрәнгән полиглот гагауз ул.

– Бөек артист булыр иде... Талант!

– Билетын тикшергәндә, кондуктор аның дүрт бармагы юклыгын шәйләп безгә хәбәр итмәсә, тагыниләр көткәнен чамаларга Шерлок Холмс зирәклеге кирәкмидер. Исән-аман котылуыгызга шатланып, кондукторга рәхмәт әйтегез.

– Ул да сезнең кешеме?

– Безнең эштә безнеке булмаган кеше юк. Сезгә дә рәхмәт.

Мине тынычландырыр өчен генә әйтелсә дә, хәлем тынычланырлык түгел иде. «Бухгалтериядә беләләр» дигән хәбәр дөньямны икегә бүлде: акка-карага, кайнар-салкынга, юмарт-саранга, яхшы-яманга. Яшәүне елга агышы белән чагыштырсак, ярларының берсендә – явызлык, икенчесендә – игелектер. Елга агарга тиеш, яшәү рәвеше шулай аның. Кешеләргә дә бер-берләрен юкка чыгарган ике көч уртасында өченче көч булып яшәргә кирәк: югалтып-табып, котыла-тотыла, биреп-алып, сөелеп-сүгелеп...

Мин бу күңелсез уйлар сазлыгына шул «саксофонист» белән «ЧП»дан соң кереп баткан булсам, аны Казан вокзалында Мәскәү-Дүшәмбе поездына утырганын күргәннән соң, тәмам чыга алмастай баткакка чумдым. Әйе, булды бу эш, күрдем – ышанмадым. «Булмас» диясем килде, «күрдем» дигәне җиңде. Кеше ышанмасны дөрес булса да сөйләмә, диләр. Үзем дә ышана алмаган очракка тукталып, тагы бер «колак» ясау ярамас. Әмма күрүем хак. «Дөньяда бер-берләренә охшаш йөзләр дә, бармаксыз-кулсызлар да очравы ихтималына ышаныйк та үз кыйссабызга кайтыйк. Хызыргаләйһиссәлам белән күзгә-күз очрашкан гөнаһлы бәндәнең күзенә тагы ни генә күренмәс тә, башына нинди генә уйлар килмәс!.. Уй килмәсә, дөньяда «хорафат» дигәне бар. Саташу, хыялланулар да кешенеке. Болардан тыш иң серле, иң мавыктыргыч «детектив» дигән һөнәр бар. Эше булгач, кешесе булмасмы? Күңелне шундый уйлар белән алдалап алга барыйк.

Мәскәүгә килеп төшүемнең «ялкынын» Матильданың Австралиягә очкан хәбәре сүндерде. Телефонда хаҗи – доктор тавышы иде:

– Әле тиз генә кайтмас. Бабасының каберен зиярәт кыласы, андагы гадлия органнарына керәсе, нотариуста варислык-мирас мәсьәләләрен ачыклыйсы бар. Кыскасы, эше күп, аны көтеп вакыт әрәм итүегез нәтиҗәсез мәшәкатьләнү генә булыр.

Гәрәй абзыйның Матильда белән сөйләшүе вәсика белән фотоларны Зәкәрия

абзый адресына салгач булганмы? Әллә Ата белән Ана йомшарып, кызларын гафу итеп, Австралиядәге чынбарлыкны белеп кайтуны аннан үтенгәннәрме? Бу мәсьәләгә оныкларының карашы ничек?

Казанга кайтуыма Мостафадан бандероль көтеп яту – яшәү маякларымны сүндереп, план-хыялларымны «челпәрәмә» китерде.

«Ике хат алдык. Берсе – Хәйдәр хәзрәттән, икенчесе – атказанган юристтан. Зәкәрия абзыйның әтисе кайда җирләнүне раслаган вәсикалар җибәргәннәр. Ике хатта ике зират күрсәтелү, үлү-күмелү көннәренең төрлелеге бу эштәге ямьсез бостанлыкны дәлилли. Нык борчылудан, Зәкәрия абзый сырхауханәгә кереп ятарга мәҗбүр булды. Тиз арада вазгыятьне ачыклаган хәбәр көтәбез. Мин хәзер вәкаләтнамәле васый. Без хәзергә Австралиядә үз вилаятебездә.

Тегеләрдән килгән вәсикаларның күчермә нөсхәләрен җибәрәм. Сәлам белән, инак Мостафа».

Уйларга баш эшләми, җавап язарга кулым бармый. Әйтерсең, җанымны паралич сукты. Учлап дару, бал белән мәтрүшкәле чәй эчеп, атна буе өйдә аунасам да, ныклы фикергә килә алмадым.

Шантажмы бу? Мошенниклыкмы? Уенмы? Әллә шуларның җинаятьчел кушылмасымы?

Дәрт-ялкыным сүнеп, ни кылырга белми ятудан файда юк иде. Эш урыныма барып, кайтканымны белдерергә, кайчаннан һәм нинди эшкә тотыначагымны ачыкларга кирәк иде. Эш кенә эзгә бастырачагына, борчылуларымны оныттырачагына өметләнеп, утыз ел эшләгән эш урыныма киттем. Тик анда күргән-белгән үзгәрешләрдән ни әйтергә белми телдән калдым: безнең телерадиокомпания икегә бүленгән: яңага һәм искегә. Мине яңасына яратмаганнар, искесенең исемлегендә калдырганнар, әмма штатымны бетергәннәр, чөнки минем эшләрнең кирәге калмаган, вакытка сыймый икән, Мәскәүнең әмере шулай, имеш. Һөнәремне кирәксез иткән үзгәреш хәбәрләре мине аяктан егып, больницага кереп ятара мәҗбүр итте.

– Безгә һөнәрчеләр түгел, күндәм кәсепчеләр кирәк, – диде замнарның яңасы.

Больницадагы табышларым шул булды: стресстан шикәр авыруы башлану белән «котладылар», аденома таптылар; йөрәкне, мае бетәр-бетмәс лампа януы белән чагыштырып, «филтәсен» алыштыру кирәклеген искәрттеләр.

Үлемнән ычкынып, больницадан чыккач, язмышым белән кызыксынып, янә «эшкә» дип барсам, мине инде оныткannар. Кайчандыр ярдәмчеләрем булып эшләгән кәсепчеләр минем белән сөйләшеп торудан «таешалар», кая кереп, кемгә дәшмим – читкә карап, яңа тәртипләр урнашуы, тапшыруларның продюсерлашып, ягъни тышлыгы алышынып, эчтәлектән котылу белән мактаналар.

Элекке кадрлар бүлегендәге «главный специалист» дигән сәер вазифа иясе, язмышымны ачыклау буенча сорауларыма җаваптан качып, минем «персонага» махсус органнар тарафыннан аерым игътибар булуын әйтеп «сөендерде».

Алардан теге яки бу резюме килмичә, статусыгыз билгесез, диде.

Статус – резюме – статус... Аңласаң – аңла, аңламасаң – шартла: нинди «резюме»? Нинди «статус»? Ни өчен «орган» гына түгел, ә «органнар»? «Нар» өстәлү «саксофончы» эше өстәлүне күрсәтәме?

Уемда да, күз алдымда да шул сораулар.

1964 елны театрыбызның Ташкент гастрольләре вакытында, «Комсомольское» дигән сулык буена кызынырга төшкәч, бер яшь артистыбызның киемнәрен урладылар. Шуннан соң аның (хәзергәчә) «су керү», «кызыну» дигән сүзләрне ишетүгә, аллергиясе башлана. Казалы булуы турындагы кыйссасын сөйләгәч кенә тынычлана. Ярты гасыр бер үк сүзне сөйли. Искә төшермә, зинһар, шуны, дисәң: мин төшермим, үзе төшеп җәфалый, ди.

Инде менә үзем шул хәлдә: кемне очратсам, минем белән «органнар» кызыксынуын сөйләп, ник икән дип сорыйм да теләктәшлек көтәм. Булмагач, инде менә колагым ишетми, күзем күрми, телем тотлыга башлады. Серләремне саклау авырлашкач, үзе дә «шулар» теңкәсенә тиюдән йөрәк чирлегә әверелгән сабакташыма тагы киңәшкә киттем. Гаебем юклыкка аны ышандырдым шикелле.

– Алар гаепне таба, анысы өчен борчылма. Синең кайчан, кайда нәрсә кылганың, гамәлләрең генә түгел, кайда ни уйлаганың да өстәп теркәлгән.

– Судка чакыру килер, диделәр, дәшкән кеше юк әле.

– Кычытмаганны кашымыйлар. Сугышырга әзерлегеңне белсәләр генә, син – шәхес, син – батыр.

– Алайса һәр батыр шәхес булып чыга?

Безнең татар егете Шакирҗанга кадәр кырык дүрт солдат шул ук батырлыкны кылган. Алтын йолдызны «Шакирҗан»нан «Александр Матросов» ясап, аңа тагалар. Тагын ике йөзләп солдат, шул ук батырлыкны кабатласалар да, Алтын йолдыз бирү кими башлый һәм гел туктала.

– Чөнки үлеп котылу массовый төс ала.

– Хикмәт анда гынамы икән?

– Төп сәбәп шул. Әйе, Матросов герой, әмма шәхесме ул?

– Рейхстагка җиңү байрагын кадаучы Гази булса да, Алтын Йолдыз грузин егетенә тагыла. Мин һәр батырны шәхес димәс идем. Әмма һәр шәхестә батырлык бар, дигәнгә кушылам.

– Геройларны хакимият билгели, шәхесне заман тудыра! Александр Невский да, Дмитрий Донской да – хакимият заказы белән тудырылган геройлар.

Сабакташым аша органнарда минем белән кемнәр кызыксынуы ихтималыннан чыгып, ике фамилияне ачыкладым да, телефоннарын белеп, шул көнне үк шалтыраттым. Беренчесе, рус фамилиялесе, җавап бирмәде. Икенчесе – Мир-Мирич дигән татар икән. Очрашу урынын ул үзе әйтте.

Җомга кичендә елга портына киттем. Үземчә күзаллап, китель кигән майорны эзләп йөрим... Эскәмиядә утыручы ак кәчтүмле ир-егет миңа исемем белән дәшкәч, ул икәнен аңлап алдым.

– Сез Мир-Миричме? Исәнмесез! – дидем.

– Тулы исемемне белсәгез дә, бусына да риза. Исән-саумысыз?

– Мине беләм, дидегез инде... Әйе... Мин шул бәндә булам.

– Сезне белмәгән татар юктыр.

Сүз шулай башланып, ресторанның кешесез бер почмагында дәвам итте. Заказ бирмәсәк тә, ике кружка сыра белән ике кипкән балык китереп куюдан, майорның монда үз кеше булуын аңладым.

– Эштән соң биредә булгалыйм. Монда аулак, тыныч.

– Сезнең өчен эш урыны кайда да аулактыр.

– Сез – сәнгать кешеләре – безнең ише плебейлар трактирыннан ерак йөрисездер? – дип, майорым мин биргән тонны кабул итмәвен сиздерде.

– Миндә диабет. Шунлыктан ашавымны мәҗбүр итмәскә тырышам.

– Ресторан күргәзмә урыны түгел, билгеле. Әмма Станиславский белән Немирович-Данченко театр төзү буенча ресторанда килешкәннәр.

– Без дә килешербез дип өметләнәм.

– Нинди мәсьәләдер бит.

– Мир-Мирич сыра эчте, мин балык чистарттым.

– Сырасын эчмәгәч, нигә әрчисез аны?

– Сезгә дип.

– Ләкин бит сез бәйсезлек турында вәгазь сагынып, вобла әрчергә килмәгәнсез?

– Сезне сагынып килүчеләр дә бармыни? – дидем мин, үзем дә сизмәстән бәхәскә керә барып.

– Яратмасалар да, эшебезнең кирәклеген белгәч, сагынучылар булгалый. Сагынмаучыларга да түзәбез.

– Ник соң күпчелек сездән һаман курка? Курку булган җирдә тигезлеккә урын юк бит.

– Бәхәсләшәсегез килә ахры?

– Без – «утопияләр» илендә тәрбияләнеп үскән буын.

– Ә хәзер реаль үзгәрешләр чоры. Утопияләр утоплены. Теләкләргә ирешү мөмкин чорда яшибез...

– Дибез. Ничек?

– Әйтик, депутатлыкка сайланып. Юлбашчы булырга да тулы ирек бар.

– Акчаң булса. Юк икән – акчалы белән дус булу кирәк.

– Анысын сез тапкансыз түгелме?

Шушы сораудан соң майорның Зәкәрия абзый тарихы белән, аның миңа йөкләнгән йомышлары – әманәте белән таныш булуына шигем калмады. Кемнәр «җиткерүен» чамаласам да, нинди максаттан чыгып «җиткерүләрен» белү кирәк иде. Сынау дәвам итте...

– «Саксофонист» операциясенә катнашыгыз юклыгы расланган. Сезгә «тагылган» Зәкари мәсхәбе дә яралгы хәлендә, бездә тамыр җибәреп, үрчү ихтималы юк...

– Шундый да мәсхәб бармыни?

– Аларның баш габиде белән шартнамәне сез төзегәнсез ич. Димәк, башлангычы бар.

– Кем белән шартнамә төзегәнмен инде мин?

– Шул мәсхәбнең башлап йөрүчесе – Башгабид белән, ягъни...

– Моннан да примитив яла булмас. Шуңа ышанасызмы сез?

– Ышансам, сезнең белән ресторанда утырмас идем, махсус бинаның яшерен бүлмәсендә сөйләшкән булыр идек.

– Шартнамә төзүем хак. Нимес офицерының Рәсәйдә туып үскән улын табу буенча. Самуэль атлы Австралия кешесе белән. Аның чын исеме – Зәкәрия, Казанныкы ул.

– Шуннан?

– Таптым мин Роммельнең улын! «Гәрәй Искәндәрович» исеме белән Сәмаркандта яши, бер кызы, оныгы бар. Кирәкле вәсикалар белән ныгытып, Гәрәйнең фотоларын салдым. «Алдым» хәбәре килсә, әманәтем үтәлгән була. Бары шул.

– «Биш миллион доллар салдык», дигән хәбәрне көтмисезме?

– Җибәрсәләр алырбыз, җибәрмәсәләр – гаепләү булмас. Әманәткә хыянәт итмәдем.

– Ә менә Гәрәй Искәндәровичның кызына ата-анасына хыянәт итү берни тормый. Бар эшен ташлап, бабасыннан калган мирасны үз исеменә күчертү буенча чаба.

– Дөрес эшли. Әмма аңа Австралиягә очарга кирәкми иде, әти-әнисе белән татулашу кирәк иде. Ата малы балага калмый кемгә булсын?!

– Ә ул сезгә калмасын өчен, сезне яманатлы итеп, әтисен Израиль шпионы итеп күрсәтергә маташа. Шуңа ялган материаллар җыя. Көлке түгел, юләр ул.

– Сезнең фирмага мөрәҗәгать иттеме?

– Безнең системада эшләп чыккан шәп юрист бар. Аңа килгән. Сезгә компромат эзләп. Аннары миңа...

– Сез, әлбәттә, таптыгыз инде?!

– «Юк», дидем ич: эзләсәк тә тапмадык.

– Алайса, минем статусым тиздән билгеле булачак?

– Үзегезнең кем икәнегезне белмисезмени? Сез – режиссёр.

– Сүз түгел – эш кирәк миңа! Аны сезнең кулда, диделәр.

– Эш булыр. Тик «Идел немесләре автономиясе»н тергезү оешмасы белән бәйләнешне өзсәгез...

– Беренче тапкыр ишетәм. Шуның өчен мине эшемнән мәхрүм иттеләрме?

– Эшләсәң – эш булыр, дим ич.

– Кайда? Сездәме?

– Тиздән республика мөселманнары мөфти сайлаячак.

– Сайлана торган вазифа түгел ич ул.

– Шулай хәл иткәннәр икән – сайларлар.

– Кемне?

– Кандидатлар бар. Һәркайсы үзенә фирка туплый. Яшерен дә, ачыктан-ачык та дим-дәлаләт, ягъни агитация эшләре алып баралар. Һәркайсына спонсор кирәк, акча ягъни.

– Кемне тәкъдим итәр идегез?

– Әгәр сезне дисәм? Коръәнне беләсез, Хаждa булдыгыз? Эчмисез, тартмыйсыз... Хатыныгызга хыянәттән куркасыз...

– Шаярмагыз.

– Биш миллион долларны «вакыф малы» дип Диния нәзарәтенә күчертәсез дә, амин-Аллаһ әкбәр, мөнбәр сезнеке.

– Мин сезнең белән шаярырга дип килмәдем, майор әфәнде.

– Депутатлыкка узмагач, монда да узмам, дисезме?

– Мин сезне, җитди урында утыргач, үзегез дә җитди офицер дип килгән идем. Рәхмәт сыегызга. Тәкъдим итәчәк кандидатыгызга Ходай – тел ачкычы, батырачак кандидатыгызга сабырлык бирсен.

Көннәрем әрәм узмасын дип, Мостафага (вазгыятьне аңлатып) хат язып салырга булдым. Аңарчы Мәхмүт абый белән Хәйдәр хәзрәтне күреп сөйләшергә кирәк иде.

Очрашу вакытын белгеләргә Мәхмүт абыйга шалтыратсам, атказанган юрист гаҗәпләнеп калды:

– Син өйдәмени? Эшеңнән, бездә эшләми ул, диделәр. Ни йомыш?

– Зәкәрия абзый йомышлары буенча сөйләшергә иде.

– Мин инде тиешле урыннарда булып, вәсикалар эшләтеп җибәрдем. Урынны барып карадым. Үзәк аллеядан ерак түгел...

– Кайсы зиратта?

– Бистә зиратында ук табарбыз дигәннәр иде, андый кеше өчен үзәк тә булсын дип тырыштык. Дәрәҗәле дә, ышанычлырак та. Мин Зәкәрия абзыйга: «Туфрагыңны җирләргә урын табарбыз», – дип сүз бирдем. Сүземдә торып урын таптым. Алла каршында да җавабым шул булыр.

– Аңа урыннан да бигрәк, этисенең каберен табу кирәк. Мин шуны, ничек кенә эзләсәм дә, таба алмадым... Зәкәрия абзыйга шулай дип ачыктан-ачык язып салыйммы? Алар миннән җавап көтә.

– Мин аңа туфрагыңны җирләрбез, дип вәгъдә иттем. Хәтерлисеңдер, аның әманәтен кем үтәсә, «отыш» шунда булыр, дип килештек.

– Бу бит ялган җиңү...

– «Табалмадык» дигән дөреслек язып, өлкән кешене җәрәхәтләүдән ни фәтва?

– Ул инде җәрәхәтләнүдән узган – больницада ята. Сез җибәргән ялганнардан яраланып. Дөресен әйтеп языйммы?

– Без җибәргән хәбәрләрдән җәрәхәтләнгән булса, син язган дөреслек аны үтерәчәк. Кайсын сайлыйсың – шулай эшлә...

Сөйләшү өзелде, телефон трубкасы куелды. Атказанган юристның «файдалы» ялган белән Зәкәрия абзыйның гонорары өчен генә тырышуы ачыклангач, аның белән сүз көрәштереп торудан мәгънә юк иде.

* * *

– Нигә икәнен әйтмәдеме?

– Сине чакыргач, миңа ник әйтсен икән? Үзеңә генә әйтер сүзе бардыр. Озак йөрмә, маргарин салып ашарга солы боткасы пешердем.

– Анда хәзер ике хуҗа. Кайсыныкы чакырды?

– Эше булса, кайсына да ярамыймы? Икесенә дә кер!

Элекке эшемә килеп, «секретётка» ханым каршына бастым, күрештем. Елмаерга тырыштым.

– Сиңа Ташкенттан хат бар, «заказной». Мә – тот!

– Ташкентта беркемем дә юк бит минем.

– Белгән кеше булганыңа күрә генә алып калдым инде, моннан соң шәхси хатларыңны өй адресыңа җибәрсеннәр, син хәзер безнең штатта түгел. Гаеп итмә.

Сүз арттырудан фәтвә юк иде. Хатны кулга алып, саклык белән генә ачтым... Ташкенттан булса да, җылытыр хәбәрләр юк иде. Хәтта, киресенчә, өскә чиләге белән бозлы су сипкәндәй, суыксытып җибәрде, күз алларым караңгыланып, башым әйләнеп киткәндәй булды.

Үземне ничек кирәк, алай «кулга алып», урамга чыгарга ашыктым. Хатны укып чыгу бер эш булса, аны тиешенчә аңлау башка эш иде: «...Мине дә, үзеңне дә котлый аласың: теләгемә ирешәм бугай. Күптән көткән бәхетемне сакларга акушерство үзәгенә Ташкентка килдем. Атна-ун көн ятылыр, диделәр. Шатлыгым белән уртаклашырга көндәшемә шалтыраткан идем, ул кайгысы белән уртаклашты: Термезда вагонга товар төяткәндә, Тәмирланны кулга алганнар. Үз кешесе саткан. Кем сатса да, ирек яулавыма юл ачык. Әмма минем исемгә язылган күчемсез малны ташлап китү үз-үземә хыянәт булыр. Син нинди киңәш бирсәң, шуны үтәргә әзермен. Гәрәй абзыйлар кайттылар. Тормышларында зур үзгәреш булу көтелә. Матильдаларын каядыр җибәргәннәр иде, әйләнеп кайтканын күрмәгәч, нинди эш белән йөрүен белмим. Татуланышулары сизелә. Әлфия апа көндәшемә сине чакырырга ниятләре

булуын әйткән. Ризалашма. Синең ярдәмгә без дә бик мохтаҗ. Адресыңны төгәл белсәм дә, квартира алырга җыйгам акчамны «до востребования» дип махсус җибәргән идем. Эшләр болайга киткәч, алмый торуың дөрес булыр. Тик ятмасын дисәң, үз кирәгеңә тота аласың. Вакытлыча. Бер җай чыгарып, үзең килеп китсәң иде. Гаиләңне ташлама, туачак бәхетемне дә ятим итмә. Мин ирле килеш тол яшәргә күнеккән инде. Җайлашырбыз. Сиңа ышаныч белән: Сәмәрканд бәхетлесе».

Хатны мөмкин кадәр вак кисәкләргә ерткалап ташласам да, тәэсиреннән туган каршылыклы уйларны ерткалап җилгә очырып та, суга агызып та булмас иде. Шантаж гына түгелме бу? Провокацияме? Товар төяткәндә кулга алганнар, имеш. Димәк, кондәшләргә ирләренең кәсебе алдан ук билгеле булган? Әгәр шуны миңа белдерүдән курыкканнар икән, димәк?.. Групповой җинаять бит бу?..

«Димәк»ләргә җавап эзләгәнче, почта бүлекчәсенә киттем. Алырга дип түгел, белергә, чынлап та, сүзендә торып, фатир алырлык акча җибәргән булса, ул бит хәләл акча булмас... Бусы – хатны укудан соң туган сорауларга бер җавап. Интрига өчен булса – икенче төрле җавап сорала.

Почта бүлекчәсенә, чынлап та, акча килгән иде. Ул аны көндәшеннән хәбәр ишеткәнче салган булырга тиеш... Әгәр бу акчаны алсам һәм үз кирәгемә куллансам, мин – «соучастник», ягъни җинаятьчел төркемдә катнашкан кеше булам түгелме? Ә инде алмасам, коллыктан котылырга теләп миңа ышанган кешегә хыянәт иткәндәй килеп чыга. Нишләргә? Икеләнү-шикләнүләремнән оператор ханым коткарды:

– Безнең почта кассасында бу кадәр суммада акча булмый. Заявка бирербез, әзерләрбез.

Рәхмәттән башка сүз таба алмадым.

Әзерләүләренә ышансам да, көтмәгәндә килеп чыккан бу хәлгә ышану да мөмкин түгел иде. Четерекле хәлләргә тарыганда, хатыным белән киңәш кылып котыла торган идем. Бу очракта аңа дөреслекне әйтсәм, болай да киеренкелектәге тормышыбыз чатнап кына калмас, челпәрәмә килеп уалыр кебек тоелды.

* * *

Миңа кадрлар бүлегенә кереп, хезмәт кенәгәмне алудан башка чара калмады. Аның соңгы битенә: «Уволен в связи с ликвидацей ГУ ГТРК «Республика», пункт 1, статья 81 Трудового кодекса РФ», дип язылган иде. Бу әмердә мине иң гаҗәпләндергәне эштән бушатылган көннең туган көнемә туры килүендә иде. Димәк, уйлаганнар, исәпләгәннәр. Шунысына рәхмәт.

Кемгәдер үпкәләп, төшенкелеккә бирелеп йөрүдән статусым үзгәрмәячәк, нинди дә булса эш табарга кирәк иде. Мунчага бергәләп йөри торган күршем – пенсиядәге милиционер дустым, аскы урамдагы балалар бакчасына төнге каравылчы кирәклеген әйтте. Акчасы әлләни булмаса да, башка эш тапканчы, эшләп торырга булдым. Укыйсыңмы, язасыңмы, сурәт ясап утырасыңмы – төн синеке. Кухнясында иртә-кич ашарлык ризык калдыралар, телевизоры да, телефоны да минем хозурда. Әдәби әсәрләр укып, болай да ярсыган йөрәкне «җилкендерәсе» килмәде, татарчага тәрҗемә ителгән Коръәнне өйрәнә башладым. Атна-ун көннәр үтеп, җаным бераз тынычлана төшкәч, телевизор кабызсам: «Киләсе җомга кичендә мөфтилеккә өч кандидат катнашында телевизион диспут булачак, сорауларыгызны телефон аша да, язмада да бирергә мөмкин», – дигән игълан ишеттем.

Күңелне көнчелек хисе «кытыклап» узды. «Эх, үзем булсаммы!» дигән уйдан узылмаса да, сорауларны телефон аша җиткерергә ниятләдем. Хаҗ вакытында шәехкә язып биргән сорауларның һәммәсе хәтердә иде. Шуларны «сипләп», яңартып, бераз үзгәртеп яздым да, телефон номерларын җыйдым.

– Бер кешедән – бер сорау, – диде дежурда утырган кыз тавышы.

– Безнең сораулар коллектив исеменнән! – дидем үҗәтләнеп.

– Почта аша җибәрсәгез, өлгермәячәк. Үзегез китереп бирсәгез, сораулар папкасына салырбыз, дигән җаваптан канәгатьләнеп, икенче көн иртәсендә (кеше эшкә килә башлаганчы) телевидениенең проходноендагы почта тартмасына илтеп салдым.

Түземсезлек белән җомга кичен көтеп алдым. Дөресен әйтим, көтүем әрәм булмады. Диспутны, өч кандидатка егермешәр минут бирелгән вакытны кушып, бер сәгать эшләгәннәр. Җаваплары, нотык-чыгышлары, нигездә, шул мин язып биргән сорауларга җаваплар иде. Күпчелек җавапларны миңа таныш булмаган яшь хәзрәт бирде, юрист Мәхмүт абый да, подполковник Хәйдәр хәзрәт тә, оппонентларын дөресләгән кыяфәттә, баш кагып, «әйе, шулай, дөрес» дип утырудан узмадылар. Бу моназарада, ягъни диспутта яшь хәзрәтнең җиңүенә куанып кына калмадым, телефон аша рәхмәтемне дә белдердем.

Иртән дәртләнеп кайтып керүемне хатынымның кәефсез каршылавы сүрелдерде:

– Юк-бар сорауларың белән борчыма, дияргә яратсаң да, әйтергә мәҗбүрмен, сиңа телеграмма бар, чит илдән.

– Кемнән?

– Син бит карамаска, укымаска куштың, карамадым, ачмадым.


– Оныт шундый ваклыкларны.

– Тел ярасы онытылмый шул.

Телеграмма Мостафадан булып, хәбәрләре дөньямның астын-өскә әйләндереп ташлады: «Матильда белән очрашудан соң кинәт кенә Зәкәрия абзый мәрхүм булды, мөселман зиратына җирләдек. Шартнамәгез буенча, «Кеше эзлим» дигән фильм төшерергә тиешсең икән. Тиз арада фильмның бер күчермәсен салып җибәрсәң яисә үзең килер булсаң, түләү операциясенә керешер идек. Бу эшне үзәк банк белән килешүсез эшләп булмый. Килешү дәүләт органнары соравы буенча гына эшләнә, ди. Сездәге тәртип ничектер, бездә Үзәк банктан килешү алмыйча, чит мәмләкәткә акча күчерү тыела. Мондагы кагыйдәләрне үзгәртү дә, законнар таләбен үтәмәү ихтималы да юк. Ышаныч белән җавап көтеп, васый – варис Мостафа».

Ни кылырга икәнен белмәүдән, мин шушы әсәрне язарга утырдым.

Үзәк банкларга йөрүдән дә, төшерелгән фильмым юклыктан да, бәлки шушы бәяным коткарыр. Әллә инде, бернигә карамый, Сәмәрканд гүзәленең фатир акчасын алып, фильм төшерә башларгамы? Шул турыда киңәшләр көтеп калам.



Ләбиб
Лерон

# БЕР ЯШИСЕ ИДЕ КЕШЕЧӘ

## Яхшылык

Бер яхшылык эшлим әле, дисәң,
Кылыйм әле, дисәң, игелек –
Тома ятимнәргә назлы сүз әйт,
Башларыннан сыйпа иелеп!

Бер игелек кылыйм әле, дисәң,
Сөяк-санак биреп киткәлә –
Бу дөньядан җылы эзләп йөргән,
Ышык эзләп йөргән этләргә!

Бер яхшылык эшлим әле, дисәң,
Үткәнеңне барла иң элек:
Шәҗәрәңне, мирасыңны барла –
Меңе белән кайтыр игелек!

Бер игелек кылыйм әле, дисәң,
Киткәннәрне һич тә онытма.
Үзеңне дә һәрчак истә тотар
Газиздән дә газиз оныклар!

Бер яхшылык эшлим әле, дисәң,
Кылыйм әле, дисәң, игелек...
Ак чәчәкләр булып гамәлләрең
Дөньялыкта калсын сибелеп!

Бер игелек кылыйм әле, дисәң,
Эшлим әле, дисәң, яхшылык –
Күңелеңдә газиз анаң булсын –
Адаштырмас сине Яктылык!

Бер яхшылык эшлим әле, дисәң,
Кылыйм әле, дисәң, игелек...
Иң әүвәле КЕШЕ булып яшә,
КЕШЕ булып кал син иң элек.

---

Ләбиб ЛЕРОН (1961) – *шагыйрь, прозаик, драматург; «Сине генә сөям», «Сөяксез тел», «Бәхеткә биш минут кала» һ.б. исемдәге күпсанлы китап авторы. М.Җәлил исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Йокысызлык

Бүген мине йокы җиңәлмәде...
Бер ялгызым төнгә керәмен.
Куанычтан дөньям – мөлдерәмә:
Шигырь эчәм – кайнар перәме!

Чыдап булмый һич тә шау тынлыкка! –
Күзләр түгел, йөрәк камаша...
Өзгәләнә эчтә ак яктылык:
Рифма белән рифма даулаша.

Тар бүлмәмдә бүген  шигырь төне:
Әллә кайдан сүзләр коела.
Куанычтан дөньям иркәләнә –
Әйтерсең лә  кояш коена.

Беркем күрми минем шатлыгымны,
Таңга каршы салмак төн ага...
...Тәүге аваз салып, исем-атсыз
Шигырь туып килә дөньяга...

## Чеховка кайту яки Ротшильд эскрипкәсе

Алдан хәбәр биреп тормый гына,
Кайттым әле Антон Чеховка:
Җылы эзләп, гәптәш эзләп кайттым,
Чит учакка кайттым – чит утка!

Таганрогның бер тар тыкрыгында
Без йөрибез икәү гәпләшеп...
Әллә колак  ялгыш ишеттеме –
Кемдер әйтте сыман: «Чәпләшке!»

Татарлыгым йөземә чыккандыр шул:
Шулай диюләре ихтимал.
Аннары бит... Чехов заманасы...
Каян килсен безгә ихтирам?!

Әле... СССРны узасы бар,
«Гололобый» булып ничә ел...
Без һаман да бөек халык түгел,
Шул ук «кече туган» – кичәге...

Азатлыкның әле исе дә юк,
Күренгәне дә юк ирекнең...
(Әкрен генә күтәрелгән чагы
Дәрәҗәсе чәшке бүрекнең!)

...Нинди хикмәт белән килеп чыктык
«Чехов базары»на – Казанга...
...Бер кинәндек халык арасында –
Азык эзләп йөрдек язарга!

...Кайсылары сыер теле ала,
Кемдер ала чучка колагы...
...Ишетелде шулчак бер кырыйда
Ротшильд эскрипкәсе[1] елавы.

## Бер яшисе иде чын-чынлап...

*Күптән инде, күптән яшәгән юк…*
Н.Акмал

Уянасы килә, уйланасы –
Арынасы килә чылбырдан…
Күптән инде, күптән яшәгән юк,
Бер яшисе иде чын-чынлап…

Алхимиклар ярдәм итә алмас –
Олыгаермын, әмма яшәрмәм…
Умырыплар ашаган бар ансы,
Яшәгән юк әмма, яшәгән!

Өсләр бөтен, тамак тук шикелле,
Акча да бар кебек өлешчә.
Тыйнак кына, җыйнак кына итеп,
Бер яшисе иде кешечә!

Ничәмә кат чирдән терелгән бар,
Юкса, күпме генә яшәлгән…
Җирдә яшәү насыйп булмый икән,
Үлгәч кенә кала… яшәргә!

## Мәңгелек өн

Оныттырмас өчен йолдызлар бар,
Сагындырыр өчен таулар бар, әй.
Исләреңә синең мин төшәрмен
Кар яуганда, яңгыр койганда, әй.

Оныттырмас өчен сурәтләр бар,
Сагындырыр өчен хатлар бардыр.
Әйтелмәгән күпме вәгъдәләр бар,
Үтәлмәгән күпме антлар бардыр.

Мин бик әйбәт кеше түгел ахры,
Актан да ак була алмадым шул.
Төшләреңә керә-нитә калсам,
Ак кәчтүмнән була алмамын шул.

Язлар булып яки көзләр булып,
Керермен дә синең төшләреңә,
Бик сак кына орынырмын, яме,
Пар алмадай ап-ак түшләреңә.

[1] Ротшильд эскрипкәсе – А.П.Чеховның шул исемдәге хикәясенә ишарә. *(Автор искәрмәсе.)*

Ничек бармын, шулай керермен мин
Сафтан да саф, керсез төшләреңә.
Пакь сөюдәй ап-ак юрганыңны
Ябармын мин синең өсләреңә.

...Онытмырмас өчен хәтерләр бар,
Сагындырыр өчен булыр уйлар.
Минем белән бәйлениләр булса,
Төшләреңдә синең булыр шулар.

Үз тормышым үзем корган идем,
Үзем җыйдым тәүге бу дөньямны...
Бүген менә шундый шигырь яздым,
Ачуланма инде мине берүк, яме…

## Кара Шәм

Үткәнгә борылып карасам,
Хәтердә яңара Кара Шәм[2].
Фаилнең авылы, нигезе...
Бишеге!
(Әйтергә яраса?!)

Кара Шәм!
Кем кушкан исемдер?
Белсә тик, бер Алла beләдер...
Кара Шәм – язучы авылы,
Кара Шәм – шагыйрьнең биләве.

Кара Шом түгел бит, Кара Шәм! –
Шулай дип әйтергә яраса...
Тарихта мәңгегә калачак
Ак шагыйрь һәм бишек –
Кара Шәм!

## Бер дус исән әле

Олыгаела. Гомер үргә бара…
Исән килеш дуслар... үлә бара.
Бигрәкләр дә сәер заман килде –
«Чын» дуслыкны күпләр түләп ала.

Дуслык булган чакта рәхәт иде –
Шул булганы өчен рәхмәт инде…
Исән килеш дуслар үлеп бара –
Акча дигән олы зәхмәт җиңде.

Исән килеш дуслар үлеп бара…
Димәк, мин дә үлгән – алар өчен!
Димәк, мин дә исән килеш – вафат!
(Нәрсә җитми моны аңлар өчен?!)

Исән килеш дуслар үлеп бара…
Олыгаела. Гомер үргә бара…
Сөен, Шагыйрь! Бер дус исән әле:
Ул да булса – Шигырь... Түргә бара!

---

[2] Юмор остасы, шагыйрь һәм язучы Фаил Шәфигуллинның (1939-1982) туган авылы.



Сирень
Якупова

# ЯТИМ ЙОРТ

хикәя

Ятимлек ни ул? Балачактан әти-әнисез, яклаучысыз-саклаучысыз калып, язмыш суыкларында туңып, ялкыннарында янып, куырылып үсеп балигъ булу дияр иде уң як күршебез Минзифа. Ятимлекме?! Аһ, ятимлек ул, өч балаңны җил-яңгыр тидерми, иркәләп-сөеп үстереп кеше иткәннән соң картлык көнеңдә ялгыз башың тилмерүде-е-р... Монысын сул ягыбызда гомер иткән Галимәттәй әйтер иде. Ятимлек ачысын берни белән дә үлчәп тә, аңлатып та булмый. Аны үзе татып караган гына белә... Акыллы, сабыр хуҗам Хәдичә авыр сулап шулай җөпләп куяр иде... Иде дим... Чөнки аларның берсе дә бүген исән түгел. Ә мин менә картайган, чалшайган булсам да, җан асрыйм әле. Син кем буласың соң, диярсез. Ни, нәрсә буласың соң, дип сорагыз. Мин – илле яшьлек, әй, илле еллык авыл йорты. Бушап калган ятим йорт... Җан асрыйм, дидемме? Дөресе дә шул. Гәүдәм агачтан, түбәм калайдан, күз-йөзем пыяладан булса да, сызлана, моңлана белгән җаным, сукрана, куана белгән йөрәгем, сизгер, бик тә сизгер күңелем бар минем. Әнә моннан биш ел элек бердәнбер кызы бик үгетләгәч, Сарытау якларына яшәргә китәргә ризалык биргән Хәдичәнең үлеме турында миңа беркем дә хәбәр итмәде бит. Җаным сизде, күңелем тойды. Май иртәсе иде. Ян бакчадагы сиреньнәрнең шәмәхә дулкынлы диңгезне хәтерләтеп шаулап чәчәк атып утырган мәле. Ышанасызмы-юкмы, кинәт чәчәкләр төсен үзгәртте, таҗларын түбән иде, «диңгезем» каралып калды. Минем бүрәнәләрем дә кысылып куйды, бөтен тәрәзләрем, ишекләрем белән мәңгелеккә югалтуның җанны сытарлык авырлыгын тойдым шикелле. Сабыр гына бер көн, бер төн көттем. Хуҗакаемның гәүдәсен туып үскән, сиксән бер ел гомере үткән авылына алып кайтырлар, якын зиратка әнисе Миңсорур янына җирләрләр дип уйладым. Капкаларны тутырып ачарга әзер торыгыз дип, таң җилләрен кисәттем. Тик юкка... Гаепле кешедәй башын иеп, Хәдичәнең туганнан туган энесе генә ачып керде ишегемне. Яшел сандыктан апасының үлемтекләрен алып чыгып ак машинага салды да, ирле-хатынлы якын күршеләрне утыртып, ерак юлга

Сирень ЯКУПОВА — *шагыйрә, прозаик; «Йолдызлы уйлар», «Яшәү сере», «Кар юлы» исемле китаплар авторы. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

кузгалды. Нишлисең, язмыш... Бердәнбер баласы, оныклары янында каласы килгәндер мескенкәемнең... Соңгы әманәте шул булгандыр.

И-и-х, бу юлысы бигрәкләр дә китәселәре килмәгән иде! Үлемнең салкын сулышын тойгач та, туган йортыма кайтып, үз ятагымда җан бирер идем дип ыңгырашкандыр бичаракай. Аралар бик ерак шул – алты йөз чакрым, алты йөз...

Исән-сау чагында, ерак араны якын итеп, елга ике-өч мәртәбә барып кайтыр иде Хәдичәм газизләре янына Сарытауга. Бик тә күңелсез булып кала иде миңа ул киткәч. Ике көнгә бер күрше кызы кереп, гөлләргә су сибеп чыга да соң. Ай күрде, кояш алды дигәндәй... Түзә идем. Чөнки белә идем, бик тиздән хуҗам туган нигезен, туган йортын, ягъни мине, өзелеп сагынып кайтып җитәчәк. Мин ташланмаган, мин ятим түгел. И аның капка тоткасын бәйләгән әлүмин чыбыкны кабаланып сүтүләре, өйалды ишегендәге кечкенә, үзе әйтмешли, «фасун» өчен генә эленгән йозакны ачып, болдыр баскычыннан менүләре, бисмилла укый-укый бусагамнан атлап керүләре, чиксез ярату, җирсү белән мөлдерәмә тулган яшьле күзләренең һәр почмагымны сыйпап, барлап чыгуы! Аннан чәй табыны әзерләү, бер-бер артлы күрше-күлән, туган-тумачаның хәл белергә агылуы... Дөресен генә әйткәндә, бездән беркайчан да кеше өзелмәде. Яшермим, шушы хәлгә ишек-идәннәремнең зар елаган чаклары да булмады түгел, булды: берсе лап-лап атлый, берсе дөп-дөп дигәндәй, берсе ишегемне каерып ача, икенчесе бар көченә шапылдатып ябып куя. Түз генә! Инде менә аңлыйм, бик бәхетле вакытлар булган икән лә ул! Хәзер айга бер тапкыр да капка келәсе күтәрелми. Ишегалдын кычыткан, әрем, өрәңге басты. Кайчандыр тыйнак матурлыклары белән җанны иркәләгән сиреньнәр дә әллә нишләде. Тәмам аздылар, әрсезләнделәр. Чәчәк атуларының гел рәте-чираты юк. Әллә минем кебек картайдылар, әллә ялкауландылар. Хәер, алар да ятим бит, ятимнәрдән ни көтәсең...

Менә тагын бер таңны аттырдым. Дүрт тәрәзәм дә кояш чыгышына карап торганга, алсу нурлар иң беренче булып күптән юылмаган, тоныкланып калган пыялаларыма төшә. Эчке якка үтеп керә алмый алар, әллә сагыштан, әллә вакыт тәэсиреннән сап-сары булып калган челтәр-пәрдәләр гел тарттырылган килеш. Эх, ачучы булсамы! Идән такталарында, акка буялган бүрәнәләремдә «кояш куяннары» биешер иде. Алар тыпырдаудан кузгалган кояшлы тузанга карап булса да күңелем күтәрелеп китәр иде ичмасам. Юк шул, юк. Ник бер адәм заты керсен. Үтәләр дә китәләр, үтәләр дә китәләр. Ара-тирә миңа караш ташлыйлар ташлавын. Кем кызгана, кем бәяли дигәндәй...

Әлләү! Әйттем исә кайттым, Түбән урам Ралия төпчек малае Әмир белән туп-туры миңа төбәп киләләр түгелме?! Билләһи, миңа таба киләләр! Әнә капка келәсен чыңлаттылар, ачтылар, ишегалдына керделәр. Керделәр дә туктап калдылар. Як-якларына караналар... Кулларында көрәк, балта, чалгы. Ни кылырга җыеналар болар, уйларында ни?! Әллә, Алланың рәхмәте, кычыткан-әремнәргә, өрәңге үсентеләренә каршы орышка чыкмакчылармы? Сөйләшәләр, тыңлыйм әле.

– Карале, әни, икебез генә булдыра алырбызмы икән? Монда урман-чытырман бит. Джунгли!

– Әйдә, бисмилла әйтеп башлыйк, улым. Иртәгә апаңнар да кайтып җитәр. Бөтенебезне түләүсез ялга җибәрделәр дип шалтыраттылар.

– Син аларның бу өйгә кайтып торачакларына ышанасыңмы?

– Ник ышанмаска? Пенсиягә чыккач, очыртып кайтырлар. Мәктәпне бетергәч, очып чыгып киткән кебек.

– Кайчан була инде ул?!

– Тә-ә-әк... Апаңа ел ярым, җизнәңә өч ел калып бара бугай. «Эһ» дигәнче үтә дә китә ул вакыт. Сизелми дә.

– Аңа тиклем җәйләрен ял көннәрендә монда яшәрләрме?

– Шулай диделәр ич! Үз теләкләре. Авызларына сугып әйттермәдем. Туган җир тарта ул, улым. Магнит кебек. Белерсең әле.

– Мин авылдан китмәячәкмен!

– Барысы да шулай әйтә. Тик аттестат алуга, выжт шәһәргә! Башта укып һөнәрле булам да кайтам, ди, аннан бераз эшләп алгач кайтырмын, дип үз-үзен алдалый, аннан өйләнә йә кияүгә чыга, аннан балалар туа, аннан тегесе-монысы... Шулай итеп, чит җирләрдә гомерләре үткәнен сизми дә калалар... Йә, улым, башлыйк булмаса, бир чалгыны.

– Чалгы үземнеке! Әнә синең урагың бар.

Үз колагыма үзем ышанмыйм! Кайталар ди бит! Яшәргә кайталар ди! Тә-ә-к, документ буенча мин – Ралиянеке. Тик аларның таштан салынган хан сарае сыман үз йортлары бар. Димәк, үксез баланы асрамага алган кебек, мин – ятим йортны башка берәүләр асрамага алмакчы! Кемнәр икән? Нинди кешеләр? Апаң, дидеме әле? Болай булгач, күргән-белгән кеше булып чыга бит инде. Авылыбызныкы. Түбән урамныкы. Иртәгәгә чаклы ничекләр түзәрмен, ә? Карале ничек эшкәябыштылар. Әбәткә тиклем ишегалдын ялт иттереп куячаклар бу уңганнар. Ян бакчага керерләрме икән? Коймаларны буяр булсалар, куакларны җәлләми кыркырга кирәк. Үсә ул куак, беркая да китми. Тамырлары җирдә бит! Тамырлар сау булганда, куркыныч түгел лә ул...

Сөбханалла, булса да булыр икән әнисенә охшап олыгайган бала! Тач Мәдинур инде менә. Хәдичәнең ахирәтен әйтүем. Ул йөзе, гәүдәсе, атлап йөрешләре дисеңме. Исеме дә исемә төште үзенең – Гөлсинә! Мәдинурның телендә гел шул кызы иде бит. Гөлсинәм бишлегә генә укый, Гөлсинәм тегә, Гөлсинәм чигә... Соңрак, Гөлсинәмә хат яздым, Гөлсинәләр кайтып китте... Гөлсинәләр нишләптер озак кайтмый...

Аңлагансыздыр инде, төне буе керфек тә какмый тагын бер таңны аттырып, булачак хуҗаларымны каршы алуым. Киләләр бит, киләләр! Иң алдан Әмир улым җилдерә. Бераз арттанрак Гөлсинә һәм озын буйлы, чандыр гәүдәле ир-ат атлый. Монысы тәгаен Гөлсинәнең хәләле. И карый инде ерактан ук миңа зәңгәр күзләрен тутырып. Тәвәккәл кешегә охшаган үзе. Кире уйламас, иншаллаһ. Ирле-хатынлы икесенең өстендә дә карасу зәңгәр төстәге кием, баш киемнәре дә шул төстә, ниндидер рәсеме дә бар, әллә ат төшерелгән шунда. Ат кебек эшлибез дигәнгә ишарәдер инде бу. «Списовка» дип атала бугай мондый күлмәк-ыштаннар. Безнең авылда да бик күп хәзер шундыйны киючеләр. Төсләре генә икенче – яшел, «татнифет» дигән язуы чекерәеп тора. Их, гөнаһ шомлыгына, кояш та болыт артында бит әле бүген. Нурлары тәрәзләремә, түбә калаена төшеп уйнакламый. Бераз матуррак, күңелгә ятышлырак булып күренер идем диюем. Хәер, буяулары тоныкланган кәрнизләргә, бик күптәннән чишмә суы белән йөгертелеп юылмаган тәрәз күзләренә кояш нуры төште ни дә, төшмәде ни. Бер сүз белән генә әйткәндә, кеше кызыгырлык түгел инде кыяфәткенәм, түгел. Аның каравы, ачык күңелем, дөресрәге җырлап ачыла торган капка-ишекләрем бар. Әнә җырлатып килеп тә керделәр... тораташтай басып та каттылар. Әллә телсез дә калдылар инде. Юк икән...

– Да-а, малай!

– Лапасны, баз өстен, утын сараен, мунчаны сүтәсе...

– Сүтмиселәрен генә сана, хатынкай. Исемлектә бер пункт та калмаска охшап тора әле монда...

– Ызбаны да сүтәсезмени?! Ни бит... Хәдичә әби...

– Бигрәкләр дә тузган икән шул бу йорт, Әмир энем. Ерактан ничава гына булып күренгән иде дә соң. Искегә тисәң исең китәр, дигән бит борынгылар. Бәладән башаяк, әллә соң сезнеке кебек ап-ак кирпечтән...

– Чүегез әле. Ул турыда соңрак сөйләшербез. Әнә каен түмәркәләре. Җайлап утырыгыз да бүгенге эш фронтын барлый торыгыз, яме. Ә мин башлап өйгә кереп чыгыйм... үзем генә...

Гөлсинәнең тавышы калтырап чыкты. Күзләре дә дымланды кебек. Дулкынлана балакай. Өч дистә ел читтә яшәгәннән соң, туган авылына кайтып төпләнергә җыена диген, ә?! Кесәсеннән кайчандыр Хәдичә апасы үз куллары белән чүпрәк бауга бәйләп куйган ачкычны чыгарды. Йозакка туры китерә алмый азаплана. Ачты, баскычтан күтәрелде, керде... Йә, Ходаем, карашы! Шундый өздереп, якын итеп карый. Сак кына атлап яшел сандык янына килде. Әллә ничә кат ачып-ябып карады. Балачагын исенә төшергәндер. Ул заманда көмеш калай белән бизәлгән яшел-зәңгәр сандыклар һәр өйнең күрке иде бит. Бүген сандык миндә генә калды бугай. Күңелем шулай тоя. Әйткәнемчә, күңелем мине беркайчан да алдамый... Түр якка үтте. Диванга иелеп чәчәкле япманы сыйпый... Күз яшьләренә төелде... елый... Шул диванны тутырып шат елмаеп утырырга яраткан әнисен исенә төшерде бугай. Әй, гомерләр диген... Агач рам эчендә эленеп торган шамаилгә бакты. Дога пышылдый. «Бисмилләһ-иррахмәнир-рахим. Әлхәмдү лилләһи раббил галәмин. Әррахмәнир-рахим...»

Укы, балакай, укы. Киткәннәрнең рухы шат булсын, үзеңнең күңелең чистарынсын, пакьләнсен. Ничә ел инде Китап сүзен ишетергә зар-интизар булып яшим. Һай, ялганлыйм! Кяфер сүз сөйлим. Авылыбызда биш иман йорты бар ла безнең. Икесен хәтта мин дә күрәм, уңга карасам – яшел манара, сулга баксам – көмешсыманы, очларында айлары балкый. Ходай күпсенмәсен берүк, көненә биш тапкыр төрле яклап яңгыраган азан моңына гына чумып утырам!

Бераз тынычланды бугай. Күрче, хатын-кыз хатын-кыз инде, кесәсеннән кулъяулыгын чыгарып, тонык көзге янына килде. Күз яшьләрен сөртте, иреннәренә сизелер-сизелмәс кенә елмаю да кунды әле. Шулай, сеңлем, яшәү дәвам итә. Дәвам иттерергә кирәк тормышны, дим. Минем белән бергәләп. Һәр бүрәнәсе, һәр идән тактасы изге күңелле Хәдичә апаң, җор телле, оста куллы әниең, күрше-күлән, авылдашларың турында бик күп якты хатирәләр саклаган өйдә.

Их, пәрдәләремне ачса! Әллә ишетте инде. Урам якка караган бер тәрәзәмнең пәрдәсен күтәрде! Уф! Никләр күтәрде дияргә калдым. Күрче, турыбыздан алпан-тилпән атлап ике ир-ат үтеп бара. Салмышлар. Ишегалдындагы кешеләрне шәйләделәр бугай. И карыйлар каерылып. Карарсың шул. Ничә ел ялгызы кукраеп утырган йорт тирәсе җанлансын да! Гөлсинә танымаса гына ярар иде боларны. Соңгы елларда танымаслык булып үзгәргән бу ирләрнең берсе – аның сабакташы Рәсим, икенчесе – бездән берничә йорт аша гына яшәүче Сәлим. Сәлим дигәннән, аны бу хәлдә күрүе бигрәкләр дә кызганыч инде. Ятим бала ул. Үз балалары булмагач, ирле-хатынлы Самания белән Закир балалар йортыннан алып кайтканнар иде янып торган җирән чәчле, ак

йөзле, почык борыны өстенә бизәкләп тезгән кебек вак сипкелләр сибелгән тиктормас малайны. Шушы ристан күз алдымда үсте, мәктәпне бетерде. Әти-әнисе генә озын гомерле булмадылар... Егет тагын тома ятим калды. Икенче тапкыр... Шул сәбәплеме, тормыш юлы да кыеккарак китте: бүген укымый да, беркайда эшләми дә әнә. Йөри, адашкан бәрән сыман, кирле-кирәкмәгән кешеләргә ияреп.

Гөлсинә дә авыр сулап куйды. Таныгандыр, танымый. Карашында аптырау, җәлләү, тагын әллә ниләр. Типсә тимер өзәрлек ирләр көпә-көндез абына-сөртенә трай тибеп йөрсеннәр дә. Бер дә күңелле хәл түгел шул. Андыйлар тагын бар әле авылда. Уттай эш өстендә, диген. Юньсезләр. Кирәк бит ә, кешенең күңелен төшереп... Дөресен генә әйткәндә, минем бөтен курыкканым да шул иде. Ник дисәң, читтә яшәгән һәрбер авыл баласы өчен туып-үскән ягыннан да изге, газиз җир юк бит инде. Аның табигате дә гүзәл, кешеләре дә уңган, эчкерсез, саф күңелле булып хәтерләрендә саклана. Туйлар узгач, туннар тузгач дигәндәй, көннәрдән бер көнне шул авыл балалары туган ояларына әйләнеп кайталар да авылдагы үзгәрешләрне күреп «аһ» итәләр. Елгалар да саеккан, балыксыз калган, күлләр дә кипкән, урманнар да киселгән, авылдашлар да элеккечә ихлас, ярдәмчел түгел. Һәммәсенең телендә акча, уенда байлык, мал җыю... Шулай итеп, кайткан берсенең бөтен татлы хатирәләре, өмет-ышанычлары челпәрәмә килә дә куя инде. Күбесе йөрәк әрнүләренә чыдый алмый бераз каңгырып йөри дә тагын шул торган шәһәрләренә китеп югала. Бу юлысы бөтенләйгә. Аннан соң зиратка берәм-берәм гәүдәләре генә кайта...

Күрәм, Гөлсинәм дә өзгәләнә. Телгә килеп: «Дөньясы үзгәрде бит, кызыкай. Шәһәре дә, авылы да танымаслык булып үзгәрде, нишлисең...» – дип юатасым, үгетлисем бик килә үзен. Тик сизеп торам, акылы белән барысын аңласа да, Гөлсинәнең йөрәге бу ачы хакыйкать белән бер генә дә килешәсе килми шул. Әнә, уйларымны раслагандай, күзем күрмәсен ичмасам диптер, пәрдәне шалт итеп ябып куйды да диванга барып утырды.

«Утырып уйлар уйлар өчен җиткән икән буйларым», диеп җырлыйлар мәле? Әйе, авыл балаларына утырып уйлар вакыт бик җитте. Авыл да тере организм ласа. Йорт-каралтылар – аның күзәнәкләре, бормаланып сузылган урам-сукмаклар – тамырлары. Авыл яшәсен, үлмәсен өчен шул урам-тамырлардан гөрләп «авыл каны» агарга тиеш. Таңнан торып эшкә ашыгучы ир-егетләр, мал-туарларын көтүгә куучы яшь киленнәр, өй тирәсендә мәш килүче әби-апалар, яшел хәтфә үләндә тәгәрәп үсүче бала-чага, тавык-чебиләр, каз-үрдәкләр, хәтта дөбер-шатыр килеп чапкан матай-машиналарына хәтле – барысы да туктаусыз хәрәкәттә булырга тиешле авыл каны. Бер йорт-нигез юкка чыккан саен, бер гаилә шәһәргә күчеп киткән саен, тамырларда кан азая, тамырлар кысыла, кибә-корый. «Үлә бит авыл...» Бу сүзләрне Гөлсинә белән икебез берьюлы әйттек бугай. Иңрәүне хәтерләткән кайтаваздан сайгакларыма хәтле ыңгырашып куйды...

Ә Гөлсинә нindидер бер катгый карарга килгән кешедәй капылт кына урыныннан сикереп торды да ишеккә юнәлде. Әллә авылга кайтып төпләнәсе килү уеннан ваз кичтеме? Әллә инде мине сүтеп, утынга тураклап, яңа өй салу уе тудымы башында? Белмим. Нишлим инде, ничек туктатыйм үзен? Тагын бер тапкыр ялварып күзләренә багар идем. Чыгып китә бит. Ишек тоткасына кулын куйды. Гөлсинә-ә-әү... Борылып карады! Кабат күзләре яшьләнде... Кинәт карашы матчадагы бишек элә торган чөйгә абынып, имәнеп китте. Үзе дә сизмәстән бугай, бишек җыры көйләгәндәй шигырь сөйли башлады:

Бишекләрдә тирбәлмәгәч,
Каян килсен балага моң?
Талбишеккә салмак булам
Инде үсеп буйга җиткән
Балаларын замананың...

Никадәр әрнү, чарасызлык, иксез-чиксез моң-сагыш иде аның тавышында! Һәм... ялгышмасам, күзләрендә кайчандыр, бик-бик күптәннән югалтканны табу шатлыгы да чагылды кебек. Әйе, әйе, аларда өмет, ышаныч чаткылары кабынуын күрдем мин!

Чү, әзият кәлүшләрен чыштырдатып, Фәйрүзә күрше кереп килә түгелме? Монысы ни «сайрап» куандырыр инде. Дөрес, Гөлсинә сеңлем, күрше апаңа әлегә ничу өйгә керергә, күзләре кирәккәнне дә, кирәкмәгәнне дә шәп шәйли аның. Шулай, шулай. Берни булмагандай шат елмаеп чыгып бас алдына. «Фәйрүзә апакаем, нихәл, разведкага килүеңме әллә?» – диепләр җибәр.

– Саумы, Фәйрүзә апа! Хәлләрең ничек?

– Безнеке картларча инде. Авылга кайтабыз дисез алайса. И-и мондагы чүп-чар, галәмәт икән. Ну-у, Маскыва ни сразы строилась...

– Һай, шәп әйттең, апакай! Күз курка, кул эшлинең урысчасы була инде бу, әйеме?

– Галимулла абзагыз яңа эш башлаган саен шулай кабатлый торганые мәрхүмкәем. Ызбаны да сүтәсездер бит?

– Юк. Сүтмибез! Эчен-тышын яңартып, курчак өе кебек матурлау безнең исәп, әйеме, Әмир энем?

– Әйе, Гөлсинә апа! Очып кына шулай дип әнигә әйтеп килим әле. Эче пошып калган иде. Мин хәзер, яме!

И игелекле күңел, артына борылып карый-карый йөгерә балакай. Ул минем өчен сөенә, мин аның өчен дигәндәй. Сөенми! Хәдичә әбисе Әмир улыма бик иртә дөнья куйган әбекәен алыштырган кеше бит. Әнисе әзерләп биргән күчтәнәч төенчекне тотып көн аралаш ялт итеп менеп җитә иде нәни егетебез. Утыралар иде картлык белән балачак чөкердәшеп чәй эчеп, гәпләшеп. Хәзер менә апаларына кунакка килеп йөрер.

Могҗиза, язмыш бүләге дими ни дисең инде. Әле берничә көн элек кенә мин тома ятим калган, ташланган, онытылган бер өй идем. Бүген исә яңа хуҗаларым табылды, хәтта күршекәем Фәйрүзә дә керер сукмагын бик тиз исенә төшерде әнә. Бу иксез-чиксез шатлык-куанычымны кем белән генә уртаклашыйм икән? Бөтен дөнья белән инде, бөтен дөнья белән!

Әй, сорыйм әле. Сиреньнәрем-гөлләрем, киләсе язларда элеккечә шаулап-кайнап чәчәк атарга вәгъдә бирәсезме? Кичә бөтен булган ботакларыбызны кистеләр, дисезме? Ә тамырларыгыз? Алар бит исән! Тамырларыбыз назлы, йомшак, миһербанлы туган җир туфрагында! Шулай булгач, яшибез әле, гөрләп чәчәк атабыз!

***Редакциядән:***

*Каләмдәшебез Сирень Якупованы юбилее белән котлыйбыз! Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез!*



Гөлзадә
Бәйрәмова

# ҺӘР СҮЗНЕҢ ҮЗ МОҢЫ, ҮЗ КӨЕ

## Язмыш

Әүвәл җиргә сүз яралган, диләр.
«Бул!» дигәннән адәм бар булган.
Каләм биргән аннан бәндәсенә,
Күк катыннан җиргә сузылган.

«Каләм яза, кәгазь түзә», диләр.
Бәндә юрар, тәкъдир, әй, көләр.
«Мин – бәхетле!» – диеп шар ярганда,
Ниләр язылганын кем белгән!

Ихтыярсыз җиргә туа кеше,
Ихтыярсыз китә дөньядан.
Үз язмышым үзем яздым мәллә,
Тайпылдыммы Ходай язганнан...

Үзгәртергә теләп мең талпындым:
«Минем язмыш мондый булалмый!»
Мин «ак», дисәм, ул гел «кара», диде,
Мин еладым, ул кычкырып көлде,
Камчылары ялык-йолык килде,
Уңнан-суңнан сукты аямый!

...Минем язмыш мондый булалмый!

## Сәяхәт

Мин Болгарда йөрим
Сәяхәттә.
Үз җиремдә бүген мин сәях.
Ислам килгән монда,
Мөселманлык,
Ибн Фадлан кылган сәяхәт.

---

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА – *шагыйрә; «Әле кайчан гына...», «Син һаман шул сандугач» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Юлъязмасын язып калдырган ул
Килер буыннарга берочтан.
Зирәкләре ханның дин үткәрер,
Тик үткәрмәс халкын кылычтан.

Җимерелгән Болгар,
Алтын Урда.
Казан ханлыклары аяныч.
Ханлыксыз да, дәүләтсез дә халык
Диндә тапкан бераз юаныч.

...Яңа буын яңа Болгар төзи,
Яңа солых кора – шартнамә.
Милләт кенә никтер берләшалмый,
Милләт кенә һаман таркала.

## Язылып бетмәгән шигырьләр

Язылып бетмәгән шигырьләр...
Һаман да күңелдә йөриләр.
Кәгазьгә төшкәннәр югыйсә,
Хисләргә салынган ул көйләр.

Юл ала агымсу шикелле,
Һәр сүзнең үз моңы, үз көе.
Кемнәрдер яратыр үз күреп,
Кырыйга тибәрер кайбере...

Язылып бетмәгән шигырьләр...
Җан өрү кирәкме сезләргә?!
Аңлаучы булырмы сезләрне,
Минем күк бәгыре өзелеп.

Уйларым – пәрәвез ятьмәсе,
Мин – әсир, колымын аларның.
Өстәлдә яталар күч булып
Буталган, чәчелгән уйларым –
Яшәлгән гомерем еллары,
Узылган гомерем юллары...

## Онытыма

Таң вакыты. Гавам йоклый.
Кемнең кемдә ни гаме!
Тулгак газабына тарган
Яшь ана гына бары.

Мин – сәждәдә. Тәһәҗҗедтә[1].
Улымның улы туа!
Нәселебез дәвамчысы –
Татар канлы ир бала!

Таңда бүген дөньяга,
Өстәлде сабый-инсан.
Исемеңә җисемең килсен,
Кальбең булсын мөселман!

Ризыгың хәләлдән булсын,
Хәрәмне итмә юлдаш.
Һөнәрне үзең сайларсың,
Йә мөгаллим, йә илбаш!

...Тулгак газабына тарып,
Тагын күпме әниләр,
Кеше тудыра дөньяга –
Бүген әле бәбиләр!

Мәрхәмәтле булчы, дөнья
Китермә сугыш-афәт!
Җан ачысы белән ана
Бала таба – мең рәхмәт!

Кендек бавы өзелүгә
Керәдер дөнья гаме.
И сабыем!
Нәселеңнең дәвамчысы,
Горурлыгы бул, яме!

[1] Тәһәҗҗед – төнлә укыла торган намаз.

***

Кочагымда – улым, әй, оныгым!
«Туган тел»не көйлим тын гына.
Милли моңны тәү кат ишетүе,
Йокы алмый аны, тын тора.

Аваз салганына бу дөньяга
Нибарысы булыр өч тәүлек.
Сихри бер моң, татлы исләр –
Җәннәт исләренә тиңләрлек.

Тәү кат ишетте ул әнкәсенең
«Улым!»  диеп өзелеп дәшүен,
И Ходаем, насыйп итсәң иде,
Милләт улы булып яшәвен.

Аллаһ сүзен – азан моңын
Ишеттерде тәү кат әткәсе.
Үзенә дә насыйп булсын иде
Исем кушып азан әйтәсе.

...Аваз салганына бу дөньяга
Нибарысы булыр өч тәүлек.
Шул өч көннең сөю-сәгадәте
Булсын гомеренә җитәрлек.

## Нигә?

Юллар безне бер сукмактан йөртә,
Очраштыра кайчак күзгә-күз.
Сүзләр генә никтер ялганалмый,
Сүзләр генә никтер кадерсез...

Аңлашулар күптән узган инде –
Хәлләреңне сөйлә-сөйләмә.
Тик бер сорау тынгы бирми җанга:
«Нигә икән, нигә, нигә лә?»

Нигә генә болай булды икән,
Тиеш иде юкса башкача.
Җыр башласаң – җырың отып алдым,
Тыңлый идем сине соңгача.

Нигә димен, нигә болай булды,
Синме, минме, кем яңадан туды?
Кемдә яңардылар яңа күзләр,
Яңа күзләр – ятлар эзен эзләр.

Ят эзләрме сине адаштырды,
Ят сукмаклар бүлде юлыңны?
Бергә салган юлда бер ялгызым,
Ниләр димен, ниләр соң булды?..

## Берәүгә

Мин бит сиңа гашыйк идем,
Үзеңә түгел, яшьлегеңә.
Яшьлекнең яшел күлмәген
Салмас идем бер көнгә дә.

Мин бит сиңа гашыйк идем,
Сөйләмеңә, йөрешеңә.
Төпле итеп, тыныч кына,
Ипле фикер сөрешеңә.

Син Йосыф та түгел үзең,
Бармы тиңнәр пәйгамбәргә!
«Йосыф-Зөләйха» кыйссалары
Иш булырмы бездәйләргә?!

Зөләйха шул аңлаталган
Сөюенең көчен, серен.
Телем-телем тураттырып
Бармакларын, итеп йөзем.

Ә безгә соң ни сан кала –
Яшерен яну, яшерен көю.
Яшьлекнең яшел күлмәген
Берәр көнгә урлап кию!

Урлашулар, беләм, гөнаһ,
Яшерен сөю тагы да газап!
Бу гөнаһлы уйларымнан,
И Раббым, итче азат!

... Ә шулай да йөгерер идем
Чыклар төшкән үләннәрдән.
Яшьлекнең яшел күлмәген
Кияр булсам берәр көнгә!

## Җавап

Үзгәрмәдең, димә, нык үзгәрдем.
Үзгәрделәр йөзем, күзләрем.
Көзгедәге чагылышым аша
Танымый да торам үзләрен.

Чапкан аргамакны туктатырлык
Карашларым талгын, сүрәннәр.
Очып кына йөргән адымнар да,
Акрын-салмак көйгә көйләнгән.

Хисләр ярсулыгы тынып калган,
Зирәклекме инде юл алган.
Үзгәрмәдең, димә, мең үзгәрдем,
Үзгәртә ул дөнья, бел, балам!



Айзирәк Гәрәева

# НИ ҺОУ! ЯКИ НИХӘЛ?

ХИКӘЯ

***

Интернетта «Фейсбук» дигән дөнья бар. Кайчак ул авылда көтү каршылаганда, берара буш вакыт табып, урамда күрше-тирә белән тегесен-монысын «чәйнәп» алуны хәтерләтә, кайчак анда, билгеле бер төркемнең эчендәгесе тышына чыксын дип, махсус оештырылган җыелышларга, хәтта митингларга килеп эләккән кебек буласың. Менә шушы дөньяда фикер алышу, вакыйгалар агышы төймәләре таралып киткән муенсаны хәтерләтә. Әмма ул төймәләр барыбер бер сәйләнгә тезелер төсле... Ул сәйлән дигәннәре – интернетка язылганнар белән компьютер каршында утыручылар һәм чын тормыш арасындагы хакыйкать инде. Хикәяне язарга да шул төймәләре таралган муенсаны хәтерләткән «Фейсбук«тагы танышлар, фикерләр, аралашулар этәрде...

**1**

Клавиатурадагы хәрефләр буйлап бармаклар бер-ике секундка гына туктап ала да тагын йөгерәләр. Менә шулай, мең чакрымнар еракта яшәүче, төгәлрәге, Төркиягә төрек телен өйрәнергә чыгып киткән дустым белән электрон почтадан язышам... Дөресрәге, ул бәйләнепме-бәйләнә...

– Яз.

– Җитте...

– Яз, дим.

– Кемгә кирәк?! Хет шуны әйт!

– Кытайларга яз.

– ???

– Кытайларга!!!

– Алар бит безнең телне аңламыйлар.

– Аның өчен кайгырма.

– Алайса, нигә нәкъ менә аларга?

– Кытайларга яз.

– Нигә, дим?

– Чөнки аларга бөтен нәрсә кирәк... Чөнки алар бөтен дөньяда... Ә синең уең гына дөньяда.

---

Айзирәк ГӘРӘЕВА – *журналист, прозаик. Казанда яши.*

– Үзем Казанда.
– Шул-шул. Кытайларга яз.
– Бәйләнмә әле, ә!
– Ә менә син башта кытайларга нидер эшләп кара!
– ???
– Язып кара, дим!

Чыннан да... Клавиатура буйлап йөгергән бармаклар туктап калды. Шул вакытта телевизордан сөйләгән колакка керә. Кытайларны мактыйлар. «Ни һоу!» диләр. Бу кытайларның исәнләшү сүзе икән. Миңа ул «Нихәл?» дип ишетелә.

– Ни һоу! Нихәл?

Бармаклар кабат җанланды...

Берәүне дә үчекләргә теләмим, шулай да кытайларга язам дип язам хәзер. Бөтенләй үк ачу китермәс өчен, башка бу хакта кабатларга тырышмам, һәрхәлдә әлегә шулай уйлыйм.

– Ни һау! Нихәл?

Нихәл дип...

**2**

Бу шәп дөньяның шундый бер гаҗәп һәм серле үзенчәлеге бар. Билгеле бер мизгелдә төрле тарафларда каңгырап йөргән бәндәләрне бер ноктага җыя. Нокта дигәч, ныграк аңлашыла кебек, ә минем өчен ул күбрәк җөйне хәтерләтә. Менә тәнгә кадалган укол эзе нокта гына кебек, ә чынлыкта ул – бөтен бер организмдагы күзгә күренмәс бер җөй. Ул җөйнең юкка чыкканы сизелми дә калырга мөмкин. Ә дөнья тәнендә андый җөйләр миллионлаган гына түгел, миллиардлаган һәм тагын без башка да китереп карамаган саннар хисабында. Күпчелек очракта аларның да барлыкка килү һәм юкка чыгулары сизелми эзсез үтә.

Без дә бер җөйгә укмашкан дүрт күзәнәк идек.

Ярый, без әле беркөнне генә бер ноктада очраштык, дип әйтим. Ярый, бүген генә юллар чатында табыштык, дим. Ярый, бу атнада очраклы хәл аркасында бәйләндек, диик... Дөрес, нәкъ шулай! Әмма без бер көнне дә, бүген дә, бу атнада да түгел, әллә кайчан бер җөйгә укмашкан күзәнәкләр булганбыз. Тере күзәнәкләр. Әйе, тере күзәнәкләр.

Бу хактагы хәбәр мине тораташ итте, бәреп екты, артыма утыртты, телсез калдырды... Әгәр ул чактагы халәтем хакында сорасалар, менә шулайрак җавап бирер идем.

**3**

...Аны күрүгә, урамда аунаган дип уйлыйсың, чөнки чалбарлары тузанга баткан. Урамда аунаган, димәк, алкаш инде. Ә бәлки, аның киемнәрен юа торган якын кешесе юктыр. Кер юу машинасы ватылгандыр әле. Алтмыш яшьләр тирәсендәге, тәбәнәк буйлы, ябык кына гәүдәле, сукбай кыяфәтле абзый үзен тыныч тотарга тырышты. Йөзе сәер шешенгән, эчә торган кеше инде бу, ә бәлки, йөрәктер, бәлки, кан басымыдыр, олы кеше бит. Нигәдер, шуны бер бетереп ташлыйм да кирედән агарта башлыйм... Ниһаять, сәбәбен аңладым: бу бәндәнең бит бөтенләй башка төрле чагын күргәнем бар!

Ул арада кыска, җыйнак кына сакаллы, кырык-илле яшьләрдәге ир аның янына урындык китереп куйды. Нindидер бер түбәнчелек белән генә сукбайга утырып торырга ишарәләде. Читтән караганда шактый тәкәббер тоелган, шактый ыспай костюм кигән ирнең сукбай көен көйләргә тырышуы үзе үк

мәзәк иде. «Бусы кем булыр икән?» – дигән уйга калдым. Бәлки табибтыр, хәлсез кешене тиз күреп алды... Юк, әнә табиб дигәннәре, өстәл артында бик тә зәһәрләнеп утыра, болар бер дә охшамаганнар бит. Ул бары гап-гади бер ир-ат, шул ук вакытта безнең барчабызга караганда да үз кадерен үзе белгәне һәм ныклыгы күз карашыннан сизелеп тора.

Хәтта телефоныннан бертуктаусыз кем беләндер һава торышы «проблемасын» хәл иткән утыз-утыз биш яшьләрдәге, мөлаем гына хатын да моңа игътибар итте. Үзе сөйләшә, үзе иргә күз ташлап-ташлап ала. Әмма бу гадәти хатын-кыз кызыксынуыннан бигрәк, аптырау галәмәте икәне күренеп тора. Күзләрендә: «Ничек инде шушындый кеше дә безнең белән?!» – дигән кебегрәк сорау язылган иде. Аның белән бергә дүрт-биш яшь чамасындагы кызы да бар. Кыз таныш түгел абыйларга карап, тыныч кына курчагын тотып утырды.

Ясалма гөлләргә күмелгән табиб бүлмәсендә очрашу озакка сузылмады. Ул тиз генә аңлатып чыкты. Өлкән яшьтәгеләрнең телләре көрмәкләнә башлаячак икән. Урта яшьтәгеләргә ишетми башлау һәм, бигрәк тә хатын-кызларга, хәтер югалту яный. Яшьрәкләргә ничек тәэсир иткәне әлегә билгесез... Бу билгесезлек миңа кагыла, чөнки мин әле үземне, егерме тугыз тулса да, яшьләр рәтендә дип ышанып йөри идем.

Менә шулай, ясалма гөлләр арасына күмелеп утырган табибтан без үзебезгә ялгыш кадалган, тикшерү узмаган яңа төр витамин уколының нәтиҗәсен белдек. Үзебезнекен әйтмичә, төгәлрәге, кычкырмыйча китмәдек тагы.

– Немедленно хатагызны төзәтегез! – дип бәргәләнде абзый.

– Мин сезнең башны судта черетәм! Зыян салган өчен түләми генә карагыз! Кызымны карарсыз! – дип өзгәләнде яшь ханым.

– Сабыр, сабыр, җәмәгать, имансызланмыйк... Дарудан гына тормый бит, – дип башкаларны тынычландыра-тынычландыра сабырсызланды ир.

– Язып чыгармын әле менә!

...Һәм шулай бераз әйткәләшеп алгач, таралыштык.

Без шул вакыттан башлап бер җөйгә укмашкан дүрт күзәнәк идек.

**4**

Гадәттә, елгага карыйбыз һәм, беренче чиратта, ике яр арасыннан туктамыйча аккан суны күрәбез. Ул безгә кадәр дә аккан һәм киләчәктә дә үз җаена агачак. Шул агым янында тукталырга була. Бәлки, бик азгадыр, бәлки, озакка. Шул елгага машинаның тишек тәгәрмәчен атып китәргә дә, табигый матурлыгына сокланырга да мөмкин. Тыныч кына утырып, шунда балык тотып кара! Бәлки, йөгереп килеп чумаргадыр?! Суда йөзеп йөргән чүпләрне җыйсаң да була икән. Һәм тагын әллә нәрсәләр эшли аласың. Әйтик, бер кеше килә дә: «Нигә суга чүп ташлыйлар инде!» – дип, башкаларны аты-юлы белән сүгәргә тотына. Суга карап сүгенсәң дә гаҗәп түгел. Әле борчуларыңны агымсуларга салып агыз, дип тә әйтәләр бугай...

Тагын...

Беренче карашка, елга ул – менә шулай ике яр арасыннан ерак-еракларга агучы агымсу. Безнең тормыш барышына буйсынганыбыз менә шушы агымга ятып йөзү белән бер инде.

Икенче карашка – башкачарак, әйтик, елгага карыйбыз, әмма су акканына да, елга озынлыгына да игътибар итмибез. Шушы елганың бары бер адым арасын гына күрә алсаң, анда тормыш кайный! Әнә бик эшлекле кыяфәттә бер бака тыныч кына утыра, калганнары әрле-бирле сикерә, балыклар йөзә, куыша, су чебеннәре мыжгый. Ярда әкәм-төкәм кабырчыклары кыймылдый. Беркая агып китәргә

җыенмаган, шунда үсеп, шунда чери торган үсемлекләр акрын гына су агымына ияреп тибрәлә. Алар өчен, бәлки, су агымы ул – су да түгел, ә искән җил генәдер!

Елга буена туктаган бәндә менә шулай, төрлечә карап башын катырырга да, катырмаска да мөмкин, үз ихтыярында, чөнки аңа андый җаваплылык турыдан-туры йөкләнмәгән бит. Елгага ялгыш төшкән кәгазь төсле агып китсә дә, атылган таш кебек су төбендә утырып калса да, бер сүз әйтә алмыйсың.

**5**

Җөйгә укмашкан дүрт күзәнәкнең берсе әмир иде. Моны студент елларыннан бирле диплом карамалары арасында сакланган журнал да раслады. Хастаханәдән кайткач та, балкондагы иске-москы кәгазь арасыннан шуны актарып табып чыгардым.

...Саргаеп беткән журнал битендә көянтәләренә каз аскан, каз йоны йолкыган апайларның фотолары тезелгән. Тагын бер фотода ак шәлъяулык бәйләгән әби каралты-курасында казлары каршына баскан да кулларын догага күтәргән. «Борын-борын заманда... Без үскән чакта каз асрыйлар иде, һәркемдә икешәр-өчәр оя була торган иде. Беренче кар төшкән, каз өмәләре башланган көн иде», – дип башланып китә фото астындагы язма.

Кулымдагы журналның беренче битен кат-кат әйләндереп карыйм, февраль саны диелгән. Ә монда беренче кар турында, каз өмәсе хакында язганнар. Февральдә үк ноябрь хакында уйлан дияселәре килгәнме?! Бәлки, ишегалды фотоларына журнал түрендә урын февраль санында гына табылгандыр, кем белгән?!

1991 елның февралендә утырганны болайрак язарга кирәк булгандыр ла...

«Борын-борын заманда... Без үскән чакларда өстәл астында талчыбыктан үрелгән кәрҗиннәрдә казлар ысылдап утыра иде. Тәрәзәгә күз ташласаң – бар җирдә аклык. Авыл урамнары карга күмелгән һәм гомергә дә кыш бетмәс кебек тоела. Кышта әллә нинди үчең бар төсле: «Кайчан бетә инде бу кыш?» – дип уйлап куясың. Ялгыш аягың өстәл астындагы кәрҗингә тиеп китә. Каз аягыңны эләктереп ала. Шунда ук бик тиз аңлыйсың. Казлар инде йомыркага утырган, димәк, язга күп вакыт калмаган. Шунда ук ана казны тышка, ата каз янына чыгарып, су эчертеп керергә кирәклеге искә төшә. Лапас тирәсендә, салам-печән коелганга, кар тизрәк эри торган урында казларга савыт белән су, ашарга куясың да, күзне чагылдыра торган язгы кояш астында ана казның бик тә әлләкемләнгән кыяфәтеннән, ата казның биеп-биеп алуыннан көлеп карап торасың...«

Бүгенге кешегә «Борын-борын заманда казлар казак какканда», дип башланып китә торган әкияттәге кебегрәк күзаллана инде бу.

Ә хәзер ни язар идем соң?

«Көне-төне кәрҗиндә йомыркаларын җылытып утырган ана казлар ишегалдындагы табактан су эчкәндә, ата казлар биеп-биеп алган заманнар үтте инде... Хәзер авыл казлары да ояга утырып бәбкә чыгармый. Авыл халкы апрель-майны һәм шул чакта үскән бәбкәләрне сатып йөрүчеләрне көтә...»

Журналның алдагы битләренә күз ташлыйм. Чынын әйткәндә, казлар, кәрҗингә утырып, бәбкәләр чыгарган заманнарда чыккан журналдан баш әмирне эзлим.

Менә ул! Саргаеп беткән журналдагы казлар янында кулын догага күтәреп басып торган ак шәлъяулыклы әби фотосурәте белән янәшә биттә аның җаваплары да урнаштырылган!

Казлар кәрҗингә утырган заманнарда ил бәйсез иде. Шул дәрәҗәдә бәйсез иде, хәтта шул бәйсезлекне яклый торган махсус кешеләргә кадәр бар иде.

Аларны «әмирләр» дип йөрттеләр. Алар арасыннан берсе, әлбәттә, баш әмир итеп билгеләнде.

Хәзер менә шушы баш әмир белән корылган әңгәмәне укып утырам. Катлаулы озын-озын сорауларны да, аларга бирелгән тагын да авыррак һәм озынрак җавапларны да күзләрем бертөсле укый, аңым еллар аша көлгән булып та, бераз мыскылларга тырышып та шәрехли бара. Шул шәрехләү генә хәтергә сеңә тора.

– Бәйсезлек яклап маташасызмы?

– Бәйсезлеккә ирешү өчен, иң беренче чиратта, илдәге милекне файдалану мәсьәләсен хәл итәргә кирәк. Әйтик, шул милекнең 80 проценты – без кергән берлеккә, 18 проценты – берлек кергән берлек карамагында булгач, безгә күпмесе кала булып чыга? Икесе. Менә шушы ике процентлы без.

– Алга таба нишләргә?

– Юлы бар аның. Партия дә, милек тә бирә торган документ язылды. Әйтәсе генә калды: «Без менә шушында язылганнар буенча яшибез һәм яшәячәкбез!«Анда партиябез дә, милкебез дә бар, дип язылган.

– Гафу итегез, бер шәхси сорау бирәм. Сез кем?

– Хатыным да, үзем дә галим-голәмә, безне җәмәгать эшлеклеләре дип әйтүчеләр дә бар. Шигырьләр дә языштырам. Шагыйрь дә әле мин бераз. Әмирләр турында язам! Гаиләм – минем терәгем. Балаларым үсеп килә менә. Киләчәктә алар да әмирләр булыр дип торам.

Казлар кәрҗиндә бәбкә чыгарган, ата казлар тыпыр-тыпыр биегән чак иде...

Саргаеп кына беткән булса да, сәер хисләр, тойгылар уятты кулымдагы журнал. Февральдә ноябрьдәге каз өмәсе турында 240 мең дә 851 кешегә укыта алганнар. Тиражы – дөнья күләмендә. Шулар ук баш әмир турында да белгәннәр. Егерме өч елдан соң исә мине 240 мең дә 852нче укучыга әйләндерделәр. Ә мин, мыскыл итеп, расшифровка ясап утырган булам тагы.

**6**

Бер атнадан соң кабат хастаханәгә юл тоттым. Үзләре, шалтыратып, килүемне үтенделәр. Менә шул чакта янә әмирне очраттым. Хастаханәгә илтә торган юлның икенче ягыннан бөрешкән, кипкән күзәнәк хәлендә калган баш әмир өстерәлеп бара иде.

Егерме өч ел элек чыккан журналның иң кирәкле герое димәссең. Кыяфәте бетсә бетсен инде, картлык галәмәтен чигендерә торган көч әмирләрдә дә юк анысы. Әмма еллар үткәч тә мәртәбәсен югалтмаган бер галим, шагыйрь булып күренсә, мин дә аңа барып эндәшергә уңайсызланып тормас идем. Ә болай, урам кешесенә барып сәлам бирү, әллә ничек бит... Җирәндерә дисәм, үзем алай пычрактан курка торган кеше дә түгел. Кыскасы, дип әйткәндә, әмир төшкән мескенлек чиркандыра, менә шул. Әмирне чолгап алган мескенлек куркыта, артка таба чигенергә мәҗбүр итә. Әйе, бу сүзләр бик тәкәббер яңгырый, «әллә кемдәй кылану» булып күренә. Ләкин дөресе шул бит, нишлим?! Менә институтта укыганда, лекцияләрнең шактые аның хакындагы әңгәмәләрне, мәкаләләрне тикшереп, өйрәнеп үткән иде. Әмир язганнарны укый-укый, горурлыктан борыннар түшәмгә тия яза иде: «Без менә нинди булган! Без хәзер менә нинди! Без хәзер менә нинди булачакбыз!«

Әмир бер кибет диварына барып терәлде, тагын кузгалып китте, тагын терәлде. Иң авыры – көче ташып торган ир-атны хәлсез бабай хәлендә күрүдер. Аннан да бигрәк яманы – мескенлеккә төшүдән кача алмаган ялгыз әмирлекне күрү.

Күңелдә кызгану хисе уянгач, юл аркылы чыгып: «Мин сезне таныдым.

Хәлләрегез ничек? Балаларыгыз кайда?» – дип сорыйсым килде. Студент чаклар истәлеге булып, саргаеп беткән журнал сакланган, диясем килде.

Светофорның яшел уты янды, юлның әмирле ягына чык инде! Кызган мескенне! Һич югы, хәлен бел!

Әмма барыбер, хәтта кызгану хисе дә аякны атлата алмады. Бу юлы тәкәбберләнү дә мишәйтләмәде, без болай да бер җөйдә бит, дигән уй туктатты.

Светофорның инде әллә ничәнче мәртәбә яшел уты янды, баш әмир ераклашканнан-ераклаша барды.

Менә шулай озын-озын елганың шаулап-гөрләп агып киткәндәй тоелган бер адым арасына бактым. Шул арага 240 мең дә 851 укучы белән бергә баш әмир дә, ихатасында дога укып торган ак шәлле әби дә, каз йолкып утырган апалар да, алар янында гармун тартып торган абзый да сыйган...

Янә яшел ут янды.

Юлның теге ягында югалган әмир тагын да ерагаеп бара иде. Шунда әллә ни кузгатты, артыннан чаптым.

– Исәнмесез!

Йончып беткән урам картын татарча эндәшү туктатты. Ул миңа тонык күзләре белән бик шикләнеп текәлде, тәнем чымырдап китте. Үзем дә аңламастан, аклангандай әйттем:

– Сез безне укыткан идегез... Башта ук танымадым, өйгә кайткач исемә төште.

Ул бер сүз эндәшмәде. Шулай да, ничектер, ирен чите белән генә елмаеп куйды. Тонык күзләренә дә нур кереп киткәндәй тоелды. Башын да чөебрәк җибәрде, күз алдында карт бераз тураебрак китте төсле. «Менә мин кем!» дигән горурлыгы уяндымы, әллә үткәндәге мактанырлык эшләре искә төштеме, белмим, миңа болары барыбер иде. Аңардагы башка үзгәрешне көтү ныграк куркытты.

Ул арада вак-вак җыерчыклар эченә яшеренеп үк беткән зәңгәр тонык күзләре дымланып китте. Томан сарган үзәнлектән тыныч кына ерак-еракларга аккан елга шәйләнде төсле. Шулчак аның бөтен тәне дерелдәп куйды. Күзләре як-якка йөгерешә башлады, кызып-кызып нидер аңлатырга теләде, кулларын болгарга кереште. Әмма авызыннан сүзләр урынына аңлашылмый торган авазлар гына бүленеп чыкты.

– К-к-к... Аң... Б-б-б... Әй-т-т...

Күпме генә омтылса да, көрмәкләнгән теле сүзләр ясый алмады. Карт әмир кабат бөкшәеп калды. Шулай бөкшәйгән килеш китеп тә барды.

Мин аңардан тетрәнеп читләштем, чөнки бу хәлгә озак карап торырга ихтыяр көчем дә, теләгем дә җитмәде.

Җөйгә укмашкан дүрт күзәнәкнең берсе – кабат табылган әмирнең телсез калган чагын күрү җанны өтеп алды.

Әйтерсең лә аның теле кайчандыр 240 мең дә 851 кеше укыган саргаеп беткән журналга качты.

Икенче тарафтан хәтер пышылдады: «Күр, табиб кисәткәннәр чынга аша башлады». Миңа ни булыр?!

## 7

Хастаханә ишегалдында тагын бер күзәнәкне – «судка бирәм», дип янап куркыткан хатынны очраттым. Күрмәмешкә салыштымы шунда, әллә танымады, үтте-китте.

Аны да артыннан барып куып тоттым.

– Гафу итегез, ни кылырга уйладыгыз...

Хатын миңа аптырап карады.

– Нәрсә дисез? Сез кем?

– Танымыйсызмы?

– Юк.

Әле әмирнең телен югалтуын күрүдән туган кичерешләр генә җитмәгән иде, хәзер менә тагын бер «сюрприз».

– Ничек инде, без бит бер җөйдә! – дидем үртәлеп.

– Нәрсә? Гафу итегез, ашыгам...

Башка бер сүз дә әйтә алмадым, хатын китеп барды. Танымады. Бу юлы йөрәккә хәнҗәр кереп чыккандай тоелды. Хәтерен югалткан, димәк, баласы барлыгын да оныткан! Ә бит «кызым», дия-дия, ду куптарган иде.

Хастаханәгә кереп, узган атнада булган кабинет каршына бардым. Шунда табиб кисәткәннәр чынга ашуны аңлап, билгесезлектән, чарасызлыктан һәм куркудан нишләргә белми, шактый аңгыраеп утырдым. Бу кабинет безнең өчен махсус эшлидер кебек тоелды, югыйсә, әнә башка кабинетларга чират тезелгән. Биредә беркем юк. Ләкин шуңа карамастан, ишеген ачарга җөрьәт итә алмадым.

Күргәннәренең хәле билгеле, башкалар ни хәлдә икән? Башкалар дигән булып, үзең дә, теге иманлы «костюм» гына калды.

Суд белән хакыйкать эзләргә йөргән кеше беренче булып бирешкән. Хәтерен югалткач, аңа нәрсәгә инде хакыйкать?! Хакыйкать табыла да югала, югала да табыла, менә баласы кызганыч. Ул сабый анасына да кирәкмәсә, тагын кемгәдер кирәк булуы бик тә икеле.

Шунда авыр уйлардан арынырга һәм кабинет ишеген ачудан качарга бер көтелмәгән сәбәп килеп чыкты – якында гына торган урындыктагы китапка күз төште, шуңа үрелдем.

Бер як тышы алсу, икенче ягы яшел төсле китапка «Бәхет китабы» дип язылган иде. Беренче битендәге җөмлә үк бәхет кошы тоткандай елмаерга мәҗбүр итте: «Бу китапны алдыннан да, артыннан да укырга була. Теләгәндә автобуста укы, теләсәң – диванда. Буш калган битләренә үзең теләгәнне яза аласың. Бу үзе үк бәхет түгелмени?» Чыннан да, чарасыз калган кешегә синең сайлау хокукың һәм хәтта, әлбәттә, иренмәсәң, язу хокукың бар, диеп өмет бирсеннәр әле!

Авыр уйларны оныттырып, алдымда яңа төр сайлау мөмкинлеге ачылды. Китапны ачуга күрдем: гадәти басма язулы битләре кулдан язылган язулар белән аралашкан иде. Китап язган кешене укыргамы, әллә аны укучынымы?!

Менә шул сорауга җавап эзләп, табибка керү кирәклеген онытканга сабышып, хастаханәдән чыгу юлына таба атладым.

**8**

«Бәхет китабы«ндагы басма язу: «Теләгәндә хәзерге көн белән киләчәк арасында да, чарасызлык белән чарасызлык чигендә дә бәхет табыла».

«Бәхет китабы«на кулдан язылган язу:

«Без икебез ике яссылыкта гомер үтәбез.

Мин туфракта чагында, син – күктә.

Мин суда чагында, син – чүлдә.

Мин чәчәкле болында чагында, син – карурманда.

Менә шушы яссылыклар чигендә бер бәхет йөри.

Таң атар алдыннан «саташкан» әтәчләр кычкырып-кычкырып алган мәлдә, туфрактагы дым күкләргә күтәрелгәндәге кебек ул.

Озын-озак вакыт көткәннән соң килеп яуган яңгыр коп-коры чүл ерганакларын юган кебек ул.

Җәйге җиләс җил урман чәчәге орлыгын болынга алып барып чәчкән кебек ул.

Шушылай бер-берсен кабатламаган, үзләштермәгән, бер-берсенә яраклашмаган ике яссылык очраша. Бәхет мизгеле менә шунда яши. Безнең бәхет. Табигый бәхет. Мәхәббәтле бәхет».

«Бәхет китабы»ндагы яңа язу: «...Без бер яссылыкта, келәм түшәлгән идәндә утырабыз. Бер яссылыкта кем генә утырмас. Менә, әйтик, ул да, мин дә каршы түгел. Шуңадыр да без бер яссылыкта.

Ничектер, күңелнең башка кешегә сыенуга ихтыяҗы шулкадәр зур иде, бермәлгә янымдагы кешене ятканым дип уйладым. Хәтта ышандым. Шул вакытлыча гына барлыкка килгән ышану хисенә бирелеп китеп, аның да мине якын итүен теләдем һәм күңелне бушаттым.

– Беләсеңме, мин бит кош, – дидем.

Ул торып утырды да пультка үрелде.

– Чынлап, мин бит кош. Шуңа күрә аларны кешеләргә караганда да ныграк кызганам һәм аңлыйм.

Ул берни эндәшми генә телевизорны кабызды. Алай да туктамадым.

– Синең берәр кайчан кошларны күзәткәнең бармы?

Ул җавап биреп тормады. Пульт белән бергә, берни эндәшми генә, кабат яныма килеп утырды. Ә миңа шул гына кирәк иде дә. Аның куенына сыенган килеш, сөйләвемне дәвам иттем:

– Күз алдыңа китер әле. Кош канатларын җилпи-җилпи, хәтта каршы искән җилләргә дә исе китми, күкләргә күтәрелә. Бертуктамый оча-оча... Биеккә... Еракларга оча... Ул бар нәрсәдән ирекле, кая тели – шунда оча. Башка илләргә, җирләргә... Карурманнар, океаннар өстеннән оча.

Минем аркылы гына каналларны барлый торгач, берсенә тукталды. Шунда йөзенә бик җитди кыяфәт чыгарып, әмма шул ук вакытта шаярткандай әйтеп куйды:

– Минем синең очканны күргән юк. Димәк, син – тавык.

Әле генә күкләрне иңләгән асыл, тылсымлы, кабатланмас бер кош идем... Әле генә, бер мизгелгә генә булса да, яраткан кешесен табуына ышанудан канатлары үскән бер җан, бер канатлы рух идем... Һәм менә тавык булып җиргә төшеп утырдым.

– Үпкәләмә инде, башка үзе канатлы, үзе очмый торган кошны белмим... Син кош булганда гына тавыктыр...

Сикереп торганымны сизми дә калдым.

– Нәрсә инде, шаяртканны да аңламыйсың?! Үзе башлады да.

Ха, бары оча алмый торган бер тавык. Шул мизгелдә, таш атып кудылар диярсең, канатларын тиз-тиз кага-кага, кошлар рухы чыгып очты.

Зәңгәр күкләр генә бирә торган ирекә тартылу, уйларда гына булса да ерак офыкларга барып кагылу теләге дә бетте. Күктә очмагач, канатларның да, җирнең дә кирәге шулкадәр генә кала икән, кадере китә. Җир гомер беткәнне көтеп басып-атлап йөрер өчен генә файдалы урынга әйләнә дә кала.

Тавык куначадан биеккәрәк оча алмый. Караңгы кетәклектә ябылып ятса, аның күзләре дә күрми башлый, диләр.

Мин әле күрәм бугай. Бәхет шул, күрәсең. «Бәхет китабы»на язарлык бер бәхет, димме, бар бәхет, димме, шул».

### 9

Без бит бер җөйгә укмашкан дүрт күзәнәк идек.

Бөтенләй күрми башлаганчы дип, иманлы «костюмны» юллап киттем. Хастаханә регистрациясендә утырган кызлар табарга булышты. Карточкасына карап, кайда

эшләгәнен әйттеләр. Шәхси эшкуар ярдәмчесе булып чыкты. Әмма офистагылар аның өч-дүрт ай элек эштән чыгуын җиткерделәр. Шунда берсе, рәхмәт яугыры: «Авылга кайтып китмәде микән, берәрсе ашка чакыргандыр», – дип сүзгә кысылды.

Авыл кибеттән башлана. Бигрәк тә анда мәчет ае күрмәсәң. Кибеттә сатучы һәм тагын ике карчык үз сүзләренә шулкадәр бирелгәннәр, кемдер кергәнгә игътибар итәргә уйламыйлар да. Шундагы юк-бар әйберләрне караштырган булып, сүзләренә колак салдым.

– Нижнекамнан кызларын үле килеш табып кайтаргач, бөтенләй бетештеләр шул.

– Хөррәттәй алдан китмәсә дә, болай ук гыйбрәткә калмас ие.

– Чынлап кортлаганмыни?

– Соң, шуны сөйләп торабыз лабаса, озата барган картлар мәет артыннан кортларын чүпләп барганнар дие.

– Кит инде! Әллә нәрсәләр сөйләп торма! Уф...

– Бер атна ятсаң, кортламассың, кортламай ни!

– Кит!

– Соң күршеләре дә кермәгәнме?

– Кемгә кем кирәк хәзер! Балаларның исәнлеген бирсен инде.

– Ярый әле, имам кайтып җитте, үзе юган, үзе ясин чыккан, кортларын да ташлатмаган, үзе тутырып куйган ди мәет янына.

– Әстәгем, нигә?!

– Алар мәетне ашаган, бергә күмелергә тиеш дип әйткән ди...

– Ярар, авылдан мәет чыккан көнне гайбәт сатып тормыйк инде. Сәгыйть абзыйның кешегә әллә ни зыяны тигәне булмады. Авыр туфрагы җиңел булсын. Хөррәттәй күптән көтә иде инде аны... Монда кеше кулларына калып, урын өстендә ятканчы, тизрәк китүең.

– Шулай, шулай...

Кибеттән әбиләрдән алдарак чыктым да шунда ишек төбендә көтеп торырга булдым.

Күп тә узмады, карчыклар сөйләнә-сөйләнә кибеттән чыгып җиттеләр. Аларны сүзләреннән бүлеп, мәчетне сорадым. Урам башындагы бер өйгә таба төртеп күрсәттеләр. Шул тарафтан манара эзләдем.

– Манарасы күренмиме соң моннан...

– Безнең авыл мәчете манарасыз, балам. Аптырама, бар, бар. Шул безнең мәчет. Имам шәһәрдән кайтып йөри. Үзенең әти-әнисе йортын мәчет итте. Әле зираттан кайтып җитмәгәннәрдер. Җомга намазы вакытына чамалап барсаң, шунда булыр. Җомгага ярты сәгать чамасы бардыр әле барын, – диде карчыкларның берсе.

Карчыклар кибет каршындагы тыкрыкта юк булдылар. Кибеттән су алып чыктым да, мәчет урамындагы бер өйнең капка төбенә утырып вакыт уздырдым. Ул арада акрын гына кыймылдаган берничә бабайның мәчеткә кереп киткәне күренде. Бераздан тыкрыктан тагын берничә бабай күренде. Шуннан соң гына мәчеткә таба атладым.

Мәчетнең элекке авыл өеннән бернинди аермасы да юк иде. Тәрәзәләренә кыска ак пәрдәләр elenгән, буялмаган яңа агач идәнендә җылы келәмнәр... Түрдә мөнбәр булуы гына мәчеткә кергәнне искәртте.

Мулла мөнбәрнең беренче бусагасына утырган да китапка оеган. Беркемнең сәламенә җавап бирми. Бабайлар исә сәлам ишетмәүләрен үзләренең колаклары каты булганга сылтапмы, бер дә аптырашмый гына тезелеп утырдылар да тынып калдылар.

Ачык калган тәрәзәдән җиләс җил исә, пәрдәләр белән уйный. Хатын-кызларга

дигән урындыр дип чамалап, мич янындагы чаршау белән капланган аралыкка кереп утырдым. Тартылып бетмәгән чаршау артыннан мөнбәр тирәсе уч төбендәге кебек күренә иде. Алда хәзрәт китабына чумып нидер укый. Бабайлар аңа карап тын калып көтәләр. Әллә хәзрәт кычкырып укый, ә бабайлар бирелеп тыңлыймы? Мин генә, бәлки, берни дә ишетмимдер? Бу кадәр тынлык басмас иде! Инде бит биш-ун минут узды! Хәтер кабат табиб әйткәннәрне кычкырды: «Кемдер ишетми башларга да мөмкин...» Бермәл үземнең ишетми башлавыма ышанып, бөтен җанымны курку били башлады... Мәчеткә атылып кергән яшүсмер малай коткарды. Ул кычкырып сәлам бирде дә алга ук барып чүгәләде, һәм аның мулла колагына пышылдаган сүзләре тып-тын калган мәчет эченә яңгырап таралды.

– Әти, ачуланма, яме! Азан тавышын ишетми калганмын.

Бабайлар бер-берсенә карап, урыннарында кыймылдашып куйдылар. Арадан бераз яшьрәгенең тавышы чыкты:

– Ишетмәгәнгә ике азан әйтмиләр.

Аннары картрак абзый кырыс кына әйтеп куйды:

– Азан бит әле булмады, улым. Без ашыгыбрак килгәнбез бугай. Әтиең дә әйтергә ашыкмый.

Малай бер әтисенә, бер бабайларга күз төшергәч, нидер аңлап алды кебек. Башка сүз әйтеп тормыйча, кыйблага карап азан әйтергә басты.

...Бабайлардан бераз соңгарак калдым. Әле аларга да, азан әйтеп, аннары намазын укыгач та чыгып йөгергән малайга да бер хакыйкать барып җитмәгән иде. Мулла бит азанны ишетмәде. Ул бабайларны да ишетмәде.

Ул бары гыйбадәтне хәтереннән генә башкарды. Намаз укыды, дога кылды, кул биреп саубуллашты. Башкаларга ишетми башлавын сиздермәде. Әле ул үзе дә бу хакта белмидер...

Барыбер бу хәлгә ышанасы килмәде. Чаршау артыннан чыктым. Су алганнан соң кесәмдә калган унлыкны капшап карадым да үзенә эндәштем:

– Хәзрәт, дога укытасым килә... Дүртебезгә дә... Хәзрәт, вакытыгыз булса...

Ул ишетмәде, тыныч кына бабайлар артыннан иярде.

– Хәзрәт, озакка түгел...

Борыл инде хет!

– Без бит бер җөйдә...

Колагы белән карап, авызы белән тыңлаган кеше ничек борылсын! Унлыгымны учымда бөгәрләгән килеш чүгәләдем, чөнки аягым калтыраудан инде басып торырлык хәлем калмаган иде. Әйтерсең, ул борылып карасын өчен үземнең бөтен җан көчемне бирдем. Әллә ниятем артык авыр булды да бар көчемне алдымы – хәлсезләнеп утырдым.

Бары тик әмирләр телсез калмасын, аналар балаларын беркайчан онытмасын дип сорап дога кылдырмакчы идем. Аннары 240 мең дә 851 укучыга багышлатмакчы идем догаларны...

Хәлем китеп утырган мәлдә авыл әбиләренең зурлап сөйләгәннәре дә исемдә кебек иде, иманлы «костюм«ның ишетми башлавында үзе гаепле түгеллекне дә беләм югыйсә, әмма, барыбер, мәчеттә дога кылдыра алмаудан күңелем өшеде.

Ун тәңкә сәдакамны калдырырга кулым тартмый чыгып киттем.

**10**

Без бер җөйгә укмашкан дүрт күзәнәк идек. Кер юу машинасы «ватылган» карт, иманлы «костюм», һава торышы «проблемасын» кайгыртучы ханым һәм 240 мең дә 852 нче укучы.

Без бер җөйгә укмашкан дүрт күзәнәк идек. Телен югалткан әмир, баласын оныткан ана, мәчет картларын ишетми башлаган имам...

Һәм җөйгә укмашкан дүрт күзәнәкнең тагын берсе – очмый торган кош, бәлки әле, ул – канатлары сынган рухтыр.

Без дөнья тәнендәге бер җөй идек. Дүрт күзәнәктән укмашкан бер җөй...

**11**

Ниһаять, берничә көннән, авылда йөреп кайтканнан соң, кабинет ишеген ачарга җөрьәт иттем. Иң тәүдә ишек төбендәге урындыкка «Бәхет китабы«н куеп калдырдым. Әйдә, башкалар да беразга гына булса да бәхет, өмет, мәхәббәт барлыгына ышансыннар.

Кабинетта исә бөтенләй башка, тегесеннән бик нык аерылып торган табиб утыра иде. Күп дигәндә, үзенә кырыклар бардыр, күзлеге генә бераз өлкәнәйтеп күрсәтә. Яшь өсти.

– Исәнмесез. Чакырган идегезме?

– Исәнмесез. Кем буласыз?

– Миңа... Безгә яңа вакцина кадаганнар ие. Шуннан соң беренче мәртәбә килүем. Монда башка табиб утыра ие, исемен оныттым, дип аңлатырга ашыктым.

– Ул табиб эшләми хәзер. Ә нинди соравыгыз бар?

– Юк. Соравым юк алай... Мине бит шалтыратып чакырдылар, шушы бүлмәгә керергә куштылар.

– Ә-ә-ә...

– Без дүртәү...

– Әйе, әйе, беләм.

Табиб башта серле генә елмаеп алды. Күзлеген салып өстәл читенә куйды да, аннары елмаюын яшерергә тырышкандай, кире алып киде. Аңа нигәдер бик кызык иде. Җитдилек сакларга тырышып сөйләп китте:

– Беләсезме, бу урында эшләгән табиб бераз ялгышкан, шуңа аны эшеннән алдылар. Ул сезгә гадәти вакцина кадаган, әмма башка бер тикшерелмәгән укол белән бутадым, дип ялгышкан. Бу хакта шул көнне үк аңлаган, шуңа, икенче көнне бит, тиз арада дүртегезне дә җыйдылар. Сез генә килмәдегез.

– Ничек алай?! Килдем мин! Балалы хатын танымыйча узып китте. Аңа табиб, хәтерең югалачак, дигән иде...

– Гомергә бер тапкыр күргән кешене икенче юлы танымау гаҗәп түгел.

«Бәхет китабы»нда дөрес язылган икән, чарасызлык белән чарасызлык чигендә дә бәхет табыла. Баласын онытмаган булып чыга бит, үзем дә сизмәстән сөенеп куйдым. Әмма әле табибка һаман ышанасы килмәде.

– Ә әмир... Бабай белән үзем сөйләштем бит. Ул, табиб әйткәнчә, сөйләшә алмый башлады. Теле көрмәкләнде...

– Сез теге инсульттан егылган картны әйтәсезме? Яшисен яшәгән... Тормышны күрмәгән түгел, күргән. Беребез дә мәңгегә килмәгән.

Шул мизгелдә кабат елга агымына баккандай булдым. Бер адым арасына. Төбендә агып китмәскә утырып калган, еллар дәвамында су агымы шомарткан ташларны шәйләдем. Әмир ташы – елга төбендә, ә теле журналда калган икән, бәгырькәемнең... Дога да укыта алмадым.

Иманлы «костюм» искә төште, ул бит ишетми башлаган иде. Аны да үзем күрдем. Табибка тизрәк аның турында әйтергә ашыктым:

– Без бит дүртәү идек. Тагын урта яшьләрдәге ир бар, ул ишетми башлады.

Табиб, «тәмам туйдырдың» дигән кыяфәт чыгарып:

– Бәй, ул укол кадаганчы ук ишетми, бездә күптәннән учётта тора. Дүрт ел инде аппарат кигәненә, авариядә зыян килгән. Син күргәндә аппаратын йә оныткан булгандыр, йә салган булгандыр. Әле күптән түгел Германиядән яңа төр аппарат кайтартты. Ул сиңа, миңа караганда да яхшырак ишетә, – дип куйды.

Уф... Чын мәгәр, тавык икәнсең! Караңгы кетәклектә озын-озак утыргач, дөнья яктысын күрми башлаган тавык баш! Барысын күрәм дип йөргән була әле! Ун сум сәдакасын кызганган башы белән!

...Без бер җөйгә укмашкан дүрт күзәнәк идек. Ярый, без әле бер көнне генә бер ноктада очраштык, дип әйтим. Ярый, бүген генә юллар чатында табыштык, дим. Ярый, бу атнада очраклы хәл аркасында бәйләндек, диик. Әмма, чынлыкта, без – бер көнне дә, бүген дә, бу атнада да түгел, әллә кайчан бер җөйгә укмашкан күзәнәкләр. Тере һәм үле күзәнәкләр. Бәхетле һәм бәхетсез күзәнәкләр. Иманлы һәм милли күзәнәкләр. Язучы һәм укучы күзәнәкләр. Ташка әйләнгән һәм канатсыз күзәнәкләр.

Дөнья тәнендә җөйләр күз алдына да китермәгән исәптә, берләре бетә, эзсез югала, икенчеләре зурая бара. Иң гаҗәбе һәм тетрәндергәне – үзләре бер җөй хасил итәрдәй күзәнәкләрнең таш булып утырганнары...

Уйларымнан табибның көр тавышы бүлде:

– Кайгырмагыз, бар да тәртиптә. Ну, әгәр дә инде моральный ущерб түләтергә уйласагыз, ансы – сезнең хокук. Түләтегез, рәхәтләндереп.

Ничектер, бу яшь табиб үзен егетләрчә тотмады кебек. Әле хезмәттәшеннән көлде, әле бездән, димме. Шушы уй күңелгә яшен утыдай атылып керде дә янгынга күмде. Ачу утын кабызды.

– Моральный ущербмы?! Баш әмир үлгән! Менә шушы рухи зыянны күтәрә аласызмы? – дип кычкырдым. Табиб телсез генә түгел, аңламыйча, шүрләп үк калды. Шулай да үзен тиз кулга алды. Сөйләшү беткәнне аңлатып, урыныннан торып басты.

– Үзегезгә карагыз.

Аның тынычлыгы тагын да күңелгә тиде. Әмма диварга кычкырудан ни мәгънә?! Аты-юлы белән сүгенеп чыгып киттем.

Ишек төбендәге урындыкка күзем төште, буш иде. «Бәхет китабы»н шул арада тагын кемдер әләктереп киткән, күрәсең.

## 12


Бармаклар клавиатура буйлап йөгерә, Төркиядә Казанны сагынып ятучы дустым белән язышам.

– Син дигәнчә булмады инде. Кытайларга түгел, кошларга яздым. Күкләрне, дөньяларны иңләгән һәм җир кадерен белгән кошларга.

– Ок! Аерма юк!

– Шунысы бар: җөйгә укмашкан дүртенче күзәнәкнең берсе – кемдер, төгәл генә үзем дә белмим. Бәлки, ул – канатлары сынган коштыр... Бәлки, бәхет эзләгән җандыр. Бәлки, елга агымының бер адым арасына бага алган бәндәдер... Бәлки, 240 мең дә 853 нче укучыдыр...

Булат
Ибраһим



# КАЙНАРЛЫК БӨРКЕЛСЕН РУХЫҢНАН

## Татар рухы һәм каләм

Болгавыр заманда
Котыра бураннар,
Җил дулый калада.
Кайгыдан туепмы,
Салкыннан куркыпмы,
Ай улый далада...

Салкыннан курыксаң,
Тумавың хәерле,
Ә тусаң –
Кайнарлык бөркелсен рухыңнан.

Рух, диләр.
Кайда ул?
Татарның нык рухы ул кайда?
Җәлилдәдер, бәлкем,
Исхакый саклыйдыр,
Асрыйдыр аны Тукай да.

Татарның нык рухы сизелә каләмдә:
Кылыч күк яра ул болытны.
Татарның рухы бар,
Бар аның каләме –
Син шуны, татарым, онытма.

Булат ИБРАҺИМ (1990) – *шагыйрь; «Балык теле», «Шагыйрь-Поэт» исемле китаплар авторы. «Йолдызлы билет» халыкара премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## 1887-1926-1938

*Сулап туймас кебек идем*
*Туган ягым һавасын.*
*Бер мосафир булып киттем,*
*Эзләп Казан каласын.*

Авылда хәбәр таралган:
«Эһ, каһәр суккан бала,
Әткәй фатихасын алмый
Казанга китеп бара.
Кем көтә, дип беләсең син,
Сине, Гали малае.
Казанда тулып ята бит
Үз ярлы-ябагае».

Бер, сигез, сигез, җиде,
Шул елда туган иде.
Кәрим атлы бу егетне
Зур юллар көтә иде.
Тиенгә кушып тиенен,
Укыйсы килә, дия.
Ишекләрен ачты аңа
Ул чак «Мөхәммәдия».

Болгавыр заман, болгавыр,
Бер әйләнә, бер баса.
Вазгыять илне бугазлый,
Син басмасаң – ул баса.
Мосафирлар арасына
Мосафир булып кереп.
«Үзбәк» дигән ут кабынды,
Җиһанны нурга күмеп.

Бер, тугыз, ике, алты,
Әй, халык, ишетәсеңме:
Шахтадан Булат кайтты,
Зәңгәр шәл алып кайтты.

Кариевтан калган йөзек,
Ялтырый бармагында.
Заһидәсе саклап килде,
Иң авыр чакларында да,
Иң кыен чакларында.
Көзнең караңгы төнендә
«Юкә чәчәк атканда»…
Ул җуймады «Мәрҗәннәр»не
Хәтта кояш батканда.

Бер, тугыз, өч һәм сигез,
Эх, артык тыйнак идең син.
Сәхнәдә пәрдәң төшкәнне
Бик соң гына белдек без.
Бер,
Тугыз,
Өч
Һәм сигез…
Күпме
Ел
Инде
Синсез…

## Дәүләт, Халык һәм Ватан

Кит әле,
Буталып йөрмәле.
Әнә, бас читкәрәк,
Чиратың җитәрәк,
Чакырырмын үзем,
Килерсең.
Ватаның түгел бу,
Бу – дәүләт.
Рәхмәткә алданып
Көтмә син Безләрдән
Мәрхәмәт.

Әлегә син нигә?
Яңгыр юк,
Болытлар куермый.
Бүреләр өере тормыйлар чикләрдә.

Син нигә, әйт әле, әлегә?
Син нигә?

Берәр көн боз явып
Туң итсә бу җирне,
Түзалмас ясалма бөекләр.
Туң булган дәүләтне уратыр
Ачлыктан котырган бүреләр.
Шулвакыт ватаның
Кабаттан чакырыр...
Ярдәмен сорар ул халыктан.

Ватылган тагарак янында калганда
Чакырыр,
Ялыныр ул дәүләт.
Ә халык –

Җанында горурлык хисләрен саклаучы,
Ашкыныр кылырга мәрхәмәт.

Әлегә син нигә?
Яңгыр юк,
Болытлар куермый,
Бүреләр өере тормыйлар чикләрдә.
Әлегә син нигә?
Син нигә?

Челләдән сусаган,
Күләгә читендә,
Син торасың, халкым,
Әй, халкым.
Ә дәүләт нигәдер
Күрергә ашкынмый,
Күрергә теләми үз халкын.

***

*Бүген төнлә минем Җирем үлде.*
*Бик авырып үлде Җир шары...*
*...Бүген төнлә минем Җирем үлде,*
*Сез, кешеләр, кайда идегез?*
К.Сибгатуллин

Белмим, тик сизенәм,
Гомер язы түгел иде аның.
Гомер көзе, бәлкем, кышы,
Ә, бәлкем, язмышы
Алып китте аның җанын.
Һәм ул үлде,
Үлде...
Рәнҗеп үлде,
Каргап үлде безнең күбебезне.
Бүген төнлә минем Җирем үлде.
Бик авырып үлде Җир шары...
Үпкәсендә аның төтен иде,
Чирле иде аның йөрәге.

Заман дигән үткен кара пычак
Теткәләде аның күкрәген.
Бүген төнлә минем Җирем үлде,
Сез, кешеләр, кайда идегез?
Ә ул сездән ярдәм көткән иде,
Ә сез бары аннан көлдегез.
Кеше тәнле сәерләнгән затлар,
Күзсез затлар үтерде аны.
Үз рухына ясин чыгарга дип
Төн кунарга калды ятим җаны...
Бүген төнлә минем җирем үлде,
Бик авырып үлде Җир шары...
Күңелемдә бер кайтаваз кебек,
Ишетелә рәнҗеп елавы.

***

Сугыш бармый кебек,
Сәбәп тә юк кебек сугышырга.
Безнең илдә бар да тыныч, диләр,
Салмак көйләр уйный,
Тезелешкән матур өйләр,
Этләр улый,
Исерек абзый кайтып килә
Дулый-дулый.
Сугыш бармый кебек.
Сугыш инде күптән беткән.
Аны күргән сугышчылар
Әрнеп сөйли,
Тимер эри иде, диеп,
Ә кайчакта тән белән җан
Кар астында үлә иде туңып, диеп.
Әрнеп сөйли алар.
Алар...

Ә аларның бик күпләре
Сөйләми дә калган.
Ә аларны якыннары
Сөялмый да калган.
Бик күпләрен.
Ә кемнәрдер эзсез югалганнар,
Бер хәбәрсез юл алганнар чиксезлеккә.
Ә кемнәрдер җиңү алып кайтып,
Җиңелүче булып мескенлектә...
Әле һаман...
Сугыш бармый кебек,
Сәбәп тә юк кебек сугышырга.
Безнең илдә бар да тыныч, диләр,
Тик нигәдер шушы тынычлыкка
Этләр улый,
Исерек абзый кайтып кılә
Дулый-дулый...
Сугыш бармый кебек.

## Рокси, Рокси...

*В Китае сын миллиардера купил*
*своей собаке две пары часов Apple,*
*каждая из которых стоит £800.*
The Daily Mail.

Ә Роксиның бүген туган көне,
Ә Роксиның олы бәйрәме.
Тау-тау булып зур бүләкләр килә:
Сәгать, зәркән, чәчәк бәйләме.
Нигә инде бу бүләкләр сиңа,
Син әйт әле, Рокси, әйт әле.
Кунакларың әнә шәраб эчә,
Син эчмисең, син бик яшь әле.
Алар сиңа бәхет-шатлык тели,
Саулык тели алар ихластан.
Син аларга усал караш белән
Утырасың каранып астан.
Рокси, Рокси, ә син беләсеңме
Җирдә күпме кеше барлыгын?
Һәм шул кешеләрнең бик күбесе
Эт тормышы алып баруын.
Рокси, Рокси, без ирекле кебек,
Тик безнең дә бар бит хуҗалар.
Туган көннәр безнең, кызганычка,
Бигрәк артык тыйнак узалар.
Рокси, Рокси, ә син «һау-һау» диеп,
Гел өрәсең әле хуҗаңа.
Ә без менә усал бер караш та
Ташлаган юк югыйсә аңа.

# ТУРГАЙЛАРНЫҢ ТУГАН ЯГЫ

Мәгълүм ки, бу фани дөньяда адәм баласы һәрбер җан иясе кебек, туа-тумыштан, әйләнә-тирәсендәге һәр күренештән үзенчә мәгънә эзләп, яңа тәэсирләр тапкан булып көн кичерә. Кош-кортлар, хайван-бөҗәкләр дөньясында һәр яңа күренешне аңлау, үзләштерү үзенә бер төрле яшәү, исән калу мәктәбе буларак санала – тик белгәннәр генә исән кала. Моңа артык гаҗәпләнәсе дә юк – яңалыкны тою, үзләштерү сәләте тереклек ияләренең һәркайсына Табигать-анабыз тарафыннан салынган. Кеше дә көндәлек котылгысыз тормыш мәшәкатьләренең бертөрлелегеннән арынырга теләп, яңалыкка омтылып яши – берәүләр яңа очрашулар эзләп, турист сыйфатында ил гизәргә чыгып китә, икенче берәүләр, әле тузарга өлгермәгән булса да, инде кия-кия туйдырып бетергән кием-салымын алмаштырырга керешә, йорт-җирен яңача үзгәртеп кора – көнкүрешендәге аз-маз яңалыгыннан да тәм тоеп яши.

Сәнгатьтә, әдәбиятта яңа һәм үз сүзен әйтә белүчеләр генә олы ихтирамга лаек. Шушы уңайдан инде прозабызга күз салыйк. Гомумән алганда, бүгенге татар прозасының зәгыйфьләнә баруы турында сөйлибез икән (ә бу сүзләрдә, чыннан да, хаклык бар һәм аның үз сәбәпләре дә билгеле), бу, иң беренче нәүбәттә, заман темасына багышланган әсәрләрдә эчтәлек һәм тема материалларының, стиль-композиция алымнарының эчпошыргыч бертөрлелегендә һәм кабатлануында чагыла. Бу өлкәнең мәйданы артык зур булмаганлыктан, кимчелек күзгә аеруча ташланып тора. Язучыларыбызның күбесе заман темасыннан, бигрәк тә аның һәркемгә җиңел аңлаешлы реалистик юнәлешеннән читләште. Әдәбиятта ат уйната торган әдипләребезнең күбесе башлыча тарихи темаларны яктыртуга күчте (мәсәлән, Марат Әмирханов, Вахит Имамов, Рабит Батулла, Ркаил Зәйдулла, Солтан Шәмси һ.б.), кайберәүләр авангардлык һәм модерн агымнарына мөкиббән китеп, мистик күренешләрне аеруча үз итәләр яисә әсәрләрен халык авыз иҗатыннан һәм борынгыдан килгән легенда-риваятьләргә нигезлиләр (Галимҗан Гыйльман, Зиннур Хөснияр һ.б.). Кайбер белгечләр монысын да реализм киртәләренә урнаштырырга теләп, бу күренешне метафизик реализм дип атыйлар *(А.Шамсутова. Татар әдәбиятында яңарыш. – К.: Татар.кит.нәшр., 2010 )*. Без бу урында башка төрле – ягъни саф реализм турында сүз йөртәбез. Шул рәвешчә, бүгенге татар реалистик прозасының яшәү даирәсе тагын да тарая төшә. Бу урында әле яңа гына мәктәп яисә вуз тәмамлап, олы прозага аяк басучы яшь каләм ияләрен вакытлыча һәм шартлы рәвештә чигереп торабыз – шөкер, берән-сәрән булса да, андыйлар да күренә башлады (Рөстәм Галиуллин, Рүзәл Мөхәммәтшин, Алмаз Мансуров һ.б.) Аларның әйтәселәре алда әле.

Менә шундый, безнең тарафтан шартлы рәвештә киртәләп куелган бүгенге реалистик әдәбият кишәрлегендә язучы Камил Кәримовның иҗат тәҗрибәләре шактый кызыклы, гыйбрәтле һәм нәтиҗәле тоела. Бу иҗатның кайбер үзенчәлекләренә галим филологлардан Рүзәл Юсупов, Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Фәрит Яхин, язучы Рафаэль Мостафин, Фоат Садриев, Рабит Батулла һ.б.лар игътибар итте. Әмма комплекслы, һәрьяктан эзләнүләрне эченә алган башка хезмәтләрне безгә әлегә очратырга туры килмәде. Хәлбуки, бүген бу могтәбәр сүз художнигының иҗатына җентекләбрәк күз салыр вакыт бик җиткән дип беләбез.

Бик күпләр яңа китапларны кулларына бер тойгы – һәр гадилектә яңалык, шуның аша үзеңне күрү теләге белән алалар. Ә җимне безгә талантлы әдипләр бирә. Менә шундый каләм осталарының берсе ул Камил Кәримов – ул һәр романы белән безне

# МИЛЛӘТНЕ ХӘТЕР ВӘ РУХ ЯШӘТӘ

**Дөресрәге, аны хәтер һәм ата-бабалар рухы аша тәрбияләнгән югары милли аң яшәтә. Фаҗигале үткәнебездән бу бик тә ачык күренә. Чыннан да, бәгъзеләр, татарның чын тарихын бозып һәм каралтып күрсәтеп, ничек кенә аның иманын какшатырга, рухын сындырырга һәм хәтереннән яздырырга тырышмасын – моңа барыбер ирешә алмады. Чөнки тарихи хәтер һәм ата-бабалар рухы, аның канына сеңеп, геннар дәрәҗәсендә, нәсел күзәнәкләре аша сакланып калган. Шуңа күрә, язмышның гаҗәеп дәрәҗәдәге авыр сынауларына да карамастан, милләт һаман да исән, яши һәм, Ходай насыйп итсә, алга таба да яшәр. Ул гына түгел, татар рухы бүген яңарыш та кичерә. Көлдән яңарган феникс кошы кебек, милләт кабат алгарышка юл тота.**

**Ә менә иҗтимагый фикерләү дәрәҗәсенә килгәндә, ул әлегә андый югарылыкта түгел. Чөнки моның өчен халыкның югары кимәлдәге (әлеге миссияне танырлык дәрәҗәдәге) милли аңга ия булуы таләп ителә.**

**Югары милли аң тәрбияләүдә, әлбәттә, гомуммилләт дәрәҗәсендә үткәрелә торган чаралар да гаять зур әһәмияткә ия. Рухи вә милли-мәдәни маяклар ролен үтәргә тиешле андый чаралар, милләт тарихындагы мөһим вакыйгалар яисә аның күренекле шәхесләре белән бәйләп үткәрелгәндә, нәтиҗәләре күпкә югары булачак. Ә татар халкы гомуммилли әһәмияткә ия булырдай вакыйга вә чараларга бик бай: һәр елны 26 апрельдә үткәрелә торган «Шигырь бәйрәме», җәй башына туры килә торган «Сабан туе», 30 августта үткәрелә торган «Республика көне», октябрьдә билгеләп үтелә торган «Хәтер көне» һ.б. Андый чаралар ел дәвамында һәр айда үткәрелсә дә артык булмастыр. Әмма, аңлашыла ки, алар югары һөнәри дәрәҗәдә, ата-бабаларыбыз рухына туры китереп һәм тирән эчтәлекле итеп үткәрелгәндә, шулай ук татарлар яшәгән барлык төбәкләргә дә барып ирешерлек итеп киң яктыртылганда гына милләт ихтыяҗларына җавап бирәчәк.**

**Ә элгәрләребез борынгы ата-бабаларыбыз рухын хасият белән, югары дәрәҗәдә саклаган, алар исеменә бервакытта да тап төшермәскә тырышкан. Үз тарихыңны һәм нәсел-нәсәбеңне белү, халкыңның гореф-гадәтләрен һәм сәнгатен тирәнтен өйрәнү алар өчен горурлык чыганагы саналган. Мәгълүм ки, Азия һәм Аурупа киңлекләрендә татар теле гомумаралашу теле дә булып хезмәт иткән. Ә үз нәселеңнең сәламәтлеге һәм затлылыгы турында кайгырту элгәрләребезгә рухи вә физик яктан сәламәт булып калырга, өзлексез чыныгырга һәм камилләшә барырга ярдәм иткән, җәмгыяви үсештә яңа үрләр яулау өчен этәргеч биргән. Шуңа күрә нәсел турында кайгырту һәм яшь буынны ата-бабалар рухында тәрбияләү алар өчен һәрчак изге бурычлардан саналган. Шан-шөһрәт элгәрләребездә байлык белән түгел, ә рух югарылыгы һәм иман ныклыгы аша билгеләнгән, кешенең таланты, тырышлыгы һәм кылган изге эш-гамәлләре белән үлчәнгән. Әлеге рухи кыйммәтләр милләт алгарышы өчен бүген дә өлге булып тора.**

**Фоат УРАЗАЙ**

гел яңалыкка ымсындыра, уйланырга чакыра һәм... бер генә очракта да өметләребез акланмый калмый. Яңалык төшенчәсен бик зурдан – әдипнең тормыш позициясе, аның әдәбият үсешенә алып кергән зур өлеше итеп бәяләп тә була торгандыр. Әдипнең һәр әсәрендә гел үз сүзен әйтергә омтылуы – ягъни әнә шундый Яңалык феномены Камил Кәримов иҗатындагы әйдәүче категорияләрнең берсенә әверелә – тәҗрибәләре, язганнары әсәрләренең бар тукымасына, күзәнәкләренә тарала – хәтта ниндидер яңалык доминантын тану аркылы кабатланмас иҗат стиле турында сүз башларга мөмкинлек бирә.

Камил Кәримов яңа гасыр бусагасын атлап керүчеләргә «Ком сәгате» романын бүләк итте. Романнар күгендәге шушы беренче карлыгач әдип иҗатында яңа циклның башланып китүе – инде кайчандыр яшьлек елларында туган «Мәхәббәт чокыры» хикәясе авторының башка югарылыкларга күтәрелүен үзенең укучысына хәбәр итүе иде. Шуннан соң бер-бер артлы әлеге романның дәвамы булган «Сакау күке», роман-фарс дип уйланылган «Игезәкләр йолдызлыгы», эстрада артистлары тормышына багышланган «Уен» һәм роман-элегия дип аталган «Тургайлы болытлар» романнары дөнья күрде. Үз укучысына дип әйтүебез дә очраклы түгел бу урында – чөнки үз укучысы булырга язмаганнар бу әсәрләр яныннан илтифатсыз һәм салкын битарафлык саклаган булып, «әй, беләбез инде Камил Кәримовның кем икәнлеген – сәхнәдә юмор сөйләгән булып, кеше көлдереп йөрүче нинди романчы булсын ул?» дип уйлаучылар нык ялгышырлар. Аның каравы, башка бик күпләр, укый башлаганда бераз сәеррәк тоелган (чөнки бүтәннәр язганча түгел?!) мондый китапка бераздан тәмам мөкиббән китеп, башларын күтәрә алмыйча утырырлар. Мин үзем дә шул соңгылары рәтенә керәм бугай – тик, тәнкыйтьче буларак, миңа, хискә артык бирелеп, онытылырга ярамый – чөнки төп вазифам – җитди, төгәл һәм гадел анализ ясау.

Беркадәр гаҗәбрәк тоелган һәм парадоксаль синдром хакында да әйтмичә булмый торгандыр. Әлеге романнар стихиясенә чумып, иҗатына дөрес һәм объектив бәя бирим дисәң, вакытлыча , билгеле бер мәлгә, Камил Кәримовның кем икәнлеген, тагынниләр белән шөгыльләнгәнлеген, ягъни аның үтә дә сәләтле журналист, концертларны бик җанлы, күңелле итеп алып баручы юморист-конферансье икәнлеген онытып торырга кирәк була.

Биш романының бишесе дә заман темасына багышланган – барысы да замандашларыбыз, кардәшләребез кичергән яисә бүген кичерә торган хәлләр турында. Моны үзенә бер төрле феноменаль күренеш дисәң дә ярый торгандыр – мин әдипнең гел заман хәлләренә ябышып, шулардан аерылмыйча язуы турында әйтәм. Бүгенгедән аерылмыйча, көнебезнең тәҗел мәсьәләләрен үзәккә куеп, аларны һәрьяклап өйрәнүче прозаикларыбыз хәзер юк диярлек, булсалар да, андыйлар бик сирәк. Калганнарын да аңларга була – заман кырыслыгына, кычкыртып талауга күндерелгән җәмгыятьтә яшәүче кешеләрнең, бигрәк тә мескенлеккә төшерелгән олы буын вәкилләренең хәлләрен бәян итеп, әдипләр-романчылар шуларны укучыларның күзләренә озаклап карап тора алмыйлар. Бу зур ихтыяр көче сорый. Ә менә укучыңны үзең белән тормышның бик еракта калган, романтик өрфиягә төренгән, истәлекләр сәхрасына алып китсәң, җан иркәләнә, рәхәтләнә, көндәлек хәсрәтләрең дә онытылып киткәндәй була. Шуңа күрә микән, бу алымнан тәҗрибәле романчыларыбыз бик теләп файдалана. Романнары да су буена сузыла.

Камил Кәримов андый отышлы кебек тоелган, ләкин инде нык тапталган юлларга басмый, фәкать үз акылын, үзе кичергән һәм күргәннәрен эшкә җигеп, яңа сүз – үз сүзен әйтергә омтыла. Шушы яктан аның криминаль фарс рәвешендәге «Игезәкләр йолдызлыгы» романы бик кызыклы, ул – язылышы, эшләнеше, стиле иҗтимагый, социаль яңгырашы ягыннан моңарчы күрелмәгән әдәбият үрнәге дип саналырга хаклы. Вакыйгаларның вакыт ягыннан алмаштыргалап, чиратлаштырып бирелүе шартлылыгын укучы бик җиңел кабул итә. Чөнки автор аны бүгенге көн җирлегеннән читләштерми. Ул вакыйгаларның ике яссылыкта тасвирлануын аңлап, күреп тора, тик аны бөтен әсәр дәвамында бер сорау борчый: ничек болай була соң бу? – әсәр башында журналист Нур Шәехнең үтерелүе турында хәбәр тарала – әсәр дәвамында

без геройның үз фаҗигасенә якынлаша баруын күзәтәбез – тик аңа кагылышлы фаҗига булмый кала: фарс законнары буенча төзелгән сюжетта, аңлашылмау аркасында, укучыга бөтенләй таныш булмаган берәүнең гомере киселә. Ә героебыз исән-сау гына, үзенең мәхәббәт кошына ияреп, каядыр чит илләргә тая. Әсәр тәмамлана – журналистның ничек үтерелгәнен белергә, күрергә нәүмизләнеп көткән, зарыккан укучыбыз, теге исемсез корбанны бөтенләй белмәгәнлектән, кайгырырга да өлгерми кала. Ул икенче бер нәрсәгә төшенә: алдашуны, ялганны өстен чыгарып яшәүгә күндерелгән тирәлектә ялгышулар, бер-береңне буташтырулар, шуның аркасында очраклы үтерешләр, гөнаһсызларның каны түгелү гайре табигый хәл түгел икән. Фарс жанрын һәм аның алымнарын эшкә җигеп, автор мондый хәлләргә карата үз сүзләрен шактый кыю әйтә алган. Мондый буташтыру алымнарының шактый драматик һәм кызыклы үрнәкләрен без Европа һәм татар әдәбиятларында элек-электән байтак еш күргәләп торабыз («Патша малае һәм хәерче», «Бергамодан килгән Труфальдино», «Швед шырпысы», «Хаҗи әфәнде өйләнә», «Галиябану» һ.б.). Ә Камил Кәримов бу очракта ялган детектив һәм фарсның кызыклы алымнарын бүгенге татар җирлегенә күчерүгә ирешкән.

Гомумән алганда, үтә дә оптимистик табигатьле, тормышның һәр мизгеленнән сөенеп, шатланып, күңел ачып яшәү тарафдары буларак, Камил Кәримов укучының да нәзакәтле сизгер күңелен фаҗигале һәм кан коюлы хәлләр, күренешләр белән җәрәхәтләмәскә, яраламаска тели – әсәрләрендә дә тормышның андый хәтәр якларыннан читләтебрәк узарга тырыша. Аның әсәрләрендә заманыбызның үзебезгә бик таныш яклары, хәтта кайберләребезнең яисә күбебезнең башларыннан узган хәлләр чагылдырыла. Әмма без ваемсыз, битараф кына яннарыннан үтеп йөргән хәлләр, вакыйгалардан да әдип мәгънәле нәтиҗә, яңача чагылышлар табып, күңелләрне җилкетә, күзләрне ача белә. Ә әсәрләренең эченә тирәнгәрәк кереп, мавыгып, бирелеп укый башласаң, халкыбызның сүз, тел байлыгының күпсанлы энҗе-мәрҗәннәренә юлыгасың, аларны үзеңнеке итәсең, йә күңел-фикер кесәләренә салып куеп, дусларыңа, фикердәшләреңә өләшәсең.

«Чорларның ызаны юк, чорлар арасындагы межаны сагыну дигән төшенчә билгели», «яшьлек ул – альбомнарда кала торган фото гына», «озаграк яшәгән саен, күбрәк югалтабыз», «җиңел килгән бәхетнең кадере юк аның», «яшьләр кулында яшәрерсең, карт кулында картаерсың», «әгәр өендә көтеп торучы кеше булмаса, ирләр бомжга, сукбайга әверелә», «ана кеше бала үстергән бишек кебек кенә ул, балаларың очып киткәч, бишекнең кирәге калмый», «без йозак күрми үстек» һ.б.лар. Хикмәтле сүзләрнең күбесе җиңелчә юмор белән өретелә: «кушканны кулының очы белән генә эшли», «хәзер кирәкле кешене хөрмәт итә беләләр», «бюджет акчасын капка төбенә җәйгән яңа байлар», «Хрущёв чәкчәк күргәч, «кукуруза что-ли?» дип сораган ди... Бүгенге татар укучысына бу гыйбарәләрнең мәгънәләрен шәрехләп торуның кирәге булмас дип уйлыйбыз. Канатлы сүзләр артында нәрсә ятканын һәммәбез бик яхшы белә. Камил Кәримов боларны гына аңларлык укучыларына исәп тотып яза торгандыр...

Әлбәттә, мондый мөнәсәбәт әдәби күренешләргә үзенчәрәк якынлашуны да күздә тота. Шуны аңлаган һәр укучы бу әдип иҗат иткәннәрнең тарафдары, якын теләктәшенә әверелә ала. Бу урында сүзне Камил Кәримовның кабатланмас, шактый ук оригиналь стиле барлыгын искә төшерәбез. Чыннан да, бу – тормыш тәҗрибәсен үзенә туплаган, аның асыл мәгънәсен фәлсәфи тирәнлегендә күрергә теләүче, халкыбыз теленең, сөйләменең нечкәлекләрен бөтен камиллегендә тоемлаучы художник стиле. Шулай гадәткә кергән инде ул: гадәттә әдәби күренешләрне бәяләгәндә төрле янәшәлекләр янына куеп карап, авторның үз иҗат билгеләрен эзлисең. Бу очракта да шулай. Камил Кәримов, күргәннәре-белгәннәренә таянып, гел үз юлыннан барырга, беркемне дә кабатламаска тырыша. Әмма яңа әдәбият беркайчан да буш урында туа алмый – әдәбиятка килүче, үзе моны телиме-теләмиме – инде күптән уелган эзләргә килеп төшә – монысы – котылгысыз хакыйкать. Әгәр дә аны үзебезнең һәм тугандаш халыклар әдәбиятлары күренешләре янына куеп, җентекләбрәк карасаң, Камил Кәримов язмаларында Фатих Хөсни, Андрей

Платонов, Михаил Зощенко, Василий Шукшин, Ильф һәм Петров кебек осталар иҗатларындагы аерым чалымнарны, телгә аеруча ихтирам һәм игътибарлылыкка нигезләнгән кайбер нечкәлекләрне танырга мөмкин булыр иде. Әлбәттә, бу урында сүз әдәбият корифейлары тапканнарны турыдан-туры кабатлау яки аларга иярү турында түгел, ә милли тел байлыгына, аның нечкәлекләренә, бизәкләренә аеруча нәзакәтле игътибарлылык турында гына бара. Нәкъ шушы фактор төрле һәм кабатланмас әдәби стиль ияләре – остазларның иҗатлары янәшәлегенә үзебезнең әдип тапкан ачышларны да куеп карау һәм өйрәнү мөмкинлеген бирә. Без мондый охшашлыкларның кайберләрен бәлки алдагы анализ барышында күрербез әле.

Бу анализ Камил Кәримовның аеруча күренекле әсәрләре – «Ком сәгате» («Сакау күке») дилогиясе, «Уен» дип аталган бәяны һәм «Тургайлы болытлар» дигән роман-элегиягә нигезләнер. Дилогиядәге Фазыл язучы Фатих Хөснинең мәшһүр герое Сәфәргалине дә («Җәяүле кеше сукмагы») хәтерләтә сыман. Ләкин характеры белән түгел, ә үткән юллары һәм язмыш борылышлары белән. Фазыл да шундый ук тар тормыш сукмакларыннан атлаучы мосафир ул, тик бүтәнрәк шартларда – әле күпләр хәтерендәге совет тормышы тирәлегендә аякка баса, егыла, сугыла, имгәнә-имгәнә үз-үзен табарга, аңларга тырыша. Көнкүреш казанында кайный торгач, ул күп нәрсәләргә төшенә, тормыш аны үзенчә талкый, сабакларын бирә. Беркатлырак Фазыл, үз күңеле саф, чиста булгач, теләсә кемгә ышанып та йөри. Әмма зирәк авыл малае буларак, тиешле нәтиҗәләрнең кайберләрен ясарга да өлгерә – тик барысын да түгел – бигрәк тә шәхси тормышында күп абыначак әле ул.

Геройларын, персонажларын әдип үзенә таныш һәм якын тирәлектән алырга тырыша, аларда, характерларда һәм вакыйгаларда шәхси биографиясенә кагылышлы әйберләр һәм элементлар да очрарга мөмкин – мондый якынлыкны автор үзе дә яшерми – тик шулай да бу әсәрләр саф автобиография дә, документаль проза үрнәкләре дә түгел. Шул рәвешчә, заман кешеләренең, геройларының тотрыклы моделе табыла. Төп герой – югары биеклекләргә омтылмыйча, яшьтәшләреннән, замандашларыннан аерылмыйча, гел гади булып калырга теләүче, намуслы, итагатьле, тәртипле кеше – ягъни совет һәм постсоциализм чорының беренче елларында күпләп тәрбияләнгән замандашларыбызның берсе.

«Без – социализмда яшәгән буын – иске машиналарыбызга төялеп капитализм дигән дөньяга килеп кердек. Димәк, без дип инде гомер көзендәге картлар исеменнән әйтәм. Без – социализмның соңгы малайлары». Әдип әнә шулар исеменнән сөйли. Язганда һәрдаим үз укучысын – үзенең лирик җанын һәм оптимистик җор күңелен, юмористик табигатен аңлардай чордашларын истә тота. «Ком сәгате», «Сакау күке», «Тургайлы болытлар» (беренче кисәк) романнарының буеннан-буена әнә шул герой үтә: һәртөрле кыенлык-каршылыкларны, эш-мәшәкатьләрен, гаилә-көнкүреш матавыкларын сабырлык белән кичерә ул, кешечә яшәп, өй-гаилә җылысын тоеп, кеше рәтендә эштә уңыш-дәрәҗә казанып яшисе килә аның. Ул – башкалар ничек көн итсә, үзе дә алардан бер ягы белән дә аерылырга теләмичә, ягъни гел кешечә булсын дип яшәүче намуслы, совет чынбарлыгында тәрбияләнгән ир-ат затындагы яшь кеше образы. Дилогиянең буеннан-буена үтүче Фазыл һәм «Тургайлы болытлар» романындагы автобиографик герой укучы күз алдына бер кеше, бер индивидуум булып килеп баса. Бәлки, укучы да бу шәхестә үзен, әйләнә-тирәлектә үзе күргән-белгәннәрне яисә шуңа охшаганнарны очрата торгандыр. Сораштырганым бар: күпләр «бу әсәрләрне укырга тотынсаң, аерылып булмый», диләр. Моның төп сәбәпләренең берсе шул охшашлыкта түгел микән?.. Әйе, мөнәсәбәтләрдәге аңлашылучан гадилек, янындагы иптәшләреңнең кайчан да таянычлы ышанычлы булулары – һәр коллектив әгъзасы, үзен җәмгыятьнең бер күзәнәге дип исәпләүче һәркем әнә шундый тирәлеккә ихтыяҗ кичерә. Бүген исә мондый сафлыкка ихтыяҗны бигрәк ачык тоясың.

Камил Кәримов үзенең әсәрләрендә соңгы елларда инде әдәбиятыбызның көн тәртибеннән төшерелеп, онытыла башлаган игелекле хезмәт темасын яңартып җибәрә.Тормыштагы муллыкка, яшәешнең чын хозурлыгына тик тырыш хезмәт аша гына ирешеп булуын һәркайсыбыз бик яхшы аңлый. Әмма хезмәткә мөнәсәбәт чорына, вакытына күрә үзгәргәләп тә тора. Шундый заман килде – бүген бик күпләр

өчен фидакарь эш, файдалы хезмәт дигән төшенчәләрнең кыйммәте, дәрәҗәсе кимеде – алдашулы базарга корылган җәмгыятьтә «эшләп кем баеган?», «үзләренә кирәксә, әнә җүләрләр эшләсен» дигән гыйбарәләр өстенлек итә башлады. Әлбәттә, бу – җәмгыятьнең барыбер кайчан да булса үтәчәк узгынчы чире. Моңа һич тә шигебез юк. Безне кызыксындырганы – моңа әдәбиятыбыз әһелләре ничек карый икән? Шунысы аянычлы: соңгы елларда әдәбиятыбызда да игелекле хезмәт, кешене кеше итүче тырыш хезмәт темасы ни өчендер арткы планнарга чигерелеп килә – татар прозасыннан бүген намуслы хезмәт каһарманнары образларын табу кыенлаша башлады. Аларны – хезмәттән ямь-тәм табып яшәүчеләрне, кыр батырларын, ферма алдынгыларын, нефтьче геройларны, кем әйтмешли, көндез чыра яндырып эзләсәң дә, бүгенге әдәбиятыбыздан таба алмассың. Тәнкыйтьчеләребез дә өстенлекне эштә уңганнардан бигрәк, эчке кичерешләрендә чамадан тыш хисчән, кичерешле, сызланучан персонажларга бирә башлады кебек. Хәер, бу соңгысын проза һәм әдәбият фәне өлкәләренә нечкә тойгылы хатын-кыз авторларыбызның күпләп пәйда булу тенденциясе белән беркадәр аклап та була торгандыр.

«Ир язмышы – ил язмышы» дигән канатлы гыйбарә һәркайсыбызга мәгълүм. Ул – һәркайсыбыз ил гамен, ил кайгысын тоеп яшәргә тиеш дигәнне аңлата.

Романнардагы баш герой Фазыл үзенең төп профессиясе итеп артезиан коеларын бораулауны сайлый, дистәләгән еллар дәвамында сусызлыктан корыган авылларда интегеп яшәүчеләргә саф сулы чишмәләр бүләк итә. Яраткан хезмәте аша аның яшәвенең мәгънәсе ачыклана, ә сулар һавасы булган кешелекнең икенче зур ихтыяҗы һәм ләззәте – эчәр суга автор герое белән бергә үзе мәдхия укый. Хәер, бу урында герой белән авторның үзара бик якын торулары турында да искәртеп китү урынлы булыр. Прототипны да еректан эзләп торасы юк – язучы үзе гомеренең иң зур өлешен нәкъ шул хезмәткә – Фазыл сайлаган профессиягә багышлаган. Гомумән, әсәрләрне фәкать үзеңнең күргәннәрең-белгәннәреңә генә таянып яки нигезләп язу – әдипнең төп иҗат кредосының иң әһәмиятле ягы булып саналырга хаклы дип тагын бер кабатлыйбыз. Әгәр дә Камил Кәримов язганнарның һәр юлыннан тормыш дөреслеге бөркеп тора икән – бәлки, аны нәкъ менә шушы фактор – лирик геройның авторның үзенә бик якын торуы белән аңлатып була торгандыр.

Әлеге якынлык вакыйгалар, сюжет охшашлыгында гына түгел, характерлар тәңгәллегендә дә чагыла. Бу урында замандашларының характер билгеләрен үзендәгеләре яисә якындагыларының сыйфатлары белән аралаштырып язарга яраткан мәшһүр рус әдибе Василий Шукшин тәҗрибәләре дә искә төшә. Әсәрләрендәге аның замандашлары – бераз сәеррәк, әмма ниләр беләндер мавыгып, тормышны үзләренчәрәк аңлап, үз кыйблаларына бирелеп, шул карашларымны яклыйм, шуларны саклыйм дип ышанып гомер итүчеләр. Камил Кәримовның да тормыш казанында кайнап, аның котылгысыз катгый кануннарына җиңел генә җайлашып яшәргә өйрәнгән ярымзыялы, ярымконформист рәвешендәге ир-ат затындагы хезмәт ияләре образлары да кайсыдыр яклары белән шул Шукшин геройларын хәтерләтәләр. Әмма бу татар балаларының характерларында Шукшин персонажларындагыча текә, креатив, башбирмәс бунтарьлыкның эзе дә юк. Алай булгач, уртаклык нәрсәдә чагыла соң? Характер типлары төрле, тик аларның һәркайсы халыктан, халыкның үз арасыннан, илне ил итүче, бар материал һәм сәламәт рухи байлыкларны булдыручы, әмма бүгенге көндә авторитеты, дәрәҗәсе калмаган гади халык катламыннан.

Чыннан да, бу милли характер ярсу Катунь елгасы буенда хөрлектә, иректә үскән рус баласыныкы түгел, ә тыныч агымлы ямьле Мишә буе чирәмнәрендә тәгәрәп, шук булса да, олылар, әти-әни, әби-бабайлар сүзеннән чыкмыйча, тыңлаулы, итагатьле бала булып үскән татар кешесенеке. Камил Кәримов әсәрләрендә бик күбәүләр бәлки үзләрен күрерләр, үз язмышларын яисә, һич булмаса, үз тормышларының кайбер чалымнарын танырлар дип тагын кабатлыйбыз.

«Сакау күке» романы биш бүлектән тора – аларның һәркайсы артезиан коеларын бораулаучы эшчеләр – шул эшнең белгечләре, осталары исемнәре белән аталган: Фазыл, Әмир, Шәйхи, Мәдияр, Текә Вәли. Геройларның һәркайсының үз язмышы, үз характер

сыйфатлары табылган. Бу бигрәк тә аеруча җылы язылган Фазыл, Әмир һәм Мәдиярга багышланган бүлекләрдә чагыла. Боларны укып, әлеге профессиянең нечкәлекләрен, кыен, уңай, тискәре һәм башка хикмәтле якларын, шунда эшләүчеләрнең психологик хәлләрен шактый тулы итеп күз алдына китереп була. Бу – үзе генә дә бик зур яңалык – әлегә әдәбиятларда бу өлкәдә эшләүчеләр тормышы турында язылган әсәрләрнең күренгәне юк иде әле.

Фазыл – әсәрнең төп герое – ул дилогияне композицион яктан бәйләп торучы образ буларак, әсәрнең буеннан-буена үтә... Аны заманыбызның Дон Кихоты дисәң дә була торгандыр. Ул да – Сервантесның мәшһүр герое сыман, һәрчак юлда, сәяхәттә. Тик аның аты – Росинанты гына юк. Аның каравы фургоны – яшел вагоны бар – аны теләсә кайсы машинага тагып, илләр, юллар гизеп була. «Бөтен яшьлегем шушы вагонда үтеп китте. Эш урыным, клубым, китапханәм, нигезем, гаиләм дә шушы вагонда... Инде улым үсеп җитеп, утка-суга керердәй егет булгандыр; ә мин һаман вагон карачкысы...» Бораулаучылар бер урында гына торып эшли алмыйлар – эшнең үзенчәлеге шундый: яңадан-яңа урыннарда артезиан коелары ачарга кирәк. Инде илле яше тулу белән, пенсиягә озатсалар да, Фазыл илне үзгәртеп кору елларында шул бригада вагонын үзенеке итеп хосусыйлаштыру җаен таба һәм аны ташбака кабыгы кебек, үзеннән калдырмыйча, очраклы машиналарга тагып өстерәтеп йөри – шуның белән аңа төп профессиясенә яңадан әйләнеп кайту мөмкинлекләре дә ачыла.

«Юл – өмет ул! Юл – маҗара! Юл – гомер! Юл – эзләнү!..» «Ах, бу юллар... Сәфәр чыксаң, адәм баласын шайтан өермәсе кебек бөтерә дә ала». «Балалар, олы юлда уйнамагыз, юл алып китәр!..» «Әниләр тагын нидер кычкырып кала, тик инде без ишетмибез...»

Камил Кәримовның хисси герое гомере буена үзенең язмыш салган юлларыннан атлый. Юллар – очрашулар, ә һәр очрашу яңа таныш, яңа кешеләр белән аралашу дигән сүз. Фазыл, Сервантес романының мәшһүр герое кебек, үзенең Дульсинеясен эзләп йөри. Әсәрләрдәге лирик линия – мәхәббәт темасы аеруча ягымлылык, җылылык белән сугарылган. Хатын-кызлар образлары роман өлешләре булган новеллалар циклын хасил итә. Бу новеллалар тезмәсе, тормыш юлындагы маяклар кебек, геройның гомер юлын яктыртып, бизәп тора. «Ком сәгате» әсәренең һәр бүлегенә бер гүзәлнең исеме куелган. Менә алар: Зөмәйрә, Фәризә, Хәмдия, Әлфинә, Суфия, Динә, Язилә һәм Галина. Һәр героиня яисә персонаж үзенә генә хас характер сызыклары яки язмышында юлыккан хәлләре, маҗаралары белән укучының хәтеренә тиз урнашып кала. Бу яктан Камил Кәримовны хәрәкәтчән яки динамикалы портрет ясау остасы дисәк тә, һич тә ялгышмабыз.

Татар классик әдәбиятында мәхәббәттә яшьлек хатасына юлыгып, алданып, шуны кичерә алмаган яисә тормышлары бозылып, җүнсез юлга баскан яшь кызлар образлары күп очрый. Камил Кәримов әсәрендә исә булачак гаилә тормышын җимерерлек хатаны егет үзе ясап, үзе алдана. Тәҗрибәсезлегеннән файдаланып, саф күңелле, беркатлы Фазылны тизрәк язылдырып, өйләндерергә керешәләр. Ә тегесе, хатаны төзәтә алмавыннан гаҗиз булып, башын комга тыккан страус хәлендә кала, проблемадан качам дип, яңа маҗараларга, очрашуларга, тагын хаталарга тап була – мондый сюжет сызыгы юмористик һәм лирик яңгырашында дилогиядә һәм «Тургайлы болытлар»да төрле вариантларда кабатлана.

Дилогиядәге Әмир карт, кызы Язиләне тизрәк кияүгә бирәм дип, рәсми никахлаштыру актын, авылга кайтып тормыйча, артезианчыларның мәгълүм яшел вагоны янында башкарырга ниятли. Менә әсәрдән бер өзек:

«Маңгаена «Агыйдел» дип язылган «Кубань» автобусыннан берәм-берәм туй кунаклары төште. Кемнәр икәнен кай арада хәтерләп өлгергәндер, Әмир агитбригада җитәкчесе кебек таныштырып барды. Иң беренче булып автобустан ак кепкалы, күн чабаталы, соры футболка өстеннән ашыгычлык белән бәйрәм пинжәге кигән түгәрәк гәүдәле, әмма җитез агай төште.

– Суксу авыл советы председателе, кулында пичәт белән ЗАГС журналы! – диде Әмир тантаналы пафос белән. Ак кепкалыга шәмәхә сатин халатлы ике хатын

ияргән иде. – Болары – никахның пүнәтәйләре! Гафу итегез – ике свидетель, алдынгы сыер савучылар. Төшке ашка кайтып килешләре. Кызым, доярка апаңнарга аш сала тор...

...Авыл советы, язылышу турындагы таныклык тутыру өчен Фазыл белән Язиләне вагонга алып кереп киткәч, калган кунаклар учак янындагы брезент җәймәгә аяк бөкләп утырдылар. Алай да Мәдияр, ыгы-зыгыдан файдаланып, гармун тавышын җиңәрлек итеп кенә Әмирдән сорашып өлгерде:

– Бу кадәр халыкны ничек күндерә алдың?

– Һәммәгезнең дә өй түренә кое бораулап бирәм дидем.

...Күчмә загс эшне тиз тотты. Язилә «шпилька» үкчәсе белән вагон баскычына чык-чык басып, язылышу турындагы таныклыкны укый-укый, брезент җәймә янына килеп басканда, Әмир майга томаланган килька белән ташкабак уылдыгы банкасын гына ачып өлгергән иде әле».

К.Кәримов әсәрләренең баш герое әледән-әле йә драматик, йә көлкеле, йә фаҗигале хәлләр эчендә кала. Мәхәббәт, гаилә өлкәсендә уңышсызлыклар, өметләрнең киселүе яисә бөтенләй юкка чыгуы аның ихтыярын гел сынап, характерын чарлап, эзәрлекләп тора. «Инде ныклап тормыш корып җибәрсәм үзе белән – ул гомерлек терәгем булыр» дип өметләнгән ярлар да бәхет алып килми. «Тургайлы болытлар»да күз атып йөргән мәгъшукасы Сәвияне, кеше сүзеннән куркып, вакытлыча калдырып, ерак Магаданнарга кадәр барып җитә, әмма сөеклесенең еракка, җир читләренә китәргә йөрәге җитми шул. Өметләр тагын өзелә. Герой күңеленә бәгырь ярасы булып калырдай күренешләр бик тәэсирле язылганнар. Менә Магадан якларында ялгыз, чарасыз калган егетнең хәләте:

«...минем өчен якты җир өстендә тормыш бетте... Сүнгән тау эчендәге шахталарга ләхет салкынлыгы үтеп керде. Ләкин аңа карап җавап үзгәрмәде...» Ник килмәдең, Сәвия?.. Минем бу дөньяда бүтән бер соравым да юк... Очты-очты самолётлар очты...»

Вәгъдәсезлекне, хыянәтне гасабиланып әнә шулай бик авыр кичерә егет. Ә тормыш юлында төрле күңел газаплары бик күп очраячак әле... Болай тиз һәм үлеп гашыйк булучыларга бу дөньяда көн итүләре бигрәк авыр шул... Әмма вакыт барын да юа. Егетебез дә моң диңгезенә чумып, бик озак утыра торганнардан түгел икән – кайдадыр өмет йолдызы булып, аңа Актаныш якларындагы Әлфинәсе балкып тора башлый. Тик аңа да барып җитә алмый Фазыл. Гомумән, мәхәббәт коллизияләрен, фаҗигаләрен кичерү ягыннан К.Кәримов геройлары танылган мәхәббәт җырчысы Фатих Хөсни тасвирлаганнардан һич тә ким түгел.

Күп еллар узгач, гомер буе читтән генә яратып, юксынып яшәгән ярларның – әллә кайларда, ерак елларда калган сөйкемле хатын-кызларның инде үсеп җиткән кыз балаларының күз карашлары аша томанлы өрфиягә төрелеп калган ямьле яшьлек истәлекләре яңаргандай була. Юк – алар Фазылның үз балалары түгел. Автор әсәрләрен нык тапталган баналь сюжетларга нигезләми. Болар лирик табигатьле геройның үзенчә җылы сурәтләнеше генә. Фазыл кебекләрнең язмыш сынауларын кичерә белүләре, күңелләренең һәркайчан яхшы, яктылыкка юнәлгәнлеге сокландыра.

Язучы сафлык, намуслылык, матурлыкның күңелгә аваздаш символларын, детальләрен дә таба алган. Шуларның берсе – әлегә әдәбиятыбызның проза дигән өлешендә моңа кадәр тиешенчә яктыртылмаган, җырланмаган су образы, су сурәте. Ир-ат затындагы геройлар гомерләрен, эшләрен халыкка чиста су бүләк итүгә багышлыйлар. Су темасы күп тарафлардан яктыртылган. Автор еш кына контраст алымнар куллана. Менә Казанның Яңа Савин бистәсендәге иске өйләрдә яшәүчеләр су басудан, идән асларына су керүдән интегәләр. Ә Идел буйларында яр кырыена бәйләп куелган иске баржа ычкынып китеп, су төбенә төшеп югала. Су – ул хәтәр дә, куркыныч та. Икенче яктан су – ул кешелек өчен яшәү чыганагы да. Ә К.Кәримовның игелекле геройлары сусызлыктан җәфаланып яшәүче төбәкләрдәге кешеләргә артезиан коелары бүләк итеп, чиста экологик сулар өләшеп йөриләр.

Су темасы әдипкә тарихыбыздагы гыйбрәтле хәлләр, яшәешебездәге аянычлы борылышлар, тискәре якка юнәлгән үзгәрешләр турында сөйләргә дә мөмкинлек бирә.

Тыгыз концентрацияле берничә җөмлә аша иҗтимагый процессның асыл мәгънәсе һәм авторның мондый хәлләргә үз мөнәсәбәте яктыртыла:

«Зур су тирәсендәге авыллар ачлыкка бирешмәгән, корылык елларны җиңелрәк кичергән. Борынгы бабаларыбыз халыкны үрчетер өчен Идел белән Чулман кушылдыгына күчеп утырган. Хәзерге эшкуарлар мөлкәтләрен саклар өчен күл тирәсенә тамыр җәя. Элеккегеләр сулы корылмалар белән дәүләтнең башкаласын саклаган. Хәзергеләргә су күңел ачу өчен кирәк.

Элек су чыгару бөтен авыл сөенерлек изге эш иде. Хәзер исә Фазыл бораулау остасы дигән һөнәре белән масая алмый. Чәнечкеле таш коймалар эчендә бикләп сакланган персональ чишмәләр суга сусаган гади халыкны куандырмый... Байларга эшләүнең сөенече юк... Ишегалларына кергәч, үзеңне батрак итеп тоясың...»

Гомумән, Камил Кәримовны хәзерге татар тормышының елъязмачысы дип санап була. Күренекле тел галиме Рүзәл Юсуповның «татар тормышының энциклопедиячесе ул» *(Ком сәгате дөрес йөри // Казан утлары, 2012. – №4)*, дигән сүзләрендә тирән хаклык бар. Илдәге, җәмгыятьтәге, төбәктәге булып торган хәлләр, үзгәрешләрнең берсе дә әдипнең үткен күзеннән, игътибарлы, ирониялe, хәтта сарказмлы карашыннан читтә калмый. Алар арасында тормышларыбызны тамырдан үзгәртеп корабыз дип башланган илкүләм хәрәкәт-вакыйгаларның шактый аянычлы нәтиҗәләре дә чагыла:

«Унсигез миллион коммунист сулъяктан уңга борылып яткач, байракларның төсе алышынды, кешеләрнең холкы үзгәрде, дөньяның асты-өскә килде – явызлар өскә менде, мәрхәмәтлеләр аска төште...» Прагматик ихтыяҗлар хакына җәмгыять тормышындагы үзгәртү-үзгәрешләрнең күп очракларда акланып җитмәвен автор реаль һәм романтик сурәтләр аша ачып бирә алган. Менә туган авылда соңгы биш ел эчендә булган үзгәрешләр турында ничек яза ул:

«...720 баланы ел дәвамында укыта алган ике катлы агач мәктәпне утынга сүткәннәр... Авыл уртасында «Яшьләр үзәге»нә әверелгән мәдәният йортын хуҗалык кирәк-яраклары сата торган кибет иткәннәр. Борынгыдан Сабан туе аланы була килгән «Мәдрәсә бакчасы»н бүлгәләп өйләр салганнар. Җыеннар мәйданы олы юл тузаны өстенә күчкән...» «Шомырт тегермәне»н яшен суккан, пардан киенгән ир уртасы наратларны егып, җиләкле аланнарны каезлап, шомыртлы әрәмәләрне күмеп, Чаллы ягына юл җәяләр. Туган ягым манзарасы кире кайтмаслык итеп җимерелгән. Яшьлегеңне сагынып кайтсаң, эзләп табарлык түгел...»

Көн дә җәмгыятебездә булып торган яңалыклар, үзгәрешләр яссылыгында автор кызыклы ачышлар ясый, аларның кайберләреннән әсәрләренең сюжет-композиция алымнары сыйфатында да файдалана. Аеруча нык басым сурәтләнгән күренешләрнең тормышчан дөреслегенә һәм композицион тарафтан логик акланганлыгына һәм мотивлаштырылуына ясала. «Тургайлы болытлар»дагы лирик геройның маҗаралары автомобильгә бәйләнгән: искесеннән арынырга бик вакыт, җае да чыгып тора – хөкүмәт әйбәт карар чыгарган: утильгә тапшырсаң, 50 мең сум акчалы да буласың – яңа машина алырга да бераз җайлы була – машина җене кагылган укучылар өчен бик тә аңлаешлы ситуация. Героебыз үзе дә әнә шул һәвәскәрләр рәтеннән һәм ул автор белән бергә әйләнә-тирәдәге һәрнәрсәгә автомобильче күзләре белән карый башлый. Машина багында 200 чакрым юл йөрерлек бензины калган икән – аны да әрәм итәсе килми – файдаланып, яндырып бетерергә кирәк. Башка зур максатлар да юк сыман. Җитмәсә, хатыны утильгә бәйләнешле теге 50 меңне гел искә төшереп тора. Һәм героебыз тагын үз стихиясендә – ул һаман да шул элеккеге Дон Кихот икән: юл маҗараларында рәхәт мизгелләр кичерә, акча артыннан кумый – утильгә тапшырылган машинасы эчендә онытылып калып, пресс астында сытылган кесә телефоны кебек вак-төякләргә дә борчылып тормый.

Мәгълүм ки, бүген техника заманында гомер итәбез. Күренекле рус язучысы, яңача язу алымнары тарафдары Андрей Платонов, техникага, шуның белән бәйләнгән яраткан профессиясенә мөкиббән китеп, паровозларга, электр станцияләренә, тимер юлчыларга дан җырлап, үлмәс әсәрләр калдырган. Камил Кәримов сурәтләренә юлыкканда, ирексездән әлеге классик искә төшә. Болар икесе дә кайчагында кеше

кулы белән тудырылган техник әсбапларга, машиналарга җан өргәндәй итәләр, хәтта аларны әңгәмәдәшләренә әйләндерәләр.

Әдипнең җанлы сурәтләр дөньясында һәркем үз тормышы, үз исәбе белән яши. Әлеге хәл кешеләргә генә түгел, теләсә кайсы җан ияләренә, хәтта җансыз предметларга, машиналарга да бердәй кагыла: «Хат ташучының сумкасыннан төшкән газетаны кыштырдатып укый Дияр агай. Кәнәфинең читенә үк китеп сузылган соры песи хуҗасының ниләр укыганын тойган кебек елмаеп ята». Йорт хайваны, өйдә яши торгач, үз кешегә, ягъни персонажга әверелгән. Менә өйгә икенче берәү – күршеләре килеп керә: «Сәлимнең килеп утыруын соры песи өнәмәде, елмаюын югалтып, кояшлы бакчага шылды – ике ир кеше булган җирдә өстәлгә ни куеласын белә иде инде ул, шушы түбә астында ничә ел яшәгәч». Тагын бер-ике мисал: туң җирне ертырга азапланган экскаватор, бу囗ештә тешем сынмагае дип, үз хуҗалыгына кайтып китә. Менә салкын кышлар да уза. «Тәки кышны җиңдек дип, бугаз киереп төтен өреп яткан ТЭЦ морҗалары да шәһәр пейзажына килешеп тора». Ә җәйге юл кырыенда тукталып калган «Matiz» машинасы безгә яңа чабылган яшел үлән чүмәләсе булып күренә.

К.Кәримов геройлары ел фасыллары алышынуын, табигать балалары – агачлар, үсемлекләр, кошлар-бөҗәкләрнең үзләренчә гомер итүләрен сизеп-күреп, сокланып яшиләр: «Күчмә кошларның кайтасы кайтып, нигез ипләде, ояларда яңа авазлар ишетелергә тора. Язгы җилләр, кемгә дә ярарга белмичә, аркылы-торкылы исә. Кышкы йокымсыраудан уянып чыккан бал кортлары гыйшыклы тал песиләрен кытыклый. Җимеш агачларында чәчәк бөреләре бүрткән…» Озак та үтми, табигатьнең киеме тагын алмашына: «...Мишә елгасының безнең авыл бәхетенә тигән өлеше шомырт урманына төренгән. Гасырлар буена үсә торгач, шомыртлык әкренләп күрше-тирәне яулап, күл читләрен, сазлыкларны, хәтта урман юлларын да басып алды».

Камил Кәримовның сайлаган төп мәсләге нәрсәдә икәнлеге турында автор үзе дә ачык әйтә: «Курантларны вакыт эталоны белән тигезләгән кебек, бүгенге прозаны Ф.Хөсни, М.Мәһдиев, Ф.Шәфигуллин, Г.Мөхәммәтшиннар каләме белән төзәтеп-көйләп, җөмлә төзелеше, стиль, тел күркәмлеге, сурәтләү чараларының күплеген кайтаруга ирешсәк, матур әдәбиятыбызның гомере озынаер иде» *(К.Кәримов. Ирләр кырыкта сынала. «Казан утлары», 2012. – №12)*.

Бүген без татар прозасында моңа кадәр очрамаган күренеш – Камил Кәримов феномены дигән иҗат дөньясы турында сүз йөртә алабыз. Хезмәтебездә талантлы әдип иҗатының тик кайбер якларына гына кагылып уздык. Журналистлык хезмәтенең барлык нечкәлекләрен тасвирлаган «Тургайлы болытлар», сәнгать дөньясы кешеләренә багышланган «Уен» романы, яшьләребезне тәрбияләүгә юнәлдерелгән повестьлар һәм хикәяләр циклы махсус һәм әтрафлы өйрәнүне сорый. Автор күзләре белән без тормыш стихиябезнең барышын күзәтәбез, югалтуларыбызны барлыйбыз, алдагы язмышларыбызны ачыкларга тырышабыз. Бу хәрәкәттә безгә әдипнең оптимистлык нурларына коендырылган якты, яхшылыкка, матурлыкка чакырып, шуңа өндәп торучы иҗаты ярдәм итә. Аның белән танышканда, күңелләребез сафланып киткәндәй була – гүзәллек чишмәләренә гел әйләнеп кайтасы килеп тора.

**Рифат СВЕРИГИН**

# ТУКАЙ ОЧЫРГАН КАРЛЫГАЧЛАР: «БЕЗДӘ ЮК, БУЛСА ДА БИК АЗДЫР, БЕЛӘМ, ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР»

Татар тәнкыйтенең рухи зәгыйфьлеге, сыйфат ноктасыннан түбәнлеге генә түгел, хәтта микъдари да азлыгы турында еллар дәвамында язабыз, әмма аның уңай нәтиҗәләргә китергәне юк. Әдәбиятны бәяләүчеләр азлыгы, булганнарының тиешле дәрәҗәдә анализ бирә алмавы турында борчылулар моннан бер гасыр элек тә күзәтелгән, әмма ул вакытта кешеләр сүзләрдән эшкә күчкән. Минем үземне шул заманнардан бик сөендергән бер күренеш шулдыр: Г.Тукай, Г.Ибраһимов һәм башка зур талант ияләре генә алынырга җөрьәт иткән бу өлкәгә, батырлыклары җитеп, хатын-кызларыбыз да үтеп кергән. Белемле һәм үзләре дә иҗатка сәләтле ханым-туташларның язганнары исем алу өчен генә иҗат итүче кайбер ир-атларыбызның да борынына чиртерлек булган. Инде минем, төп фикер агымына керешкәнче әйтәсе килгән сүзем шул: ханымнар, җенестәш каләмдәшләрем, әйдәгез әле, бергәләп тамырлары бик борынгыда ятса да, Тукайлар чорында гына ныклап җанланып киткән тәнкыйтьне ирләрне шаккатырырлык итеп җанландырыйк. Бу юлда безгә үрнәк булырлык мисаллар бар. Ерак барасы да түгел. Нибары бер гасырлык ара. Җир шарының без күзаллый алмаслык саннар белән билгеләнгән гомерендә ул мизгел дәрәҗәсендә дә түгелдер.

XX гасыр башында Тукайның шигъри каләме, үткер фикере, башкалар иҗатына бәяләмәләре тәэсирендә әдәбият мәйданына баскан күпсанлы хатын-кызларыбыз арасында сүз сәнгатенең иң кыен өлкәсе булган тәнкыйтьне алга җибәрүгә көч куючыларның берсе – Мәфтуха Вәлидия. Бу өлкәдәге бушлыкка һәм, чын тәнкыйть булмаганлыктан, үзенчәлекле һәм мөстәкыйль текстларның сан ягыннан артмавына борчылган Мәфтуха Вәлидия «Кыйтга» шигырендә болай ди:

*Бездә юк, булса да бик аздыр, беләм, тәнкыйтьчеләр,*
*Шул нисбәттә бездә бик күптер сукыр тәнкыйтьчеләр.*
*(Шул сәбәпле бездә бик күптер сукыр рәвештә ияреп язучылар.)*

1915 елда Казанда басылган «Күңел бүләкләре» исемле җыентыгына керештә М.Вәлидия (1894-1925) шигырьнең укучыга хисси тәэсире һәм тәрбияви йогынтысы турында сүз алып бара; каләм иясенең «Фәлсәфи бер тәнбиһ» шигырендә исә, татар вакытлы матбугат органнарының күпсанлы исемнәрен төрле мәгънә яссылыкларында файдаланып, берьяктан, әлеге органнарның эчтәлек-мәсләкләрен билгеләп уза, икенче яктан, яңа заман укучысының, яшьләрнең, гомумән, татарның нинди булырга тиешлеге турында сөйли:

*Сезгә әйтәм, туганнарым, тырышсак,*
*Һич шик вә шөбһәсез, «Аң»лы булырбыз,*
*Күрсәтик без йөзебезне «Кояш»ка,*
*Йитәр, күп йөрдек инде карап аска.*
*Асыл таш тикле юк бит кыйммәтебез,*
*Чыгадыр, ятмый урынында асыл таш та.*
*Булыйк без сүзебездә «Бәянелхак»,*
*Сөйлик гәрчә, ачы булсын хакыйкать.*

Бу шигырьдә М.Вәлидия Г.Тукай хезмәттәшлек иткән газета-журналларга югары бәя бирә. Шагыйрәнең үз иҗатына да Тукай йогынтысы сизелерлек.

Маһруй Мозаффария (1873-1945) «Габдулла әфәнде Тукаевның хатын-кыз галәменә тәэсире» язмасында татар әдәбиятындагы бәйләнешләр турында заманына күрә югары дәрәҗәдә сүз алып бара. Монда ул Г.Тукай иҗатының һәр сыйныфка адреслануы, эчтәлеге, рухы, әлеге иҗатта хатын-кызларга мөнәсәбәт кебек проблемаларын күтәрә. Мәхбүбҗәмал Акчурина шулай ук, Тукай һәм аның даирәсендәге башка талантлы каләмдәшләре үрнәгендә, «Иске әдәбиятымыз»га күзәтү ясый, «Сәйфелмөлек», «Таһир илә Зөһрә» кебек әсәрләргә анализ биреп үтә, милли ядкарьләрне саклау, сүз сәнгатенең, музыканың борынгы тамырлары турында төрле фикерләр язып уза.

Г.Тукай, гадәттә, вакытлы матбугат материалларына, басмаханәчеләргә, теге яки бу басмада хезмәт итүчеләргә юмор-сатира ракурсыннан карый, ә менә аны олылыклаган шагыйрә туташлар татарча дөнья күргән һәр язманың уңай якларын тотып алырга тырышалар. Алар шул ук вакытта, Тукай кебек үк, татар сүз сәнгатендә хатын-кызлар тавышы күбрәк яңгырауны кайгырталар. Дөрес, вакытлы матбугаттагы материалларга, аерым авторларга, аларның эш-гамәлләренә тәнкыйди бәяләмәләр бирүчеләр дә юк түгел. Әйтик, Фәрханә Алушева «Сибирия хатынларының тавышы» язмасында каләмдәшләренә, Тукай стилендә – аныңча төрттерүләр белән, шушы рәвешчә мөрәҗәгать итә: «Әй, кардәшем Сөләйманова мөкаддәмләре, сезләрнең мәкаләләреңезне «Казан мөхбире»ндә укып шатланмыш идек. Нә булды сәңа, тавышың бетте? Әллә Һади әфәнденең әлифбасындан чыга алмыйсыңмы? Куй аны, ал кулыңа хөрмәтле каләмеңне!

И Шәфыйка ханым! Сезләр бик олуг исемдә журнал нәшер идә башлап та, берничә чигү канар вә берничә негр хатинларының рәсемләрен күстәреп, бик тиздән инәңезне башыңыза кадап уйкуга талдыңыз. Нә гаҗәп, бик тиз гайрәтеңез кайтты? Синең атаң ирләр өчен 25 сәнә күпме агырлыкларга тәхәммел идеп, хезмәтендә дәвам итте. Гыйбрәт! Гыйбрәт!»

Әдәбиятка нисбәтле фикерләрне Мәхмүдә Мозаффариянең шигъри текстларыннан да табарга мөмкин. «Ханымнар» әсәрендә Тукай иҗтимагый тормыштагы искелекне, ахмаклыкны, мәгънәсез эш-күренешләрне тәнкыйть иткән пародиясенә сюжетын нигез итеп алган «Кисекбаш» поэмасын шагыйрә шушы рәвешчә телгә алып уза:

*Иҗек-миҗек, «Кисекбаш»тан туйдык инде,*
*Искелекне җилкәсеннән суйдык инде.*

XX гасыр башында иҗат иткән шагыйрәләребезнең нәфис текстларында Г.Тукай иҗатына бәяләмәләр шактый югары. Мәсәлән, Х.Шаммасова «Наме үлмәс!»тә Г.Тукай язганнарга фикер төзеклеге, бөеклеге, милләтҗанлылык хас икәнлекне ачык аңлаешлы яза. Шагыйрәләр мирасыннан иҗат лабораториясе, илһам, язып китү һ.б. күренешләр турында фикерләр табарга мөмкин (Х.Шаммасова. «Каләмәем»).

Мөнирәнең «Шагыйрьләрдән илтимас» язмасында, Г.Тукай кебек, милли көйләребез, әдәбиятыбыз нинди булырга тиешлеге проблемасын күтәрә, аның узган чордагы әдәбиятка бәяләмәләре билгеле бер күләмдә Г.Тукай карашлары белән аваздаш.

Шулай да хатын-кызлар каләменнән төшкән саф тәнкыйди-публицистик язмаларның бик мөһиме – Мәрьям Мөхетдиниянең шагыйрь вафатына өч ел тулу мөнәсәбәте илә иҗат ителгән «Габдулла Тукаев әдәбияты» язмасы. Анда Г.Тукай шигърияте танылган урыс шагыйрьләре җирлегенә куеп бәяләнә һәм үз чоры өчен, халыкка хезмәт итү ноктасыннан якын килгәндә, аларныкына караганда да кыйммәте зуррак икәнлеге күрсәтелә. Әдибә фикеренчә, моның сәбәбе шунда: Тукай фаҗигале язмышка ия татар халкының һәр социаль катламының язмышын кайгырта, проблемаларын җырлый: «Безнең бүген искә төшерә торган милли шагыйребез Тукай да тормышның бер генә кылын чиертми: аның шигырьләрендә җырланмыйча калган нәрсә, аның күңелендә искә төшермичә үткәрелгән хәятның һичбер тармагы юк; ул кышларны, җәйләрне көйли, шәһәр вә авылларны, иске мәктәп вә мәдрәсәләрне искә төшерә; дус вә дошманнарны, кайгы вә хәсрәтне, гашыйк вә мәгъшукларны берсен дә калдырмый шигырьләрендә яд итә (искә ала)».

Тәнкыйтьче милли гамьнәр, мәгариф һәм мәгърифәт, яшьләргә өмет һәм башка проблемалар белән янган шагыйрь иҗатында хәтта мәхәббәткә дә тиешле дәрәҗәдә урын бирелгәнлеген күрә, бу хисне чагылдыруның романтиклыгы турында да язып үтә: «Хәят суының һәрбер дулкынында йөзә торган шагыйрь хатыннар турысында да сызланмый калмый. Ул үзенең шигырьләрендә гыйшкыны көйли, аңар күп урын бирә; ләкин дикъкать итәргә кирәк: Тукайның мәхәббәте гали һәм пакь рухани мәхәббәт».

Шул ук вакытта, автор фикеренчә, Тукай бары тик мәхәббәт хисләрен җырлау белән генә чикләнми, хатын-кызның җәмгыятьтәге ролен үстерүне, аны ирекле итүне дә кайгырта: «Сөйкемле хатыннарның коллыкта, тоткында торулары шагыйрьгә начар тәэсир итә. Ул адәмнәрнең яртысы булган ханымнарның хөр, ирекле булуларын чын күңеленнән тели. /.../ Шагыйрьнең хатыннарга вә бөтен адәмнәргә хөрлек теләве аның табигатенең гали булганлыгына куәтле бер дәлилдер».

М.Мөхетдиния Г.Тукайның төрле катламнарны аңлавын, һәрберсен ирекле итәргә теләвенең сәбәбен шәхси сыйфатлары – үзенең дә ирек сөюе белән китереп бәйли. Шагыйрь үзенең бу карашларын тормышта да булдырырга тырыша, аның гали табигате агымга ияреп коллыкка бирелми, дип белдерә.

Тәнкыйтьче Г.Тукай иҗат иткән лирик минне шагыйрь белән тиңләштерә, күпмедер инфантильрәк тотышын холкындагы горурлык чагылышы дип кабул итә: «Шагыйрьнең үзен яратканнарны гына яратуы да горурлыгын ап-ачык күрсәтә. /.../

М.Мөхетдиния тәнкыйте бу заманда да шактый актуаль яңгырашлы. Ул тәнкыйтьчеләрнең дустан дошманы күбрәк булу, урынсыз һөҗүмнәргә дучар ителүе турында да сүз алып бара.

Тәнкыйтьче ханым Тукайны аңлауга бик тиешле күрсәтмәләр биреп уза: «Шагыйрьнең мондый шигырьләре тәрбия өчен бик мәгъкуль, ләкин мөрәбби вә мөрәббияләребез (тәрбияче ир һәм хатын-кызларыбыз), шагыйрьне тормыштан югары иде, әҗәл тели иде, дип уйлап, шул ук фикерне шәкертләренә дә тукып, пессимистлар җитештермәсеннәр иде. /.../ Юк, Тукай башта чын күңеле белән дөньяны сөя, әҗәл теләми иде. /.../ Аның кайсыбер шигырьләрендә «дөньядан туйдым» дигән сүзләре булса да, психология буенча һәр күңел тынычланырга тырыша.

Менә безнең Тукай да дәртенә дәрман булмагач кына, әҗәлдән кача алмаслыгын белгәч кенә, үзен тынычландырыр өчен, «әҗәл сөям» дип күңелен юата. «Ләззәт вә тәм нәрсәдә?» дигән шигырендә ул дөньяның тәмен эзләп карый: сөюен, ачуын, патша вә башка могътәбәр кешеләр булуын, сугышта нишан алуны да уйлый, тагы әллә нәрсәләр башына китерә...»

М.Мөхетдиния тәнкыйтендә, үз сүзләре беләнрәк әйткәндә, Тукайның милли шагыйрьлеге, хәзерге һәм киләчәк буын татар балаларының рухын тәрбия итәчәклеге, аның тирән мәгънәле шигырьләре күп кешеләрне якты, яңа тормышка алып барачаклыгы турында сөйләнә.

Әдәби тәнкыйтьнең форма-алымнары бихисаптыр. Әле ул махсус өлкә булып аерылып чыкканчы, каләм ияләре, шул ук Кол Гали, Кандалый һәм башкалар сүз нәфислеге, мәгънәлелеге, иҗатның максат-бурычлары турында шигъри текстлар эчендә әйтеп биргән. Соңрак әдәби-публицистик формалар тәнкыйтьнең бер оясын калыплаштырган. Әле татар тәнкыйтенең мөстәкыйльләшеп килгән чорында да поэзия ярдәмендә иҗат турында фикер йөртүләр киң таралышта булган. Язучыларга язылган мәрсия-мәдхияләр дә, эчтәлекләренә бәйле рәвештә, шушы оя эченә керә ала.

XX гасыр башының танылган шагыйрәләре арасында йөргән Оркыя Ибраһимованың күләмле «Китте шагыйрь» ядкарьнамәсе шагыйрь иҗатын шактый киң ача, аның милли рухлылыгына, халыкчанлыгына, тормышчанлыгына, фольклор белән бәйләнешләренә игътибар итә. Ул шушы рәвешчә башлана:

*Китте дөньядан бу милләтнең чын шагыйре,*
*Яуме мәхшәр фаидәсенә шигъре улсын шаһиде.*

**Рифә РАХМАН**




*Галимҗан Ибраһимов һәм тел галиме Гыйбад Алпаров. 1933 ел.*



*Язучылар Казандагы М.Горький музеенда. Сулдан уңга: Рафаэль Мостафин, Ил Саттаров, Нәби Дәүли, Мария Елизарова. 1980 ел.*



*Себердә яшәп иҗат иткән, «Иртыш таңнары» романы авторы Якуб Зәнкиев һәм галим Фәрит Хатыйпов. 1980 ел.*




*Фәрит Бәшир (Фәрит Кәрим улы Бәширов. 1958-2009). Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче.*



*Мәшһүр галим, «Полынь половецкого поля», «Тюрки и мир: сокровенная история», «Европа. Тюрки. Великая степь» кебек гыйльми-популяр китаплар авторы Морат Хаҗи (Мурад Аджи) «Казан утлары» журналы редакциясендә кунакта. 2005 ел.*

# ГОМЕР – БЕР МИЗГЕЛ

## МИҢГОЛ ГАЛИЕВКӘ 75 ЯШЬ



Безнең авыл зур түгел (йөз хуҗалык чамасы), ләкин элек-электән җидееллык мәктәбе булган, биш-алты авылның балалары башлангыч класслардан соң безнең авылда укыдылар.

Безнең чорда бөтен районга ике урта белем алу мәктәбе бар иде. Унъеллык мәктәп тәмамлау ул зур дәрәҗә иде.

Без унбиш бала беренче класска кердек. Бер кызның гына әтисе бар, ул да сыңар аяк белән сугыштан кайткан почта начальнигы!

Безнең очта гына яши торган бер малай һәм аның апасы белән бер класста укыйбыз. Кичләрен башны башка терәп, сукыр лампа тирәсендә йә дәрес әзерлибез, яисә шашкалы уйныйбыз (бу инде әтидән калган хәзинә), табышмаклар әйтешәбез. Әниләр башка өйдә кич утыралар: ямау ямыйлар, оек-бияләй бәйлиләр, чабата үрәләр, моңлы җырлар җырлыйлар, елыйлар.

Җидееллык мәктәпне тәмамлагач, җәй көне абыем ялга кайтты, мине үзе белән Украинага алып китте (ул – капитан!). Бер авыз урысча белмәгәч, миңа башта уку авыр булды. Шулай да сөйләшергә, укырга бик тиз өйрәндем, спорт мәктәбенә дә зур теләк белән йөрдем. Сабакташларым ихтирамлы булдылар. Күбесе офицер балалары.

Сигезне тәмамлаганчы ук, абыемны Германиягә күчерәселәре билгеле булды. Мин авылга кайттым. Укыйсы килә... Пенсия дә егерме биш сумга җитте (минем әти сержант булган!).

Авылда бер ел укымыйча торган иптәш кызым бар иде, әнисе «укытырга мөмкинлегем юк», дип җибәрми, ул пенсия алмый, әтисе хәбәрсез югалган, имеш, пленда үлгән, «халык дошманы» кызы. Елашабыз. Ниһаять, Мамадыш урта мәктәбенең 9 «Б» классына килеп кердек. Миңлегол белән тәүге очрашуым да шунда булды...

Ул шул мизгелне болай дип искә ала: «Бер чибәр генә, бераз кыланчыграк, «гы»ны украинчарак әйтүче бер кыз класска килеп керде».

Авыл аралары якын гына булса да, без Миңлегол белән очрашмаганбыз (югыйсә 100нче квартал посёлогына без аларның өйләре каршыннан ипигә, майга йөри идек). Миңлегол дүртенче классны тәмамлауга, алар мәктәбендә бишенче, аннан алтынчы... класслар ачылган, ул безнең авылга укырга килмәгән, ә абыйсының безнең авыл мәктәбендә минем абыем белән бер класста укыганын хәтерлим.

Без, сугыш вакытында туган, төрле авыллардан җыелган иллеләп бала, тулай торакта – Мамадыш башлангыч мәктәбенең (ярымподвал) өч бүлмәсендә яшибез. Һәр шимбә укудан соң авылга җәяүләп кайтып, алга таба яшәү өчен биштәргә тутырып бәрәңге, өч тәңкә акча (анысы кибеттән ипи, токмач алып, җылы аш пешереп ашарга кирәк) алып киләбез. Шулай йөргәндә, 1958 елның февраль бураннарында, безнең авыл егете – 9нчы класс укучысы Иванны югалттык. Аны яз көне яр астыннан әнисе табып, җитмеш көннән соң гына Җир-Ана куенына тапшыру насыйп булды

Кышкы каникулдан соң, М.Фәйзинең «Асылъяр» спектаклен куярга өйрәнә башладык. Рольләрне кем бүлгәндер, белмим, Миңлеголга – Шәрәф (билгеле инде, ул җырлый), миңа Ләлә ролен биргәннәр. Шәрәф белән кара-каршы сөйләшү һәм җырлар

күп. Миңлеголга мине җырларга өйрәтү җиңел булмады (мин аның беренче укучысы!).

Ул спектакльне безнең авылда да, Миңлеголлар авылында да, мәктәптә дә куйдык. Иске Комазан авылы балалары мине өйләнешкәнче «Ләлә апа» дип йөрделәр.

Миңлегол искиткеч матур итеп, ничектер тамагы белән бераз сызгыртып җырлый иде. Ата-аналар җыелышына спортзалны тутырып тол әниләр килә (әтиләр саны кул бармакларына сыеп бетә торган гына). «Әниемнең җылы кочагы», «Әниемә хат»ны һәм халык җырларын гаять моңлы итеп башкара ул, сагышлы-моңлы әниләребез елап утыралар. Зур концерт әзерли идек без ул очрашуларга. Миңлегол бик актив, аны яратмый мөмкин дә түгел. Класс җитәкчесе Шәмсинур Габдрахман кызы: «Миңлегол, иртәгә мәктәп радиосыннан сөйләргә кирәк! Стенгазета чыкканмы? Бәйрәмгә концерт әзерме?..» – дип кенә тора иде.

Класста парталар өч рәт. Мин өченче рәттә беренче партада утырам, Миңлегол – икенче рәттә икенче партада, стенада Гёте портреты эленгән, шуңа караганда күз карашларыбыз очраша иде.

Без тулай торакның бер бүлмәсендә тугыз кыз торабыз, бары ике авылдан килеп укучы егетләрне генә (биш-алты кеше) кертәбез. Уйныйбыз, көләбез. Бер тапкыр Арташ авылы кызлары: «Мунчалы» уйныйбыз», – диделәр. Ул болай була: ике урындыкны артлары белән бер-берсенә терәп куеп, егет һәм кыз утыртыла. «Бер, ике, өч» – дип әйтүгә, икесе ике якка борылса, бу пар уеннан чыгарыла. Мине Миңлегол белән утырттылар, «бер, ике, өч», диюгә, ялт итеп бер якка карадык. Безне «барыгыз мунчага», дип коридорга чыгарып җибәрделәр, бераздан «керегез», диләр. Алда – Миңлегол, ишекне ачуга, бер чүмеч суны өстенә койдылар.

«Йолдыз санау», «Кем сукты?» уеннары... Ачлы-туклы яшәешебезне шулай тулыландырабыз. Егетләрнең чәчләрен йолкыйбыз. Шулай бервакыт айнып киткән кебек булдым, мин Миңлеголның чәчен йолкымыйм, җиңелчә тартам гына икән... Шуннан көндәлек яза башладым. Аны бергә укучы туганы Мөҗип алып Миңлеголга күрсәткән. Мин көндәлекне шул көнне үк мичкә яктым, кызганыч...

Ә Миңлеголның беренче шигъри хатын саkладым мин. Менә ул:

*Кечкенә генә шигырь язам сиңа,*
*Тиз-тиз генә йөри каләмем.*
*Керсез күңелемдәге уйларымны*
*Менә хәзер ачып саламын.*

*Синең көндәлегең укыдым мин,*
*Чын күңелдән язган сүзләрең.*
*Шул вакытта килде күз алдыма*
*Очкынланып торган күзләрең.*

*Ышанмадым башта язганыңа,*
*Мөмкин түгелдер дип уйладым.*
*Сиңа булган яшьлек мәхәббәтем*
*Кире якка борды уйларым.*

*Күңелеңне белдем, дөрес булса,*
*Дәфтәреңнән укып ике бит.*
*Ачуланма миңа, классташым,*
*Күңелем кушты миңа, гафу ит.*

*Һич чыкмыйсың минем исемнән,*
*Күңелем һаман тели күрергә,*
*Сөям сине, әгәр теләсәң,*
*Керсез дустың булам гомергә.*

*Көндәлегең укыгач, белсәң иде,*
*Күңелемдә туган сөенечне.*
*Үткән көннәремне сөйләр идем,*
*Син теләсәң, матур бер кичне.*

Тулай торакның ишегалды бик зур, иртән физзарядкага чыгабыз. Миңлегол – малайлар, мин кызлар уртасында – физруклар!

Көннәр җылынып, мәктәп ишегалды кипкәч, бик матур итеп кичке уеннар оештыра идек. Могҗизалар була инде анда. Нинди генә уеннар уйнамый идек! Илья Рязанов бик матур итеп гармун уйный. Башлап йөрүчеләр – Дүсмәт егетләре: Михаил Ефимов, Иван Степанов, Николай Гурьянов – бииләр! «Тыкрыклы», «Йөзек салышлы», «Чүпләмле», «Түгәрәкле уен»... Шулай бер кичне уеннан соң Миңлегол белән капкадан чыгып, торак тәрәзәсе каршында сөйләшеп торабыз. Беренче очрашу! Берәү кесә фонарен яктыртып килә. Безнең янга җитәрәк, утын сүндереп узды да, яңадан кабызып алга таба китте. Мәктәп директоры Павел Петрович Шипшов булган бу! Класс җитәкчесенә әйткән, ул соңрак безнең белән аерым-аерым сөйләште.

Тугызынчыны тәмамлар алдыннан, әлеге дә баягы тулай торакның тәрәзәләре каршында торабыз, саубуллашканда иреннәр иренгә тиеп алды. Полисадник коймасына басып, койма аша бакчага сикердем дә шаулап үсеп утырган кычыткан арасына килеп төштем. Уныпып озак утырдым, елап туйгач, әкрен генә койма кырыена өеп куйган утын әрдәнәсе өстенә мендем. Миңлегол көтеп тора икән, мине күтәреп алып җиргә төшерде.

Икенче тапкыр үбешүне дә яхшы хәтерлим. Яхшы укыган балаларны җыеп Казанга турбазага җибәрделәр. (Ул Гвардия урамында, Г.Кутуй тукталышында иде.) Кызларны – агач йортларга, малайларны дүртәр кешелек палаткаларга урнаштырдылар. Шәһәрдә экскурсиядә булып кайткач, безнең авыл егете Михаилдан сорыйм: «Миңлегол нигә күренми икән?» Ул: «Аның борчуы зур, ул кыек якалы чиккән күлмәк алган һәм кибеттә үк югалткан», – ди. Мин хәлен белмәкче, юатмакчы булып палаткага кердем. Ул үзе генә, караватка сузылып яткан иде. Сөйләшеп утырдык, аннары... иреннәренә иренемне тидердем дә чыгарга дип ыргылдым. Ишек дигәнем тәрәзә булган икән. Миңлегол йомшак кына нидер эндәште, мин борылып ишектән чыгып йөгердем. Без бит үбешергә дә ояла идек, бер-береңә сыенып утыру – иң рәхәт мизгелләр иде ул.

Без, авылның егет һәм кызлары, бер чакрымдагы Акман авылы Сабан туена төштек.. Элек бит сабан туйлары авылларда чиратлап була, яшьләр бер-беренә кунакка йөрешәләр иде, шунда танышулар, көз көне кавышулар бик күңелле була торган иде. Миңлегол да килде Сабантуйга. Без, авыл яшьләре, соң гына кайтырга чыктык. Гөжләтеп яңгыр ява башлады. Барыбыз бергә авыл башындагы ферма өенә кереп тулдык. Андагы кандала! Яңгыр озак яуды. Таңда яланаяк, туфлиләрне кулга тотып, авылга кайттык. Әни кәҗә сава иде инде. Мин әкрен генә кереп яттым.

Минем әби бик дини иде, ул бездән урман аша ун чакрымдагы Җөри авылында яшәде, сирәк күрешә идек. Бер барганда: «Җырак әби, мин татар егетен яратам бит, әгәр башканы ярата алмасам, нишләрмен инде?» – дип сорадым. Әби тезде генә: «Кызым, Алла бар, ул бер генә. Кем аңа ничек табына, анысы үз эше. Сезнең заманыгыз шундый (1958 ел), кешеләргә начарлык кылмагыз, чәчүлек орлык урламагыз», – тагын әллә ниләр, әллә ниләр... Бүгенге муллалар вәгазеннән ким булмаганча акыл өйрәтте. Аллага шөкер, Алла биргән язмышым – Миңлеголым булды.


Каникул. Авыллар арасы – дүрт чакрым. Миңлегол колхоз атларын көтә.

Көндез эш күп. Кич җитүгә, инде мин «көтәм»: Миңлегол килгәнне! Әни белән өйалдында йоклыйбыз, өйдә кызу. «Ике йолдыз» көенә әкрен генә сызгырып, атка атланып, Миңлегол килә. Мин тиз генә торып, өйгә кереп, тәрәзә аша урамга чыгам. Әни ишетмәсен, янәсе. Таң ата башлаганчы усак бүрәнәләр (абыем өй салырга дип алып куйды) өстендә сыенышып утырабыз. Рәхәт. Ат усак кайрысы кимерә. Әни иртәгесен: «Озак утырасыз, ни сөйләшәсез шулхәтле?» – дип сорый. Мин: «Без сөйләшмичә генә утырабыз, әни», – дим.

Тулай торакта безнең ике тәрбияче апабыз бар иде. Унынчыда укыганда, Резидә Гаязовна дигәне безнең бүлмәнең ишеген киереп ачып, бер матур гына апа белән килеп керде дә: «Миңсылу апа, менә, синең булачак киленең шушы инде», – дип миңа төртеп күрсәтте. Алга таба кем нәрсә әйткәнен хәтерләмим, ничектер читенсендемме, оялдыммы?! Әмма дә ләкин бу сүзләр Аллаһы Тәгаләнең «Амин» дигән вакытына туры килгәндер. Алланың биргәненә рәхмәтләр укып яшим.

Чытлыграк идем. Хәзерге типография алдында Ленин һәйкәле иде (анда хәзер Шәйхи Маннур һәйкәле тора), янында – агачлар, утыргычлар. Шулай ямьле җәйге кичтә Миңлегол белән утырабыз. Мин аның куен кесәсенә тыгылдым (бик матур сары, ак, зәңгәр, кара вак шакмаклы күлмәк), ә анда папирос! Әкрен генә алып, сытып ташладым. Ә ул шул чакта үзенә «гомеремдә дә тәмәке тартмам» дип сүз биргән икән һәм шулай булды да.

Урта мәктәпне тәмамлагач, иртән иртүк бөтен класс белән көймәләргә төялеп Нократ елгасының аръягына чыктык. Анда комлык, анда киңлек, хозурлык... Коендык, кызындык, кыскасы, соңгы тапкыр җыелышып, көнне бергәләшеп киләчәк турында сөйләшеп, истә калырлык итеп үткәрдек. Кайтырга җыенганда, Миңлегол миңа бер кочак гөлҗимеш чәчәкләре бүләк итте, алар роза чәчәкләре кебек эреләр, бик матурлар.



*Хатыны Фәния ханым белән*

(Тормыш иткәндә дә һәрдаим бүлмәдә чәчәкләр булды, билгеле инде, чәнечкелеләре дә булгалады.)

Мин медсестра булып эшли башладым (сигез айлык курсларда укыган идем).

Җәй үтте. Миңлегол килми, инде сентябрь. Ул беркемгә дә әйтми генә консерваториянең хәзерлек курсларына кергән, биш егет – Миңлегол, Шамил Әхмәтҗанов, Котдус Хөснуллин, Ясир Нурлыгаянов, Рәис Сабиров – районда гастрольләрдә йөриләр икән.

Шуннан хат аша аралашу башланды.

Без бер акушерка белән эшлибез, урыс кызы – Галя. Безгә кадәр медпунктта Әминә белән Тамара байтак еллар эшләгәннәр иде, бик тә хөрмәткә лаек кызлар. Эш күп. Өч авылга хезмәт күрсәтәбез, иртән медпунктка килүгә, әбиләр укол ясатырга җыела (бабайлар яуда ятып калган). «Кызым, син җиңел ясыйсың», дип, күбесе миңа чират тора. Аннан мин дүрт чакрым ераклыктагы зур авыл – Комазан башына сумка асып чыгып китәм. Көн саен. Төннәрен хатыннар өйләрендә бәби таба, ирләре тизрәк безне алырга килә. Районга бер больница, анда бала табарга бармыйлар , ул бик ерак. Акман авылыннан бер хатынның бәбиләгәнен төне буе көттек. Иртәнге якта колхоз рәисе Зәйнулла Шәйхулловичның «УАЗ»игын сорап алып, район больницасына дип чыгып китеп, баласын юлда кабул иттек.

Ул вакытта авыллар гөжләп тора. Бер тапкыр «Әти» дип әйтергә тилмереп үскән балалар үзләре ата булдылар. Әле тол әниләр, ярлары яуда ятып калган парсыз кызлар да үз көчендә. Эше дә, ашы да җитәрлек. Терлекләр хуҗалыкта да, колхозда да исәпсез. Кукуруз үстерәләр, кырларда икмәк, бәрәңге үсә. Халык җәй буе басуда, һәммәсенең чүбен кул белән утыйлар. Әле урак белән иген җыю да шул чорга кадәр булды, соңрак ярдәмгә анда-санда комбайннар күренә башлады. Ә басуның бер кишәрлеге дә чәчелмичә яисә утыртылмыйча калмады. Авылдан басу капкасын чыгуга – иген кыры, казларны елгага куу да читен, алар икмәккә ашыга, ә анда – сакчы (полевой). Икмәкнең һәр бөртеге кадерле. Ул вакытта гектарыннан ун-унике центнер уңыш алу зур дәрәҗә иде.

...Казанда ел ярым чамасы укыгач, Миңлегол Октябрь бәйрәме көннәрендә кайтты. Армиягә китә икән, миңа ефәк баш яулыгы бүләк итте.

Мамадышка еш йөреләә, дарулар алып кайтасы бар. Шулай көзге бер көндә район үзәгенә барганда (җәяү йөри идек, егерме чакрым), Иске Комазанны үткәч, ат арбасына төялгән яшьләр куып җитте, мине дә утырттылар. Әллә нәрсә, ат та кызу бара алмый, юл пычрак, җәяү дә атлыйбыз, озак бардык. Сөйләшәбез, көләбез... Шунда Миңлеголның абыйсы Салих абый да бар икән. Беренче һәм соңгы очрашу (ул гармунда бик матур уйный торган булган). Армиядән кайткан, әле хәрби формасын да салмаган, военкоматка бара. Үзе бик чибәр, кара тут йөзле, урта буйлы, акыллы сөйләшә, минем белән дә сөйләшеп, ат артыннан озак атладык. Казанда энесе белән очрашкач: «Кызың бик ошады, ташлама, син өйләнмәсәң, үзем аңа өйләнермен», – дигән. Тик ул озак яши алмады, Сахалинга эшкә барырга армиядә үк юллама алган булган, шунда мәңгелеккә ятып калды.

Миңлеголның икенче абыйсы белән дә юлда таныштык. Инде җир каткан, кар яумаган әле. Районда икмәк кабул итү пункты каршында авылга кайтырга машина көтеп торам. Шәп гәүдәле, солдат киемендәге бер егет тә көтә. Салкынча, селкенми торсаң, туңасың. Каткан карлы кәсне шайба урынына типкәләп, жылынып җиткәнче

уйнадык. Бераздан фураж төялгән машина килде. Сузылып менеп яттык. Теге егет шунда әйтеп куймасынмы: «Кем белән «шайба» типкәнеңне белдеңме? Мин синең абыең», – ди. Аптырадым инде. «Әйе, әйе, мин Миңлеголның абыйсы», – ди. Миңа читен дә, рәхәт тә булып китте. Аллага шөкер, Миңнехан абый һәм аның гаиләсе белән җан дуслар – туганнар булып яшибез.

...Кичке уеннарга да чыккалыйбыз. «Түгәрәкле уен»да берәү – уртада, калганнар, кулга-кул тотынышып түгәрәктә әйләнәләр. Гармунчы салмак кына халык көе уйный, берсе җыр башлый, башкалар кушылалар. Көй кызулана, уртадагы кеше, биеп килеп, берәрсен уртага чакыра, култыклашып әйләнәләр, чакырылган кеше уртада кала. Кеше күп булса, ике түгәрәк була, икенче түгәрәк каршы якка әйләнә. Уртадагы кешегә төртмәле – үртәбрәк җыр башкарыла. Миңлегол консерваториядә укыганда, миңа:

*Иркәң китте артистлыкка,*
*Сине өзелеп сөя.*
*Нихәл итәрсең, сөюе*
*Булса репетиция?!*

– дип, иске Яңа елга каршы төндә «Балдак салу» (күрәзә) уенында, Миңлегол армиядә вакытта:

*Китте иркәң еракларга,*
*Армиядә бит әле.*
*Тагы да бер ел, тагы да бер ел,*
*Тагы да бер ел көт әле!*

– дип җырладылар. Хәзер дә аптырап куям авыл кызларының тапкырлыгына.

Кыш көне, Миңлегол армиядә вакытта, ял көннәрендә, ат җигеп, мине Комазанга Миңсылу апа (Миңлеголның әнисе) янына алып төшәләр иде. Без хатлар укып, язып; оекбашлар бәйләп, Миңсылу апа җырлап, мөнәҗәтләр әйтеп (тавышы искиткеч матур) кич утыра идек. Шулай оекбашлар бәйләп, посылка салдык, Себердә хезмәт итә бит. Мин хат яздым, Миңлегол: «Әйтәм бер носки җылырак булды», дип язды. Тик кемне мактавы булгандыр, мин үземә дип кабул иттем ул чакта. Миңлегол әнисе белән гарәп имлясында хат язышa иде.

Ат арбасы шыгырдаса да, машина гөрелтесе ишетелсә дә, әни белән торып утырабыз. Әни: «Тагын сиңа килделәр», – ди. Тәмам таушалдык. Әни әйтә: «Кызым, бу белемең белән калып булмас, алга таба укы», – ди. Désormais Мединститутка кереп карадым, экзаменнарны да яхшы бирдем, тик бер урынга унбер кешедән артык иде – узмадым. Ул чорда ук «блат» чәчәк атып килә иде (1961 ел).

Красноярскида ике буын абый бар. Әни: «Казанга барма, шунда кит», – ди. Миңлеголны Казанда артистлыкка укый дип уйлый. Миңлегол армиядә, Ачинскта хезмәт итә. Красноярск белән Ачинск картада берсе өстенә берсе язылган. Өч ел эшләгәч, Ачинскка юл тоттым, ара дүрт сәгатьлек юл икән. Күрешә алмадык. Миңлегол, дүрт айда унбер айлык авиамеханик курсларын тәмамлап, Саратов өлкәсенең Энгельс шәһәренә тагын ике ел хезмәт итәргә китеп барды. Алар Казаннан өч егет – Айрат, Фиргәт, Миңлегол – өч ел бергә хезмәт иттеләр.

Без дүрт ел күрешмәдек. Миңлегол армиядән кайткач, җәйге каникул вакытында очраштык. Бер-беребезгә сыенып, хәтта сөйләшкәнне дә хәтерләмим, озак утырдык. Аерылыр алдыннан, Миңлегол: «Күзеңне йом», – ди, йомдым. Ул кесәсеннән нидер алды, муеныма такты. Муенса! Тик күзне ачкач та күренми: бердән, караңгы, икенчедән, муенда. Аерылышу белән өйалдына кердем дә, муенымнан салып, шырпы яктыртып карадым. Муенса күп төрле төсләр белән яна! Кадерләп саклап кына таккаладым. Тик 1991 елда фатирыбызны караклар басты. Бик кирәкле һәм кадерле әйберләребезне алып чыктылар. Муенса да шулар кулына төште.

...Миңлегол, мин юллама буенча племзавод «Элита»да зоотехник булып эшли башлагач, кышкы каникул вакытында яныма килде. Без юллама буенча Оренбургтан

җибәрелгән агроном кыз белән махсус бирелгән ике бүлмәле фатирда яшибез. Мин эштән пирог рецепты язып алып кайттым, бөтенесен язылганча эшләдем, ә пирогның эчлеге ага, ни генә эшләтмәдем, асты яна (май ике тапкыр артык язылган булган икән). Миңлегол мичтән пирогны алып, астын кырып ташлап, шуның белән чәй эчерде. Мин елыйм, ул: «Ничәнче мәртәбә пирог пешерәсең?» – дип сорый. «Беренче», – дим. «Менә унынчы тапкыр пешергәч, остарырсың әле», – диде. Ул киткәч тә, шул сүзләрне искә алып, күп еладым.

Бераздан Миңлегол белән икәү аның Черногорскида гаиләсе белән яшәүче апасына кунакка бардык. Шунда Миңлеголның классташы Әюп һәм аның гаиләсе белән очраштык. Әюп минем исememне исенә төшерә алмый тора: «Дуся...» Ике дә уйлап тормыйча: «Фәния», – дидем. Ә исемем – Федосия. Красноярскидагы абыйга килеп төшкәч, хатыны Васса Николаевна: «Юк, алай дип әйтмә, Фаина буласың», – дип, миңа икенче исем кушты. Шулай итеп, минем дүрт-биш исемем булды. Миңлегол шуннан соң хатларында «Фәниям» дип яза башлады.

Язмамда гел «Миңлегол» (миңле угыл) дип яздым, бу – аның әнисенең әтисе Исхак бабай кушкан исем, күрәсең, туганда ук миңнәре күп булгандыр. Ә «Миңгол» дип аны музыка белгече Зәйнәп апа Хәйруллина, радиода эшләгәндә, беренче язмасы Хөснул Вәлиуллинның «Урал таңы»н эфирга чыгарганда атый.

Хатлар, хатлар...

Мин эшлим, Миңлегол әле укый. Яза: «Фәния, кайт инде, бозылуым бар», – ди. Мин: «Суыткычка кереп утырып торгала», – дип язам. Ул: «Ярый, алайса, үзем барып алам», – ди. Мин: «Бер юлны ике тапкыр тиресләмик инде», – дип кайтырга булам.

Казан, Казан – хыял үзәге!!!

Минем белгечлек белән ничек эшкә урнашырсың? Аллага шөкер, юлымда бик күп яхшы кешеләр очрады... Ике атна эчендә пропискага кереп, эшкә урнаштым.

Июль ае. Бер атнага ял сорап, авылга кайттык. Авыл советында язылыштык. Печән өсте. Миңлеголның туганнары күп. Кунактан кунакка йөрдек. Аннан үзебездә – Миңлеголларда кичә ясадык. Кичен Миңнехан абый (ул урманда эшли): «Энем, әбиеңә ике машина утын китердек, ярырга кирәк булыр», – ди. Иртәгесен Дүсмәткә киттек. Миңлегол көне буе утын ярды, юан-юан каен кискәләрен. Без авылның очында торабыз, безнең очта кәнсәләр, машиналар паркы, пилорама, ындыр табагы... Эшкә баручы, кайтучы шуннан йөри. Өлкән ирләр: «Егет, тукта, эштән чыгасың», – диләр. Миңлегол яра, мин җитешкәнчә өеп торам. Тәки кичкә утынны ярып бетерде. Әни тәмле итеп ашарга әзерләгән, бер акбаш та чыгарып куйды. Миңлегол эчмәде. Ашагач: «Минем тәнемне аракы белән у әле, Фәния», – диде.

Безнең бакча артында гына үзән, тау – бер ягында наратлар, икенче ягында имәннәр үсә. Кич искиткеч матур, җылы, тын. Миңлегол кырын ятып әкрен генә җырлый. Ул җыр бөтен авылга ишетелгән икән. Шуннан соң «Фәния артистны гына түгел, менә нинди егетне көткән икән!» – дип, авыл халкы сүзсез генә миңа фатихасын бирде.

Казанга кайттык, торыр урын юк. Миңлегол Татарстанның ун еллыгы исемендәге мәдәният сараенда эшли, җәй көне Петров паркында яшьләрне таганнарда атындыра. Ике атналап мәдәният сараенда тордык. Мәннәф абый (урыны җәннәттә булсын) – Миңлеголның әнисенең энесе дә шул сарайда эшли. Ул безгә яшәргә бер әбине (С.Сәйдәшевнең кече улының хатыны Тәлия апаның әнисе) табып бирде. Бер бүлмәле квартира, яшибез: кешеләр өчәү, бозау хәтле унөч яшьлек эт, ике мәче, аннары дүрт балалары туды, язга алты мәче булды. Эш күп: Миңлегол укый, эшли, этне карда коендыра, тарый, мәчеләрнең комын алыштыра, тырнакларын кисә, ә мин йон җыям да юам, йон җыям да юам...

Мин кайткан елны ук, ел ахырында «Мәхәббәт тәүбәсе» спектаклен сәхнәгә куйдылар. Миңлегол Энҗе исемле бик чибәр кыз белән төп рольләрдә уйныйлар. Яхшы уйнадылар. Мин спектакльдән кайтканда: «Дустым, болай булса, без бергә яши алмабыздыр», – дигәч, Миңлегол: «Ярар, ашыкма, син дә яңадан сәхнәгә басарсың, шунда аңларсың», – диде. Шулай итеп, Дилюс абый Ильясов сәхнәләштергән «Фәйзи» спектаклендә – Миңлегол-Фәйзинең кызы; Гөлсем апа Миргасимова сәхнәләштергән «Гөлшат» спектаклендә – төп рольләрдә; «Яшь йөрәкләр»дә Хәйретдин белән Сәрби

булып уйнадык. Шунда төшендем инде, сәхнә белән тормыш арасында бәйләнеш юк икән. «Асылъяр»да гына үзебез булып уйнаганбыз икән...

Аннан, хәзерге «Сәламәтлек комбинаты» урынындагы бер складтан ясалган квартирда тагын бер ел яшәдек. Улыбыз Марат шунда туды. Хуҗабыз, Просковья Никоноровна бик күп авырлыклар кичергән акыллы хатын, тормыш ваклыкларыннан ничек чыгарга икәнен өйрәтте, аның соңгы сулышынача аралашып яшәдек (урыны оҗмахта булсын).

Миңлегол консерваторияне тәмамлады. Культура сараеның директоры Савченко: «Квартир бирәм, үзебездә кал», – диде. Әйбәт кеше иде. Безнең бәхетсезлеккә каршы, үлеп китте. Яңа директор, усал хатын – Дунаева, безгә барактан унөч квадрат метрлы бүлмә бирде. Шунда балалар, әни һәм туганнар сыйды. Без анда унөч күрше бер коридорда, бер кухняда ашарга пешереп, чөкердәшеп яшәдек. Әни һаман саен шул вакытны сагына иде. Кызыбыз Роза туды. Тикмәгә генә халык мәкалендә: «Һәр бала үз ризыгы белән, үз бәхете белән туа», дип әйтелми, кызыбыз тугач, безгә минем эштән квартир бирделәр.

Икебез дә җаваплы эшләрдә эшләдек, икебез ике өлкәдә республика халкына хезмәт иттек.

Музфонд директоры булып эшләгәндә Миңлегол, өлкә комитетының икенче секретаре Рәис Кыямович Беляев ярдәмендә, Композиторлар союзына шәһәр үзәгендә бина алып, искиткеч зур тырышлык белән ремонтлатып, гүзәл Музыка йорты ясатты.

Татарстанның  халык артисты, КФУ профессоры Миңгол Вәгыйз улы Галиев, ягъни минем ирем, 1977 елдан музыка факультетында укытып, илебезнең төрле төбәкләреннән килгән йөзләрчә баланы олы тормыш юлына бастырды, һәм алар һәркайсы үз урынында халкыбызга хезмәт итә, остазларына зур хөрмәтлеләр. Татар милләтенең моңын, телен саклауда хезмәт куялар. Аның бүгенге шәкертләренең яше өчтән сиксәнгә кадәр.

Мин Авыл хуҗалыгы министрлыгы системасында утыз ел өлкән белгеч булып эшләдем, гел колхозларда нәселле терлекләр үстерү, сату, учёт, отчёт эшләрен тикшереп, ярдәм итеп йөрдем, республикабызда мин булмаган хуҗалык сирәктер.

Без ике бала үстердек. Марат авиация институтын тәмамлады, бөтен инженерларга инженер – олы белгеч, кызы Наилә 11нче сыйныфта укый. Розабыз кабатланмас илаһи тавышлы җырчы, укытучы, тормышны яратучы талант иясе иде. «Иде», дим, чөнки 37 яшендә 9 яшьлек улын, 6 яше тулмаган кызын калдырып, 2010 елның август ае челләсендә вафат булды. Иске Комазан авылы зиратында, әбисенең баш очына күмелде. Аллаһы Тәгалә беркемгә дә мондый хәсрәтне бирмәсен иде.

Әнием соңгы ундүрт елын безнең белән бергә Казанда яшәде. Мин – командировкаларда, Миңлегол – гастрольләрдә. Әни балалар үскәндә бик булышты, өйнең бизәге дә, йозагы да булды. 76 яшендә мәңгелеккә күчте, туган авылы Җөри зиратында әби, бабай, туганнар янында җирләнде.

Гомер – бер мизгел шул, бик тиз үтә. Безгә быел инде 75 яшь тула, Алла боерса.


Аллага шөкер, бер-беребезгә тугрылыклы булдык. Урта мәктәпне тәмамлагач, ун ел хат языштык, менә инде кырык сигез ел бергә.

Бер-береңә ышанып, бер-берең, балаларың өчен яшәү һәм кешеләр белән аралашып, ярдәмләшеп гомер итүне зур Бәхет дип саныйм.

**Фәния ГАЛИЕВА**

# ШИГЪРИ ДОГА ОСТАСЫ ИДЕ УЛ...

*Ул коеп куйган шагыйрь иде.*
Роберт Миңнуллин



Харрас Әюп (1946-2008) татар шигъриятенә романтик һәм үтә милли шагыйрь булып кереп калыр. Аның «Ничә гасыр елый Йагъкуб халыкның йөрәгендә» исемле шигырь юлы үзе бер милли тарих. Шигырь китапларының исеменә күз салсаң да, аларның йә моңлы[1], йә җырлы[2], йә сабыр[3], йә якты[4], йә кояшлы[5] булуын күрәсең. Символик мәгънә салынган калган китапларының да исемнәре хикмәтле: берсе «Җәяүле буран»[6] булса, икенчесе – «Каен балкышы»[7], аннан – «Таң суы»[8]. Ә менә күләмле лирик шигырьләрен ул «Ут аркылы сикерү»[9] исеменә туплаган. Инде беренче китабының «Ышаныч»[10] булуын да искәртик. Х.Әюпның рус телендә чыккан китаплары да бар[11]. Чирек гасырдан бераз гына узып киткән иҗат гомере өчен күләм артык зур түгел. Шагыйрь өчен сан түгел, ә сыйфатның беренче урында торганлыгы бәхәссез. Бу иҗатка бәя бирүчеләр арасында М.Бакиров, Ф.Галимуллин, Р.Миңнуллин, Р.Гаташ, Зөлфәт, Р.Сибат, Р.Вәли, М.Әхмәтҗанов, Р.Кутуйлар күренә. Шулай да фәнни бәяләмәләрнең азрак булуы сизелә.

Һәр шагыйрьнең башкалардан аерылып торган бер сыйфаты була. Х.Әюпта ул дини тематикага барып тоташа. 90нчы еллар әдәбиятында ул «иманлы шигырьләр»не иң күп язучы булгандыр. «Биш вакыт намаз» исемле китап та чыгарды ул.

Шагыйрьнең намазлыгы – язылмаган кәгазь. Иртәнге намаз вакытында шул кәгазьдә ул чын ихластан шигырь яза. Өйлә намазында ул адәм баласының Җирдә яшәвен акларлык гамәл турында уйлана. Икенде намазында лирик герой, дөнья карасына мана-мана җанын агартса, ахшамда төрле сәяси чорларда югалган мәңгелек рухи кыйммәтләрне исенә төшерә, ястүдә исә табына торган кыйбланың бер генә булуына инана. Әлеге шигырьдә дини эчтәлек бик тирәнгә яшеренгән, төп фикер тормыш фәлсәфәсендә чагыла. Күренекле галим М.Бакиров Х.Әюпның бу шигырен «дога-монолог» дип карый һәм, әсәрне атаклы грузин кинорежиссёры Тенгиз Абуладзеның «Покаяние» («Тәүбә итү») исемле фильмы белән чагыштырып, күп кенә уртак яклар таба. Алар совет тәрбиясе алган кешенең дин храмына килү юлын тасвирлауда күренә.

Шагыйрь иҗатының бер тармагы иман булса, икенчесе – тарихи хәтер. «Капка баганасы турында баллада» – Х.Әюпның иң уңышлы әсәрләренең берсе. Дин әһеле

---

1 Әюп Х.Г. Моңлы бер кыл: шигырьләр, баллада, поэмалар / төз. Р.Сабирҗанов, кереш сүз авт. Р.Миңнуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2012.
2 Әюп Х.Г. Көй эзләү: поэмалар, баллада. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2001.
3 Әюп Х.Г. Сабыр савытлары: шигырьләр һәм поэмалар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1992.
4 Әюп Х.Г. Йөз яктысы: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005.
5 Әюп Х.Г. Кояшлы яңгыр: шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983.
6 Әюп Х.Г. Җәяүле буран: шигырьләр һәм поэмалар / Кереш сүз авт. Зөлфәт. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996.
7 Әюп Х.Г. Каен балкышы: шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1985.
8 Әюп Х.Г. Таң суы: шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1987.
9 Әюп Х.Г. Ут аркылы сикерү: шигырьләр, поэмалар. – Казан: Мәгариф, 2004.
10 Әюп Х.Г. Ышаныч: шигырьләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1980.
11 Радуга: стихи поэтов Башкирии, Мордовии, Татарии, Чувашии и Куйбышевской области. – Куйбышев: Куйбышевское кн.изд-во, 1987. – Стихи Х.Аюпа в переводе Бориса Сиротина. – С.111-117; Аюп Х.Г. Летнее течение: стихи, поэмы / пер. с тат. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2008.

нәселенең унбер мизгелен тасвирлауга юнәлтелә бу баллада. Капка баганасының куышына язын сыерчыклар оя кора. Кешеләр күпне күргән имән баганалардан серләр сөйләтмәкче була. ...Хәзрәтнең хуҗалыгы яна. Янгыннан бары тик ике багана гына исән кала. Тырыш мулла яңа йорт җиткезә. Күмерләнгән ике багана да эшкә ярап куя. Төзелеп беткәч, бу нигезгә дә хуҗа табыла. Хәзрәт «кулак» дип куыла, өйгә бер ялкау күчә. Мулла балалары күптөрле кимсетелү күреп үсә. Яклаучы юк, сөйләшергә ярамый, капка баганалары гына күз яшенә чылана. Сугыш вакытында баганага атлар бәйлиләр. Алар чайкала, әмма аумый. Биш балалы мулла кызы үзе ахирәткә күчкәч, балалары шәһәргә китеп беткәч, йорт бушагач та баганалар басып тора әле. Ә сыерчыклар һаман кайта, оя кора. Менә берзаман баганалар ава. Кешеләр моңа ияләшә, ә кошлар юк. 30нчы еллар фаҗигасен менә шулай сурәтли шагыйрь. Билгеле, 1990 елда язылган бу әсәрдә Гариф Ахуновның «Идел кызы»ндагы Габбас мулла белән параллельләр сизелә, Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган»ы белән кисешкән урыннар да бар. Әмма бу баллада – камил тезмә формада, кызыксынып укырлык, бик тәэсирле мөстәкыйль әсәр.

«Базарлар» публицистик поэмасы да – Х.Әюп иҗатының бер уңышы. 1989 елда язылган поэма үз вакытында бик актуаль иде, хәзер дә кыйммәтен югалтмаган. Әсәрдә лирик персонаж базарга болай гына, бабайлардан калган бер гадәт буенча, бер йомышсыз, ил хәлен белер өчен генә чыга. Күренеп тора, шагыйрь биредә традицион башлам куллана:

*Базар карап йөрү – борынгыдан,*
*Бабайлардан калган бер гадәт.*
*Илнең хәлен базарлардан белеш –*
*Йомышсыз да йөрим кергәләп.*
*Белешкәлим әйбер бәяләрен,*
*Булмасам да болай сәүдәгәр...*
*Сөйли базар, бөтенесен сөйли,*
*Колак салсаң бераз син әгәр.*

Базар турында татар шагыйрьләре аз язмады. Ренат Харисның «Чехов базары» поэмасын искә алу да җитә. Разил Вәлиевнең «Чират» шигыре дә укучыны татар тарихына, әдәбиятына алып керде, Газинур Морат «Талчук» шигырендә Дөнья базарына ук барып чыкты. Әмма Х.Әюп «базары» – бөтенләй башка базар. Аның үзгәлеге – поэманың композициясендә. Ул, дөрестән дә, базарны хәтерләтә. Аның беренче һәм соңгы бүлекләре бару-кайту булса, төп өлеш, төрле базар исемнәре белән аталып, сату урыннарын хәтерләтә. Мәсәлән, «Колхоз базары», «Печән базары», «Әмәкәй базары», «Болгар базары», «Сорочи базары», «Дөнья базары».

Поэмада күп кенә проблемалар күтәрелә. Биредә әхлак та, сәясәт тә, икътисад та, фәлсәфә дә җитәрлек. Лирик персонаж тормышта таяныр кыйбла эзли.

*Кая таба карап табыныйм соң,*
*Дүрт ягым да минем кыйбла,*

– ди ул.

Поэмада сорауга җавап бар. Кыйбланың да кыйбласы булырлык як – ул кеше, шәхес булырдай кеше, беренче чиратта шагыйрь үзе. Ә «Өч кенә сүз» дип исемләнгән шигырендә заман китереп чыгарган проблемаларны чишә ала торган шәхес үзе үк күрсәтелә.

*Бер ишеләр яратылган базар өчен,*
*Икенчеләр яратылган азар өчен,*
*Өченчеләр яратылган илдәгенең*
*Бөтенесен бәйнә-бәйнә язар өчен.*

Харрас Әюпның бик матур пейзаж лирикасы турында әйтми үтеп булмый. Аның «Әбиләр чуагы» шигыреннән бер мисал:

*Табигатьнең Вакыт каршысында,*
*Тып-тын калып, башын игән мәле.*
*Тезелешеп, җәйне озатырга*
*Чыгып баскан печән кибәннәре.*

Шагыйрьнең бу шигыре әдәбият теориясенең бар таләпләренә җавап бирә. Моннан тыш Х.Әюпта шигъри гармония тулысынча саклана. Сурәтләү чаралары артык кычкырып, күзгә бәрелеп тормый, әмма һәр лирик шигыре үзе бер җанлы картина булып чыга. Анда табигатьне җанландыру бик көчле бирелә. Шагыйрь кешедә булмаган өр-яңа троплар эзләү белән дә мавыкмый. Шул ук вакытта беркемне кабатламый да. Ә менә «Су буенда казлар төзәтенә...» дип башланып киткән шигыре тагын да тәэсирлерәк килеп чыккан.

*Су буенда казлар төзәтенә,*
*Уйнап туйганнар да инештә.*
*Ап-ак булып әзерләнә алар,*
*Әзерләнә туйлар килешкә.*

*Агымсуда таллар чәч юалар...*
*Усакларда – алсу намазлык:*
*Гамәл-гыйбадәткә талганнардыр,*
*Илгә-көнгә теләп тазалык.*

Тагын бер тармакны халык педагогикасы, йолалар, татар халкының матур гадәтләре турында язылган шигырьләр тәшкил итә. Менә «Татар җыры» исемле шигырьдән бер өзек:

*Шушындадыр бу дөньяның*
*Бәрәкәтләр ятар җире:*
*Уятадыр, уйлатадыр,*
*Юатадыр татар җыры...*

Ә «Өй салу» шигыре үзе бер педагогика.

*Васыять итеп калдыргандыр безгә,*
*Юкка әйтмәгәндер бу халык:*
*Үз гомереңдә бары бер булса да*
*Син кирәргә тиеш өй салып.*

«Бусага» шигыренә дә битараф калып булмый. Х.Әюпның һәр шигыренә якташлары, авылдашлары, нигезе, табигате килеп керә. Ул аларга үзенчә дәшә белә. «Урамдашлар, чирәмдәшләр, шатлыкташлар, кайгыдашлар, җырдашлар» үзләрен «Чакыру» шигыреннән таба алгандыр. Шагыйрь, гәрчә исемнәрен әйтмәсә дә, Мөхәммәт Мәһдиев кебек, авылдашларын әдәбиятка кертеп калдырган. «Авылымда шундый шагыйрьләр бар» шигырендә аның авылдашлары тапкыр, җор сүзле булып күз алдына килеп баса.

*Беркайчан да алар тапкыр сүзгә*
*Кермәгәннәр кеше кесәсенә,*
*Онытылмаслык итеп әйтә белгән,*
*Исәп тотмый телгә күчәсенә.*

Х.Әюпның «Шигырьнең өч халәте» триптихы форма һәм интонациясе белән Һади Такташны да хәтерләтеп куя. Бирелә шагыйрь сыйфатлы шигырь өчен көрәшә. Ул рифма-ритм тезмәләренең генә шигырь булмавын күрсәтә. «Буш шигырь»дән сакланырга чакыра.

*Язылмый кал лутчы,*
*Ил телендә*
*Яманат алганчы: «Буш шигырь...»*
*Яхшы чакта аерыла белик*
*Бер-беребездән – ярый, хуш, шигырь!*

Х.Әюпның һәр шигыреннән моң сизелеп тора. Бу моңның сәбәбе сагыну сагышы, юксыну, әрнү, үпкәләүдәдер дип фаразлап була. «Йөрәк атым» поэмасының үзәгенә татар халкы тарихы салынган. Атларның хуҗалыктагы вазифасыннан башлап, «ирләр йөрәгендә иярләнгән ат ятар» мәкале аша сугыш чорларында үзләре җигү атына әйләнгән хатын-кыз, бала-чаганы кертеп:

*Илдән язуың да ерак йөрмәс,*
*Башың иеп һаман тик торсаң –*
*Ат күрмәгән адәм актыгының*
*Кулларына тезген тоттырсаң...*

– кебек сәяси хатага ук барып чыга. Поэмада татар халык мәкальләре белән сүз уйнату еш кабатлана. Шуларның берсе болай яңгырый:

*Ир-ат исмен йөртеп,*
*Йөрәгенә*
*Атлар сыйдыралыр ир сирәк...*

«Дүрт аяклы ат та абына» дисә дә, шагыйрь илдәге эчүчелек проблемасын да читләтеп үтми. Ат тарталмас кайгы килгәндә, халыкны җыр-атлар юатуын да күрсәтә. «Карурман» җыры аша исереклектән адашкан кешеләргә чыгу юлын табып бирә. Иярләнгән атның кайвакыт хатын-кыз йөрәгендә дә ятуын тасвирлый. Социаль юнәлешкә дә игътибар итә шагыйрь. Поэмада мәхәббәт тә бар. «Йөрәк атым» чакыру белән тәмамлана.

*Ирләр арасында йөрим бүген,*
*Ирләр табалмыйча аптырап,*
*Яман икән атсыз яшәүләре –*
*Ирләр йөрәгенә ат кирәк!*

Мәктәп программаларында да урын алырга хаклы әсәр бу. Тәэсир итү көче бик зур. Димәк, безнең арадан бик вакытсыз киткән үзенчәлекле, моңлы шагыйрь Харрас Әюп иҗатына кабат-кабат әйләнеп кайтасылар бар әле...

**Фәридә ХӘСӘНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

## Харрас Әюп

### Авырткан җир

Авырткан җир бәрелүчән була,
Тагын бәрдек сине, милләтем!
Чорга бәрдек,
Игелексез чорга,
Ничек түзәсеңдер син ятим.
Наркотиклар кадамакчы сиңа,
Чыгып басып кемдер мөнбәргә,
Күзләреңә карап алдамакчы...
Сөяк-фәлән юк шул телләрдә.
Авырткан җир бәрелүчән була,
Бу юлы да саклый алмадык.
Сизмәмешкә күпләр салындылар,
Дәрәҗәгә, малга алданып.
Мәнсезлекнең аның милләте юк,
Кемдер бәрә – халык сызлана:
Башкаенда йөрер йөз төрле уй,
Йөрәгендә сыкрар йөз яра.
Замананың башы авыртмый шул...
Булмаган баш ничек авыртсын!
Барсына да эндәшмичә түзгән –
Без бу чаклы нинди халык соң?!
Әллә халык, әллә кара сарык:
Тел – йозакта, язмыш – киртәдә.
Авырткан җир бәрелүчән була, –
Кая бәрелербез иртәгә?

### Хәтер

Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Яшәмәде халык хәтерсез;
Томаларга теләсә дә еллар,
Бәреп чыкты барыбер әйтер сүз.

Гөрләгән дә булды, дөрләгән дә –
Язып бара хәтер барын да:
Югалтырга безнең юк хакыбыз
Яманын да, яхшыларын да.

Мәкер өчен түгел безнең хәтер,
Зураймыйдыр һичкем үч алып.
Бүгенгесен, үткәндәген җуйса,
Киләчәктән мәхрүм ул халык...

Халык хәтереннән аерылганның
Яшәве дә әрәм, гел зая.
Азга гына килә җиргә кеше –
Хәтерләрдә гомер озая.

Яшералмас вакыт пәрдәләре,
Киткәннәр дә кире кайтырлар –
Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Югалмасын бары хәтерләр!..

***

Җир-суларым иркен сулап ята,
Кырларымда иген өлгерә.
Сайрасыннар әйдә – кошларыма
Җырларымны бирдем өлгегә.

Колачымны җәеп чыгып басам:
Болытларым килә, җилләрем...
Кешеләрем – йөрәк түрләремдә, –
Һичбер вакыт ятка бирмәмен.

Күкләремне карап кына торам,
Гел янымда кояш-айларым.
Һич зарланмыйм керфек какмасам да –
Бу язмышны үзем сайладым.
Киталмамдыр җирдән,
Юкса дөнья
Кемгә калыр, нигә юлыгыр?
Яз-күзләрем барлап чыгыйм диеп
Йөрү генә минем бу гомер...

## Бусага

Киткәннәрнең җылы аяк эзен
Саклап тора сыман бусага,
Кеше кайта,
Кайта туган өйгә,
Бик күп сулар аккач булса да.

Исән булса, үзе кайтып төшә,
Хат-хәбәре килә, соңласа,
Җилләр булып газиз җаны кайта,
Даны кайта, исән булмаса.

Тәүге эзгә бер басарга тиеш
Кеше, кайтып ничек булса да;
Намусыңа кара таплар кунса,
Юк, уздырмый эчкә бусага.

Үталмасаң әгәр аның аша,
Урын табылмаса түреңдә, –
Каһәрләнеп куылган эт кебек,
Син елларның ишек төбендә.

Нинди хәлдә кайтып баш орырбыз
Туган өйгә – изге тупсага?
Без узарга тиеш түргә кадәр,
Урыныннан йөрәк купса да!..

***

Бу дөньяда мине яраттылар.
Дөньяларын мин дә яраттым:
Ак җанымны, җилләренә җәеп,
Шул дөньяда йөзеп каралттым.

Дөньяларын мин дә яраттым ла,
Яраттым ла азга булса да.
Ятканнар – кала...
И җир йөзе!
Миннән соң да назга сусама...

# СӘХНӘДӘН НУР ЧӘЧЕП



– Тукта, кайда соң әле мин? – дип уйлап куйды кыз, батып барган кояш нурларыннан аллана башлаган болытларга карап. Ә-ә, аркасына чалкан яткан хәлдә Кабан күлен бер яктан икенче якка иңләп йөзә икән. Әнисе үлгәннән бирле, Дания гел шушы Урта Кабанда булды. Җәен коенды, кышын чаңгыда шуды. Бер ярында аларның үз йортлары, каршы якта ботан бакчасы. «Бәрәч, кояш та сүрелеп беткән», – дип ашыга-ашыга өйләре торган яр ягына колачлап йөзеп китте кыз. Көндездән үк җыеп куйган сулары тәмам җылынып җиткән, Дания яшелчәләрне ипләп кенә коендырып үткәч, җимеш агачларын да сугара башлады, шунда бер дә көтмәгәндә аның күңелен «нигә барып карамаска, ашамаслар әле» дигән уй чеметеп алды.

Әмма дә ләкин бөтен күргән-белгәннәре тарафыннан «чын артистка» дип макталган кызны конкурста төшереп калдырдылар. Ялгыштылар микәнни? Алай дисәң, имтихан алучыларның беренчесе – Камал театрының баш режиссёры Ширияздан Сарымсаков, икенчесе – шәп артист булу өстенә режиссёрлыкка да укып кайтып, инде танылу алган Празат Исәнбәт ләбаса...

Училищега керә алмавында, бәлки, үзенең дә гаебе булгандыр. Зур алма, гадәттә, соң өлгерә – балалыгы баштан ашкан... Аның көндәшләре янып торалар, искиткеч чаялар да. Сәхнә чи утынга охшаган артистларны өнәми шул.

Тагын бер ел үтте. Дания инде тугыз класс тәмамлаган, бер айдан паспортлы да буласы зур кыз. Шулай да каршысына килүче егет-җиләннең туктап артыннан озын-озак карап калуларына ияләнә алмый. Вахитов клубындагы концерттан соң булса кирәк, аның янына өлкән яшьтәге фотограф килеп: «Кызым, рөхсәт итсәң, фотога төшерер идем», – диде. Кабат-кабат, төрле ракурслардан торып төшергәч, көрсенеп:

– Мэрилин Монроң бер читтә торсын, кызганыч, мондый чибәрләр бәхетле була алмый! – дип, аптырап калган Дания яныннан уйчан гына китеп барды.

Нишләп алай ди бу карт абый, әнием үлгәнне белеп кызганамы? Әйе, театральныйга бу юлы да алмасалар, бәхетсез итәрләр шул – яңа курсны өч-дүрт ел үткәч кенә җыясылар икән. Дания өенә моңсу гына кайтып керде. Һәммәсе инде йокыда. Әнисе өйрәткән догаларны укыгач, ул да ереп йоклап китте. Иртүк торып трамвай тукталышына йөгерде һәм, якынлашып килгән 8нче трамвайның ачык баскычына очып кына кунып, Казанның үзәге булган Кольцо ягына юл тотты. Баумандагы Республика фәнни-методик үзәге урнашкан йорт каршында төркем-төркем булып яшь җилкенчәк урала. Абитуриентлар, йортның беренче катыннан икенче катына алып менүче текә баскычларны да сырып алганнар, имтихан буласы бүлмә каршындагы коридор да умарта оясыдай гөж килә. «Керергә теләүчеләр былтыргыдан да күбрәк икән!» – дигән уй яндырып үтте Даниянең күңелен. Аңа таба төшеп килүче арык кына малай, әйтерсең, аның уен сизеп: «Артист булырга теләүчеләр 500ләп диделәр анда», – дип дивардагы исемлеккә ымлады. Имтихан алучыларның шул узган ел үзен кире борып

кайтарган режиссёр абыйлар икәнен дә абайлап алды кыз, әмма курыкмады, ни әйтсәң дә, былтыргы «шөкәтсез үрдәк бәбкәсе» түгел инде ул, тугыз класс тәмамлаган, бер айдан паспортлы да буласы зур кыз... Имтиханнар берничә көнгә сузылса да, Дания ару-талуны сизмәде.

Әлеге аралашучан малайның исеме Юныс икән. Ул, Данияне җитәкләп:

– Әйдә, алынганнарның исемлеген чыгардылар!.. – дип, аны үзе белән ияртеп алып китте. Фамилияләрен туйганчы карагач, кайтырга дип баскычлардан торган тышкы коридорга чыктылар.

Әле иске исемлекне дә алмаганнар! (Әлеге исемлекнең берничә бите мәкалә авторында саклана.) Дания ансын да карарга булды. Тик чандыр малайның: «Ә хәзер менә монда кара, апа!» – дигән сүзен ишеткәч, «Ниткән апа булыйм ди мин сиңа?» – дип турсайды.

– Мин сигезне бетереп килдем, ә син, әнә, тугызны!.. Ярар, ачуланмасаң, «Дания» дим алайса...

– Шулай диң шул, «энем» Юныс. Без бит курсташлар!

1962 елның 15 июленнән бирле 53 ел вакыт узып китсә дә, берни онытылмавы сәер һәм сәер дә түгел.

– Кара әле, Дания курсташ! Монда сиңа кадәргеләрдән – 16 кешене, синнән соң булганнардан 12сен сызганнар. Сине 28 кеше арасыннан сайлап алганнар булып чыга түгелме соң?!.

Имтихан алучылар аеруча шуны ачыкларга тиеш: булачак артист үзендә зур рухи көч тәрбияли алу сәләтенә ияме? Режиссёр ягыннан искән җил уңаена гына борылгалап торучы флюгерь булып калмасмы? Әнә бит: «Җитте, җитте, җырыңны туктат!» – дип торганда да, Даниянең үзсүзлеләнеп: «Юк-юк, җырлап бетерәм, җырлап бетерәм! Әле мин сезгә биеп тә күрсәтәм!» – дип чәчрәп торуын начар якка да юрап була лабаса. Әйтик, артистлардан җансыз курчаклар ясарга хыялланучы бүгенге сектант режиссёрлар Данияне, һичшиксез, кире борып чыгарырлар иде. Чөнки аларга кысыр фантазияләрен тормышка ашыру өчен крепостной крестьян дәрәҗәсенә төшерелгән артистлар кирәк.Даниянең театр дөньясына килеп керүе, әлбәттә, җентекләп өйрәнүгә лаек. 1961 һәм дә 1962 ел курсларына сайлап алынган утызлап кыз арасыннан бары ул гына театр сәнгатенә һаман да бөтен күңеле белән хезмәт итә. Әйе, театр сәнгатен фәнни өйрәнүчеләр бу артистканың иҗаты ничек шулай озын гомерле булуын, өстәвенә һаман үсештә икәнен дә күреп, артистканың болар өчен көчне кайлардан алуын махсус өйрәнергә тиешләрдер...

1962 елның 16 июлендә «Укырга алынганнар исемлеге» каршында кичергән мизгелләрнең дәвамы булып кояшлы сентябрьнең беренче көне килеп җитте. 3нче, 5нче, 8нче маршрутларның трамвайлары даңгыр-доңгыр килеп йөргән К.Маркс урамының протез заводы итеп үзгәртелгән чиркәвенә каршы якта физкультура институты бар. Әнә шуның икенче катындагы иң зур аудиториядә башланды инде бу яңа җыелган төркемнең беренче адымнары. Уку башланып киткәндә, кызлар егетләрдән күбрәк иде. Физкультура институтында соңгы елларын укып, иртәгә педагог булып чыгабыз дип йөрүче ир-ат халкы берьюлы шулчаклы күп матур кыз белән очрашканда: «Каян гына табып бетерделәр икән боларны?» – дип аптырап кала. Беренче елны ук унлап кыздан колак какты курсыбыз. Моны кыз баланың кияүгә чыгып калырга дигән омтылышы белән генә бәйләп карау бик үк дөрес тә булмас. Иң аяныч сәбәбе дип шул чорда Камал театры кичергән шаукымны атар идем. Татар тамашачысының татар театрыннан бизгән чоры иде бу. Празат Исәнбәт, Дамир Бәдретдинов, Асия Хәйруллина, Шәхсәнәм Әсфәндияроваларның дәресләре ничек кенә җанлы барса да, татар театрын ябып куярга хәзерләнәләр дигән шомлы сүзләр күңелләргә керә торды.

Әмма безнең остазлар да төшеп калганнардан булмады: сәхнә теле укытучыбыз Асия Хәйруллина, аның ире Халит Кумысников, татар теле һәм әдәбиятын укыткан Вахит Хаков, француз теле укытучысы Миләүшә Маннурова, икенче курс студентларына сәхнә теленнән дәресләр бирүче атаклы Габдулла Шамуков (Наил Әюп, Хәлим Җәләлов, Наил Шәйхетдин һ.б.ларны укытканда, безне дә якын итеп үз канаты астына алгалый иде) кебек чын милләтпәрвәрләребез безгә күп нәрсәне төшендерде.

Дания, сәхнә теле педагогы, җан җылысы ташып торган, ихлас күңелле, милли җанлы Асия Хәйруллинага сыенды. Аңардан көч алды. Асия апабыз да үги ана тәрбиясендә калган бу кызга чын ана булырга тырышты. Яшүсмер кызга кирәкле киңәшләрен биреп торды. Рухын үстерде.

Празат Исәнбәт киткәч, актёрлык осталыгын укыту Рәфкать Бикчәнтәев белән Нәҗип Гайнуллинга күчте. Рәфкать абый режиссурадан да дәресләр бирде. Сәхнә хәрәкәтләрен Шәхсәнәм Әсфәндиярова, биюләрне Анна Гацуллина, фехтованиене исә Марсель Сәлимҗанов үткәрде. Дания алардан да үзенә кирәкне ала белде.1965 елны Ширияздан Сарымсаков өченче курста укып йөрүче Даниягә Мостай Кәримнең «Ай тотылган төндә»ге Шәфәкъ ролен тапшырып, үзе Дәрвиш роленә алынып, репетицияләр башлады. Безгә репетицияләрен дә, спектакльләрен дә күп тапкырлар карау бәхете тигәнгә, ул көннәр дә яхшы ук истә. Спектакльнең иң көчле тәэсир иткән ягын әйт, дисәләр, Даниянең моң, наз, тетрәндергеч сагышларны сыйдырган көчле күкрәк тавышына Ширияздан абыйның чын трагикларда була торган көр тавышы килеп кушылган мизгелләрне искә төшереп, үземне шунда бөтенләй башка бер ят театрда утыргандай хис иткәнемне сөйләр идем. Ә бит Станиславский «Трагик булыр өчен ни кирәк?» дип сораучыга «тавыш» дип, юкка гына әйтмәгәндер. Сәхнә тәҗрибәсе җитенкерәмәгән студентка гына булса да, нәкъ менә Ходай Тәгалә бүләк иткән гүзәл тавышы белән Шәфәкъне ул дәһшәт чәчүче олы көчкә ия Дәрвиш белән көрәшерлек шәхес итеп гәүдәләндерә алды. Үз теләгенә ирешә алмаган Дәрвишнең күк күкрәгәндәй итеп, «теләсәм, айны да сүндерәм» диюенә каршы, «яхшы чакта чыгып котыл» дип гайрәт белән нәгърә орулары әлегәчә хәтердә.

19 яшьлек студентканың Шәфәгын икърар иткән Ширияздан Сарымсаков, шул ук елны, Әхсән Баянның «Күзләре нинди иде?» дигән әсәрендәге Айса ролен дә Даниягә ышанып тапшырды. Дөрес, әлеге спектакльләр артык озын гомерле булмады кебек. Бигрәк тә соңгысы ифрат аз уйналды. Әмма монда төп рольләрдә уйнаучы Даниянең һичбер гаебе юк иде. Болар режиссура сайлаган юл белән бәйле. Әйе, артист иҗатын тулы тасвирлау өчен, режиссёр эше белән бәйләп өйрәнү сорала. Образ дөньяга аларның уртак җимеше булып туа...

Марсель Сәлимҗанов театрның киләчәген бары үз шәкертләре кулында гына итеп күрергә тели иде. Ул, табигый теләгенә каршы килеп булса да, башка мәктәп үткән студентканы үзендә калдырасы итте.

Карт фотограф Дания турында Мэрилин Монроң моның бер ягында торсын, дигән. Ә бит чыннан да бик кәттә киенмәсә дә (күп очракта шактый киелгән яшел җәйге пәлтәдән йөрер иде), бизәнмәсә дә, Даниянең ир-атларга тәэсире чик-чамасыз иде. Хәтта үз курсыбызның бик тәҗрибәле егетләре дә Калинин посёлогында яшәүче Нургаяз абзый (Даниянең атасы) янына барып, 18 яшьлек кызын кияүгә сорап йөдәттеләр. Бергә укулар күп чакта бер-береңнән биздерә, туйдыра, чөнки күп кенә кирәкмәгән нәрсәләргә дә күзең төшә. Ә менә безнең ир-егетләрдә Дания, киресенчә, бик яхшы тойгылар уята алган булып чыкты. Әгәр Дания ризалык биргән булса (бу турыда уйлавы да куркыныч), театр училищесыннан ук бала да үстерә башлаган булыр иде. Һәм бу очрак тулаем өлгереп җитмәгән артисткага үсешен тоткарлаучы, күп нәрсәдән мәхрүм итүче бер авыр йөккә әверелер иде. Шуның белән бергә, ире башка театрга билгеләнгән очракта, Даниягә дә ерак шәһәргә китү куркынычы янар иде.

Соңгы уку елында Данияне Х.Уразиков куйган «Хуҗа Насретдин»да биюче персонаж сыйфатында да сынап карарга өлгерделәр.

1969 елда армия хезмәтендә йөреп кайтсам, театрда азәрбайҗан режиссёры Агакиши Кязимовның диплом спектакле бара. Мин киткәндә, Дания «Хуҗа Насретдин»да сүзе дә булмаган Кара Җарияне биеп калган иде, инде Җаббарлының «Айдын»ында да эпизодик роль белән биеп каршылый... шәп биесә дә, кайда моның сәхнә үсеше, дими ни дисең?! Шул ук ярым ялангач гәүдәсе белән кызыктыру гына бит инде! Үзгәреш – өстәлгә үк менгереп биетүләрендә – Шансонетка Сусанна оятсыз булып күренсә дә ярый, диюләреме... Әлбәттә, Даниядән күпне көткән курсташын нәүмиз итте бу хәл. Аның каравы, берничә көн үтүгә, Данияне «Миркәй белән Айсылу»да күргәч, курсташым янына кулларым алкышлардан, күзләрем исә елаудан кызарган килеш



*Ф.Бүләков. «Сөясеңме, сөймисеңме?»*
*Карчык – Д.Нуруллина, Карт – Р.Шәрәфиев.*

атылып кердем. М.Гафуриның «Кара йөзләр» повесте буенча Н.Исәнбәт язган бу пьеса М.Сәлимҗанов тарафыннан сәхнәләштерелеп 1966 елда ук сәхнә тота башлаган икән. Танышлар: «О, ул Марсель Сәлимҗанов!» – дип сөйләсәләр дә, бу яңа баш режиссёрның 1966 елда «Соңгы хат»ын гына күрү насыйп булганга («Бәйрәм кичендә» комедиясен ул әле мин армиягә киткәндә башлап кына калды), Рәфкать Бикчәнтәевнең кояш тулы милли спектакльләрен күргән мин фәкыйрьнең күңелендә Марсель Сәлимҗанов исеме әлегә ифрат бертөсле, эчпошыргыч уйлар гына уята иде. Ә менә аның режиссурасындагы «Миркәй белән Айсылу» тетрәндергеч югарылыкта ачылып, Данияне бөтен куәтенә балкыткач, мин ни әйтергә белмәдем. Курсташым: «Мәскәү Кече театрыннан Новохижин килеп куйган спектакльне дә кара әле, бу юлы минем чират», – дигәч, анысына да бардым. Даниябез А.Островскийның «Соңгы корбан»ында Юлия Тугинаролендә иде. Бу роль беркайчан да очраклы артистларга бирелми. Аны заманында рус сәхнәсенең иң бөек артисткалары М.Н.Ермолова, А.К.Тарасовалар уйнаган. Даниягә дә башта Юлияне уйнаучы Шәхсәнәм Әсфәндиярова янәшәсендә халык күренешләрендә генә йөрергә туры килгән икән. Әмма соң булса да, уң булган, сәхнә тормышын әле башлап кына җибәргән артистканың инде шундый катлаулы рольгә дә өлгереп җитүе Даниянең генә түгел татар театрының да үсештә булуын күрсәтә иде.

– Образларың бер-беренә охшамаган, Шәфәкъ, Айсылу, Юлия шундый да төрлеләр, палитраң бик бай икән, – дип мактавыма «Партнёрларым әйбәт!» дип кенә куйды Дания. Чыннан да, «Миркәй белән Айсылу»да Ринат Таҗетдин белән уйнаса, Юлиянең Дульчины – Шәүкәт Биктимер, Прибытковы – Фуат Халитов – өчесе дә татар сәхнәсенең гигантлары! Кайбер артисткаларга мондый бәхет ун елга бер елмая!

Әмма шагыйрь Фәйзуллин шигырендәгечә, «шатлыгы да, кайгысы да бөтен бездә» дигән дөреслекне дә оныттырмый аңа сәхнә. Хатын-кыз үз вакытында иргә дә чыгып калырга тиеш. Ярый ла ире хатынын сәхнә белән бүлешергә риза булса! Бу сынау Дания җилкәсенә дә төште. Сәлимҗанов «театрны ташлама», дип күпме орышып та тыңлата алмагач, «ирнең сәхнә ярата торганын да таба алыр идең, дура син!» дип озатып кала. Ике елын радиода сәхнәсез тилмереп уздырган Дания, ире белән аерылышып, 1972 елгы кечкенә Айсылуын – олы юанычын тоткан хәлдә театрга кире кайтты. Марсель Сәлимҗанов, ачуын онытып, аны кабат төрле рольләр белән каршылады. Нурихан Фәттахның «Кол Гали» әсәрендәге онытылмас Чәчәк образы сәхнәгә нәкъ шул 1974 елда күтәрелде. 1975 елны исә гастрольләр уңае белән «Огонёк» журналының август санында Мәскәү театр белгече Г.Данилованың «Старейший национальный» дигән мәкаләсе чыкты. Анда шундый юллар да бар иде: «Заметны работы Д.Нуруллиной, у неё своя, звучная, чистая и трепетная интонация…» Дания әлеге Мәскәү гастрольләрендә Чәчәктән тыш Б.Горбатовның «Бер төн»е буенча М.Сәлимҗанов куйган спектакльдә илбасарларга каршы туган илен якларга күтәрелгән Варяны да уйнады.

Марсель Сәлимҗанов: «Дания, ике елга китеп торган арада артистка буларак шактый күпне югалтырга өлгергән», – дип сукрангаласа да, үзе аның белән яратып эшләде. Даниягә дә аның белән иҗатташлык итү җан рәхәте иде. Кайбер режиссёрлар «икенче план, икенче план» дип туктаусыз сөйләнсәләр дә, аларның спектакльләрендә икенче планның эзе дә булмас, эксперимент дигәннәре дә ватык машина әрҗәсенә утырып йөрүгә генә охшар, күпне сыйдыручы системадан шыткан Марсель Сәлимҗанов режиссурасы исә япон яки немец машиналары кебек күп чакрымлы араларны да

җиңел үтәр, тегеләрнекедәй бер урында таптанып, болганып, ялган хәрәкәт кенә күрсәтеп маташмас. Артистның алтын вакытын беркайчан да юк-барга әрәм итмәүче, иң мөһиме, Станиславский системасындагы «жизнь человеческого духа»ны ачуга хезмәт иттерүче Сәлимҗанов режиссурасын Дания бүген дә сагына. Алар бергә тапкан утыздан артык образ арасында Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар»ындагы Биктимер картның (Шәүкәт Биктимеров) килене, ире өстеннән йөрүче оятсыз, зәһәр телле Зәмзәмбану да бар. Шушындый үткен характерлы рольләре рәтендә Аяз Гыйләҗевның «Китмәгез, тургайлар!» драмасындагы дәрте чиктән ташып торган Фаягөлне дә күрсәтергә була.

Дания, алда әйтелгәнчә, сәхнә партнёрлары мәсьәләсендә дә бәхетле иде. Андый сәхнә бәхете артистканың гомерлек юлдашына әверелде. Шәүкәт Биктимер белән иҗатташлыклары «Зәңгәр шәл»дә Ишанның икенче хатыны Мәрфуга, «Баһадирлар»да Ленин-Биктимеров һәм Ирина-Нуруллина, «Алты кызга бер кияү»дә Хәдичә һәм дә Рәхмәтулла ролендә дәвам итте (дөрес, бу ролен Шәүкәт абый якын итмәде, бер-ике уйнауга ук ташлады); Ринат Таҗетдин белән бергә уйнаган роле янына да тора-бара яңалары өстәлде. Кол Гали һәм аның «Кыйссаи Йосыф» поэмасын уттан да саклап кала алган Чәчәк булып уйнадылар, «Кичер мине, әнкәй»дә Рульсез Кирам белән тотнаксыз Дилфүзә булып уртак баланы апаларына ташлап киттеләр, «Илгизәр + Вера»да исә ваемсызның ваемсызы булган ире Хәлиулла янәшәсендә, беркатлы хатыны булып марҗа киленнәре Вера белән интектеләр, «Баскетболчы»да беренчесе – данга сусаган баскетболчы Сократ, икенчесе бу хыялый иреннән тәмам гарык Люция булып та мәш килделәр. Кыргызларның моңсу комедияләрендә Празат Исәнбәт аларны Бопуш Миңколаев һәм Кукуш ханым итеп тә уйнатты. Монда да комик осталыклары яңа яктан ачылды. Дания Равил Шәрәфи белән дә тамашачы һәрчак яратып карый торган пар була алды. «Һиҗрәт»тә Гайнетдин (Шәрәфиев) мулланың Саниясе, «Хуҗа Насретдин»дә Хуҗаның Гөлбануы, «Канлы күләгәләр»дә Габриэль Фастосның сеңлесе Клара Фастос дисеңме, артистканың хәтта Равил Шәрәфи «Сөйгән ярым ятка кала» комедиясендә уйнаган Харамша сәүдәгәргә берүзе берьюлы өч хатын ролендә, ягъни Сыңарсылу (зифа буйлы ямьсез хатын), Майҗыя (чибәр йөзле иләмсез хатын) һәм Артистка Әфсания Арчинская булып партнёрлык иткәне дә бар. Әлбәттә, берьюлы өч роль уйнау авыр. Монда да артистканың «партнёрдан да тора» дигәне искә төшә. Бу фикергә режиссёрдан да күп нәрсә тора дип өстәр идем. «Сөйгән ярым ятка кала»га тормыш бирүне бик кызыклы, беркемнекенә дә охшамаган алымнар белән эш итүче Фаил Ибраһимовка тапшырулары артистканың уенын отыры баетты, театрның репертуарына да бик мөһим бизәк өстәде бу спектакль. Иҗатчыларга бик үк камил булмаган бу пьеса белән җиңү яулау авырлыклар аша килсә дә, артистканың эш алымында яңа төсләр пәйда булды. Әйе, яңа режиссёрлар белән эшләү бик мөһим. Үз казанында гына кайнаучы артистлар иртә үтмәсләнә. Дания хәтта яшь-яшь, тәҗрибәсезрәк режиссёр белән дә бик теләп эшли. Вакытында әдәби бүлек башлыгын Марсель Сәлимҗанов «Сөясеңме, сөймисеңме?» әсәрен алып кергәне өчен, «мондый юк нәрсәләр белән йөрмә инде», дип кире борган иде. Радик Бариев шуны театр китапханәсеннән табып булса кирәк, төп рольләргә Дания Нурлы белән Равил Шәрәфине алып, яшь чакларын уйнауны талантлы яшьләргә дә тапшырып, сәхнәгә менгезгәч, зур уңышка иреште. Әйе, режиссёр һәм артистлар әсәрнең ясалмалылыгын тормышның үзеннән тапкан тере орлыклар белән баетып, эш барышында шулардан татлы һәм ачы җимешләр үстереп, әсәрне бүгенге тамашачылар да тетрәнеп карарлык спектакль итә алды.

Яшь режиссёр дигәннән, Даниянең моннан 23 ел элек Ренат Әюп белән берлектә иҗат иткән Кәбирәсен дә искә төшерү зарур. Монда да Дания Равил Шәрәфи белән партнёр иде. Гафур Каюмовның «Һинд кызы» дигән комедиясе нигезендә туган бу гаҗәеп кызыклы спектакль, тамашачылар кырылып йөрүгә карамастан, үзенә тиң мактау сүзләре ишетмәде. Ул чактагы сәнгать яшьләренең хәле бүгенге яшьләрнекеннән бик аерыла иде шул. Хәзергеләр бер-ике спектакль куюга, йә булмаса бер-ике пьеса язуга, классиклар дәрәҗәсендә йөри башлыйлар. Без яшь чакта фикерләре күптән искергән драматургларның әсәрләре дә яшь көчләрнең әсәрләренә юлны яба ала иде. Ә хәзер шундый гаҗәп заман килде: тере драматургларны да тизрәк күмеп куярга ашыгалар. Мин ни өчен «Һинд кызы»н сокланып искә төшердем соң, чөнки ул Т.Миңнуллин

«Дивана»сында кузгаткан теманы моннан 23 ел элек үк, искиткеч табигый рәвештә күтәрә алды. Кәбирә (Дания) белән Габдрахманның (Равил Шәрәфи) авыл халкы килеп капкан тозактан, үзен һәрьяклап урап алган ямьсез тормыштан саташа башлаган кызлары чит ил кинолары тасвирлаган гүзәллеккә гашыйк булып, дивана рәвешендә йөри башлый. Ата-ана – авыл җитәкчеләре дә булгач – кызы савыксын өчен, авылда һинд киноларында гына була торган матур тормышны булдыра. Ренат Әюпның бу эше Вахтангов режиссурасы ирешкәннәргә таянганга, аеруча шуны артистлар уены аша да тормышка ашыра алганга, спектакль үз йөзе булган гаҗәеп бер камиллеккә иреште. Бу уңышның ныклы нигезе артистларның, шул исәптән Данияләнең дә режиссёр сайлаган яңа форманы һич икеләнүсез кабул итеп тормышка ашыруларында да иде. Элек-электән биюләр аша катлаулы гәүдә ритмикасына күнеккән артисткага режиссёр теләгән яңа уйнау алымнарына күчү, шуңа эчке ритмиканы табу да беренчеләрдән булып килде, эзләнүләре, тырышлыгы башкаларга да шушы юнәлештә үсәргә үрнәк булды дияр идем.

Дания Нуруллинаны универсаль артистка дип тә әйтеп буладыр. Чөнки ул сәхнәдә бик еш очрашып тормаган артистлар белән дә уртак ансамбльне тудыра ала. Бу уңайдан иң беренче итеп Наил Дунаевны искә алыр идем. «Ай тотылган төндә»ге Шәфәкъ һәм Акъегет арасындагы тирән фаҗигадән соң Марсель Сәлимҗанов куйган «Агыйдел»дә (М.Әмир) Гаяз һәм Артыкбикә образларын тудырдылар. Аларның бу уңышлы эшләре спектакльгә онытылмаслык үзгә аһәң өстәде. Марсель абый аларны Островский һәм Соловьёв бергә иҗат иткән «Җимерелгән бәхет» драмасында кабат очраштырды. Төп рольләрдә булмасалар да, аларның оста уенын тамашачыларның алкышлап караулары истә.

Наил Әюпов белән, театрда әле эшли генә башлаганда, берсе – Салават (бу рольдә Дамир Хәйруллин да уйнарга өлгерде), икенчесе Айса булып күренгәч, Сәлимҗанов аларны «Миңлекамал»ындагы Кылый Хәлим белән дәртле Мәймүнә рольләрендә сынады. Бозыклыкта гаҗәп тиң булган парларны тудырды алар. Артистларының иҗади мөмкинлекләреннән канатланган режиссёр аларны «Портфельле кияү»гә алды. Назга котырган Мәстүрә һәм җай чыкканда типтереп калырга маһир швейцар Хизбулла Төхфәтуллин рольләрен башкаручылар (Дания белән Наил) заманында агитпьеса рәвешендәрәк язылган «Портфельле кияү»не дә чын тормыш белән тутырдылар. Чөнки режиссёр һәм артистлар фарс чараларын калку итү белән бергә рус сәхнәсенең Вахтангов, Лобанов кебек бөек режиссёрларының табышларыннан да иҗади файдаланганнар иде. Әлбәттә, әсәргә һәм Наил белән Данияләнең уенына тирәнлек бирүдә Мәстүрәнең ире Миргаяны уйнаучы Әзһәр Шакиров та, Тактабашев-Биктимеров та, Камаретдин – Шәрәфиев тә зур өлеш кертте. Бик үзенчәлекле артист Әсхәт Хисмәт «Казан сөлгесе»ндә Илдар Хәйруллин белән Ильяс шәкертне чиратлап уйнады. Әлеге Ильяска гашыйк Саҗидә ролендәге Даниягә аларның икесе белән дә уйнарга туры килде. Дания һәр ике партнёры белән дә тәңгәллеккә иреште. Әсхәт белән аларны әлеге «Миңлекамал» очраштырды. «Әни килде»дә Максуд белән Саимә булып та шатландыра алдылар. Данияләнең Саимәсенә Мәскәүдән килгән театр белгече А.Иняхинның бәясен дә искә төшерик: «…сверкающая озорством, обоянием и жизнелюбием характерность, высший пилотаж в которой демонстрирует Д.Нуруллина в роли Саимы, бабёнки суматошной, простодушной и порядочной, хоть всегда готовой к обороне. За исполнение этой роли артистка удостоена наград фестиваля им. К.Тинчурина» («Театральная жизнь» журналы, 1999 ел, 12 сан). Бу бәя Мәскәүнең иң дәрәҗәле театр белгече тарафыннан әйтелүе белән икеләтә кадерле. Без биредә телгә алган спектакльләр – асылда Марсель Сәлимҗанов спектакльләре. Чыннан да, уйнаган рольләренең күпчелеге М.Сәлимҗанов режиссурасында дөнья күрде. Театрны 35 ел җитәкләү дәверендә бу режиссёр беркайчан да ялкау, сәләтсез артистлар белән эшләмәде. Халтура күрсә, рольдән куып чыгарырга да күп сорап тормый иде. Дания Нуруллинаны ул үзенең утыздан артык спектакленә алган.

Бер режиссёрга күнеккән артист белән икенче режиссёрлар эшләргә бик яратмый. Дания исә күпкырлы. Аның белән П.Исәнбәт тә яратып эшләде. Әмма читтән чакырылган режиссёрлар Данияне күбрәк М.Сәлимҗанов белән П.Исәнбәт тапкан

кысалардарак файдаландылар. Дания белән Ф.Бикчәнтәевнең эшләргә алынуы артисткага гына түгел, Данияне күптән белеп бетердек дип уйлаучы тамашачыларга да кызыклы бүләккә әверелде. «Мин төш күрдем» пьесасын Зөлфәт Хәкимнең уңышлы әсәре дип әйтеп булмый. Бик күп тамашачылар, спектакльдән чыгып барышлый, күбрәк чемоданны уйнаттылар, аны ни өчен төрле төсләргә буяганнарын барыбер аңламадык, дип китәләр иде. Әмма бу спектакль яшь режиссёрның эксперименты буларак кызыклы иде. Бергә эзләнүләре аларны соңрак Т.Миңнуллинның «Дивана»сына китерде. Аеруча Даниядә моңа кадәр бик ишетелмәгән кылларның яңгырап алуы кадерле мизгелләр булып истә саклана. Кайчак бертуктаусыз бер-беренә охшаган рольләр бирелү аркасында күбрәк үз казанында кайнарга мәҗбүр булган артист ирексез кабатлана башлый. Әмма баштан ук күп режиссёрлар белән эшләргә гадәтләнгән Дания элекке табышларына гына ябышып ятмаска омтылуы белән Фәрит кул астында да кирәкле нәтиҗәгә иреште. Бөтенләй башка алымнар, башка буяулар эзләде, башка стильдә яшәп алды. Өстәвенә Дания чын татар хатын-кызларыдай тыйнак, оялчан. Тыйнак булган зур талантларга мактаулы исемнәр шактый соңлап килә, әмма борыннарын салындырмаганнарын һәрчак яңа ачышлар, яңа эшләр көтә.

Ркаил Зәйдулланың «Үлеп яратты» әсәре буенча Илгиз Зәйни куйган спектакльдәге Мөхлисә Бубый роле Дания Нурлының әнә шундый яңа уңышы булды. 2011 елда куелган бу спектакль менә инде берничә ел буе татар халкының иманлы балаларын театрга тартып китерә.

Бу урында безгә кабат Дания Нурлының Радик Бариев сәхнәләштергән «Сөясеңме, сөймисеңме?» спектаклендәге Карчык образын искә төшерергә туры килә. Татарстанның барлык театрлары катнаша торган «Тантана» бәйгесенең театраль премияләре җиңүчеләргә Халыкара театр көнендә тапшырыла. Һәм менә шушы гүзәл бәйрәм барган 2015 елның 27 мартында Дания Нурлы әле атаган соклангыч эше өчен «Иң яхшы хатын-кызлар роле» номинациясендә зур җиңү яулады. Г.Камал театрына җыелган күпсанлы театр сөючеләр, татарларыбыздан гына түгел, рус театрларыннан да килгән йөзләрчә артистлар Дания Нурлы исеме яңгырауга бердәм күтәрелеп, мактау сүзләрен әйтә-әйтә, алкышларга тотындылар. Бу алкышлар шул чаклы озакка сузылды ки, күздән шатлык яшьләре тәгәрәшә башлады. Әгәр бу көнне безнең арада Ширияздан Сарымсаков, Празат Исәнбәт, аеруча Марсель Сәлимҗанов булса, алар үз тырышлыкларының юкка китмәвен, үзләре үстергән татар театры традицияләренең җимеш бирүен күреп, юкка яшәмәгән икәнбез, дип шатланырлар иде кебек. Талант дигән асылташ халкына шатлык китерсен өчен, режиссёрларыбызның гына бөек булуы җитми шул.

Дания Нурлының радиода алып барган тапшырулары да, телевизион спектакльләрдәге эшләре дә халык арасында һәрчак кызыксыну уята. Аның тамашачылары кайсы өлкәне алсаң да җитәрлек. Тагын бер кадерле ягы: менә унбиш ел буена ул йөзләгән бәйрәмебезне Сөембикә ханбикә булып бизәп килде. Бер генә милли бәйрәм дә аңардан башка үтмәде. Милли бәйрәмнәребездә ел да Сөембикә киемнәрендә балкыган Данияне күреп, тамашачылар аның аша Сөембикәнең татар сәхнәсенә күтәрелүен дә теләделәр, әмма ул артисткадан гына тора торган нәрсә түгел шул – насыйп булмады. Яңарулар безнең халыкка кайбер өлкәләрдә соңлап та килә, бәхәсләр эчендә адашып та калгалый. Камал сәхнәсе өчен «Сөембикә» әсәренең язылмый калуына да әнә шундый таркаулык гаепле. 2006 елда «Сөембикә ханбикә» дигән китап нәшер ителде. Һәм мин аның соңгы битләрендә рәссам Рифкат Вахитовның «Сөембикә образында Дания Нурлы» дип исемләнгән портретына юлыктым. Милли фаҗигане тирән тойган күзләрендә дөрләп янган хәсрәт уты, милли терелү хакына үлемгә дә барырлык рухи көчкә ия булуы тетрәндерерлек итеп сурәтләнгән иде анда. Шунда мин тагын бер кат, замандашлары Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисткасы Дания Нуруллинаны юкка гына азатлык символын чагылдыручы Сөембикә итеп кабул итмиләр икән дип уйлап куйдым.

**Юныс САФИУЛЛИН,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

# ТЕАТР – ТЫЛСЫМЛЫ УЧАК



*Россиянең халык артисты, Россия Дәүләт премиясе, Башкортстанның С.Юлаев исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Оренбург рус драма театрының баш режиссёры* ***Рифкать Вәкил улы Исрафилов*** *белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире* ***Илфак Ибраһимов*** *әңгәмәсе.*

***– Театр сәнгате уенга корылган. Шулай булса да, ул безнең тормышыбызның чагылышы... Һәрхәлдә, параллель дөньяны күрсәтми ул... Әмма театр дөньясы дигән дөнья да бар бит әле... Бүгенге глобаль дөньяда театр сәнгате, театр дөньясының йөзе – портреты нинди... Нинди үзгәрешләр кичерә ул... Моннан йөз ел элек Тукаебыз әйткәнчә, яктылыкка, нурга илтәме ул кешелекне?..***

– Театр – кешеләрне тормыш турында уйлану, үз-үзләренә эчтән карау өчен үз тирәсенә җыя торган тылсымлы учакка тиң ул. Театр турында шулкадәр күп язылган ки, безгә аны өр-яңадан ачу, мөгаен, мөмкин булмастай эштер. Хәтта борынгы греклар да, шәһәр төзергә керешер алдыннан, башта театрның кайда булачагын уйлаганнар. Юкка гына түгелдер. Кайсы гына шәһәргә килсәң дә, анда театр булмаса, шәһәрнең үз йөзе юктыр кебек тоела. Телисезме-теләмисезме, рухи дәрәҗә барыбер театр, сәнгать һәм мәдәниятнең торышы белән билгеләнә.

Күп еллар дәвамында Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының сәнгать лидеры һәм җитәкчесе Марсель Сәлимҗанов булды. Бөек режиссёр, ул үз заманының сәнгать зәвыгы кануннарын да булдыручы иде. Һәм Татар театрының даны бөтен Россиягә яңгырады. Әлбәттә, театрлар күптөрле: кемдер рус психология театрын яклый, кемдер рус психологиясе мәктәбе кысаларында яңа формалар табарга омтыла. Кемдер, искелеккә санап, Станиславский системасын кире кага. Театр тирәсендә нинди генә бәхәсләр кабынса да, җанлы театр үзгәрешсез кала! Әгәр сәхнәдә ниндидер җанлы тормыш бара һәм ул кешенең күңеленә кагыла икән, димәк, мондый сәнгатьнең яшәргә хакы бар. Ә бит безнең театр эшенең нигезендә өч кит ята. Беренчесе – фәлсәфә. Сәхнә әсәре нинди фикер алып килә. Ә без беләбез: фикер хисләрне тудыра, һәм шуннан икенчесе – образлы сәнгатьлелек, ул спектакльнең эмоциональ энергетикасын барлыкка китерә. Шунда инде өченчесе – тамашачының катнашы (мөнәсәбәте) беленә. Ягъни тамашачы спектакльнең тууында катнашучы булып чыга. Әгәр шушы компонентларның барысы да булса, югары сәнгать – җанлы театр туа!

***– Бүгенге театр дөньясы дигәндә, әлбәттә, милли театрыбызның хәл-әхвәле турында фикерләрегезне беләсебез килә... Гәрчә сез инде ике дистә елга якын Оренбургта, рус театрында – баш режиссёр. Шуңа да карамастан, Сезнең***

***милли театр сәнгатеннән читләшкәнегез юк. Бүгенге заман театрының герое, каһарманы кем? Тамашачы нинди образларны күрергә сусаган бүген?***

– Мин рус һәм милли театр проблемаларын әллә ни аерып карамас идем. Аларның мәктәбе бер. Марсель Сәлимҗанов, Азәрбайҗан Мамбетов (М.Ауэзов ис. Казакъ академия театрына җитәкчелек итте) кебек талантлы режиссёрлар һәм башка бик күпләр театраль белемне А.Луначарский исемендәге ГИТИСның күренекле рус театраль педагогларыннан алдылар. Үзләренең милли театрларында Мәскәү театраль уку йортлары программалары буенча актёрлык кадрларын әзерләү методларын керттеләр. Ягъни укыту һәм әзерләү методикасы бер үк иде. Артист осталыгының база мәктәбе бер үк. Бездә актёр уенының тереклек рәвеше һәм табигате психологик кичерешләр театры мәктәбенә нигезләнә.

Әлбәттә, күпмедер дәрәҗәдә аерымлыклар бар. Милли театр актёры үз героеның эчке кичерешләрен чагылдыруда эмоциональрәк, ачыграк, әмма җанлы уенга нигезләнгән театрның тегесендә дә, монысында да фикер тирәнлеге бердәй. Атаклы режиссёр Питер Брук әйтүенчә, җанлы булмаган театрда актёрлар вакыйганы яшәмиләр, ә сөйләп күрсәтәләр, ягъни сәхнәдә барысы да текст дәрәҗәсендә бара. Ә без сәхнәдә кеше җаннары өчен көрәшүче, оятсызлык, тупаслык белән көрәшүче кыю, намуслы геройларны күрергә телибез. Сәхнәдә герой төзүче булырга тиеш, ә җимерүче түгел. Тискәре персонажмы ул, уңаймы – барыбер.

***– Алдагы соравым очраклы түгел иде... Соңгы гастрольләрегездә Василий Шукшин әсәрләреннән төзелгән тамаша-спектакль тәкъдим иттегез. Шукшин – чын-чынлап халык әдибе. Халыкның рухын, эчке потенциалын халыкның үз фольклоры, йолалары, традицияләре белән күрсәттегез. Ике ел элек Петербург рус драма театры, Фёдоров романын сәхнәләштереп, биш сәгатьлек спектакль күрсәтеп әсир иткән иде. Әлбәттә, алар кассовый спектакльләр түгел...***

– Безнең театр репертуарында В.Шукшин, А.Вампилов, В.Гуркин һәрвакыт аерым урын алып тора. Игътибарыбыз халык драмасына юнәлтелгән. Алар рус халкының өметләрен һәм әрнүләрен, авылның кискен проблемаларын, крестьянлык нигезләренең ничек акрынлап җимерелә баруын эчтән торып белгән. Бу проблемалар бар кешене дә, татар тамашачысын да борчый.

Моннан күп еллар элек без Башкорт академия театры белән Хәйбулла районында гастрольләрдә булдык. Зур авыл, кечкенә генә клуб. Бөтен авыл спектакль карарга килде, тәрәзәләр ачылды, барысын да сыйдыру өчен могҗизалы баскычлар куелды – спектакльне эленгән хәлдә диярлек карадылар. Ә аннары, тамашачылар соравы буенча, артистлар кояш чыкканчы концерт куйдылар, колхозчылар шуннан турыдан-туры җырлый-җырлый эшкә таралды. Бүген менә мондый рухны без югалттык!

Хәтеремдә, минем туган авыл – Башкортстанның Мәчетле районындагы Яңа Мөслим авылында кешеләр иртән эшкә җырлап китәләр, ә кояш баеганда җырлап кайталар иде. Ачлар – ашар әйбер юк. Әмма рухи күтәренкелек һәрвакыт бар иде. Мин әнә шуларның барысының юкка чыгуы, алмашка җимереклек килү турында спектакль куйдым. Бу – Василий Шукшин темасы. Минем әрнүләрем дә ул! Бүгенге чынбарлыкка ни дәрәҗәдә аваздаш булды, тамашачыны, үз йөзен күрсәтә алдымы ул? Минемчә В.Шукшин безгә әле бик озак еллар кирәк булыр...

***– Театр сәнгате – борынгыдан сүзгә, әдәбиятка корылган сәнгать. Эсхил, Софокл, Аристофаннардан алып, Шекспир театры, Мольер театры, Гольдони театры, Лопе де Вега, Ибсен, Островский, Чехов, Галиәсгар Камал, Тинчурин, Мостай Кәрим, Туфан Миңнуллин театры – бар да драматурглар... Бүгенге***



*Ю.Поляков.«Гөмбәләр патшасы».*

***театрда әдәби сегмент нинди урында? Аның урынын кечерәйтеп күрсәтүгә Сезнең карашыгыз нинди?***

– Театр сәнгате хәрәкәткә нигезләнгән. Бу хәрәкәттә нинди фикерләр үстерелә – төп момент шул үзе инде. Кайчакта А.П.Чехов сүзләр урынына «пауза» дип яза. Бу паузада сүзләр юк, әмма актёр фикерне сүзсез дә җиткерә алырга тиеш. Һичшиксез, хәрәкәттә сүзләр мөһим, әмма анысы – соңгы инстанция. Әгәр текст фикерсез генә уйналса, бу начар театр, Питер Брук әйтмешли, «үле театр». Безнең театр репертуарында «Письма памяти» («Хәтер хатлары») дигән искиткеч спектакль бар. Анда бер генә сүз дә ишетелми, әмма гаҗәп дәрәҗәдә фикер һәм хәрәкәт үстерелә – тамашачылар елый! Тик бу факт һич тә драматургның икенче урында калуы турында сөйләми. Юк һәм тагын бер кат юк! Драматург, әлбәттә, драматургик материалга салынган үз фәлсәфәсе, фикерләре белән – беренче урында. Без, режиссёрлар, авторның юл арасына яшерелгән тирән фәлсәфәсен ачарга тиеш. Инде бу хакта В.Шукшин мисалында фикерләремне җиткердем.

Без ГИТИСны тәмамлаганда, күпләребез теләсә кайсы китаптан, хәтта телефон белешмәлегеннән дә спектакль куеп була дип уйлый иде. Бу тәҗрибәсез чыгарылыш студентларының, әле бер тапкыр да авызлары пешмәгән «бала-чага»ның, тирән ялгышуы иде. Мин күптән болай уйламыйм инде! Әлбәттә, минем өчен беренче урында үз фәлсәфәсе булган автор тора. Миңа күренекле драматурглар – рус һәм чит ил классиклары, милли авторларның пьесалары белән эшләү бәхете тиде. Туфан Миңнуллин, аның иҗаты белән очрашу иҗат тормышымның бәхетле чоры булды. Туфан Миңнуллин пьесаларын кую минем өчен сөенеч иде! Аның пьесалары Россиянең күп театрларында зур уңыш белән барды. Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия театры артистларының ничек илһамланып эшләүләрен искә алам, репетицияләр тоташ бәйрәм иде. Театр тарихында Туфан Миңнуллин иҗаты үзе бер чор тәшкил итте. Димәк, Туфан Миңнуллин ТЕАТРЫ бар иде һәм бар!

***– Соравымны икенче яктан болайрак итеп бирим әле... Станиславский театры, Таиров, Мейерхольд, Товстоногов, Эфрос, Струве театрлары, Марсель Сәлимҗанов, Рифкать Исрафилов театрлары булды һәм бүген дә бар... Болар инде даһи режиссёрлар. Театр режиссурасында үз мәктәбен булдырган мастерлар. Санап үткәннәрнең һәркайсы әдәбиятның ролен иң беренче урынга куйдылар. Әллә заман, модернизм дигәннәре башка юнәлешкә өстенлек бирүне кулайрак күрәме?***

– Әлбәттә, һәрбер сәнгать дөньясы үз театрын төзиячәк. Һәркемнең үз театраль почеркы. Әмма база мәктәбе – психологик театр мәктәбе нигез (фундамент) булып кала. Югарыда телгә алынган театр эшлеклеләре үз иҗатларында нәкъ менә рус психология мәктәбе ярдәме белән канат ярдылар. Аларның һәркайсы форманы үзенчә һәм төрле юллар белән эзләде һәм эзли, әмма сәхнәдәге тормыш үзгәрешсез кала. Әдәбият исә һәрвакыт беренчел чыганак булды һәм шулай булып кала да.

Театр тарихында экспериментлар күп булды. Хәзер дә интенсив рәвештә яңа формалар, яңа «сәхнә теле» эзләү дәвам итә – кайчакта уңышлар, кайчакта оттырулар белән. Бу – театр үсеше тарихының табигый барышы. Тик беркайчан да чын авангардны «колхоз авангарды» (Анна Кузнецованың «Литературная газета»да әйткән гыйбарәсе) белән бутарга ярамый. Ә менә бу мәсьәләдә, ни кызганыч, «Алтын битлек» милли премиясе кайчакта ялгышкалый.

***– Без – Сәлимҗанов театры традицияләрендә үскән буын... Исрафилов режиссурасында төп үзенчәлек, минем күзәтүемчә, ул спектакльләрнең поэтик чишелеше булуда... Сез 70нче елларда Казанга алып килгән «Галиябану» (М.Фәйзи), «Тапшырылмаган хатлар» (Г.Кутуй) спектакльләре белән тамашачыны әсир иттегез... «Галиябану»да каеннарның шашып шаулавы, биюләре... Гомумән, шигъриятле, хисле тамашалар... Гафури театрында эшләгән елларыгызда бөтен татар классикларын сәхнәләштердегез... Тамашачы аңына җаны аша үтеп керүдә шигъриятне ачкыч итеп куллануга ничек ирешәсез?***

– Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт академия театрындагы эшчәнлегемне югары бәяләвегез өчен зур рәхмәт. Казандагы беренче гастрольләребезне һәрвакыт җылы итеп искә алам. Режиссёрлык эшчәнлегемне югары бәяләгән Казан тамашачылары онытылмас хисләр калдырды. Ул чакта бик шәп татар язучысы Рабит Батулла Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» спектакле турында «Бөек сәнгать белән очрашу» дигән искиткеч мәкалә язып чыкты. «Тапшырылмаган хатлар» спектакленә Минтимер Шәймиев килде. Шунда мин беренче тапкыр бу гаҗәеп кеше – акыл иясе һәм философ белән таныштым. Минем иҗади тормышымда ул биниһая зур роль уйнады. Булдыра алганча, ул минем яңа эшләремне карап барды, һәрвакыт аларга үз бәясен бирде һәм хуплады. Һәрвакыт аның аталарча кайгыртуын тойдым. Башкортстанда вазгыять кискенләшкәч, без аның белән берничә тапкыр очраштык һәм ул тагын ярдәм кулын сузды... Аңа чиксез рәхмәтлемен. Хәзер мин Казанга гастрольләр белән башка – Оренбург театры белән киләм, тик барыбер үземнең эчке тоемлавым аша әле дә рухташым – Минтимер Шәймиев каршында хисап бирүемне дәвам итәм. Аллаһ аңа озын гомер насыйп итсен!

Гастрольләр вакытында кызыклы шәхесләр – Туфан Миңнуллин, Равил Фәйзуллин, Илдар Юзеев... белән таныштым. Ул чакта халык язучылары һәм шагыйрьләре түгел иде әле алар. Алар белән аралашу үзе бер рәхәтлек бирә иде. Андый шәхесләр белән аралашу сине һәрчак баета, халыкта юкка гына: «Дустың кем икәнен әйтсәң, синең кем икәнеңне әйтермен», – димиләр бит. Мин алар белән озак дуслашып йөрдем, безнең очрашулар һәрвакыт кызыклы булды. Ни кызганыч, Туфан белән Илдар инде бакый дөньяга күчтеләр. Ә менә Равил белән күптән түгел гастрольләрдә очраштык. Аның дачасында, каен суы эчеп, иртәнгә кадәр сөйләшеп утырдык...

Шигърият, шигъри чишелеш мәсьәләсенә килгәндә, бу инде безнең һәркайсыбызның шәхесенә, иҗат итү стиленә дә бәйле... Безнең милли йөзебезне, уртаклыгыбызны билгеләүче илаһи бер халәт, төшенчә бар бит әле... Ул – Моңыбыз... Аның төгәл аңлатмасы юк, дибез... Әмма Моң шигъриятсез була алмый... Ул аның төп элементы... Болай әйтү ваклау була: Шигъриятсез – Моң, Моңсыз Шигърият була алмый...

Спектакльләр чишелешендә аны, ягъни шигъриятне кертәм-кертмим дип уйламыйсың... Ул үзеннән-үзе, пьесаның әдәби тукымасыннан килеп чыга... Үзегез дә әйттегез, В.Шукшин белән дә шулай килеп чыкты. Мин спектакльгә рус фольклорын керттем. Ул үзе үк шигърият... Моң дәрәҗәсендәме? Анысы инде тамашачының күңелендә туа. Тамашачы сәхнәдәге уеннан әнә шул сихри, мәңгелек көчкә ия шигъриятне көтә. Бу – театр өчен генә түгел, эстрада өчен дә хас күренеш... Моңлы тамашага без тамашачы белән ирешәбез, чөнки тамашачы, халкыбыз моңлы, шигъриятле...

***– Милли театрларыбызда халкыбыз тормышына, милли каһарманнарыбызга багышланган әсәрләр куелмавы, куелса да, репертуардан төшеп калуы уйландыра. Бу хакта журналыбызда махсус фикер алышулар да уздырып, укучыларга тәкъдим иттек. Меңьеллык дәүләтчелеге булган халыкның милли каһарманнары азмы әллә? Сез, мәсәлән, Оренбург рус театрында Г.Державинның «Сююмбика – царица» драмасын, Казанда яки Уфада Гаяз Исхакыйның «Олуг Мөхәммәд» трагедиясен куяр идегезме? Әллә Шекспир трагедияләре барыбыз өчен дә чын-чынлап универсалмы?..***

– Театрның репертуар сәясәте – шактый катлаулы процесс. Репертуарны төзегәндә, бик күп әйберне истә тотарга кирәк. Әлбәттә, беренче урында – теге яисә бу сәхнә әсәренең сәнгати дәрәҗәсе. Пьеса вакыт сорауларына һәм таләпләренә җавап бирәме? Бервакыт мине башкорт классикасын куймауда гаепләделәр. Бу классикадан заманга туры килгәннәрен куйдым, ә калганнары – гадәти уртакул пьесалар иде, аларны ничек куясың? Әгәр теләсә кайсы тарихи драма А.Пушкинның «Борис Годунов»ы дәрәҗәсендә язылса – ышаныгыз, күп театрлар аларны үз репертуарына кертәчәк. Әгәр нибары даталар гына билгеләнгән булса – нәрсә куярга? Советлар чорында язылган тарихи темалар, шул исәптән тарихи шәхесләргә кагылышлы әсәрләрдә дәүләтнең ул чактагы идеология таләпләре ярылып ята иде. Ул чакта ук күп ак таплары булган вакыйгаларны сәхнәгә алып менү ихлас иҗатчы алдында бик күп әхлакый сораулар да куя... Совет заманы гына түгел, Сез атап үткән йөз илле, ике йөз ел элек язылган әсәрләрдә дә шул чорның идеологиясе ярылып ята. Бүген аны шул хәлендә сәхнәгә менгерүнең зыяны сәхнәләштермәүгә караганда күбрәк...

Бу фикерем һич кенә дә мондый спектакльләр булмаска тиеш дигәннән түгел... Алар кирәк һәм репертуарда һәрчак булырга да тиеш. Тарихилык шәхесләрсез булмыйдыр. Әмма безнең фольклорыбыз, мифларыбыз, әкиятләребез дә сәхнәгә менәргә чират көтеп ята. Бүгенге көн әдипләре, бәлки, иң әүвәл балалар театрлары өчен язарлар тарихыбызга кагылышлы пьесаларны... Әлбәттә, «Галиябану» (М.Фәйзи), «Ат карагы», (Т.Миңнуллин) да тарихи әсәрләр... Әмма шәхесләр турында язу кирәк. Шәхес дигәннән, Сез бер Шекспир җитәме, дидегез... Бездә, чыннан да, аның «Ричард III»е зур уңыш белән бара. Тарих нәрсә ул? Ул – бүгенге, кичәге көнебез! Бүгенге көндә тарихи әһәмияткә ия әсәрләр яза алсак, тарихи әһәмияткә ия спектакльләр куя алсак, зур эш башкарган булырбыз.

***– Рәсәй – түнтәрелешләр, үзгәртү-реформалар иле... Хәзер кабат сыйнфый бүленеш, социаль тигезсезлек, гаделсезлек күренешләре калкып чыга. Алар сәхнәгә юл сорамыймы? Илне, җәмгыятьне алдан кисәтү өчен, бүген «Борис Годунов»ны кую кирәктер, бәлки, барлык драмтеатрларда?.. Оренбург – гади, гадәти шәһәр түгел...***

– Яхшы театр һәрвакыт заман белән бергә атлый. Үз спектакльләрендә үз заманының проблемаларын күтәреп, театр барометр булып тора. Шуңа да театрлар һәрвакыт бүгенге көн әрнүләрен чагылдырган спектакльләргә кабат әйләнеп кайта. Шул исәптән, А.Пушкинның «Борис Годунов»ына да.

Әгәр исегездә булса, моннан күп еллар элек, әле совет заманында ук, Е.Вахтангов театры Азат Абдуллинның «Унөченче председатель»ен куйды. Бу спектакльне күп тапкыр тыйганнар иде һәм, ниһаять, аны караганнан соң, Косыгин үзенең фатихасын бирде. Ә бит спектакльдә Советлар Союзының булу-булмау мәсьәләсе күтәрелгән иде. Театрлар ул чакта ук чаң какты! Ишеттеләрме? Юкмы? Ә нәрсә килеп чыкты?

***– Казандагы гастрольләрегез бик уңышлы булды. Ишетеп белүебезчә, Сез тулы сәнгать тормышы белән яшисез. Спектакльләр кую белән бергә, үзегезнең те-***

***атр мәктәбендә шәкертләр әзерлисез, Уфа, Казанда милли театрларыбызда спектакльләр куясыз. Т.Миңнуллинның «Әзләдем, бәгърем, сине» әсәре буенча куелган спектакль минем өчен газиздән-газизрәк. Кызганыч, репертуардан төшеп калды. Алдагы көннәрдә безнең театрларыбызда спектакльләр куярга тәкъдимнәр бармы?***



*Премьерадан соң.*

– Оренбург драма театры эшчәнлеген яхшы бәяләвегез өчен рәхмәт. Шөкер, бүген безнең театр спектакльләренә ихтыяҗ бар. Алла бирсә, 2016 елның 18 сентябрендә, Калуга шәһәрендә, фестиваль оештыручылар чакыруы буенча, В.Шукшин хикәяләренә нигезләнгән «Милые люди» («Сөйкемле кешеләр») спектаклен күрсәтәчәкбез. Бу бик кызыклы, Россиянең борынгы театрлары фестивале. Ә 24 ноябрьдә шушы ук спектакльне Мәскәүдә, «Золотой витязь» фестивалендә куярга җыенабыз.

Мин, Оренбургка килү белән, иң элек өлкә җитәкчелеге алдына сәнгать институтында актёрлык факультеты ачу мәсьәләсен куйдым. Һәм үзебездә, Оренбургта, актёрлар әзерли башладым. Хәзер театр труппасының сиксән процентын үзебезнең институтны тәмамлаучылар тәшкил итә.

Инде күп еллар Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрына талантлы режиссёр Фәрит Бикчәнтәев җитәкчелек итә. Без аның белән күптәннән дуслар. Ул мине яңа куелышларга чакыра, ләкин үз театрымны берничә айга калдырып китү авыр. Урыныма калдырыр кеше юк. Артистлар эш белән тәэмин ителергә һәм бары иҗат белән генә шөгыльләнергә тиеш. Аларны, балалар кебек үк, озакка ташлап китәргә ярамый!

Әлбәттә, гаҗәеп драматург Туфан Миңнуллин иҗаты белән кабат очрашасы килә – ул әсәрләрендә яшәвен дәвам итә. Аллаһ насыйп итсә, бәлки, теләкләребез тормышка ашар!

***– Инде күренгәнчә, Сез киләчәккә өметле ышаныч белән карыйсыз. Димәк, безнең милли мәдәниятебез, сәнгатебез бар, яши... Безне рухи савыктыру, яшәүгә өметләндерү миссиясен алга таба да үти алачак. Ихлас әңгәмә өчен Сезгә зур рәхмәт!***

**Редакциядән:**

*Рифкать Вәкил улын 75 яшьлек юбилее белән ихластан котлыйбыз! Аңа исәнлек-саулык, озын гомер, иҗат уңышлары телибез.*

# СОҢГЫ ТУРАНЧЫ...

##ҺАДИ АТЛАСИНЫҢ ТУУЫНА 140 ЕЛ

Әйе, Һади Атласи – ахырга хәтле татар халкының азатлыгы өчен көрәшкән, гомере буе төрки халыкларны берләштереп, бер бәйсез дәүләт төзү хыялы белән яшәгән, шуңа омтылган, шушы уй-гамәлләре өчен гомере белән түләгән соңгы туранчы ул... Һади Атласи үзенең төркиче-милләтче (пантюркист) булуын беркайчан да яшермәгән, төрки-татарлар бары тик үз бәйсез дәүләтләре булганда гына исән калачаклар, дип матбугатка да язган, кулга алынгач, сорау алганда да шушыны кабатлаган, судта да соңгы сүзе итеп милләтнең азатлыгы турында сөйләгән. Ул үз халкына гына түгел, хәтта палачларына да һәр милләтнең ирекле булырга хакы барлыгын исбатларга тырышкан, басып алучылар кул астында яшәргә мәҗбүр булган татар халкының әкренләп бетүгә таба баруын аңлаткан. Кайбер тарихчылар Атласи бу сүзләрне, бәйсез төрки-татар дәүләте төзергә омтылуын төрмәләрдә кыйнауга түзә алмыйча әйткән, үзенә карата алдан әзерләнгән гаепләүләр белән ризалашкан, дип язалар. Әмма Һади Атласи сорау алганда да, мәхкәмә барышында да үзенең милләт азатлыгы өчен гомер буе көрәшүен яшермәгән, төрки халыклар бергә булганда гына исән калачакларын әйткән.

Һади Атласи соңгы утыз ел гомерендә дүрт тапкыр төрмәдә утырган, беренчесе – 1909 елда патша зинданында, икенчесе – 1920 елда большевиклар төрмәсендә, өченчесе – 1929-1933 елларда Сталин концлагеренда һәм дүртенчесе – 1936-1938 елларда Казан төрмәсендә, соңгысында аны «халык дошманы, чит ил шпионы» дип атып үтерәләр. **«Атласовчылар-Атласовщина»** дип дан алган, бөтен Татарстанны тетрәткән бу җинаять эше буенча 1936-1937 елларда Әлмәт-Бөгелмә-Шөгер төбәгеннән 107 татар кулга алына, алар арасында 54 интеллигент-зыялы, 35 мулла, 18 «кулак-сәүдәгәр» була. Күпчелеге укытучылардан торган бу төркемнең башлыгы итеп танылган тарихчы, җәмәгать эшлеклесе, язучы-публицист, мөгаллим Һади Атласи «билгеләнә». 1937 елның 23-28 октябрендә Казан шәһәрендә шушы төркемнән 24 кешегә суд була, Хәрби трибунал 9 татарны атып үтерергә, дип хөкем карары чыгара, калганнарын төрле елларга төрмәгә ябалар, аларның күпчелеге шунда үлеп кала...

1938 елның 15 февралендә хөкем карары тормышка ашырыла – «бәйсез төрки-татар дәүләте төзергә теләгән» 9 татар зыялысы атып үтерелә. Менә алар, динебез, телебез, бәйсез дәүләтебез өчен шәһит киткән каһарман татарлар: **Һади Атласи (тарихчы) – 1876-1938; Гани Алтынбаев (укытучы) – 1902-1938; Касыйм Исхаков (имам) – 1890-1938; Фазыл Туйкин (язучы) – 1887-1938; Кәбир Туйкин (укытучы) – 1878-1938; Сабир Уразманов (укытучы) – 1892-1938; Барый Фәттахов (имам) – 1875-1938; Зәкәрия Фәттахов (хезмәткәр) – 1910-1938; Рәшит Яруллин (имам) – 1880-1938**. Урыныгыз җәннәттә булсын, газиз кардәшләребез, без сезне онытмадык һәм догада калабыз...

Халык арасында «Милләтчеләр», «Укытучылар» дип аталып йөртелгән 2242нче номерлы бу җинаять эше буенча кулга алулар һәм мәхкәмәләр әле соңыннан да дәвам итә, татар зыялыларының чыннан да бәйсез төрки дәүләт төзергә әзерләнүләренә палачлар үзләре дә ышана башлый, халыкны да шуңа ышандыралар. Әйе, һәр заманда, хакимияттә кем генә утырса да, Россиядә нинди генә режим булса да, урыслар татарларның үз бәйсез дәүләтләрен торгызуын теләмиләр, аңа каршы эшлиләр, шул уй-теләк белән йөрүчеләрне төрле сәбәпләр белән юк итәләр... Атласилар төркемен дә,

чит илдәге мөһаҗир татарлар белән берләшеп, СССРга каршы эшләүдә, аны җимереп, бәйсез төрки-татар дәүләте төзергә теләүдә гаепллиләр.

***«На территории Тат.АССР на протяжении многих лет существовала широкоразвлётвленная, контрреволюционная, националистическая, повстанческая, разведывательная организация, созданная по указаниям представителей иностранного государства (иноразведки), занимавшаяся контрреволюционной работой по подготовке свержения советской власти, с целью образования на территории СССР т.н. независимого тюрко-татарского государства буржуазно-демократического строя. Организацию непосредственно создал и ею руководил главный обвиняемый по настоящему делу Атласов Гади, известный в СССР татарский буржуазно-националистический деятель, пантюркист, бывший правый эсер, бывший член 2-й Государственной думы, бывший белогвардеец, дважды судимый в прошлом за контрреволюционную деятельность»***, – дип языла гаепләү карарында. *(А.Л.Литвин. Запрет на жизнь. – Казань, 1993, стр.44.)*

Тарихта әле мондый хәлнең булганы булмый – «бәйсез төрки-татар дәүләте төзергә теләгәннәр» дип, берьюлы, бер көндә, бер сәгатьтә, үз туган илендә, үз туган җирендә 9 татарны атып үтерәләр, алар арасында өч мулла, өч укытучы, ике тарихчы, бер хезмәткәр була. Милләтнең иң асыл ир-егетләре, иманлы мөселманнар, акыл ияләре, нахакка гаепләнеп, фаҗигале рәвештә гомерләре өзелгән золым корбаннары... Бу хәлләр бит фашист Германиясендә түгел, ә СССР дигән илдә, үзебезнең совет Татарстанында барган!

Әлбәттә, мондый яшерен оешма булмаган, хөкем ителүчеләр беркайчан да шпионлык һәм җимерү-диверсия эшләре белән шөгыльләнмәгәннәр, алар моны судта да әйткәннәр. Әмма хөкем ителүче татарларның һәрберсе диярлек бәйсез татар дәүләте турында хыялланган, кайберләре, шул исәптән Һади Атласи үзе дә, 1917-1918 елда Милли Мәҗлес эшләрендә катнашкан, Идел-Урал штатын төзү юнәлешендә гамәлләр кылган. Сталин төрмәләрендә утырып чыкканнан соң, шомлы утызынчы елларда, бу илдә, бу чорда бәйсез татар дәүләте төзеп булмасын Атласи үзе дә аңлаган, ул дәүләт аның хыялында гына калган. Әмма, ахыргача тугры кеше буларак, ул сорау алганда да, суд барышында да дөресен әйткән, **«татар халкы бары тик үз бәйсез дәүләте булганда гына милләт буларак исән калачак»**, дигән.

Һади Атласиның 1937 елның 24 октябрендә Казанда, мәхкәмәдә сөйләгән соңгы сүзе дә бик әһәмиятле. Ел ярым Казан төрмәләрендә кыйналып, тән һәм җан саулыгын югалтса да, ул, үлемнең күзенә карап, *«Мин – тарихчы, революционер, милләтче һәм пантюркист... Мин бердәм һәм бәйсез төрки-татар дәүләте төзү максаты куйдым, ләкин моңа эволюция юлы белән барырга теләдем»*, дип әйтергә көч таба. Мин, шушы юлларның авторы, 2016 елның 29-30 гыйнварында Бөгелмә шәһәрендә Һади Атласиның оныгы Әлфия Атласоваларда махсус булып, аннан бабасы белән бәйле документларның күчермәсен эшләтеп алган идем. Бу документлар арасында Һади Атласидан 1936-1937 елларда төрмәдә сорау алу беркетмәләре дә, аның мәхкәмәдә соңгы сүзе дә, кайбер башка материаллар да бар, алар барысы да рус телендә. Әмма, аңлавымча, Атласи һәм аның тарафдарлары судта татарча сөйләгәннәр, алар өчен махсус тәрҗемәче китерелгән, ул Бауман райкомында сәркатип булып эшләүче Улунбәков фамилияле кеше булган. Бу хакта тарихчы Булат Солтанбәков менә нәрсә яза:

***«Председателя суда Микляева, членов Тулина и Кутушева не интересовало выяснения истины. Они обрывали обвиняемых, требовали от официального переводчика (им был назначен секретарь Бауманского райкома Улунбеков) краткости, детали их не интересовали».*** *(Б.Ф.Султанбеков. Хади Атласов предупреждает // Б.Ф.Султанбеков, С.Ю.Малышева. Трагические судьбы. – Казань, 1996, стр.100.)*

Шулардан чыгып, әлеге язмабызда Атласиның судтагы чыгышыннан өзекләрнең кайберләрен татарча бирергә булдык. Аның бу сүзләре үзенә үлем карары игълан ителүгә дүрт көн кала яңгыраган...

***«Мин инде карт, элеккеге җәмәгать эшлеклесе. Тарихчы һәм укытучы.***

***Революциягә кадәр үк төркичелек (пантюркизм) хәрәкәте белән таныша башладым. Чит илләрдән газеталар яздырып алдырдым. Шул газеталар аша төркичелек хәрәкәте белән таныштым. 1900 елларда Европа һәм рус әдәбияты белән таныша башладым. Сәясәт белән яхшы таныш идем. Ул вакытта Россиядә бер генә дә үзәкләшкән татарча газета юк иде, бары тик Кырымда гына бер татарча газета чыга иде. (...) Мин – мулла малае, ләкин ятим үстем. Бала чактан крестьян эшен башкардым. 1901 елдан үз әсәрләремне яза башладым, 1902 елда беренче китабым басылып чыкты. Аннан тарих белән кызыксына башладым. 1907 елда Дәүләт Думасы депутаты итеп сайландым. (...) Патша заманында (самодержавие) язган китабым өчен 1909 елда хөкемгә тартылдым. Брошюрамны яндырдылар. (...) Февраль түнтәрелешенә кадәр мин полиция күзәтүе астында булдым. Ул вакытта бик күп тарих белән шөгыльләндем. (...) Үземнең төркиче (пантюркист) булуымнан баш тартмыйм. Мин социалист идем, чөнки Энгельс әйткән, үз территориясе, үз мәдәнияте булмаган милләт социализм төзи алмый, дигән. Без башка милләтләр өстеннән хакимлек итә торган дәүләт төзергә тиешбез, дип мин беркайчан да әйтмәдем. Яшермим, бөекдержавачылык шовинизмына каршы көрәштем. Тарихчы буларак, таркалып, юкка чыгу мәсьәләләре белән шөгыльләндем. Мин татар милләте әкренләп үлә бара, дип исәплим, әйтик, Кырымда 16 гасырда 2 миллион кеше (татар) булса, хәзер анда 80 меңләп кеше калды. Юкка чыгу совет чорында да дәвам итте, 1921 елда 4 мең татар ачтан үлде. (...) Татар теле тулы мәгънәсендә дәүләт теле, университет теле булып тормый, ул гаилә, кухня теле булып кына санала. (...) Совет власте килгәч, мәктәпләрдә тарих укытылмады. Дин кирәк дип исәплим, динне кискен рәвештә бетерү милләтнең үлеменә алып бара. Шушылар нигезендә мин төркичегә әйләндем. Мин – дарвинчы, чөнки ул, яраклаша алмау – бетү билгесе, ди. Башка милләт тәэсире астында булган милләт яши алмый. Мин бәйсез төрки-татар дәүләте төзү буенча оешманы җитәкләргә булдым, әмма ул оешмада мин берьялгызым идем. Судта мине совет властена каршы күтәрелергә тели, дип әйттеләр, бу дөрес түгел. Кайберәүләр исә мине совет власте җимерелгәч, төрки-татар дәүләте оештырырга уйлый, диделәр, менә монысы дөрес. (...) Әмма мин баш күтәрүләргә каршы, ничек инде ни коралың, ни ярдәм булмаган килеш, коры кул белән, хакимияткә каршы күтәрелергә мөмкин? Шпионлык белән беркайчан шөгыльләнмәдем, ул яктан үземне чиста дип саныйм. Мин элеккеге кеше инде, бүгенге заман кешесе түгел – элеккеге укытучы, элеккеге эсер, депутат, элеккеге тарихчы... (...) Ә Төркия илчесенә мин республиканың хәле, аның экономик һәм географик торышы турында сөйләдем. Мин Төркия илчесенә үземнең соңгы максатым – бөтен төрки халыкларны бер зур төрки-татар бәйсез дәүләтенә берләштерү икәнлеген әйттем, алардан ярдәм сорадым. (...) Бәйсез төрки-татар дәүләтен советлар власте җимерелгәндә генә төзеп буласын аңладым, ә аның җимереләчәгенә мин ышандым...»*** *(Атласиларның шәхси архивыннан.)*

Хәрби трибунал беркетмәсеннән күренгәнчә, мәхкәмә рәисе Һади Атласины берничә тапкыр бүлдерә, аңа чит илләрдә яшәүче мөһаҗир татарлар – Гаяз Исхакый, Әгъдәс Нигъмәти, Галимҗан Идриси, Габдрахман Шәфиев (Шәфи Алмаз), Әхмәт Яруллин (Әхмәт Тимер), шулай ук Бубыйлар Диния нәзарәте турында өстәмә сораулар бирә. Атласиның җавапларын язмабызның алдагы бүлекләрендә бәян итәрбез, инша Аллаһ! Шулай ук Һади Атласиның яшьлегендә «дарвинизм» белән мавыгуын, әмма моның маймыл белән кеше арасындагы бәйләнешләр булмыйча, ә аны дөньяның һәм милләтләрнең үзгәреш-эволюциясе кызыксындыруын да аңлатырбыз. Тарихчы буларак, ни өчен Һади Атласи беренче булып Казан ханлыгы чорын түгел, ә Себер тарихын өйрәнә башлавына да җавап табарга тырышырбыз. Мулла малае, төпле дини белем алган, үзе дә мәктәп-мәдрәсәләрдә укыткан, бер чорда Әлмәттә мәчеттә имам булып торган Һади Атласи ни өчен төркичелек-туранчылык белән мавыга башлаган? Тарихчы буларак, ул чор өчен Атласи нинди ачышлар ясаган – инде бу сорауларга да җавап бирер вакыт җитте. Әмма безнең өчен иң кадерлесе – ул мөселман булганы хәлдә, милләтебезнең бәйсезлеге, азатлыгы өчен шәһит киткән кеше. Милли каһарман. Соңгы туранчы...

15 февральне татарлар төрлечә билгеләп үтәләр – кемнәр өчендер ул шагыйрь Муса Җәлилнең туган көне, җырчы Илһам Шакиров та шушы көндә туган, 15 февральдә Әфганстаннан совет гаскәрләре чыгарылуын да искә алучылар бар. Әмма милләтнең бер өлеше өчен 15 февраль – Хәтер көне, Һади Атласи һәм аның тарафдарлары атып үтерелгән көн, моны Бөгелмәдә шулай билгеләп үтәләр дә. Татарның дәүләт бәйсезлеге, милләт азатлыгы, дин ирегe өчен ахыргача көрәшеп, ахыргача мөселман-татар булып калган, безгә дә шушы изге нәрсәләрне васыять итеп дөньядан үткән шәһитләрне дога һәм ант белән искә алу көне. ХӘТЕР КӨНЕ.

## Атласиның беренче төрмәсе

Һади Атласи үз чоры өчен, бигрәк тә егерменче йөзнең башларында олуг фикер иясе, зур тарихчы, үткен публицист булып саналган, хәзер дә аның күп кенә хезмәтләре тарихчылар һәм милли зыялылар өчен үрнәк булып тора. Югыйсә, ул бит бары тик авыл мәдрәсәләрендә генә белем алган, чит илләрдә уку һәм эшләү аңа эләкмәгән, әмма, шуңа карамастан, динне дә, фәнне дә бик яхшы белгән һәм тормышында кулланган, татар, төрек, гарәп, фарсы, рус телләрен яхшы белгән, соңрак немец, француз, инглиз телләрен дә өйрәнгән. Һади Атласи – егерменче йөз башларында милләтнең мәңгелек рухи төпкелләреннән күтәрелеп чыккан акыл иясе, тере күзәнәге, язмышына үз халкы өчен корбан булу язылган бөек һәм фаҗигале шәхес... Ул гомер буе үз өстендә эшләгән, кая барса да, гыйлем һәм гыйбрәт алган, эзләнгән, милләтнең асыл тамырларын барлаган, белгәнен һәм мөгаллим, һәм язучы, һәм тарихчы буларак башкалар белән дә уртаклашкан татар зыялысы... Без дә аның тормышы, иҗаты һәм гомер юлы турында укучыларыбызга бераз мәгълүмат биреп үтик.

Мөхәммәтһади Мифтахетдин улы 1876 елның 29 августында элеккеге Сембер губернасы Буа өязе Түбән Чәке авылында мулла гаиләсендә туа, хәзер ул төбәк Татарстанның Чүпрәле районына керә. Башлангыч белемне Буа мәдрәсәсендә ала, аннан соң Оренбург төбәгендәге Татар Каргалысы авылында татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен өч еллык укытучылар курсын тәмамлый (1899-1902). Мәгърифәтле Оренбург Һади Атласига шәхес буларак формалашуга нык тәэсир итә, биредә ул алдынгы карашлы татар зыялылары, шул исәптән Гаяз Исхакый, Фатих Кәримиләр белән таныша, шәрык телләрен өйрәнә. Туган төбәге Буа мәдрәсәсенә кайтып бераз укыткач, 1902-1903 елдан Һади Атласины Әлмәт авылы мәчетенә имам итеп билгелиләр, ул биредә укыту эшләрен дә башлап җибәрә. Биредә ул үзенең гаилә бәхетен таба – Түбән Чыршылы авылы мулласы Габделфәттах хәзрәтнең кызы Хөсникамалга өйләнә, алар бергәләп авыл балаларын укыта башлыйлар.

Әлмәт чоры – Һади Атласи тормышында иң бәхетле, иң нәтиҗәле, иң мәртәбәле вакытлар, дип әйтер идем. Бу чор 1902 елдан 1917гә кадәр, ягъни Атласилар гаиләсе янәшәдәге Бөгелмә шәһәренә күчкәнче дәвам итә. Дөрес, бу вакытка Һади Атласиның, Дәүләт Думасына депутат итеп сайланып, 1907 елда өч ай ярым Петербургта яшәгән көннәре дә керә, шулай ук 1909 елда, язганнары өчен хөкем ителеп, өч ай төрмәдә утыруы да шушы чорга туры килә. Һәм, әлбәттә, даими рәвештә Казанга, Уфага, Оренбургка, Петербургка, Мәскәүгә, Түбән Новгородка, Себер-Уралга барып торулар, анда архив-китапханәләрдә эшләүләр, төрки-татарлар, рус галимнәре белән очрашулар... 1906 елда Атласиның Петербургта үткән «Иттифакъ әл-мөслимин» фиркасе съездларында актив катнашуын, хәтта бу партиянең Үзәк комитетына сайлануын да әйтеп үтәргә кирәк. Шушы чорда ул танылган дин әһеле, галим, милли сәясәтче ***Габдрәшит Ибраһимов*** белән якыннан таныша, Петербургта яшәгәндә, аларда еш була. Думадагы мөселман депутатларының җыелышлары да еш кына Габдрәшит Ибраһимов квартирасында үтә, анда Атласи да катнаша.

***«Члены фракции наметили время заседаний на каждую пятницу и сняли квартиру, – дип яза бу хакта тарихчылар. – …Заседания фракции нередко проходили и на квартире Габдрашида Ибрагимова».*** *(Диляра Усманова. Хади Атласи в Государственной Думе // Һади Атласи. – Казан, 2007, стр.285.)*

1907 елның июнь башында Дума куып таратылгач та, мөселман депутатлары, шул

исәптән Һади Атласи да, тагы Габдрәшит Ибраһимов квартирасына җыелалар, әмма аларның эзләренә бастырып полиция килеп җитә һәм моннан да куып тарата. Һади Атласиның Рәсәй җәза органнары белән беренче бәрелеше шушыннан башлана һәм ул гомер буе дәвам итә.

***«Роспуск второй Думы не стал для мусульманских депутатов неожиданностью, но произвёл на всех крайне удручающее впечатление, – дип яза тарихчылар. – Поздно вечером 3 июня около двадцати членов мусульманской фракции собрались в квартире Рашида Ибрагимова, чтобы обсудить преждевременный роспуск Думы и последствия для мусульман нового избирательного закона. Приблизительно через час в квартиру Ибрагимова прибыли полицейский пристав с городовыми и дворниками. На вопрос о причинах собрания бывшие депутаты заявили, что пришли побеседовать друг с другом и попрощаться с хозяином квартиры перед отъездом из столицы. Тем не менее, пристав велел всем собравшимся немедленно разойтись, что и было осуществлено бывшими депутатами. Уходя, пристав заявил хозяину квартиры, что он доложит градоначальнику об устройстве им в квартире незаконного собрания. 9 июня вышел последний, 85-й номер газеты «Ульфят», издаваемой Р.Ибрагимовым, а сам издатель вскоре был выслан из столицы».*** *(Диләрә Усманова, күрсәтелгән хезмәт, 299 бит.) (По словам столичных надзирающих органов, Г.-Р.Ибрагимов «в день роспуска Думы 2-го созыва учредил у себя собрание членов Государственной Думы, за что и был выслан из Петербурга». Цит.по: РГИА. Ф. 821. Оп. 133. Д. 449. Л. 161 об.)*

Шулай итеп, Петербургта «сәяси чирканыч» алганнан соң, Атласи тагы Әлмәткә кайта, өендә аны гаиләсе, берәм-берәм туган нәни сабыйлары көтеп тора... Әлмәттә Һади Атласи үзенең иң көчле әсәрләрен, тарихи хезмәтләрен яза, аларны Казан, Оренбург матбагаларында бастырып чыгара. Шушы чорда Атласи тарафыннан язылган һәм милләтнең алтын мирасы булып саналган хезмәтләр – «Себер тарихы» *(Казан, 1911)*, «Казан ханлыгы» *(Казан, 1914)* һәм «Сөен-бикә» *(Казан, 1914)* китаплары. Без әле алдагы бүлекләрдә бу хезмәтләргә аерым тукталырбыз, ә хәзер Һади Атласины төрмәгә яптырган хезмәте – 1906 елда Оренбургта басылып чыккан кечкенә генә китапчык-брошюра турында мәгълүмат бирербез.

**«Яңа низам вә голямаларыбыз»** дип аталган бу китапчык нибары 14 биттән тора, ә ул тудырган шау-шу берничә елга бара, авторын төрмәгә утырта һәм эшсез калдыра. Һади Атласиның моңа кадәр дә матбугатта хезмәтләре басыла башлаган була, әле 1902 елда ук аның Казанда «Гыйльме һәйәт» («Астрономия фәне»), «Тарихе табигый» (Табигать гыйлеме тарихы») китаплары дөнья күрә. Әйткәнебезчә, Атласи яшьлегендә дарвинизм өйрәтүләре белән мавыгып ала, әмма, дин әһеле буларак, «кеше маймылдан килеп чыккан» дигән түбәнлеккә төшми, ә дөньяның эволюция юлы белән үзгәрә баруын өйрәнә, «яшәү өчен көрәш» теориясенә килеп чыга. Ул Чарльз Дарвинның бу тәгълиматын милләтләр һәм кавемнәр тарихына күчереп чагыштыра, **«башка милләт кул астында булган һәм үз хокуклары өчен көрәшмәгән милләт юкка чыга»**, дигән фикерне алга уздыра. Соңгы судында да Атласи шушы фикеренә тугры булып кала:

***«Минем максат бердәм төрки-татар бәйсез дәүләтен төзү иде, ләкин моңа мин бары тик эволюция юлы белән генә барырга теләдем, – ди ул. – Ни өчен мин бәйсез төрки-татар дәүләте төзү тарафдары булдым? Мин – тарихчы, мин төрки халыкларның тормыш-халәтен, тарихын, руслар тарафыннан изелү аша таркалып бетүен һәм үлә баруын өйрәндем».*** *(Атласиларның шәхси архивыннан.)*

Һади Атласиның беренче суды һәм төрмәсе дә милләт өчен була, ул нәкъ йөз ун ел элек мәктәп-мәдрәсәләрне урыслаштыруга каршы күкрәге белән каплана. Бу урында укучыларыбызга ул чордагы вазгыять турында бераз мәгълүмат биреп үтик. Билгеле булганча, узган гасырларда татарларның күпсанлы мәктәп-мәдрәсәләре империя кануннарыннан бераз читтә, чагыштырмача мөстәкыйль эш алып бара. Россия империясенең карагруһ шовинистик көчләре, бигрәк тә мәгариф өлкәсендә эшләүчеләре, татарларның мәктәп-мәдрәсәләрен үз кулларына алырга, үз тәртипләрен кертергә берничә тапкыр омтылып карыйлар. Бу хакта татар тарихчылары менә ничек яза:

***«1905 елның маенда Русиянең көнчыгышында «урыс булмаган» халыкларны уку-укыту мәсьәләләре буенча хөкүмәт махсус киңәшмә үткәрә. Анда империя тарафыннан изелгән халыкларның милли аңы үсешенә киртә кую максаты белән татар әлифбасын урыс хәрефләренә күчерү (димәк, бу Сталин һәм партия башлангычы түгел), аларның мәктәпләрендә урыс теле укытуны мәҗбүри итеп кую, урыс рухында тәрбияләү мәсьәләләре карала. Киңәшмәнең карарлары 1906 елның мартында мәгариф министры тарафыннан кагыйдәләр җыелмасы рәвешендә расланып, бастырып чыгарыла. Карагруһчыларның шовинистик планнарына кискен протест белдереп, Һади Атласи 1906 елда искә алынган мәкаләсен яза. Бу публицистик әсәрендә ул хөкүмәтне изелгән милләт ихтыяҗларын исәпкә алмавы, бары тик урыс халкы мәнфәгатьләрен кайгыртуы өчен каты тәнкыйть итә».*** *(Сәлам Алишев, Рәшит Галләмов. Ут эчендә калган күгәрчен // Һади Атласи. Тарихи-документаль җыентык. – Казан, 2007, 375-376 битләр.)*

Күрәсез, империячел көчләр, козгын кебек, һәрвакыт татарның мәктәпләренә тырнакларын батырган, ә милләтнең Атласи кебек уллары, бөркет булып, бу үләксә козгыннарына каршы ташланган. Хәер, «Яңа низам вә голямаларыбыз» дигән ялкынлы язмасында Һади Атласи үзен «ут эчендә калган күгәрчен» белән чагыштыра. ***«Бу тарихтан өч-дүрт ел элек мин үзем бюрократиянең безне бетерәчәген, динебезне вә милләтебезне корытачагын бик ачык белмәктә, «бетәбез, юк булабыз!» җөмләләрен җан ачысы белән кычкырмакта, ни кылырга белмәенчә, ут эчендә калган күгәрчен кебек ахылдап, төрле тарафка чапмакта идем...»*** – дип яза. *(Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 2 том. – Казан, 2010, 17-18 битләр.)* Чыннан да, Атласиның бу язмасыннан ялкын бәреп тора, аның җан авазы ишетелә, милли мәктәп бетсә, милләт үзе дә бетәсен ул гасырлар аша безгә ачыргаланып кычкыра, кисәтә, ашыгыч чаралар күрергә чакыра...

**«Бу хәреф үзгәртү мәсьәләсе – тышкы яктан бик кечкенә генә вә бик тә әһәмиятсез генә күренсә дә, ләкин эчке катта гаять зур вә соңгы олуг нәтиҗәле бер мәсьәләдер,** – дип яза ул. – **...Белгәне вә яратканы каһәр вә золым булган бу хөкүмәтнең безне бетермәк вә җир йөзеннән корытмак фикере – бик иске вә бик тә борынгы һәм дә үзенчә беренче дәрәҗәдә кирәкле фикердер. Ничә йөз меңнәрдән гыйбарәт булган мәкруһларны рәсми сурәттә христиан итүе, ислам дине тотдыклары хәлдә араларына миссионерларны күндерүе, поплар җибәреп, аларга ирексезләп христианлык индерүе, башын бөкмәгәннәрне Сибирия сахраларына сөрүе – барчасы да күз алдыбызда ап-ачык вә кояш кебек ап-актыдыр. Тугрысы, кыскача әйткәндә, бюрократиянең беренче максаты – безнең динебезне вә милләтебезне юк итмәк, җир йөзеннән корытмактыр».** *(Күрсәтелгән хезмәт.)*

Һади Атласи бу язмасында Россияне *«дөньяның иң артта калган, надан, караңгы мәмләкәте»*, дип атый, анда *«гыйлем урынына – наданлык, хөррият урынына – пулемёт, мәктәп урынына төрмәләр»* хөкем сөрүен яза. Әмма Атласины иң ачындырганы – бу илнең, бу хөкүмәтнең үз халкына, беренче чиратта, мөселманнарга, татарларга карата кылган золым-җәберләре, аларны руслаштырырга һәм христианлаштырырга омтылулары. Ул Россиядә инде йөз меңләгән карендәш халыкларның көчләп чукындыруларын, әгәр уянмасак, инде безне дә шул көн көткәнен кире каккысыз дәлилләр белән исбат итә.

***«Безне дә шуларча итмәк, дин вә милләтебезне үзенең сөйдеке дине белән алмаштырмак хакында изүче хөкүмәт чук заманнан бирле иҗтиһад итеп килмәктә, максатын акрынлап булдыра бармакта, күпме еллардан соң безне дә тәмам хак христиан итәчәгенә канәгать кылмакта, ачыктан-ачык гаскәр вә куәтле җәбер кулланмаганда да, хәрби куәт канаты астында булган миссионерлар, инсафсыз вә вөҗдансыз чиновниклар аркасында безне корытачагын куя, расламакта вә, сугым симерткән кебек, вакыты җиткәнче симертмәктә иде. Заманнар искечә барганда, җилләр һаман, бюрократия теләгәнчә, уңайлы яктан гына исеп килгәндә, безне бетерәчәгендә, дин вә милләтебезне тузан***

***бөртеге итәчәгендә тузан кадәр дә шик вә шөбһә дә юк иде»,*** дип яза Һади Атласи. *(Күрсәтелгән хезмәт.)*

Әйе, Һади Атласи бик дөрес тотып алган – урыс хөкүмәте соңгы татарларны гаскәр һәм сугыш белән түгел, әкрен-әкрен мәктәпләр аша, миссионерлар һәм түрә-чиновниклар ярдәмендә, барыбер чукындырып бетерәчәгенә ышанган һәм эшчәнлеген шул юнәлештә дәвам иткән. Һади Атласи ул елларда ук милләт өчен хәреф алмаштыруның – тел һәм динне алыштыру белән тәмамланачагын бик яхшы аңлаган һәм безне алда көткән инкыйраз фаҗигасе турында йөз ел элек кисәтеп чаң каккан!

Һади Атласи, сизгер сәясәтче буларак, патша хакимиятенә бу мәкерле эшләрен башкарып чыгарга илдә барган хәлләрнең комачау итеп торуын аңлата, ягъни 1905 елгы демократик күтәрелешләр, Россиянең шул елларда японнардан хурлыклы җиңелүе татар мәсьәләсен бераз оныттырып тора. Әмма кара реакция елларында барысы да яңадан үз урынына кайта – тышкы сәясәттә җиңелү хурлыгын каплау өчен, илдә эчке дошман кирәк була, һәм бу урынга тагы мөселманнарны-татарларны «билгелиләр».

***«Ләкин хөррият хәрәкәтләре вакытында тау тишегендәге боеккан елан кебек боегып яткан зәһәрле еланнар бу көндә терелә башлады, – дип яза Атласи. – Җыенда үзен куштаннар кыйнап эт иткән мужикның өенә кайтып ачуыннан күсәк белән атын, чыбыркы белән хатынын кыйнарга башлаганы кеби, инсафсыз вә кара йөрәкле бюрократлар да хезмәтчеләр ачуын бездән ала башладылар. Бу көндә мәгълүм сурәттә динебезне вә милләтебезне рәнҗеттеләр. Җәнабе хак тарафыннан пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһис-салавате вәссәлам, аның белән Кәляме Шәриф иңдерелгән мөкаддәс хәрефләребезне, тел вә әдәбиятыбызны аңлатуда бөтенләй җитешсез булган рус хәрефләре белән алмаштырып, уку хакында законнар чыгардылар».*** *(Күрсәтелгән хезмәт.)*

Империянең мөселман-татарларга карата алып барган мәкерле сәясәтен Һади Атласи бик үтемле тел белән, тормышның үзеннән мисаллар китереп аңлата. Аның әдәби чагыштыруларына, метафораларына таң калырлык! Хөррият заманында тынып торырга мәҗбүр булган залимнәрне ул *«яшеннән качкан шайтаннар», «карчыгадан качкан чыпчыклар», «бүредән качкан этләр», «күзлекле еланнар»* белән тиңли, залим бюрократияне *«черек карт имән агачы»* белән чагыштыра, бары тик хөррият җиле генә аны җимерә алуын әйтә. Әмма Атласиның төп максаты – шушы залим хакимиятнең милләтебезне бетерү өчен ахыргача көрәшүен халыкка аңлату, аларның бөтен карталарын ачып салу:

**«Сәяси вә гражданский хокукларыбызны алып җәберләү җитмәгән кебек, рухани-дини булган җәберләрне бу көнгәчә татыганлыгыбыз туярлык булмаган кебек, иң актыккы җәберләргә бу көндә тагын да башладылар,** – дип яза ул. – **Әүвәлдәге рәнҗүләре бетмәгән, борынгы яралары да төзәлмәгән йөрәкләребезгә хәнҗәрләр белән тагын да чәнчеделәр... Корырга җиткән каннарыбызга, чыгарга җиткән җаннарыбызга тагын да агулар сиптеләр... Беренче буларак эшне хәреф үзгәртүдән башладылар. Әле дә сезне күп саклап килдек, вакыт җитте, диеп, һичбер каршы төшүләребезгә илтифат итми эшкә керештеләр. Акрынлык белән эш булачак түгеллеген, аз булса да уянуыбызны күреп, көч белән тиз заманда эшне башкарырга уйлап һөҗүм иттеләр. Ильминский кебек ислам бәласе булган адәмнең планын аз заман эчендә тормышка ашырып, дин вә милләтебезгә хатимә бирергә (азагына китерергә) чын көч белән керештеләр... иман ярып! Илаһым хакына... дәһа кыскарак аңлата алам: бюрократиянең әүвәлге вә хакыйкый фикере – безне бетермәктер. Хәреф үзгәртү – шуның башыдыр».** *(Күрсәтелгән хезмәт.)*

Йә, милли вә дини хәлебезне моннан да ачык, моннан да ачы, моннан да үзәк өзгеч итеп кем аңлата ала? Һәм шушы йөз ел эчендә нәрсә үзгәрде? Әйе, ул вакытта милләтнең Атласи кебек асыл уллары, илаһи хәрефләребезне, динебезне, милли хокукларыбызны бирмәс өчен утка ташландылар, төрмәләрдә утырдылар, гомерләрен бирделәр. Әмма ул көн килде – мең ел буе милләтебезгә хезмәт иткән гарәп хәрефләрен башта – латинга, аннан кирилл әлифбасына алыштырдылар. Атласи латинга да каршы була, 1929 елда кабат төрмәгә утыртылуына ул да сәбәпче булгандыр, инде латинны

да урыс хәрефләренә алыштырыр алдыннан, 1938 елда Һади Атласины инде милләтче булларак атып үтерәләр.

«Яңа низам вә голямаларыбыз» дип аталган язмасында Һади Атласи, иң беренче чиратта, дин әһелләренә мөрәҗәгать итә, аларны диннән вә дөньядан бихәбәр булып ятмаска өнди. Әйе, бер караганда, мәктәп-мәдрәсәләрдә русча укытыла башлауга, изге Коръән хәрефләрен урысныкына алыштыруга иң беренче чиратта дин әһелләре, мөфти-муллалар каршы чыгарга тиеш иде кебек. Әмма, Атласиның язмасыннан күренгәнчә, моңа каршы бары тик Оренбург имамнары һәм мөселманнары гына протест белдерә. **«Тавышларын җир кырыена кадәр ишеттерделәр. Дини гайрәтнең һәм милли уяулыкның нәрсә икәнлеген фигыльләре белән күрсәттеләр, күңелләрендә иман нуры вә Коръән игътикады барлыгын мәйданга куеп, иманлы вә хак мөселманнар тарафыннан чын күңелдән ихлас калеб белән булган рәхмәт вә догалар алдылар. Яшәсен Оренбург имамнары вә мөселманнары!»** – дип яза ул.

Һади Атласи бу язмасында дин әһелләренә шактый каты һәм урынлы бәрелә. Хәер, аның дин әһелләре белән бәрелешләре беренчесе генә булмый, алар аның «Ахырзаман ишаны», «Мәктәп һәм мулла» кебек язмаларын һәм дарвинизм белән мавыгуын кабул итмәгән булырга тиешләр. Шулай ук Һади Атласиның дингә һәм дөньяга бөтенләй яңача карашы, зур эрудицияле булуы, күп кенә дин әһелләре белмәгәннәрне белүе, үз фикерен ныклы дәлилләр белән, сеңдерерлек итеп аңлата алуы кайберәүләрне аннан читләштерә һәм куркыта. Бу язмасында да ул дин әһелләрен бик конкрет һәм усал сораулары белән стенага тери:

**«Әйе, дин башлыгы – хисап ителгән безнең пәйгамбәрләрнең укымышлы варислар! Сезләр кайдасыз? Сезнең гайрәтегез вә химмәтегез кайдадыр?** – дип сорый ул алардан. – **Сезнең мөселманлыгыгызның мәгънәсе нидер? Пәйгамбәр варислары булуыгыз кай кулыгызда, кай җирегездәдер? Кайда сезнең иман вә Коръән гайрәтегез? Кайда сезнең иманнан тумыш уяулыгыгыз? Кайда сезнең милләт кайгыгыз? (...) Дине исламга каршы диеп, кирәкмәгән җирләрдә ач бозау кадәр кычкырдыгыз хәлдә, динебезгә хакыйкый хиляф булган кебек урыннарда, дин вә милләтебезне юк итәргә беренче сәбәп булган бу кебек мәсьәләләрдә ни хәйлә таптыгыз да постыгыз? Нигә протест бирмисез? Нигә бирергә өндәмисез?»**

Һади Атласиның бу сүзләре бүгенге дин әһелләренә дә туры килә. Мәктәпләребез тоташ урыслашып барганда, инде мәчетләргә дә урыс теле үтеп кергәндә, милләтнең бер өлеше үзенең туган теле дип урыс телен санаганда, кайда моңа каршы дин әһелләренең протесты? Атласи сүзләре белән әйткәндә, *«...сезнең бу кадәр гайрәтсез, вә бу кадәр ваемсыз, вә бу кадәр каткан булуыгызның мәгънәсе нидер?»* Батыршалар шушының өчен көрәштеме, Атласилар шушының өчен корбан булдымы? Милләт шушы ачы нәтиҗәгә килер өчен тереләй сират күперләрен кичтеме? Без урыслашу өчен, урыс милләтен үрчетү өчен исән калдыкмы?!

Әлеге китабы өчен Һади Атласины хөкем итәләр һәм төрмәгә ябалар. Бу хәл 1909 елның 19 июнендә була, китапның нашире Фатих Кәримине һәм авторы Һади Атласины Саратов шәһәренең суд палатасы хөкем итә. Нәтиҗәдә, Фатих Кәримигә штраф салына, китапның барлык нөсхәләре яндырыла, ә Һади Атласи төрмәгә озатыла. Судның «Обвинительный акт» дип аталган гаепләү карарында түбәндәге юллар язылган:

**«Брошюра эта составлена по поводу распоряжения правительства от 31 марта 1906 года о введении в русско-татарских школах транскрипцию татарских текстов буквами русского алфавита и заключает в себе призыв к мусульманскому духовенству о необходимости самого решительного протеста против этого правительственного распоряжения и об оказаний противодействия введению его в жизнь. Автор брошюры Атласов указывает в ней, что русское правительство, стремящееся по отношению ко всему русскому народу держать его в невежестве и на требования о свободе и образование отвечающее пулемётами и ссылкою в Сибирь, в отношении мусульман задалось целью обрусить их, обратить в христианство и уничтожить их национальность и в конце концов «стереть с лица земли».** *(Татарстан Республикасы Милли архивы. Фонд 1370, тасвирлама 1, эш 5, 2-3 битләр.)*

1906 елда чыккан китапчык өчен бары тик 1909 елда гына хөкем итүләренең дә үз сәбәпләре бар, беренчедән, 1907 елда Һади Атласи Дәүләт Думасы депутаты булып тора, икенчедән, ул бөтен Рәсәй империясе буенча бик күп сәяси дуслар таба, өченчедән, аның үз халкы алдында да абруе бик зур була. Шул сәбәпле, Һади Атласига тотынмыйчарак торалар, әмма соңыннан барыбер хөкем итәләр. Атласиның иҗатын һәм тормышын махсус өйрәнеп, фәнни монография язган тарих фәннәре кандидаты Алсу Мөхәмәтдинова бу вакыйгаларны менә ничек тасвирлый:

**«Хөсникамал Атласованың язма истәлекләрендә әлеге вакыйга турында мондый юллар бар: «Һади Атласиның әнисе – Сәхипҗамал апа – аның ирегеннән мәхрүм ителүен белгәч, елап җибәрде. Һади Атласи, әнисен тынычландырып: «Әни, минем ябылуыма борчылма. Мин үз милләтемнең азатлыгы хакына төрмәгә керәм, минем өчен бу – бер шәрәф», – ди. Һади Атласи тарафыннан 1909 елда әйтелгән бу сүзләр, безнең карашыбызча, аның тормышы һәм иҗатының мәгънәсен шактый тулы ача».** *(Алсу Мөхәмәтдинова. Һади Атласиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 1 том. – Казан, 2009, 15-16 битләр.)*

Безгә Һади Атласиның ул вакытта кайсы төрмәдә утыруы билгеле түгел, суд Саратовта булгач, анда утыруы да мөмкин. Күренекле галим Әхмәт Тимер үзенең истәлекләрендә җизнәсе Һади Атласиның төрмәдә бер ай утыруын яза, әмма ул вакытта ул әле тумаган да була, шуңа күрә ялгышуы да бар. Дөрес, Хөсникамал абыстайның истәлекләрендә дә иренең бер айга төрмәгә хөкем ителүе турында хәбәр бар, әмма рәсми язмаларда өч ай дип күрсәтелгәч, без дә шунсына тукталдык. Атласиның «Выборог мөрәҗәгате»нә кул куеп, шуның өчен бер ай төрмәдә утырып чыгуы да билгеле, бәлки шуның белән бутыйлардыр. 1200 данә чыккан «Яңа низам вә голямаларыбыз» брошюрасы берничә көн эчендә полиция тарафыннан җыеп алына. Хөкем барышында Атласиларның өендә дә тентүләр була, бу хакта апалы-сеңелле Хөсникамал һәм Зәйнәп абыстайлар (Әхмәт Тимернең әнисе) газетага хат язып җибәрәләр:

***«Мөхтәрәм мөхаррир әфәнде!***

***12 февраль кич сәгать дүрттә пристав, стражниклар килеп, Әлмәт карьясендә имам Атласов йортында тентү ясады. Тентү ике сәгать дәвам итте. Өйдә булган барча нәрсәләре актарылып, бераз мәктүб вә башка зарарсыз кәгазьләр алынды. Кызлар мәктәбен ябарга әмер итеп: «Укытасыгыз килсә, губернатордан разрешение сорарсыз, әгәр минем бу юлы тыюыма карышып укытсагыз, өегезне дә печатьләрмен!» – дип катгый тыйды. Вә беренче дәрәҗәдә гүзәл итеп кара-каршы салынган кызлар өчен махсус мәдрәсәдә иртәдән башлап кичкә кадәр гөрләп укый торган балалар, бүген һәрбере килеп елашып, мәдрәсәдән аерылма мәҗбүр булдылар».*** *(«Вакыт», 1909, №436.)*

Шушы хәлләрдән соң Һади Атласины имамлык хокукыннан мәхрүм итәләр, мәктәбен яптыралар, үзе исә 1917 елга кадәр полиция күзәтүе астында була. Әмма ул төшенкелеккә бирелми, вакытын әрәм итми, башы-аягы белән татар тарихын өйрәнүгә кереп чума. Әйткәнебезчә, бу чорда аның милләт язмышы турында иң көчле публицистик язмалары, татар тарихы турында иң көчле әсәрләре дөнья күрә, алар турында алдагы бүлекләрдә бәян итәрбез.

Быел күренекле галим, тарихчы, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, шәхес культы корбаны Һади Атласиның тууына 140 ел тула, ә аның «Яңа низам вә голямаларыбыз» хезмәтенең язылуына һәм басылып чыгуына – 110 ел. Милләт дип янган, милләт өчен язган, милләт өчен үлгән бу бөек шәхесебезнең олуг юбилеен милләт дәрәҗәсендә билгеләп үтәсе иде. Кызганычка каршы, ни Казанда, ни Әлмәттә Һади Атласи исемендәге урамнар юк, ул яшәгән һәм эшләгән йортларга истәлек такталары куелмаган, аның иҗаты буенча фәнни-мәдәни чаралар уздырылмый. Хәзергә бары тик Бөгелмәдә һәм Атласиның туган ягы Чүпрәледә генә аны онытмыйлар, зурлап искә алалар. Югыйсә, Казанның Менженский исемендәге клуб диварына да, 1937 елның октябрендә Һади Атласига һәм аның көрәштәшләренә үлем карары чыгарылган НКВД бинасына бу тугыз татарның исемнәре уеп язылган истәлек тактасы куярга күптән кирәк иде. Шулай ук Атласиның хезмәтләрен Төркиядә һәм төрки республикаларда

бастырып чыгару, халык арасында иҗатын пропагандалау эшләрен башлап җибәрергә вакыт. Моңа кадәр Һади Атласиның бай мирасын нигездә тарихчылар гына өйрәнде, инде язучыларга, мәгърифәтчеләргә дә аның иҗатына йөз белән борылырга вакыт җитте. Кайда татарның дәүләт бәйсезлеге өчен атып үтерелгән тугыз татар ир-егете турында шигырь-поэмалар, хикәя-романнар, фильм-спектакльләр? Язмабызның бу өлешен Һади Атласиның үз сүзләре белән тәмамлыйсы килә:

**«Үзенең кем икәнен белмәгән инсан ничаклы хиссез исә, үзенең милләтенең тарихын белмәгән инсан да шул нисбәттә хиссездер... Без татар балалары да юкка чыгарга теләмәсәк, мөмкин кадәр әдәбиятыбызны баетырга, бөек бабаларыбызның нурлы эшләре язылган якты тарихларыбызны белергә тиешлебез».**

Моңа өстәп, шуны әйтәм: һәм, һичшиксез, милләт өчен башын салган каһарман татарлар тарихын, Атласилар язмышын килер буыннар өчен дә язып калдырырга тиешбез!

## Атласиның милли-сәяси язмалары

Һади Атласи үзенең күләмле тарихи әсәрләренә милләт темасына язылган публицистик язмалары аша килде, ягъни, тарих төпкелләренә чумганчы, милли чишмәләрдә чирканчык алды, үзен шуларда сынап карады. Аның бигрәк тә 1906-1914 еллар арасында язылган мәкаләләре үзләренең тема төрлелеге, актуальлеге, тел үткенлеге һәм үтемле булулары белән аерылып тора. Бу елларда Һади Атласи бигрәк тә Оренбургта чыга торган «Шура» журналы һәм «Вакыт» газетасында, шулай ук Казандагы «Аң» журналында һәм «Йолдыз» газеталарында еш басыла. Темасы ягыннан исә Атласи күтәргән проблемалар киң колачлы була – монда тел-милләт, милли мәгариф-мәктәп, төрки тарих, ислам һәм дин әһелләре, иҗтимагый-сәяси хәлләр турында язмалар урын алган. Язылу рәвеше, тел-өслүбе белән Атласи мәкаләләре полемика-бәхәс формасында да, фәлсәфә алып бару рәвешендә дә язылган, алардан һәркем үзенә кирәкне эзләп таба ала. Әмма барлык мәкаләләреннән дә шул күренә: Һади Атласиның төп өйрәнү өлкәсе – үз халкы, аның чишелмәгән проблемалары, төзәлмәгән җан яралары, милләт хәдимнәре вә милләт ятимнәре... Атласи публицистикасының бу ягына танылган галим Миркасыйм Госманов та игътибар иткән:

***«Авторның үзалдына куйган төп һәм бердәнбер дип әйтерлек максаты ул – туган халкын, газиз милләтен гасырлар буе хөкем сөргән торгынлыктан чыгаруга өлеш кертү,*** – дип яза ул. ***...Һәр конкрет мәкаләдә, ни турында гына сүз бармасын, авторның әйтергә теләгән төп фикере һәрвакытта укучыларын аң-белемне үстерүгә, тәрәккыяткә чакыруга кайтып кала. Бу алым, кызыл җеп булып, Һади Атласиның бөтен публицистикасы буенча уздырыла».*** *(Миркасыйм Госманов. Яңа сыйфатлар ачыла бара // Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 2 том. – Казан, 2010. 7-8 битләр.)*

Әйткәнебезчә, Атласи үз өстендә бик нык эшли, язмаларында күп чыганаклардан файдалана, укучыга татар тормышыннан гына түгел, дөньядагы вазгыять, тарих, классик әдәбият, сәясәт буенча да күп мәгълүмат җиткерә. Әйтик, 1901 елда Оренбургта язган һәм 1902 елда Казанда басылып чыккан «Тарихе табигый» хезмәтендә ул «Хөсәения» мәдрәсәсендә булган бай китапханәдән, имам Газали хезмәтләреннән файдалана. Анда булган Шәрык һәм Европа әдәбиятына таянып, әмма иң алга Коръәнне куеп, 25 яшьлек Һади Атласи милләткә җир һәм күкләрнең төзелешен аңлатуга алына. Бу хезмәтендә ул, саф татар телендә, һәркемгә аңлашырлык популяр жанрда, җир астында һәм өстендә булган хәлләр, һава һәм сулар, таулар һәм янартаулар, табигать торышы һәм кешелек тарихы турында яза. Һади Атласиның бу китабын язуының төп сәбәбе – «иҗтиһадка юл ябык», дип, Коръәннең асыл мәгънәсен халыкка аңлатуны тыючы дин әһелләренә җавап булып тора. Атласи фикеренчә, Коръәнне халыкка аңлату кирәк, әмма аның өчен динне генә түгел, фәнне дә, әйтик, шул ук астрономия, биология, анатомия, геология (җир гыйлеме), табигать белемен дә белү кирәк.

***«Һәр милләт үзенең хокукын, дәрәҗәсенең ни кебек икәнен белергә бурычлыдыр,***

***– дип яза ул. – ...Кыскача әйткәнемдә, бөтен гыйлем һәм хикмәтне җыеп, «Әгәр... диңгез суы яза торган кара булса» аяте белән олуглыгына ишарә ителгән Коръәнне өйрәнү, андагы хикмәтләрне аңлап, шул кыйммәтле булган хикмәтләр белән хәрәкәт вә идарә итү безнең милләттәшләребезгә лязим булган хокукларның берседер. Шул бөек булган хокукларын танымаулары өчен дә араларында шайтаннарны куркытырдай низаглар вә сугышлар барлыкка килә вә шунда тәкфир, шелтә телләрендә күпме вакытлар зикер ителгәннән соң, ак кәгазьләр өстенә язылып, бөтен дөнья адәмнәрен хәйрәттә калдыра вә фикерле адәмнәрне «аһ» дип тәкрар иттерә. Йа Аллаһ! Ни олуг хәсрәт! Гыйбрәт күзе белән Коръәнгә бер карау! Ни әйткәнен аңлау! Безнең сәгадәтебезгә сәбәп ул түгелме соң?!»*** *(Тарихе табигый // Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 2 том..., 303-304 битләр.)*

Халыкка шушыларны аңлатасы урында, *«ысулы җәдидә-ысулы кадимә»* дип *«дөнья сасытып»* ятуны яшь кеше, булачак зур галим Һади Атласи, әлбәттә, кабул итә алмый. Ул тормышының башында ук, диннән китмәгәне хәлендә, үз юлын эзли башлый, дарвинизм белән мавыгып алуы да шушы елларга туры килә. Ул елларда Һади Атласи Петербургтан либераль газеталар яздырып ала башлый, дөньяның барышы, сәяси-иҗтимагый хәлләр турында яһүди һәм рус интеллигенциясенең дә фикерләре белән танышып-кызыксынып тора. Ул нәрсә генә укыса да, нәрсә генә белсә дә, аны татар тормышы белән чагыштырып карый, дөньядагы шушы үзгәрешләрдә милләтнең тоткан урынын табарга тырыша. Һәм таба алмый – милләт барысыннан да читтә. Һәм тагы өзгәләнеп-бәргәләнеп яза башлый, үз татарларымыз арасыннан фикердәшләр эзли...

Үзенең эволюция юлы белән үзгәрә баруын Атласи судта, 1937 елның 24 октябрендә дә сөйли. Ул либераль газеталарның анда русларга карата ышанмау тәрбияләвен, миссионерлар язган хезмәтләрнең дә мөселманнарга каршы булуын әйтә, әмма тора-бара, социалистларның хезмәтләрен өйрәнгәннән соң, барлык урысларны да мөселманнарга каршы дип исәпләргә ярамавын аңлавын сөйли. Суд беркетмәләре рус телендә тутырылган булганлыктан, Атласиның чыгышыннан бу өзекне дә шул телдә тәкъдим итәбез.

***«Я – старый общественник, историк, педагог. Ещё задолго до революции я начал знакомиться с пантюркским движением. Я выписывал газеты из-за границы. Через эти газеты я знакомился с пантюркским движением. В 1900 годах стал знакомиться с европейской литературой и с русской литературой. Я был хорошо знаком с политикой. В это время издавалась только одна татарская газета (в Крыму), в России не было ни одной центральной татарской газеты. С русской литературой я начал постепенно знакомиться с 1898 года. Я читал газету «Свет». Эта газета воспитывала во мне недоверие к русским. Впоследствии я начал знакомиться с миссионерскими книгами; студентами был издан сборник, в котором были статьи против мусульман. В то время я думал, что русские против мусульман, против тюрко-татарского населения, тогда я ещё не был знаком с националистическими произведениями. С конца 1905 года я начал знакомиться с социалистическими произведениями. Я сделал открытие, я решил, что нельзя всех русских считать противниками мусульман. Я предполагал, что есть люди, которые защищают интересы угнетённых классов, угнетённых национальностей. Я начал постепенно знакомиться с Марксо-Энгельсскими произведениями, во мне произошёл крупный переворот».*** *(Атласиларның шәхси архивыннан.)*

Бәлки Атласи Маркс-Энгельс турында сүзләрен суд карарын йомшарту нияте белән генә әйткәндер, чөнки аның бу темага язмалары юк диярлек. Киресенчә, узган гасыр башында аның бөтен язганнары – милләт, милләт, бары тик милләт турында! Мулла башы белән, аның ярсып каләмгә тотынуының да сәбәбе – милләткә дөньяда барган кискен үзгәрешләрне аңлатучы булмаганнан, аның наданлык аркасында харап булуыннан куркуыннан, хокуксыз татарны башка халыклар дәрәҗәсенә күтәрергә теләүдән килеп чыккан. 1907 елның башында Россия Дәүләт Думасына депутат итеп сайлангач, Һади Атласига үз халкының хәле тагы да ачык булып күренә. Бередә ул үз өстендә эшләүгә дә күп вакыт бирә – монда аңа Санкт-Петербургның данлыклы китапханәләрендә шәркый әдәбият, төрки тарих буенча фәнни хезмәтләр белән танышу

мөмкинлеге ачыла. Алар аша Һади Атласи рус тарихчыларының да бу темага язылган хезмәтләренә, елъязмаларга килеп чыга, алга таба татар тарихын язар өчен кыйммәтле материал белән кораллана. Ул шулай ук дөньякүләм энциклопедик сүзлекләрне, төрле тарихи белешмәләрне дә хезмәтләрендә файдалана, андагы мәгълүматларны татар тормышы белән чагыштырып өйрәнә.

***«Россиядә Шәрыкны өйрәнүче эре үзәк булган Санкт-Петербургта торып, Һ.Атласи шәхси китапханәсен кыйммәтле фәнни-әдәбият белән баета, – дип яза галимә Алсу Мөхәммәтдинова. – Шәһәрнең мәдәни-тарихи мохите һәм Петербургның электән килгән гыйльми традицияләре аның фәнни тикшеренүләре өчен кирәкле чыганаклар базасын әзерләвенә файдалы тәэсир ясаган».*** *(Алсу Мөхәммәтдинова. Һади Атласиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Һади Атласи. Тарихи-документаль җыентык. – Казан, 2007, 18 б.)*

Бераз алга китеп, шуны да әйтергә була: Һади Атласиның төрки-татар тарихы белән профессиональ дәрәҗәдә һәм нәтиҗәле эшләвен күреп, аны Беренче Бөтендөнья сугышыннан соң Петербург университетының шәрык бүлегенә эшкә чакыралар. Хатыны Хөсникамал абыстай Әлмәттән китәргә теләми, шул сәбәпле Атласи да Петербурга күчмичә кала. Атласиның Франциягә, Сорбонна университетына укырга китәргә әзерләнүе дә, Беренче Бөтендөнья сугышы башлану сәбәпле, тормышка ашмыйча кала. Егерменче еллар урталарында да ул берничә тапкыр Төркиягә китәргә омтылып карый, әмма бу эше дә барып чыкмый, тимер капкалар ябылып өлгерә. Хәер, болары турында алдагы бүлекләрдә бәян итәрбез, ә хәзер тагы Атласиның Әлмәт чорына әйләнеп кайтыйк.

Әйткәнебезчә, Әлмәттә яшәсә дә, Атласи үзенең үткен һәм төпле язмалары белән бөтен татар дөньясын дер селкетеп тота, аңа яңадан йокыга китәргә ирек бирми. Сез аның мәкалә исемнәренә генә игътибар итегез – үлгән кешең сикереп торырлык! «Төрек галәменнән» (1907), «Ислах ни димәктер?» (1908), «Йогышлы рәнҗү һәм татарлар» (1910), «Наданлык вә аның җимешләре» (1910), «Миссионерлар җәмгыятьләре» (1910), «Дин саклау вә аңа ләякать» (1909-1910), «Бай һәм ярлы телләр, төрекчә югалган сүзләр» (1910), «Борынгы эш вә борынгы сүзләр» (1910), «Безнең тел» (1910), «Безнең тәрәккый» (1910), «Ике дөнья» (1911), «Әрәм акчалар» (1913), «Ярлылык вә аның сәбәпләре» (1913), «Кытай фетнәсе» (1913), «Инкыйраз вә аның сәбәпләре» (1913), «Күчмәлек вә аның зарарлары» (1913), «Америка көтепханәләре» (1914), «Аурупа дәүләтләре» (1914) һәм башкалар, һәм башкалар... Әлеге язмаларның күпчелеге 2007 һәм 2010 елларда Казанда басылып чыккан Атласи җыентыкларына кертелгән, хезмәтебезнең бу бүлегендә без дә шулардан файдаландык.

Һади Атласиның барлык мәкаләләрендә дә диярлек дин һәм төркилек мәсьәләләре алгы урынга чыга, ул аларны милләтнең рухи нигезе дип саный. Әмма шул ук вакытта Атласи надан, дөньядан артта калган дин әһелләрен кискен тәнкыйтьли, аларны *«икейөзле наданнар», «сукыр суфилар», «мәче башлы ябалаклар», «эшсез суфи-дәрвишләр», «кабер коллары», «исламның черек әгъзаләре», «ялган доносчы Ишми нәселе», «Кизләү мөридләре»* дип атый. Атласиның «Кизләү вә аның мәдрәсәсе» дип аталган мәкаләсен укыгач, безгә «традицион ислам»ның кайдан килгәнлеген аңлый башлыйсың. «Кизләү мөридләре» өчен Коръән һәм хәдисләр нигез булып тормыйча, Кизләү авылы гореф-гадәтләре күрсәтмә булып торган икән.

***«Русиядәге ишанлыклар арасында Кизләү чаклы үз халкын надан калдырган һичбер ишанлык юктыр,*** – дип яза Атласи. – ***Һинд мәҗүсиләрендә генә була торган әллә нинди бозык инанулар барысы да шуның табгысындадыр. Кизләү үзе артка калырга ничаклы хезмәт итсә дә, аның мәдрәсәсе дә шулчаклы хезмәт итте. Ул мәдрәсәдән чыккан шәкертләр өчен Кизләүнең гореф-гадәтләре мәҗбүри кануннар кабиленнәндер. Ул гореф-гадәтләрдән бер адым алга вә яхуд артка атламак катыгыян мөмкин түгелдер».***

Чистай өязендәге бу авылның Кизләү чишмәсе янында, әүлия күмелгән дип, Самар, Сембер, Казан губернасы мишәрләренең өелешеп ятуын Атласи ачынып һәм аптырап яза, моның саф дингә бернинди катнашы булмаганлыгын әйтә. Йә, бүген дә авыл саен әүлия кабере, изге чишмәләр эзләп йөрүчеләр, ат төкләрен бәгъзе кешеләрнең сакал-

мыегы дип күтәреп йөрүчеләр, «традицион ислам» битлеге астында милләтне яңадан мәҗүсилеккә өстерәүчеләр юкмыни? Бар, ишаннары да бар, мөридләре дә бар, әмма шуларны күзләренә карап әйтүче Атласилар гына юк...

***«Черегән агачлардан чыдамлы биналар ясамак мөмкин улмаганлыгы кеби, нигезе череп эштән чыгып беткән мәҗүс схоластика илә дә мәктәп-мәдрәсәләребезне ислах итмәк, шунлар илә милләткә хәят бирүче адәмнәр җитештермәк мөмкин түгел хәлдер», дип яза ул үзенең «Ислах ни димәктер?»*** дип аталган мәкаләсендә. Әлбәттә, Атласи ул чордагы мәктәп-мәдрәсәләр алдына үтәп чыга алмаслык бурычлар куя, алардан *«хаким, фәйләсуф, мөхәррир, мөҗтәһиде голәмә (энциклопедист)»*лар әзерләүне көтә, әмма моның өчен милләтнең үз институтлары һәм университетлары булу кирәк бит! Болар булсын өчен, үзеңнең мөстәкыйль дәүләтең булуы шарт. Дөрес, Атласи тора-бара шушы фикергә килә, шуның өчен гомере белән түли, әмма милли көрәшенең башында дин әһелләрен, мәктәп-мәдрәсәләрне кискен тәнкыйтьләү белән мавыга, бар нәрсәдә аларны гаепли.

***«Мин дә әйтәм: «Наданлык һәм аның нәтиҗәсе булган инкыйраз үзләренә күрә бер төрле чокырлардыр ки: милләтне ул чокырларга динне тар аңлаучы руханилар илтеп батыралар. Түбәнлек һәм мескенлек. Аллаһның иң олуг җәзаларыдыр ки, шунларга милләт начар галимнәр сәбәпле дучар була»***, дип нәтиҗә ясый ул «Дин саклау вә аңа ләякать» мәкаләсендә. Атласи руханилардан бик күп нәрсә таләп итә, әмма, иң беренче чиратта, ул алардан милләтне торгынлык, мескенлек, ваемсызлык, наданлык, өметсезлек баткагыннан алып чыгуны көтә, моның өчен дөньяви гыйлемнәр дә алуны таләп итә. Үзенең язмаларында дин әһелләренә шактый каты кагылса да, Атласи милләтне яратып һәм кызганып яза, аны *«гаять юаш вә гаять җәберләнгән зур бер милләт»*, дип атый, аңа кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тырыша.

Инде төркилек, татарлык, милләтчелек мәсьәләләренә килгәндә, Атласи башта ук үзен зур төрки цивилизациянең бер вәкиле, дип игълан итә. ***«Мин үзем төрек** *(төрки – ред.)***, милләтем төрек, иң сөйгән нәрсәм дәһа төрек булдыгы өчен, мактаулар булсын, төрекләрнең тарихы һәм теле хакында байтак нәрсәләр укырга муафыйк булдым»***, дип яза ул үзенең «Мәктүп» дигән мәкаләсендә. Әмма шул ук вакытта төрки халыкларның, шул исәптән татарларның да, *«дин бозылу сәбәпле, ләхеткә дип багышланган җирләреннән дә мәхрүм ителүләрен»* яза. Атласи «төрекләр» дигәндә, еш кына аңа бөтен төркиләрне, шул исәптән татарларны да кертә, гел уртак тарих, уртак тел һәм дингә ишарә ясый.

***«Урынсыз тәгассыб (фанатизм) һәм наданлык шомлыгында без төрекләрнең оҗмахка охшашлы өлкәләре харап булып беткән кебек, борынгыдан бай булган телләре дә төрекләрнең үзләре кебек харап булырга якынлашкан. Алай да үлекләрне торгызган көчле Аллаһның рәхмәте белән соңгы заманнарда төрекләр уяна, вә шул нигездә төрекләр «төрек» булып яшәр өчен ниләр кирәк икәнне төшенә башладылар. Төрекләрнең ата-бабаларын тикшерүләре, шулай ук югалган төрек көч-куәте белән онытылган төрек телләрен торгызырга тырышулары – барысы да төрекләрдә төреклек галәмәте була башлауга иң чын галәмәтләр»***, дип яза ул үзенең «Безнең тел» мәкаләсендә.

Шул ук вакытта Һади Атласи госманлы Төркиясенең үзендә телнең бик ярлы булуын әйтә, аларны үз телләрен башкалар белән бутаганнары өчен тәнкыйть итә. ***«Госманлылар исә, һаман да шул борынгы начар гадәт белән китеп, безнең өчен изге булган төрки сүзләрне күмеп калдыра килгәннәр,*** – дип яза ул. – ***Мин үзем чын госманлы(ны) сөюче булсам да, госманлы телен һич сөймим. Алар сөйләгән төрекчәне төрек теле дип белмим. Аңарга гарәпчә, фарсычадан вә бераз гына төрекчәдән катыштырылып ясалган боламык дип кенә карыйм»***, дип яза ул «Бай һәм ярлы телләр, төрекчә югалган сүзләр» дип аталган мәкаләсендә. Каты әйткән, әмма хак әйткән. Шуңа күрә Атласи госманлы төрекчәсен төрки телләр рәтенә кертми, башка төрки халыкларны да шуңа өнди. ***«Без татарлар үзебезне госманлы төрекләреннән гыйлем вә мәгариф алырга шәкерт итәргә тиешле дип белсәк тә, тел ягыннан аларга шәкерт булырга ихтыяҗыбыз юк!»*** дип яза ул шушы ук мәкаләсендә. Атласи

фикеренчә, телне төрекләштерү өчен әдәбиятта борынгы төрки сүзләрне һәм халык сөйләшен куллану кирәк.

Һади Атласи алга таба төркичелек, тел-дин мәсьәләләреннән тарих проблемаларына күчә, татар тарихы аның төп темасына әйләнә. Атласиның тарих темасына язган мәкаләләре зур тарихи әсәрләр язган чорга туры килә, алар бергә иҗат ителә. Милләтнең аңын уятуда, үзенең КЕМ булуын һәм кемгә әйләнүен аңлатуда Атласи тарихның зур ролен күрә. ***«Бер милләтнең яшьләренә бабаларының борынгы хәлләре, аларның кылган эшләре белән сөйләгән сүзләре билгеле булса, ул милләт шиксез бар булып килә вә киләчәктә дә бар булачак»***, дип яза ул «Борынгы эш вә борынгы сүзләр» мәкаләсендә. Нинди хак сүзләр! Һәм ни кызганыч, әле бүген дә шушы хакыйкатьне аңлап бетермиләр – үз тарихын белмәгән, аннан гыйбрәт алмаган милләтнең киләчәге дә юк. Бөек акыл иясе Атласи моны әле моннан йөз ел элек үк аңлаган һәм безләргә дә васыять итеп язып калдырган. ***«Без татар балалары да юкка чыгарга теләмәсәк, мөмкин кадәр әдәбиятыбызны баетырга, бөек бабаларыбызның нурлы эшләре язылган якты тарихларыбызны белергә тиешлебез»***, дип әйткән. Ничек дөрес һәм матур әйткән – *«бөек бабаларыбызның нурлы эшләре язылган якты тарихыбызны белергә тиешбез»*, дигән. Ә без, бүгенге татарлар, беләбезме бөек бабаларыбызның нурлы, якты тарихын, әллә һаман «татар-монгол изүе» дигән әкияткә ышанып йөрибезме?

Атласи үзенең тарих турында мәкаләләрендә бик борынгы заманнардан үзе яшәгән чорларга кадәр араны колачлый, Кытай-Монголиялрдән алып, Хәзәр каганатларына кадәр ил-дәүләтләргә, ыруг-кабиләләргә, халыкларга бәя бирә. «Саркыл шәһәре» мәкаләсендә ул хәзәрләрнең төрки булуларын, «Кытай фетнәсендә» – гасырлар буе Кытай белән идарә иткән манчьжурларның кытай милләтеннән булмавын, башка хезмәтләрендә, бигрәк тә – «Себер тарихында» – скифларның төрки халык булуын һәм Себернең ул заманнарда Скифия-Туран иле дип аталуын ул татар тарихчыларыннан беренче булып әйтә. Һади Атласиның тарих турында язмалары милләт тарафыннан да, рус зыялылары тарафыннан да зур кызыксыну белән, яхшы кабул ителә. 1913 елгы мөселман календаре аны *«милләтнең алмазы-асылташы»*, дип атый, ә рус зыялылары Атласины шул ук елда Казан университетының Археология, тарих һәм этнография җәмгыятенә хакыйкый әгъза итеп сайлый. Атласи өчен зур тарихка – меңьеллыкларны колачлаган төрки-татар тарихына юл ачыла... Болар хакында алдагы бүлекләрдә бәян итәрбез, инша Аллаһ!

## Һади Атласиның «Себер тарихы»

Егерменче гасыр башында татар дөньясында барлык өлкәләрдә дә зур җанлану, уяну сизелә. Инде үз милли байлары барлыкка килгән татарлар мәгариф, матбугат, дин, тарих, әдәбият өлкәсендә дә нык алга чыгалар, милләт тормышында зур үзгәрешләр башлана. Бу уянуны җәдитчеләр-кадимчеләр көрәшенә, дини реформаларга гына кайтарып калдыру дөрес булмас иде, халыкта, бигрәк тә укымышлы яшьләр арасында дөнья тормышы, узганнар, аеруча милли тарих белән кызыксыну арта. Бер-бер артлы Казанда, Оренбургта, Уфада, Әстерханда, хәтта империя башкаласы Петербургта татарча газета-журналлар чыга башлый, аларның даими авторлары һәм укучылары барлыкка килә, милли матбугат татар тарихына да зур урын бирә һәм алга таба бу өлкәдә күләмле хезмәтләр туугa сәбәпче булып тора.

Һади Атласи менә шушы рухи уяну, милли тамырларны эзләү башланган яңарыш чорында шәхес буларак формалаша, үзе дә башы-аягы белән шушы дәрьяга ташлана... Әйткәнебезчә, тарихи темага язуларын ул башта газета-журнал битләрендә сынап карый, халыкта моңа ихтыяҗ һәм зур кызыксыну күргәч, зур тарихи хезмәтләргә тотынырга батырчылык итә. Дөрес, ул бу өлкәдә беренче булмый, егерменче гасыр башында татар зыялылары арасында милләт тарихы буенча күләмле хезмәтләр язучылар инде күренә башлаган була. Бу урында Хәсәнгата Габәшинең «Мөфассал тарих кауме төрки» китабын (1909), Гайнетдин Әхмәровның «Болгар тарихы» (1909), «Казан тарихы», (1910), Габделбари Батталның «Төрек кабиләсе тарихы» (1912), Зәки

Вәлидинең «Төрек вә татар тарихы» (1912), Ризаэддин Фәхреддиннең «Асар»ын һәм унтугызынчы гасыр галимнәре Шиһабетдин Мәрҗани, Габденнасыйр Курсави һәм башкаларның хезмәтләрен атап үтәргә була. Әлбәттә, Һади Атласи аларның барысы белән дә таныш булган, кайберләрен үз хезмәтләрен язганда да файдаланган, әмма шушы темага булган рус чыганакларына өстенлек биргән. Бу хәлгә бүгенге тарихчылар да игътибар иткән:

***«Төрки-татарлар тарихына караган материаллар җыйганда, яшь галим төрки-татар дөньясы галимнәре тарафыннан үз тарихларының начар яктыртылуы кебек үзенчәлеккә игътибар итә, – дип яза алар. – Бу хәлне Һ.Атласи төрки телләрдәге чыганакларның аз булуы яки бөтенләй булмавы белән аңлата. Шәркый чыганакларны этрафлы өйрәнеп, яшь тарихчы алга таба рус тарихи әдәбиятына һәм рус елъязмаларына мөрәҗәгать итә. Әлеге материалларның бер өлешен ориенталистика буенча сирәк басмаларны Һ.Атласи нәкъ менә Санкт-Петербургта туплый».*** *(Алсу Мөхәмәтдинова. Һади Атласиның тормыш юлы һәм эшчәнлеге // Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 1 том. – Казан, 2009, 14-15 битләр.)*

«Себер тарихы»на кереш сүзендә Атласи милли тарихыбыз булмавына кайгыруын белдерә, ***«үз галимнәребез шул хосуста бернәрсә дә язмаганнар»***, ди. Әмма бу дөреслеккә туры килеп бетми, әйткәнебезчә, ул чорда инде бездә дә тарихи хезмәтләр күренгәли башлый. Әмма, әйткәнебезчә, Атласига татар тарихын язарга төп этәргечне урыс галимнәренең хезмәтләре бирә. Бигрәк тә Петербург чоры Атласи тормышында, иҗатында тирән эз калдыра һәм дөньяга карашын үзгәртә.

Әйе, 1907 елда Россия Дәүләт Думасына депутат итеп сайланганнан соң, Һади Атласи берара Петербургта яшәп ала. Биредә ул депутат эшчәнлегеннән тыш, үзенең белемен арттыру өстендә дә эшли, буш вакытын башкала китапханәләрендә һәм архивларында уздыра. Төрки-татар темасына руслар тарафыннан язылган әдәбият һәм тарихи хезмәтләр белән җентекле танышу Атласига күп яңа мәгълүмат бирә, әмма ул алар белән артык мавыгып китеп, кайбер фактик һәм идеологик хаталар да җибәрә. Ул хаталарга хезмәтләрнең үзләрен тикшергәндә махсус тукталырбыз.

Атласи зур тарихи хезмәтләрен язганда, инде бер тапкыр төрмәдә утырып чыккан була, шуңа күрәдерме, ул алга таба урыс-татар мәсьәләсенә бик сак килә, хөкүмәткә дә артык тел тидерми. Аның урыс чыганакларына таянып эшләве дә, бәлки, шул сәбәпле булгандыр, чөнки ул хезмәтләр барысы да цензура тарафыннан расланган, рөхсәт ителгән китаплар булган. Ә Соловьёв, Карамзин, Татищевлар, гомумән, рәсми тарихчылардан саналган һәм патша хакимиятендә шик уятмаган. Милләтләре белән алман булган Миллер, Радлов хезмәтләре дә империя цензурасын үтеп, ышанычлылар исемлегендә йөри, Атласи аларның хезмәтләрен дә киң файдалана.

***«Иге һәм чиге күренми торган татар өлкәләре ят милләтләр тарафыннан басып алынгач, аларның мәмләкәтләре илә катнашып, икенче төскә кердекләре кеби, милли тарихларыбызга караган вакыйгалар да, тегеләрнең тарихларына катнашып, икенче төскә кергәннәр, – дип яза Атласи бу турыда. – ...Без – татарлар – бу көндәге урыс мәдәниятеннән файдалар иттегебез кеби, тарихыбызга караган нәрсәләр хакында да урыс голәмәсеы тарафыннан язылган тарихлардан бик күп файдалар итәчәгебез мәгълүмдер».*** *(Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 1 том. – Казан, 2009, 46 бит.)*

Әмма шул ук вакытта Атласи кайбер урыс елъязмачыларының һәм тарихчыларының фанатизмга артык бирелеп, вакыйгаларны үзгәртеп язуларын да кисәтә. Ул вакыйгаларны гадел тасвирлаган урыс тарихчылары барлыгын да әйтә, «Себер тарихы» хезмәтенең кереш сүзендә аларга үзенең рәхмәтләрен җиткерә. ***«Урыс телендәге төрле фәннәргә даир язылган санап бетергесез китаплар татарлар өчен олуг хәзинәләр булганлыкларына охшашлы, тарих фәненә даир язылган китаплар да алар өчен иң кыйммәтле мөкаддәс нәрсәләрдер... Төрки-татар тарихына карата русча язылган бик күп кыйммәтле әсәрләр бардыр».*** *(Күрсәтелгән хезмәт.)*

Һади Атласи Петербургта яшәгәндә, шәркый галимнәр (востоковедлар) белән дә очрашкан булырга тиеш, соңрак аны башкала университетына эшкә чакырулары да шәхси мөнәсәбәтләр сәбәпле булырга мөмкин. Ә менә ***«Себер тарихы»***н язганда, ул

Казанда тюрколог Николай Катанов белән махсус очраша, бу турыда аның мәкаләсе дә бар. Бу хәл 1910 елның октябрендә булган булырга тиеш, чөнки Атласиның ***«Профессор Катанов илә мөсахәбә»*** язмасы 1911 елда «Шура» журналының 23нче санында басылып чыга. Атласи Катановның төрки тарихтан бик мәгълүматлы булуына таң калса да, аның кайбер фикерләре белән килешмәвен дә сиздергән. Әйтик, Катанов скифларның төрки булуларын кире кага, ул шулай ук Туран турында да каршылыклы фикерләр әйтә. Әйе, алар тарихтан бик мәгълүматлы булсалар да, әлеге мирасны татарга бирмәс өчен тагы да күп дәлилләр чыгарып салалар.

Бу урында мин Атласиның үзенең дә кайбер фикерләрен кабул итеп бетермим, әйтик, Катанов белән очрашуы турында язмасында ул берничә урында *«надан татарлар»* сүзен куллана, имеш, әнә тегеләр ничек гыйлем дә, менә безнең татарлар тарих-фән өлкәсендә нинди надан... Әмма бу «наданлыкның» бик җитди сәбәпләре бар бит, туганым! Басып алучы хаким халык белән яулап алынган һәм кол ителгән милләт берничек тә, бер өлкәдә дә тигез була алмый, бу мәгариф-фән өлкәсенә дә кагыла. Узган гасырларда татар, Катанов кебек чукынса гына, бу университетларга якын килә алган, аңа басып алучыларның гыйлем мәгарәләре ачылган. Безнекеләр исә гыйлемне дини китаплар аша алганнар, шулай ук Шәрыкның тарихчылары да аларга таныш булган. Әйтик, шул ук Һади Атласи үзе дә тарихи хезмәтләрен язганда, Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрек» әсәреннән, шулай ук урта гасырлар галимнәре Рәшидеддиннең «Елъязмалар җыентыгы»ннан, Ибне Баттута, Ибне Гарәбшаһ, Якут әл-Хәмәви хезмәтләреннән киң файдаланган. Әмма ул үзенең тарихи хезмәтләрендә шәркый галимнәрнең кайберләрен генә искә ала, калганнарын чыганак буларак күрсәтми.

Урыс чыганакларына өстенлек бирсә дә, Һади Атласи татар тарихчыларының үзенә кадәр язылган тарихи хезмәтләрен дә өйрәнгән. ***«Һади Атласи төрки-татарларның килеп чыгышы проблемаларына, аларның дәүләтчелеге үсешенә караган татар чыганакларының ул заманда булганнарын тулаем диярлек барлап чыга, – дип яза бу хакта тарихчы Алсу Мөхәммәтдинова. – Моннан тыш Шиһабеддин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Хәсәнгата Габәши хезмәтләрен өйрәнә. Галим тәүгеләрдән булып 1523 елгы Сәхибгәрәй хан ярлыгы, «Ханәкә-солтан» тарихи бәете кебек беренчел чыганакларны файдалана һәм фәнни әйләнешкә кертә».*** *(Алсу Мөхәммәтдинова. Һади Атласиның..., 16 бит.)*

Безнең фикеребезчә, үзенең тарихи хезмәтләрен, бигрәк тә «Себер тарихы»н язганда, Һади Атласига Әбелгазый Баһадур ханның «Шәҗәрәи төрек» һәм Хәсәнгата Габәшинең «Мөфассал тарих кауме төрки» нык тәэсир иткән булырга тиеш. Хәсәнгата казыйның тарихи фикерләре турында Атласи Катанов белән очрашканда да уңай яктан искә ала, әмма үз хезмәтләрендә аның исемен телгә алмый. Моңа тарихчы Сәлам Алишев та игътибар иткән:

***«Себер тарихы» тулысынча урыс тарихчыларының хезмәтләренә нигезләнеп язылган, – дип яза ул. – Авторның Ш.Мәрҗанигә, Әбелгазый Баһадур ханга һәм кайбер башка төрки, гарәп китапларына берничә урында искәрмә ясавы бу нәтиҗәне какшата алмый. Авторның «татар халкының тарихы юк» дигән сүзләрен китергән идек. Менә мондый сорау туа: нигә Һ.Атласи аңа кадәр басылып чыккан татар тарихларыннан файдаланмый? Аңа кадәр Гайнетдин Әхмәров 1909-1910 елларда Болгар һәм Казан тарихлары, Хәсәнгата Габәши 1909 елда борынгы төрки кавемнәр хакында китаплар бастыралар. Габәшинең китабында Себердә борынгыда булган әллә никадәр төрки шәһәрләрнең исемнәре язылган. Атласиның, бәлки, мөмкинлеге булмагандыр йә булмаса белми калгандыр. Шулай булса да, Атласиның бу китабы кирәк иде һәм аның әһәмияте зур булды. Ул татар халкын үзенең кардәш халкы – Себер татарлары белән таныштырды, күп төркиләрнең ватаны булган Себернең соңгы вакыттагы хәл-әхвәлен аңлатты».*** *(Сәлам Алишев. Татар тарихчылары. – Казан, 2006, 194 бит.)*

Ә бит Хәсәнгата Габәшинең төрки кавемнәр турында 1909 елда басылып чыккан бу китабы – энциклопедик хезмәт! Дөрес, ул дәреслек рәвешендә язылган, кыска-кыска бүлекләрдән тора, әмма биредә скифлар, һуннар, Туран иле, төрки-татар кавемнәр

турында шактый мәгълүмат алырга мөмкин. Һәм Атласи, һичшиксез, бу хезмәтне белгән. Хәсәнгата Габәшинең аңа кадәр дә 1897 елда – «Төрк ыруглары», ә 1899 елда «Мохтасар тарих каум төрки» китаплары басылып чыккан була. Безнең уебызча, Һади Атласи нәкъ менә Габәши хезмәтләрен укып-өйрәнеп Туран иленә – Себергә-Скифиягә килеп чыккан, төрки-татар тарихының никадәр бөеклеген аңлаган, үзе дә шушы теманы дәвам итеп, кулына каләм алган. Катанов белән булган әңгәмәсендә дә Атласи, аңа каршы төшеп, скиф-төрки мәсьәләсендә Габәши фикерен яклый, *«Скифларны төрекләр дию өчен Хәсәнгата казый дәлил әйтте. Скифларның төрекләр булуы бик ышанычлы тарихи дәлилләр илә шиксез булганлыктан, табигый, без үзебезнекен дөресләп сөйләдек»*, дип яза.

Әмма Һади Атласиның «Себер тарихы» үзенең бербөтен-монолит булуы, бары тик Себергә генә багышлануы һәм бай мәгълүматлы, хисчән булуы белән аерылып тора. Автор *«Язучыдан бер-ике сүз»* дип аталган кереш сүзендә үк бу китабын милләтебез өчен язуын ачыклап куя, тарихны өйрәнүгә зур бәя бирә. ***«Инсанны чын мәгънәсе илә инсан иткән гыйлемнәрнең беренчесе, һич шөбһәсез, тарих гыйлемедер,*** – дип яза ул. – ***Үзенең кем икәнен белмәгән инсан ничаклы хиссез исә, үз милләтенең тарихын белмәгән инсан да шул нисбәттә хиссездер. Тарих гыйлеме инсанда милләт хисе уятучы гыйлемнәрнең бердәнбере булганлыгы сәбәпле, алдынгы милләтләр үз тарихларына фәүкылгадә әһәмият биргәннәр вә һаман бирмәктәдер. Безнең бабаларыбыз булган төрек-татарлар борынгы заманнарда иң атаклы халыклардан булганлыклары сәбәпле, аларның тарихлары иң парлак тарихлар җөмләсеннәндер».***

«Себер тарихы»на кереш сүзендә Атласи милли тарихыбызның булмавына, дин әһелләренең моңа игътибар бирмәвенә зарлана. Бу урында дин әһелләрен яклап үз сүземне әйтәсем килә – татар тарихы буенча беренче күләмле хезмәтләрне Шиһабетдин Мәрҗани, Хәсәнгата Габәши, Ризаэддин Фәхреддин, Морад Рәмзи кебек дин әһелләре язды, Һади Атласи үзе дә мәдрәсәдә имамлыкка укыган һәм мәчеттә мулла булып эшләгән кеше бит! Ә менә ул заманда татар мәктәп-мәдрәсәләрендә милли тарихыбызның укытылмавы хак, аның дәреслекләре дә, укытучылары да, программасы да булмый. Һади Атласи үзенең тарихи хезмәтләрен менә шушы бушлыкны тутыру өчен дә яза, милли чыганаклар булмаганлыктан, рус галимнәре хезмәтләреннән файдалануын әйтә:

***«Мин үзем милли тарихыбызның юклыгына чын күңелемнән кайгыра идем,*** – дип яза ул. – ***Күз алдыбызда язарлык милли чыганаклар булмаганлыктан, ул тарихның вөҗүдкә киләчәгенә дә бик авыр ышана идем, ләкин төрле рус голәмәсе тарафыннан язылган тарихларны җентекләп өйрәнә башладыгым заманнан алып, мин татар тарихының вөҗүдкә киләчәгенә чын күңелемнән ышана бардым. Шушы ышану нәтиҗәсе буларак, тәвәккәллек илә татар тарихына караган нәрсәләрне язарга ният итеп эшкә керештем. Иң әүвәл буларак шушы Себер тарихын язарга керешеп, аның әүвәлге җилден яздым».***

Атласи «рус тарихчылары» дип язса да, аның «Себер тарихы»нда өлге булып алман Миллерның *«История Сибири»* хезмәте ята. Гигант хезмәт, ун ел буе бөтен Себерне иңләп, Төньяк Боз океанынннан Тын океанга хәтле араны узып, һәр халык, һәр кавем, һәр кала һәм сала турында җентекләп язылган китап. Әлбәттә, анда да, цензура кулы кагылу сәбәпле, идеологик төгәлсезлекләр бар, аларны Атласи да кабатларга мәҗбүр, әмма Миллер хезмәте дә, аның артыннан барган Атласи китабы да халыкка Себердә яшәгән төрки халыклар, беренче чиратта, татарлар турында бай мәгълүмат бирә. Габәши китабы кавемнәр тарихы булса, Атласи хезмәте – турыдан-туры Себер тарихы. Безнең өчен бигрәк тә хезмәтнең *«Төркиләр, Скифия, Туран, Себер»* дип аталган башлангыч бүлекчәсе кадерле, монда Һади Атласиның һәм тарихчы, һәм төркиче-туранчы буларак, дөнья тарихына карашы, фәнни концепциясе бирелгән. Әйе, Атласи төрки-татар халкының Ана-Ватаны Себер икәнлеген, заманында аның Скифия яки Туран иле дип аталуын, төрки-татарларның борынгы бабалары скифлар булуын ачыктан-ачык яза. Дөрес, аңа кадәр шундыйрак фикерләрне Хәсәнгата Габәши хезмәтләреннән дә укырга була иде, әмма Һади Атласи скифларны Себер белән бәйләп

карый һәм бу хакта зур ышаныч белән яза. Ул гына да түгел, әле моннан дүрт мең еллар элек Себердә – *«Тын океан илә Урал таулары, Төньяк котып океаны илә Хәзәр (Каспий) диңгезе араларында»* төрки-татар кавемнәр яшәвен, аларның *«кайчагында бөек дәүләтләр тәшкил итүләрен»* әйтә.

***«Димәк ки, юнан голәмәсенең Скифия дип атадыклары урыннар төрки халыкның утрагы булган Төркестан, ягъни иранилар тарафыннан Туран исеме бирелгән өлкәдер, – дип яза ул. – Тугрысы, Туран, Төркестан дип төркиләр илә утрак ителгән җирләргә әйтелгән кебек, борынгы юнанилар тарафыннан «Скифия» дип шушы төркиләр анда таралып утырган урыннарга әйтелгән. Димәк ки, Туран, Төркестан, Скифия сүзләре бер урынга бирелгән төрлечә исемнәрдер... Хәзерге Сибирия борынгы Скифиянең бер кисәге икәнчелеге мәгълүм буладыр... Туран исеме астына борынгыда хәзерге Сибирия тарафлары да кергән икәнчелеге бик ачык аңланадыр... Аңланадыр ки: ираниларның Туран дип атаган җирләре юнаниларның Скифия дип аталдыклары урыннардыр. Соңгыларның скиф атадыклары халыклар да төркиләрдер».***

Һади Атласи бик ачык итеп аңлатканча, фарсылар Себерне – Туран, дип, ә греклар – Скифия дип атаган, ә анда яшәүчеләр төрки-татарлар булган. Язмасыннан күренгәнчә, Атласи үзе Себерне Туран дип атау ягында, ул Әбелгазый Баһадур ханның да үз хезмәтендә Себерне бары тик Туран дип кенә атаганын әйтә. Бу, чыннан да, шулай. Төрки кавемнәрнең зур тарихын язган милләттәшебез Хәсәнгата Габәши дә үзенең хезмәтендә Себер сүзен телгә алмый, ә бары тик, Туран, арилар, скифлар, һуннар, төрки-татарлар һәм башка халыклар турында яза. Атласи фикеренчә, «себер» атамасын урыслар кушкан булырга тиеш, бу сүз «север» – «төньяк» мәгънәсен дә, татар башкаласы исемен дә, хәтта төрки-татар кавеме атамасын да аңлатырга мөмкин. Ни булса да, исем мәсьәләсе ачык кала һәм бу темага бәхәсләр бүгенге көнгә кадәр дәвам итә...

Атласи алга таба Себер тарихын Чыңгыз хан заманы белән дәвам итә, ул Төрки каганатлар чорына кагылып тормый. Чыңгыз ханны ул Себердә, хәзерге Чита өлкәсендә, Монголия чигендә, Онон елгасы буйларында туган, дип яза, әмма җәйләрен Алтай таулары тирәсендә дә яшәүләрен әйтә. Чыңгыз хан турында зур булмаган бүлектә Атласи аның туганнан алып үлгәнгә кадәр тарихын бирә, ул яулап алган хисапсыз илҗирләр турында яза. Атласи Чыңгыз ханга зур бәя бирә, аны *«Дөньяның иң атаклы сугышчыларыннан, Себер тарихын тәртипкә китерүче»*, дип атый.

***«Давая оценку Чингизхану, Х.Атласи видел в нём всемирно известную историческую личность, великого полководца, основателя могучего государства, выдающегося политика»,*** дип яза бу хакта бүгенге тарихчылар. *(А.Х.Мухаметдинова. Хади Атласи: общественный деятель и историк. – Казань, 2004, стр.71.)*

Себер тарихын язганда Атласи үз чоры өчен кул астында булган бик күп чыганакларны өйрәнгән, бигрәк тә тарихчылар Фишер, Небольсин, Миллер, Карамзин, Радлов, Татищев, Андриевич, Соловьёв, Ключевский, Буцинский, Словцов, Межов, Витзен хезмәтләренә, рус елъязмаларына, Брокгауз-Ефронның энциклопедик сүзлегенә, Мәрҗани, Әбелгазый, Габәши язмаларына нык игътибар иткән. Урыны-урыны белән ул башка авторларның тексты белән шулкадәр мавыгып киткән, моны хәтта тәрҗемә әсәр дип тә кабул итә башлыйсың. Шул мавыгу сәбәпле, Атласи рус тарихчыларының хаталарын да кабатларга мәҗбүр булган. Хәзер шуларның кайберләренә тукталып үтик.

Үзенең бу хезмәтендә Атласи кыргызларны (казах) бик күтәрә, бөтен Себердә аларны хуҗа кебек итеп күрсәтә. Шул ук вакытта үзенә үк каршы килеп, ул «***Сибирия урыслар тарафыннан яуланганчыга чаклы, ул тарафларда татар ханнарының падишаһлык иткәнлекләре тарих илә мәгълүм булган бер мәсьәләдер»,*** дип яза. Урыс елъязмачыларына ияреп, Атласи Тайбуганы Көнбатыш Себернең беренче ханы, дип атый, аны кыргыз ханының улы, ди. Болар да хата, чөнки Тайбуга Себернең беренче ханы түгел, милләте буенча да ул җирле татарлардан була. Татищев хезмәтләренә артык ышанып, Атласи, Казан алынганнан соң, татарлар арасында таркаулыкны, үзара каршылыкны ерткычлык дәрәҗәсенә күтәрә, бу да һич дөрес түгел. Себер ханы Ядегәрнең Явыз Иванны Казан алынуы белән котлавын һәм

Мәскәүгә ясак түләвен дә ул бөтен татарларның гаебе итеп күрсәтә, ул чактагы вазгыятькә дөрес бәя бирми.

***«Бу заманнарда татарлар арасында дуслык, мәхәббәт, туганлык, берлек кебек матур сыйфатларның һичберсе калмаенча күчеп китүләре сәбәпле, алар үз туганнарының канына һәм җанына сусаган ерткычлар булып әверелгәннәр иде»***, дип яза ул. Аерым кешеләрдә мондый сыйфатлар булса да, моны тулаем татарларга карата әйтергә ярамый. Онытмыйк, бу милләтнең кан эчендә үлем көтеп яткан еллары, илсез-җирсез, дәүләтсез калган иң фаҗигале чоры! Кара урманнарга качып, тау куышларына яшеренеп, сазлыкларда ятып, исән калу өчен җан тартышкан вакытлары... Рус тарихчылары безне шушындый яралы чакта да ерткыч итеп күрсәтергә теләгәннәр икән, алар артыннан безгә бу ялганны кабатларга ярамый. Шул ук Татищевка таянып, алга таба Атласи болай дип яза:

***«Русларның ул дәвердә кылган эшләренең һәрберсе милләт хисе, дин гайрәте илә кылынган файдалы эшләр булса да, киресенчә, татарларның һәрбер эше имансызлык илә вөҗдансызлык сәбәпле кылынган милли һәм дини җинаятьләр иде»,*** дип яза. Милләткә карата мондый тискәре бәя белән һич тә килешеп булмый. Нинди имансызлык, нинди вөҗдансызлык? Безме кемнеңдер илен басып алып, халкын суеп чыккан?! Безме башкаларны терелəй утларда яндырган, бозлы суларда батырып үтергән?! Урысларның бу эшләре үзләре өчен файдалы булса да, милләтебез өчен канлы фаҗига, мәңгелек яра бит! Атласиның аерым сатлык татарларга булган нәфрәте бөтен милләткә карата кара тамга булырга тиеш түгел иде, моны укучылар искә алсыннар иде.

Һади Атласиның «Себер тарихы» хезмәте, нигездә, урыс чыганакларына таянып язылса да, ул урыны-урыны белән рәсми фикергә каршы килә, моңа бүгенге татар тарихчылары да игътибар иткән. ***«Автор байтак урында үзенең фикерен үткәрергә тырышкан,*** – дип яза Сәлам Алишев. – ***Мәсәлән, ул Н.М.Карамзин һәм С.М.Соловьёвларның Ермакны Строгоновлар чакырып алдылар, Себергә поход әзерләп, анда җирләр басып алу өчен җибәрделәр, дигән карашларына каршы килеп, Ермак үзенең теләге белән, бандасын ияртеп, талау походы ясый, анда җирле халыкны талап, үзенчә яшәргә уйлаган, ди. Ермакны Күчем хан тырышлыгы белән үтерделәр. Ә Күчем хан үзе картаеп, ләкин бирешмичә каядыр китеп югалды, ди».*** *(Татар тарихчылары..., 194 бит.)*

Атласи Урал һәм Себерне үзләштерүдә урыс байлары Строгоновларның ролен шактый җентекле яза, ул шулай ук башкисәр Ермакның бу якларга ничек килеп чыгуын да дөрес тасвирлый. Әмма Атласиның Ермакны берничә урында *«Сибирияне алучы»* дип язуы белән һич тә килешеп булмый, чөнки Ермак Себер ханлыгының башкаласы Искәрне генә ала, аны да татарлар үзләре вакытлыча калдырып чыгалар. Атласи Ермакның Себергә сәфәре елларын да дөрес күрсәтмәгән, чөнки бу дата урыс чыганакларында да каршылыклы. Шулай ук бу сәфәрнең елларга сузылуы да дөрес түгел, ул су юлы буйлап берничә ай гына дәвам иткән, анда катнашучы казаклар саны да меңнәрчә булмаган. Хәер, Һади Атласи бу мәгълүматларны ул чактагы урыс чыганакларыннан алган, ә алар хәзер дә бик каршылыклы, очы-очка ялганып бетми.

Атласи язганча, Күчем хан башкаласыннан чыгып качмый, ә вәзирләре белән киңәш-табыш иткәннән соң, халкын алып, шәһәрне калдырып чыга, кешеләрне урыс мылтыгы астына куясы килми. Ермак бередә нибары өч ел була, Искәр тирәсендәге кала һәм салаларны талау һәм кыру белән шөгыльләнә, ике кыш рәттән Искәрдә чолганышта ятып, казаклары ачтан үлеп беткәч, Себердән чыгып качу юлларын эзли башлый. Әмма татарлар аңа котылырга ирек бирмиләр – Күчем хан яугирләре белән орышта башкисәр Ермак Вагай суы төбенә китә. Шулай ук Атласиның, Күчем хан чүлдә качып йөрде, казаклар өстенә сугыш белән бармады, дип язуы да урыс тарихчыларына артык ышанудан килеп чыккан ялгыш, чөнки Күчем хан һәм аның яугирләре Ермак бандитларына каршы туктаусыз сугышлар алып баралар, нәтиҗәдә, аларның исән калганнарын Себердән чыгып качарга мәҗбүр итәләр.

Патша тарихчысы Николай Карамзинның Ермакны күкләргә чөеп мактавыннан хисләнеп, Атласи да аңа башкисәр дип түгел, батыр дип бәя бирә, бәлки цензурадан үтү

өчен шулай язгандыр. ***«Бер уч иптәшләре илә олы мөселман ханлыгын басып алуга ирешкән Ермакның нинди гайрәт вә дәрт иясе булганлыгы үзлегеннән күренәдер,*** – дип яза ул. – ***Бу кебек эшләрне тормышка ашыру өчен ничаклы фидаилык вә ничаклы түземлелек кирәклеге һәрбер гакыл иясенә мәгълүмдер».*** Әйе, кешенең иленә вә өенә килеп, бу кадәр явызлыкны кылу өчен зур батырлык кирәкми, ерткыч башкисәр булу да җитә. Күчем хан һәм себер татарлары моны яхшы аңлаган һәм Ермак бандасы белән ахыргача сугышкан.

***«Тиңдәшсез дошман булган Ермакның үлүе, шулай ук калган казакларның да Искәрне ташлап Русиягә качулары татарлар өчен чиктән тыш шатлык булды»,*** дип яза Атласи үзе дә хезмәтенең *«Русларның Себердән качулары»* дип аталган бүлегендә. Ни булса да, Атласи үз белгәнен язган, үз фикерен дә әйтергә тырышкан. Ул Күчем ханга карата аерата бер хөрмәт белән карый, аның Чыңгыз хан нәселен дәвам итүче булуын да, урысның иң зур дошманы икәнлеген дә, үз иреге белән илен бирмәвен дә шактый дөрес тасвирлый. *«Урысларның Себерне икенче кат алулары»* дип аталган бүлектә Атласи, Ермак үлгәннән соң, 1585 һәм 1600 еллар арасында Күчем хан гаскәре һәм Мәскәүнең Себер өстенә ябырылган регуляр армиясе арасында барган канкойгыч сугышлар турында хәбәр итә.

***«Рус тарихчыларыннан кайсыларының әйтүенчә, Күчем хан руслар өчен гайрәтле, куркынычлы, арымый торган дошман иде. Себердә яуланган җирләрне имин итәр өчен, урысларга Күчем ханны бетермәк тиеш иде».*** Әйе, Күчем хан Мәскәүнең утлы корал белән янавына да, ярлыклар вәгъдә итеп алдавына да карамый, татар илен үз иреге белән дошманга бирми, тарихта андый хурлыклы эз калдырмый, 80 яшенә кадәр яу кырында сугышып үлә. Атласи үзенең язмасында Күчем ханның диненә, милләтенә, холык-фигыленә дә бәя биргән, аны бөтен яктан тасвирларга тырышкан.

***«Алтын Урда ханлыгына буйсынган халыклар арасында ислам дине таратып, аны ныгытырга тырышучы Үзбәк хан булган кебек, Себер ханлыгына караган халыклар арасына ислам таратучы, һич шөбһәсез, Күчем хандыр,*** – дип яза ул. – ***...Күчем ханның, Ядкәрләр кебек хиссез булмаенча, мөкаддәс уйлар иясе булуы үзе генә дә аны аерым бүлектә яд итүне таләп итәдер иде.»***

Әмма шул ук вакытта без Атласиның Күчем ханны кырт кисеп кыргыз-казакъ ясавын кабул итмибез, чөнки ул Чыңгыз хан нәселен дәвам итүче татар ханы булган, тарихта моны исбат итүче дәлилләр күп. Шулай ук Күчем ханның биләмәләрен Төмән-Тубыл белән генә чикләү дә тарихи дөреслеккә туры килми, чөнки Себер ханлыгының җирләре ике океан арасында җәйрәп яткан, Бараба далаларын, Татар сахрасын, Котып тарафларын үз эченә алган. Казакъ урдасы белән Себер ханлыгын тәңгәл кую да тарихи дөреслеккә туры килми. Шул ук вакытта Атласиның Күчем ханны *«Себер халкын агартучы»* дип атавы – бик уйлап һәм бу шәхесне озак өйрәнгәннән соң ясалган нәтиҗә.

***«Күчем хан Себер йортына хан булгач та, андагы халыкларны дине ислам илә нурландыру өчен иҗтиһадлар сарыф кыла башлады,*** – дип яза ул. – ***...Мондый олуг эшне ялгызы гына башкару бик кыен икәнен белгәч тә, Күчем хан атасы Мортазадан ярдәм сораган... Бәгъзе бер хәбәргә караганда, Күчем хан Казаннан да бик күп галимнәр китермеш».***

Әйе, ярыммәҗүси Себердә ислам динен таратырга Күчем ханга Бохара һәм Казан галимнәре зур ярдәм итә. Бу урында Атласи, урыс тарихчыларыннан тыш, Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин һәм Морат Рәмзи хезмәтләренә дә мөрәҗәгать итә. Әмма ул кайбер урыннарда Мәрҗани хәзрәтләре белән бәхәскә дә керә, бигрәк тә Күчем ханның соңгы көннәре турында язганда, ул Мәрҗани фикере белән килешми.

***«Бу хосуста Мәрҗани хәзрәтләре: «1003 елда мәмләкәтләренә Ермак ибне Тимофей атлы зат басып алып, шәһәрен дә сакларга хәле булмадыгыннан, Русия дәүләтенә бигъ итте вә Күчем хан кадерсез рәвештә башкорт арасына китеп вафат улды», дидер. Минем белүемчә, Мәрҗанинең Күчем хакында мәмләкәтен Русия дәүләтенә бигъ итте (сатты) диюе дә хата булдыгы кеби, башкорт арасына китеп вафат булды диюе дә хатадыр. Чөнки Күчем русларның иң чын дошманы***

***булып, үзенең соңгы сулышларына чаклы Русия дәүләте илә сугышуы бик күп ышанычлы ярлыклар илә исбатланганлыктан, аның мәмләкәтен Русиягә сатуын уйларга һич тә юл юктыр. Башкортлар ул заманнарда Русия кул астына кереп беткән булдыклары сәбәпле, Күчемнең башкортлар арасына качуын да уйларга мөмкин түгелдер»,*** дип яза ул «Себер тарихы»ның ахырында.

Хак сүзләр. Күчем хан соңгы сулышына кадәр иле, җире, дине, дәүләте өчен көрәшә, яу кырында батырларча үлә. Мәскәү патшалары аңа башта да, соңрак та кат-кат мөрәҗәгать итәләр, сугышмыйча буйсынган очракта, үзенә дә, нәселенә дә рәхәт тормыш вәгъдә итәләр. Әмма Себернең соңгы татар ханы мондый хурлыклы коллыкка бармый, ил-җирен, дәүләтен үз иреге белән дошманга бирми, тарихта сатлык дигән кара тап калдырмый... Нәкъ менә шуның өчен ул татар тарихчысы Һади Атласиның хөрмәтен һәм мәхәббәтен яулаган, милли каһарман булып, аның әсәрендә дә теркәлеп калган.

Әлбәттә, бу хезмәтендә Атласи бөтен Себер тормышын, андагы милләттәшләребез яшәешен яктыртуны үзенә максат итеп куймаган, бу – сугышлар тарихы, тагы бер татар дәүләтенең барлыкка килү һәм юкка чыгу тарихы. ***«В историческом труде «История Сибири» главным для Х.Атласи являлась проблема происхождения, эволюции и гибели татарского государства»***, дип яза бу хакта тарихчы Алсу Мөхәмәтдинова югарыда телгә алган хезмәтендә *(68 бит)*. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, кайбер фактик һәм идеологик хаталары булса да, Һади Атласиның «Себер тарихы» хезмәте 1969 елда Мәскәүдә басылып чыккан *«Советская историческая энциклопедия»*дә Себер ханлыгы буенча иң ышанычлы хезмәтләрнең берсе, дип аталган. Ә күренекле галим, академик В.В.Бартольд Атласиның тарихи хезмәтләрен *«татар патриоты»* күзлегеннән язылган әсәрләр, дип бәяли. Һади Атласиның тормыш юлы һәм иҗаты буенча фәнни монография авторы Алсу Мөхәмәтдинова аның «Себер тарихы» хезмәтен гомумтөрки тарих белән бәйләп карый.

***«Историю Сибири Х.Атласи прежде всего увязывал с историей тюрков,*** – дип яза ул. – ***Исследователь определил ключевое место в Сибирской истории именно тюркских народов. Начало всей татарской истории он рассматривал в масштабах Сибири в неразрывной связи с тюркским миром. Тем самым Хади Атласи отстаивал принцип целостности и единства тюрко-татарской истории».*** *(А.Х.Мухаметдинова. Хади Атласи..., стр.67.)*

Әйе, Һади Атласи «Себер тарихы» аша зур төрки дөньяга ишек ача, татар укучысын үзенең асыл тамырлары белән таныштыра. Ул бу әсәрендә үзен, чын мәгънәсендә, зур дәрәҗәдә төркиче-туранчы итеп күрсәтә. 1936-1937 елларда Казан төрмәләрендә сорау алган вакытларда да Атласи үзен төркиче-пантюркист дип атый, бөтен төрки халыкларны берләштерү фикереннән беркайчан да кире кайтмый, шушы идея өчен атып үтерелгән «Соңгы туранчы» булып тарихка кереп кала...

## Атласиның «Казан ханлыгы» хезмәте

Һади Атласиның «Сөембикә» китабы – 1913 елның ахырында, ә «Казан ханлыгы» 1914 елның башында Казанда басылып чыга. Кайбер галимнәрнең әйтүенчә, алар башта икесе бер хезмәт булган, аннан Атласи «Сөембикә»не аерып алып, аерым китап итеп чыгарган. Бу бик мөмкин хәл, чөнки «Сөембикә», чыннан да, үзе аерым зур тема, һәм аны «Казан ханлыгы» кысаларында гына ачып бетерү мөмкин түгел. Атласиның Казан ханбикәсе Сөембикәгә карата зур хөрмәте һәм мәхәббәте дә шуңа этәргән булуы бар. «Сөембикә» алданрак басылып чыкса да, без сүзебезне «Казан ханлыгы»ннан башларбыз, чөнки Казан тарихыннан башка Сөембикә язмышын да тулысынча ачып бирү мөмкин түгел.

Казан ханлыгы турында Атласига кадәр дә хезмәтләр булган, рус тарихчылары да, татарлар да бу теманы яктыртырга тырышканнар. Әмма Атласи алар арасында бар тарихи хезмәтләрне җыеп өйрәнеп, чагыштырып, анализлап, бер системага салучы буларак аерылып тора. ***«Заслуга Х.Атласи состоит в том, что ему на основе многочисленных источников, многие из которых впервые вводились в***

***научный оборот, удалось воссоздать более целостную картину исторического развития государственного образования татар»***, дип яза бу хакта галимнәр. *(А.Х.Мухаметдинова. Хади Атласи: общественный деятель и историк. – Казань, 2004, стр.81.)*

Әйткәнебезчә, Һади Атласи үзенең Казан тарихы турында фәнни хезмәтләренә бары тик Себер тарихын өйрәнгәннән соң гына тотынган. Башта аның өчен татарларның асыл тамырларын ачыклау мөһим булган, Себерне ул төрки-татарларның Ана-Ватаны, милли бишеге дип караган, татарларны скиф-һуннарның дәвамчысы итеп күргән. Бары тик шушы хакыйкатьне ачыклаганнан һәм шуңа ахыргача инанганнан соң гына, Атласи Казан тарихына тотынган. Әлбәттә, бу хезмәтендә дә ул урыс тарихчыларына нык таянган һәм аларга артык ышанган, шул сәбәпле милләт өчен шактый зарарлы гомумиләштерүләргә дә килгән, аларга алга таба тукталырбыз. Атласи шулай ук татар тарихчыларының үзенә кадәр язылган хезмәтләрен дә яхшы белгән булырга тиеш. Әйтик, шул ук Шиһабетдин Мәрҗанинең дә, Гайнетдин Әхмәревнең дә ул вакытта инде Казан тарихы турында саллы-саллы хезмәтләре басылып чыккан була. Дөрес, цензура пычагы аша үткән, нигездә, урыс чыганакларына таянып язылган бу әсәрләрдән татар файдасына идеологик яктан әллә ни табып булмый, әмма алар да фактик яктан шактый мәгълүмат бирә.

Замандашы буларак, Атласи бигрәк тә Гайнетдин Әхмәров әсәрләренә игътибар иткәне сизелә. «Казан тарихы»ның болгар чоры белән башланып китүе, аны Болгар белән бәйләргә тырышу да шул тәэсир сәбәпле булырга мөмкин. Атласиның «Казан ханлыгы» белән Гайнетдин Әхмәровның «Казан тарихы» әсәрләре төзелешләре белән дә охшаш – икесендә дә Казанга нигез салыну, ханнар тарихы, урыслар белән сугышлар һәм Казанның алынуы тасвирлана. Гайнетдин Әхмәровта Казан ханлыгында яшәгән башка милләтләр турында аерым бүлекләр бар, Атласида ул әсәрнең эчендә бирелгән. Гайнетдин Әхмәровта Сөембикә ханбикә турында аерым соңгы бүлек булса, Атласида Сөембикә аерым китап итеп бирелгән.

Әмма, әйткәнебезчә, Һади Атласи «Казан ханлыгы»н язганда, төп мәгълүмати нигез итеп урыс чыганакларын файдалана, ул шулай ук чит ил тарихчыларының хезмәтләренә дә мөрәҗәгать итә. Ул чор өчен чыганаклар базасы бик бай, Атласи шуларның һәрберсен җентекләп өйрәнеп чыккан, чагыштырган, әсәрләрендә файдаланган. Бу нисбәттән галимнең эшчәнлегенә, тырышлыгына таң калырлык, ул Казан тарихы буенча борынгы рус елъязмаларыннан алып үз замандашларының хезмәтләренә кадәр өйрәнгән һәм кулланган. Монда Никон, Воскресенская, Ермоловская, Симеон, Лаврентьев, Львов, Авраам, Тверь, Софийская елъязмаларына, Россия тарихчылары Вельяминов-Зернов, Карамзин, Татищев, Пинегин, Арцыбашев, Ашмарин, Миллер, Рычков, Новиков, Щербатов, чит ил галимнәре Рубрук, Герберштейн, Иовий, Олеарий, Плано Карпини, Лависс, Рамбо хезмәтләренә, шулай ук «Соловецкий список», «Казанская история», «История о взятии Казани», «Бархатная книга», «Царственная книга», «Русский хронограф», «Сказания князя Курбского» язмаларына, сүзлекләргә искәрмәләр ясалган. Ә бит бу хезмәтләрнең күпчелеге – иске славян хәрефләре белән кулдан язылган хезмәтләр. Атласи аларның барысын да күз нурларын түгеп укыган, юкка чыккан дәүләтебезнең тарихын урыс архивларыннан, чиркәү һәм монастырь базларыннан эзләргә мәҗбүр булган.

Бу хезмәтендә Атласи Шиһабетдин Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбәр фи әхвали Казан вә Болгар» («Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр»), Әбелгазый Баһадир ханның «Шәҗәрәи төрек», Рәшид-әд-диннең «Җамиг әт-тәварих», шулай ук «Тарихы мәдәният», Хисаметдин Мөслими хезмәтләренә, татар халык авыз иҗатына искәрмәләр ясый, әмма Гайнетдин Әхмәровның «Казан тарихы»н искә алмый. Гайнетдин Әхмәров инде 1911 елда ук үлгән була, һәм без бу ике тарихчының шәхси мөнәсәбәтләрен белмибез. Атласи шулай ук Ризаэддин Фәхреддиннең «Шура» журналында чыгып килгән татар ханнары турында язмаларын да яхшы белгән булырга тиеш.

Һади Атласи бу хезмәтендә Казан ханлыгының тарихын Олуг Мөхәммәдтән башлап җибәрә, яңа татар дәүләтенә Болгар ханнары түгел, ә Алтын Урда ханнары

нигез салганлыгын ассызыклый. ***«Безнең максатыбыз Казан ханлыгы исеме илә тарихта атаклы һәм дә мәркәзе Идел буендагы Казан булган ханлыкны язу булганлыгы өчен, сүзне шул ханлыкның барлыгына сәбәп булган Олуг Мөхәммәд ханнан башлыйсыбыз килә вә шуңа күрә теге Алтынбәк илә Галимбәкләрне зикер итәсебез килмидер»,*** дип яза ул. *(Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 1 том. – Казан, 2009, 268 бит.) Олуг Мөхәммәд ханнан соң «Мәхмүдәк хан, аннан соң – Хәлил, Ибраһим, Илһам, Мөхәммәдәмин, Габделләтыйф, Шәехгали, Сәхибгәрәй, Сафагәрәй, Җангали, Үтәмешгәрәй, Ядкәр»* ханнарның Казан дәүләте белән идарә итүләре тасвирлана. Гайнетдин Әхмәровта исә Себердән *Мамук* хан да өстәлгән, аерым бүлек багышламаса да, Казан ханнары исемлегенә ул *Алтынбәк* белән *Галимбәкне* дә керткән. Ризаэддин Фәхреддиннең «Казан ханнары» хезмәтендә исә татар ханнарның исемлеге Һади Атласиныкы белән туры килә.

Әйткәнебезчә, Атласиның «Казан ханлыгы»нда төп чыганак булып урыс елъязмалары тора, галим уңга-сулга карамыйча алар артыннан бара, бик сирәк кенә тукталып комментарийлар биреп куя. Әйе, әлеге китап – татар падишаһлары һәм урыс-татар орышлары турында. Әмма шуңа карамастан, бу хезмәттән Казан ханнарының тормышы да, милләт язмышы, дәүләт югалту фаҗигасе дә ачык күренә. Ул гына да түгел, Һади Атласи, урыс чыганакларына таянып булса да, Мәскәү белән Казан арасында барган дистәләрчә сугышларның сәбәбен ачкан, урысларның – талау, татарларның үз-үзләрен саклау өчен сугышуларын язган. Моңа бүгенге тарихчылар да игътибар иткән:

***«Х.Атласи… подчёркивал, что казанское правительство никогда не ставило перед собой захватнические цели. В большинстве случаев казанские походы являлись ответом на предшествующие русские вторжения или же действиями защитного характера… Исследователь стремился объективно воссоздать военные события. Он указывал на то, что русская сторона вела войны с целью обеспечения своих экономических интересов, с целью наживы. При этом он подчёркивал мысль о том, что казанские татары, противодействуя русским вторжениям, отстаивали тем самым свою независимость», дип яза алар.*** *(А.Х.Мухаметдинова. Хади Атласи…, стр.91.)*

Әйе, бу чыннан да шулай, һәм урысларның татарларга карата талау, басып алу сәясәте алып барганлыгын инде күп тарихчылар исбат итте. Һади Атласи да, урысларга бик каты бәрелмичә генә (бәлки, каты әйткән урыннарын патша цензурасы алып ташлагандыр), Мәскәүнең Казанга каршы алып барган сугышларын яулап алу сугышлары икәнлеген ача алган. Әмма урыс чыганакларына артык ышану Атласины көтелмәгән нәтиҗәләргә дә китергән. Моның иң әрнетеп һәм күзгә, күңелгә бәрелеп торганы – галим Казан ханлыгының җимерелүендә, татар дәүләтенең юкка чыгуында, нигездә, татарларның үзләрен гаепли. Бигрәк тә, ил белән идарә итүчеләрне, җитәкчелек тирәсендә булучыларны, милли һәм дини элитаны сатлык коткычылар, дип атый. Әлеге фикер Атласи хезмәтенең башыннан ахырына кадәр кара тамга булып бара, моның белән килешәсе килми, чөнки бу бөтен милләткә карата нахак бәя булып яңгырый. Моңа бүгенге татар тарихчылары да игътибар иткән.

***«Урыс чыганакларына, бигрәк тә елъязмаларга таянып, алардагы барлык сүзне дөрес дип хуплап, автор Казан мәмләкәтенең һәлакәте бары тик татарларның үзләренең сатлыкҗан, хыянәтчел булуыннан гына булган дип, җан өшеткеч «ачыш» ясый,*** – дип яза Сәлам Алишев. – ***«Алар үзара тату-тыныч яши алмадылар, һәрчак ызгыш-талаш белән мәшгуль иделәр, дәүләт һәм милләт мәнфәгатьләрен кайгыртмадылар, бары тик үз шәхси файдаларын гына уйладылар, байлык өчен куып бер-берсен саттылар, бүре бүре итен ашамаган хәлдә, казанлылар бер-берсен дә, Казанны да ашадылар, саттылар», – ди. Дәүләтнең мөстәкыйльлеген саклый алмаган өчен, татар халкын гаепләү әсәрнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузылган. Урыс елъязмаларында да бу шулай».*** *(Сәлам Алишев. Татар тарихчылары. – Казан, 2006, 196-197 битләр.)*

Тарихчы Сәлам Алишев каты әйткән, әмма хак әйткән. Мин дә Атласиның татарларга карата шулкадәр нәфрәтен аңлый алмыйм. Моны урыс тарихчыларына,

елъязмаларга артык нык ышану дип тә, цензура тәэсире дип тә аңлатырга мөмкин, әмма ниндидер шәхси сәбәп тә булуы бар. 1909 елны ул төрмәгә татарлар әлеге буенча утыра бит, аннан соң да матбугат битләрендә аерым дин әһелләре белән бәрелешләре булып тора, әмма болар, тарихи хезмәт язганда, милләтеңне хыянәттә гаепләү өчен сәбәп булып тора аламы? Юк, әлбәттә. Ни кызганыч, Казан алыну фаҗигасен, тарихчы буларак, ни Мәрҗани, ни Гайнетдин Әхмәров, ни Атласи ахыргача ачып бирә алмаган, алар, нигездә, урыс елъязмаларындагы фактларны гына сөйләп чыкканнар, дигән фикер кала. Аларның бөтен ялгыш-хаталарын, татарларның үзләрен гаепләп язып калдырган ялганнарын, шәрехләмичә генә, татарчага аударганнар.

Казан ханлыгы тарихын, татарларның милләт буларак бөеклеген, аның дәүләт югалту фаҗигасен беренче булып иң дөрес ачучы тарихчы – рус кешесе Михаил Георгиевич Худяков. Әгәр ул «Очерки по истории Казанского ханства» китабын патша заманында чыгарган булса, ул бу рәвештә дөнья күрмәс иде, урысларны, Мәскәүне гаепләгән бөтен урыннарын алып ташларга кушкан булырлар иде. Аның әлеге китабы 1923 елда, Казанда басылып чыга, ул вакытта патша заманындагы бөтен явызлыкларны ачарга һәм тәнкыйтьләргә рөхсәт ителә, большевиклар шулай итеп үзләренең нинди юл белән хакимияткә килүләрен акларга тырышалар. Ә Худяков шул форсаттан файдаланып, үзенең татарлар турында иң дөрес китабын чыгарып өлгерә... Хәер, бу китабы өчен җәза аны барыбер куып җитә – Михаил Худяковны, халык дошманы дип, 1936 елның декабрендә Ленинградта атып үтерәләр, ә Атласи ул вакытта Казан төрмәсендә хөкем карары көтеп ята...

Тагы Һади Атласиның «Казан ханлыгы» хезмәтенә кайтыйк, галимне аңларга тырышыйк. Әлбәттә, дәүләт кадәр дәүләтне югалту фаҗигасен ул да күңеленнән бик авыр кичергән, тарихның канлы тузаннарында казынып, моның сәбәпләрен табарга тырышкан. Кызып яки мавыгып китеп, ялгышуы да бар. Белүебезчә, ул бит «Казан ханлыгы»ның дәвамын язарга теләгән, бу турыда матбугатта да белдергән, әмма хезмәтенең дәвамы булмаган. Бәлки, язылып та, туктаусыз тентүләр һәм төрмәләр сәбәпле, кульязмасы юкка чыккандыр, бәлки, бу теманы кабат күтәрүнең вакытсыз икәнен аңлагандыр, бәлки, кирәген дә тапмагандыр... Хәзер тагы татар тарихчыларының Атласи хезмәтләрен бәяләвенә тукталыйк.

***«Атласи аерым мәсьәләләр буенча төрле авторларның хезмәтләренә, фикерләренә туктала,*** – дип дәвам итә Сәлам Алишев. – ***Кайвакыт аларга каршы килә, үзенең фикерен үткәрергә тырыша. Шул ук вакытта ул күп кенә очракларда чыганакларга анализ ясамый, елъязмаларда язылганны кабатлый. Мәсәлән, ул, «Казанская история» ялганына ышанып, 1552 елда Казанны алгач, йөз мең урыс әсире коткарылды, дип, шул фантастик әкиятне кабатлый. Патша Россиясенең ничә еллар буе Казан дәүләтен һәм Себерне яулап алу өчен сугышуына тиешле бәя бирә алмый. Ул русларны һәм аларның патшасы Иван IVне мактап, «алар милли хисле, ә татарлар хиссез иделәр» дип яза. Бу патшаның әшәкелекләрен күрми һәм әйтми. Бәлки, цензурадан курыккандыр, ул бит хөкүмәткә каршы язганы өчен төрмәдә утырып чыккан, эшен югалткан, полиция күзәтчелегендә яшәүче кеше иде».*** *(Сәлам Алишев. Татар тарихчылары..., 197-198 битләр.)*

Һади Атласиның иҗатын һәм тормышын фәнни яктан өйрәнгән галимә Алсу Мөхәмәтдинова да аның бу якларына игътибар иткән, әмма болар хакында тынычрак әйтергә тырышкан. Ул Атласиның татарларны гаепләп язуына җитди сәбәпләр булырга тиешлеген әйткән, төп сәбәп – дәүләтчелекне югалту фаҗигасе икәнлеген сиздергән. Галимә фикеренчә, Атласи татар ханзадәләренең һәм бәкләренең милләт өчен хәлиткеч вакытта халыкны милли һәм дини яктан бер байрак астына туплый алмауларына, адым саен бер-берләре өстеннән әләк белән Мәскәүгә йөгерүләренә әрнегән, аларны кискен гаепләгән, шуңа күрә, сатлыкҗаннар һәм хыянәтчеләр, дип атаган.

***«Учёный главной причиной падения Казанского государства называл отсутствие у татар единства и организованности, недостаточный уровень религиозного и национального чувства. Это проявилось в борьбе различных сил внутри татарского общества, ослаблявших это общество. Мыслитель критиковал самих же татар, считал их ответственными за гибель собственного***

***государства. Здесь Х.Атласи выполнял своеобразную роль судьи, не оправдывал поведение своих соплеменников какими-то объективными причинами».*** *(Алсу Мухаметдинова. Хади Атласи…, стр.109-110.)*

Әйе, Казан ханлыгының җимерелүендә Атласи дәүләтне саклый алмаган татарларның үзләрен гаепли. Әмма, безгә калса, бу – зур проблемага, милләтебез өчен җиһани фаҗигагә берьяклы гына караш. Михаил Худяков исә үзенең «Очерки по истории Казанского ханства» хезмәтендә Мәскәүнең Казанга, татарларга карата алып барган мәкерле сәясәтен бик дөрес ачып бирә алган, дәүләт бәйсезлеге юкка чыгуда татарларны гына гаепләп калдырмаган. Димәк, шулай да язып була?! Атласи Казанга ярдәм итмәгәннәре өчен төрки-ислам дәүләтләрен, бигрәк тә Төркияне һәм Кырымны да гаепли, ә Нугай Йортын, аның хуҗаларын «каткан, кара күңелле азгыннар», дип атый.

***«Нугайлар белән казанлылар бер дин, бер милләт кешеләре булсалар да, болар арасында туганлык, берлек юк иде, – дип яза ул. – Урыс князьләренең Казан ханлыгы белән шаяруларында, шулай ук Казан йорты өстенә туктаусыз баскынлык итүләрендә Казан олугларының зур катнашлары булган кеби, нугай мирзаларының да шулчаклы катнашлары булды».*** *(Һади Атласи. Сайланма әсәрләр. 1 том. – Казан, 2009, 432 бит.)*

1549 елда Нугай иле башлыкларының, урыслар белән берләшеп, Казан өстенә яу белән килергә әзерләнүләрен дә Атласи кискен гаепли. ***«Йосыф мирза Сөенбикәнең атасы, Үтәмешгәрәйнең бабасы була торып та, Казан ханлыгының шундый авыр көннәрендә кызы белән торынына ярдәм итмәве, Иван белән бергәләшеп Казан өстенә йөрергә әзерләнүе искитәрлек бер эш иде,*** – дип яза ул. – ***Дөнья яратылганнан бирле мондый эшне һичкем эшләгәне юк иде исә дә, Йосыфның каткан күңеле аны эшләүдән тартынмады».*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 438 бит.)*

Әйе, без никадәр төрки берлек турында сөйләсәк тә, тарихта аның киресе күренә, бу бигрәк тә Казан фаҗигасендә ачык чагыла. Төрки-мөселман булган Кырым белән Нугай иленең туктаусыз тарткалашулары, инде аларның Казанга үтеп кереп тә үз тәртипләрен, үз кешеләрен урнаштырырга тырышулары татарлар арасында зур каршылыклар тудырган һәм нәтиҗәдә дәүләт бәйсезлеген югалту белән тәмамланган. Һәркем Казан тәхетенә үз ханын куярга тырышкан, хакимияткә кырымлы яки нугайлы килгәнгә карап, аңа каршы булганнар кырып салынган; исән калганнар, ярдәм сорап, Мәскәүгә качкан. Менә шулай итеп, Казанның үз эчендә дә, тышында да аңа каршы көчләр – төрки-татар оппозициясе барлыкка килгән, һәм алар, иваннарга ияреп, Казан өстенә яу чапкан...

***«Урыслар өчен казанлыларның кырылулары күңелле эш булган кеби, Казан өстенә һөҗүм иткән татарларның кырылулары да күңелсез түгел иде. Этне эт белән талату ничаклы көлке булса, татарларның берсен икенчесеннән талату да урыслар өчен шулай ук көлке иде»,*** дип яза ул, әрнеп. *(Күрсәтелгән хезмәт, 454 бит.)*

Һади Атласи Казанга иң нык каршы эшләүче татарлар дип Булат бәкне, Хөршидә бикәне, Боерган сәедне атый, *«Булат Казанның иң азгын бәкләреннән булып, аңарда изге тойгыларың берсе дә юк иде. Бу кеше кайчагында йорт өчен тырышкалый иде исә дә, тискәреләнгән чагында йортны сатудан да тартынмыйдыр иде», «Хөршидә илә Булат Казанның иң зур коткычыларыннан вә шуның белән бәрабәр Сафагәрәй ханга дошман кешеләр...», «үзара орыш-талашлар белән кешелектән чыгып беткән казан татарлары»,* дип яза. Ибраһим ханның кызы Гәүһәршад-Хөршидә бикәгә Атласидан бигрәк тә нык «эләгә», ул аны *«тезгенсез хатын»* дип атый.

***«Бу кеше үзе хатын гына булса да, аның Казан ханлыгына иткән зарарлары мең ирнекеннән артык булды, – дип яза ул. – Казан ханлыгының бетүенә көч куйган кешеләр арасында бу хатын иң зур урын тотты. Бу тезгенсез хатын көчсез ханлыкның бетүе өчен батыр хезмәтче булды».*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 384 бит.)*

Каты әйткән! Хәер, Гәүһәршад-Хөршидә бикәнең Казан ханлыгында тоткан урыны турында әле бүген дә бәхәсләр бара, дөресен бер Аллаһ кына белә. Атласи Казан бәкләренең, татар түрәләренең үз дәүләтләренә каршы алып барган сәясәтләрен аңлый алмый, аңларга да теләми. Һәм аның бу сатлыкҗаннарга, хыянәтчеләргә биргән кискен

бәясе белән кайчагында килешмичә дә мөмкин түгел. Гомумән, бер Казан ханлыгында гына түгел, бөтен төрки дәүләтләрдә дөрес тышкы сәясәт булмаган икән, сугыша белгәннәр, ә тышкы дөньядан килгән мәкерне күрә һәм аңа җавап бирә белмәгәннәр, дигән фикергә киләсең. Киресенчә, күпчелек казан һәм нугай татар түрәләре, үз мәнфәгатьләре өчен илне дә, җирне дә, хәтта телне-динне дә сатканнар.

«Казан бәкләренең күбесе йорт өчен файдалы эш кылырга булдыра алмасалар да, ан***ың зарарына байтак эш кылырга хәлләреннән килә иде, – дип яза Атласи. – Боларда изге тойгылар булмаганлыгы сәбәпле, алар өчен йорт сату шалкан ашау кебек җиңел иде. Болар ил файдасын күзәтмиләр. Йорт өчен кайгырмыйлар, шуңа күрә үзләренең шәхси файдалары өчен ханлыкны корбан итүдән тартынмыйлар иде. Бер нәрсә өчен ханга күңелләре калса, урыс князьләренә хәбәр җибәрәләр, Казанны килеп алуларын алардан үтенәләр иде. Берәүгә ачулары кабарса, шуны, дингә һәм милләткә җинаять кылып булса да, басудан чиркәнмиләр иде. Казанның бу оеткысы бара торгач бигрәк тә көчәйде. Казанда шуның белән агуланмаган берәү дә юк иде. Бу оеткы соңгы буыннарга да мирас булып калды».*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 411-412 битләр.)*

Әлбәттә, бик авыр һәм кискен бәя, әмма монда дөреслек тә бар, бу милләтнең, бигрәк тә, җитәкчелекнең ни дәрәҗәдә эчтән череп таркалуын-диградацияне күрсәтә. Казан үзенең фаҗигасенә менә шундый хәлдә килеп керә, сукыр татар түрәләре Казан алынуны чираттагы тәхет алышыну итеп кенә күрәләр, әмма бу гасырларга сузылган һәм хәзер дә дәвам иткән коллык булып чыга... Һәм Атласи, халык арасыннан чыккан татар тарихчысы, бу фаҗигане бөтен йөрәге белән тоя, аңлый, сатлыкҗаннарны, хыянәтчеләрне каләме белән хөкем итә. Әйе, боларны белү – гыйбрәт өчен кирәк, милләт һәм дәүләт фаҗигасенә китергән ялгышлар кабатланмасын өчен кирәк, алга таба дөрес яшәү өчен кирәк...

Һади Атласи турында, «русларны мактаган, татарларны хурлаган» дип әйтүләр дә дөреслеккә туры килми, ул русларның үз-үзләрен тотышларын татарларның хәлфигыльләре белән чагыштырган, һәм бу чагыштыру татар файдасына түгел икәнен күрсәткән. Әлбәттә, монда аңа рус елъязмаларының да көчле тәэсире булган, әмма ул һәр ялганга ышанып утыра торган кеше түгел бит, Атласи нәтиҗәгә карап бәя биргән. Ә нәтиҗә безнең файдага түгел. Дин-милләт-дәүләт дигәндә, урысларның омтылышыргылышлары безгә караганда күпкә көчле булган, ул хәзер дә шулай. Моны, әлбәттә, Атласи да тойган һәм шундый нәтиҗә ясаган:

***«Шушы чакларда урыслар, христиан дине өчен бар көчләрен сарыф итеп, татарлар белән орышмакта һәм дә аларның князьләре үзләренең халкын сугышка өндәгәндә, христианлык исеменнән өндәмәктә исә дә, татар олуглары арасында ислам дине өчен тырышкан юк, аның файдасын күзәткән дә юк иде. Киресенчә, алар урыс князьләренең теләкләренә сукыр корал булып хезмәт итәләр, дин һәм мылтыкларын юк бәягә саталар иде. Боларның күңелләрендә туган кайгысы булмаенча, торганы корсак кайгысы гына иде. Менә шундыйларның берсе Хөршидә исемле әлеге тезгенсез хатын иде».*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 409 бит.)*

Әлбәттә, бу бәя бөтен милләткә кагылмый, һәм бу ямьсез сыйфатлар да бөтен татарга хас түгел. Урысларның Казан өстенә дистәләрчә тапкыр яу белән килүе билгеле, татар ирләре аларны батырларча кире кага, урысларны яу кырында сугышып җиңә, илдәүләт өчен сугышып үлә. Ә менә диннең зәгыйфьләнүе булган булырга мөмкин, чөнки иман көчле булса, туган туганга, мөселман мөселманга кул күтәрмәс иде. Ә Казан-Кырым-Нугай илләренең тарихында юк өчен дә үзара дошманлашу, бер-берләренең җанын кыю, бер-берләре өстеннән кяфергә әләк белән бару очраклары шактый бит! Әлбәттә, тәҗрибәле тарихчы Атласи да моны күргән, һәм мөселман, һәм төркиче буларак, моңа җаны әрнегән, бу хакта килер буыннарга да язып калдырырга теләгән. Һәм ул урыс белән татар арасындагы кайбер аерымлыкларны да күрсәтеп биргән.

***«Урыслар белән татарлар арасында дошманлык бик нык тамыр җәйгәнлеге сәбәпле, аны тиз генә бетерергә мөмкин түгел иде,*** – дип яза ул. – ***Урыслар татарларны чын күңеленнән яратмадыклары кеби, татарлар да урысларны яратмыйлар иде. Шулай булса да, ике арада аерма бар иде: урыслардан, татарларга***

***килеп, үз падишаһлыкларының серләрен сатучылар булмадыгы хәлдә, татар олуглары төркем-төркем Мәскәүгә киләләр, йортларының бөтен серләрен ачып бирәләр иде».*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 449 бит.)*

Ни кызганыч, бу бүген дә шулай бит! Казан түрәләре белән килешә алмаган күпме татар ир-егетләре Мәскәүдә сыену таптылар, шунда качып котылдылар. Аларны нинди дәүләт серләрен ачканнардыр дип әйтеп булмый, әмма татар буларак үз илендә урын тапмыйча, урыс җирендә сыену табулары Казан түрәләренең чал тарихтан гыйбрәт алмауларын күрсәтә. Һади Атласи Сөембикә ханбикәнең, Казан алынмас борын, Мәскәүгә әсир итеп бирелүен дә бик авыр кичергән. ***«Мондый вакыйганың охшашын тарих күрмәгән булса да, татар күңеле аны эшләүдән тартынмады. Борынгыдан бирле берсе икенчесенең канын агызып килгән, үзара талашуны йола иткән аталарның балаларына бу эш ят күренмәде», дип язып калдырган.*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 461 бит.)*

Әйе, Сөембикә ханбикә язмышы – ул милләт язмышы, аның әсирлеге – ул милләт әсирлеге, Сөембикә фаҗигасе – ул милләт фаҗигасе... Һәм аның аянычлы нәтиҗәсе – Казанның урыслар тарафыннан алынуы, татар дәүләтенең юкка чыгуы, гасырларга сузылган коллык... Урыс чыганакларына таянып булса да, Һади Атласи Казан алыну күренешен милләткә җиткерергә тырышкан:

***«Болар (урыслар) тизлек белән татарлар артыннан җитеп, аларны кыра башлады. Үлгән һәм яраланган кешеләр сансыз иде: Казан елгасыннан урманга чаклы булган болынлык, шулай ук урман кырыендагы аланнар, эчендәге яланнар – барысы да татар үлекләре белән тулган иде. Шәһәрнең эче белән тирәсе бигрәк тә куркынычлы булып, аның һәрбер урамнары үлекләр белән тулган, йөрүчеләр үлекләр өстеннән йөриләр иде. Хан йорты артындагы чокырлар, Казан елгасы буе, болынлык – барысы да татар үлекләре белән тулып, кайсыбер урыннарда өем-өем яталар иде. Татарлардан үлгән һәм яраланган кешеләрнең саны ачык билгеле булмаса да, аларның 10ар меңләп булганлыгы билгеле иде. Татарлардан үлүчеләр сансыз күп булдыгы кеби, тоткын ителүчеләр дә бик күп булды. Иван аларның хатын-кыз һәм яшь балаларын тере калдырырга боерып, эшкә ярарлык ирләрнең барчасын үтерергә боерды. Тере калдырылганнары урыс гаскәренә өләшенеп, аларның һәрберсенә диярлек берәр тоткын тигән иде. Шулай итеп, Казан алынды, ханы тоткын ителде, Казанның ялавы да урыслар кулына төште. Атаклы Казан ханлыгының хуҗасы урыслар булып калды. Урысларның борынгыдан бирле дошманы булып килгән ханлыкның бетүе алар өчен сөйләп бетергесез шатлык булды».*** *(Күрсәтелгән хезмәт, 549 бит.)*

Әйе, тарих ул – гыйбрәт, тарих ул – сабак, тарих ул ачы үкенечләрдән һәм ялгышлардан да тора... Һади Атласиның «Казан ханлыгы» әсәре – моның ачык мисалы. Әйе, кабул итүе авыр, әмма бу хәлләр татар тарихына канлы тамгалар белән язылган, алардан ваз кичеп булмый. Әйе, тәкъдир безгә явыз күршеләрне биргән, бездә алар мәкеренә каршы торырлык мәкер булмаган, бар усаллык үзара ызгышларга, бет ваклыгына киткән... Дәүләт төзи белгән татар ирләренең аны тотарлык җиһани сәясәтләре булмаган, дөнья гел шулай барыр дип уйлаганнар. Бу сәяси сукырлыкның нәтиҗәсе дәүләтнең явыз күршеләр тарафыннан яулап алынуы, милләтнең аларга кол булуы белән тәмамланган. Татар тарихчысы Атласи шул хакта кисәткән, шул хакта килер буыннарга язып калдырган...

**Фәүзия БӘЙРӘМОВА**

*(Дәвамы алдагы саннарда.)*

# АБ-225

ОЧЕРК

Минем снайперлар ротасына яңа гына килгән көннәремнең берсе иде. Кичке тикшерүдән соң рота командиры лейтенант Буров:

– Иртәгә АБ-225кә багышланган кичә булачак, әзерләнегез, иптәшләр, – диде. Янымда басып торган иптәшләр һәммәсе бер авыздан:

– Бик яхшы, була ул. Без һөнәрне күрсәтербез, – дип җавап бирделәр.

Димәк, кичә булачак. Нинди көн соң иртәгә? 23 июль. Нәрсә соң ул АБ-225? Һөнәрне күрсәтегез, хәзерләнегез, – ди лейтенант. Димәк, кичә кызыклы вакыйгаларга бай булачак. Кичәнең артистлары да минем янда ук басып торалар. Шулай да ни өчен соң кичә АБ-225кә багышлана? Полкның да, дивизиянең дә номеры алай түгел.

Гомумән, мине кызыксынулы борчу биләп алды. Иптәшләрдән бу санның һәм кичәнең серен сорыйм, ә алар, тирән сер саклаган кыяфәттә, хәйләкәр елмаялар гына.

– Әле син белмисеңмени? Алайса күрерсең, кызык ул.

Минем белән беренче көнне үк танышып өлгергән татар егете Абдуллин да, кара кашларын сикертеп:

– Ашыкма, якташ, иртәгә күрерсең, – дип шаяртып кына җавап бирде.

Ә икенче көнне иптәшләр хәзерләнә үк башладылар, һәркем төймәсен ялтырата, итекләр чистарта. Абдуллин әллә кайчан итеген дә, төймәләрен дә чистартып өлгергән, ак якачыгы аңа аеруча матурлык биреп тора. Ул ыспай гына йөри. Гармунчы егет баянны ыңгыраштыра, бер төркем егетләр аңа кушылып яңа бер көйне өйрәнәләр. Музыка тавышы күңелләрне кузгата, солдатны казармалардан тышка, кояш янына чакыра кебек, көйне озак итеп тыңлыйсы килә, уйлар еракка, авыл урамына, сабан туенда кызларны биетеп утырган чакларга китә...

Димәк, бүген концерт була. Мин дә, итекнең «җанын алганчы» сукно белән ышкып, кояш нурлары итеккә төшкән чакта туры почмак ясап, икенче бер караңгы урынга шәүләсен җибәрерлек иттем. Көтеп йөрим. Биеп ташларга да ният юк түгел. Югарыдан кунаклар да килергә тиешлеген ишеттем.

Көтелмәгән минутлар килеп җитте, без ял иткән район үзәгенең клубында кичә башланды. Мин ни күрәм? Президиумда Абдуллин да утыра, ниндидер полковник аның белән нәрсә турындадыр сөйләшә, алар көлешәләр. Ә стенада Абдуллинның рәсеме.

Безнең ротаның командиры кичәне ача һәм һәркемгә ишетелерлек итеп:

– Данлыклы снайперыбыз гвардияче өлкән сержант Абдуллин Бәхетгәрәйнең 225 немецны үтерүенә һәм аның икенче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләнүенә багышланган кичәне ачык дип саныйм, иптәшләр, – диде.

Залда «ура» тавышлары һәм: «рәхмәт сиңа, батыр Абдуллин». «Батыр снайперга кайнар сәлам!» – дигән сүзләр яңгырады.

Абдуллинның сугышчан дуслары, бер-бер артлы сүз алып, аны тәбрик иттеләр һәм котладылар. Мин дә, серле санның ачылуын күреп, якташымны тәбрик иттем, уңыш теләдем.

Билгесез полковник Абдуллинны Икенче дәрәҗә Дан ордены белән бүләкләү турындагы приказны укыды һәм залдагы кул чабулар, тәбрик тавышлары астында үз кулы белән орденны атаклы снайперның күкрәгенә кадады. Абдуллин, полковникның кулын кысып:

– Рәхмәт бөек ватаныма, бу соңгы орден булмас, – дип, елмаеп җавап бирде.

Аның сүзләре тагын залга ыргытылган девиз булып яңгырадылар, залдагылар аны тагын алкышладылар. Абдуллинның күкрәгендә балкыган Кызыл Байрак, Кызыл Йолдыз, Өченче дәрәҗә Дан орденнары һәм «Батырлык өчен», «Сталинград оборонасы өчен» медальләре янында тагын бер орден артты. Аның күкрәгендә – сугышчан юлы. «Гвардия» һәм «Отличный снайпер» значоклары, яралану билгеләре...

Абдуллин үзе чибәр генә егет. Урта буйлы, калку күкрәкле, кара бөдрә чәчле. Үткен шомырт кара күзләре өстендәге кыйгач, кара кашларын сагынып җырлаган кызлар аз түгелдер.

Абдуллин аяк өстендә, елмаеп залга карый, уң кулын күтәреп, үзен тәбрикләүчеләргә рәхмәт белдерә.

Менә аның тавышы залны яңгыратты:

– Сталинград өчен каты көрәшләр башланган вакытта мин, снайперлар мәктәбен тәмамлап, фронтка килдем. Безнең командир, миңа снайперлар винтовкасын биреп:

– Кара аны, иптәш Абдуллин, винтовканың сериясе синең инициалга бик килешле АБ, саны – 225, сиңа тик 225 немецны үтереп инициал янына өстәргә генә кала, – диде. Бу сүзләр мине, чыннан да, ашкындырдылар, беренче көнне мин өч немецны үтердем, икенче «ау»да тагын биш немец дөмекте. Янган танк эчендә өч көнгә сузылган «авымда» безнең якка үрмәләгән немецларны чүпләп яттым. Тик санбатка алып барган чакта гына, өч көндә 28 немецны үтерүемне исәпләп, яра газапларын онытып, чын күңелемнән шатландым. Кыскасы, түбәндәгечә: Сталинград далаларында – 61 немец, Орёл өлкәсендә – 114, Белоруссиядә – 38, Польшада – 12.

Ничек сугышканымны күрдегез, арагызда үстем. Бирелгән бурычны намус белән үтәү өчен тырышуым, Ватан алдында үземне җаваплы сизүем нәтиҗәсендә, илемнең хөрмәтләвенә ирештем, моның өчен мине үстергән Ватаным, Бөек Сталинга рәхмәт! Һәрвакыт миндә шушы АБ серияле, саны 225ле винтовка булды, һәрвакыт АБ инициаллы снайпер охотага йөрде һәм 225не тигезләде.

Залда күңелле көлү, алкышлар.

Мин дә 225нең серен тәмам аңладым. Кичә бик күңелле үтте, сынатмаска тырышып, кичәдә бик яхшылап биеп тә ташладым. Казармага мин Абдуллин белән бергә кайттым.

– Дус булып йөрисең тагын, ә миңа моңа чаклы сөйләгәнең дә юк иде, – диюемә, ул шаркылдап көлде:

– Мактанып булмый инде ул, үзең кызыксынып сорамагач, – диде.

Мин, үземнең гаепле булуымны сизеп:

– Мин каян белим синең бөтен фронтка данлыклы булуыңны, – дип куйдым.

***

Кайчандыр Минзәлә районында гади колхозчы булып эшләп йөргән Татарстан егете, хәзер Висла елгасын узып, Польша җирендә сугышчан юлын дәвам итә.

Аның винтовкасы 225 нче номерлы булып калса да, үтерелгән немецлар саны күптән үк артып китте инде.

Килер көннәр, сугышып үткән юллары аша Абдуллин сөекле Идел буена ашыгыр. Аны поляклар озатып:

– Безне азат итүче ул, – диярләр. Белорус халкы аны:

– Таныш егет, безнең герой ул, – дип ихтирамлап озатып калыр.

Орёл җирендә ул үзе узган җирләрнең «үзе куганын» тагын татып, халыкның рәхмәтен алыр. Сталинград урамнары аша горур атлап үтәр, Сталинград халкы аңа хөрмәт белән карар.

Татарстан аны олылап каршы алыр, түрдәге иң кадерле урынын күрсәтер, сыен-хөрмәтен куяр, әнкәсе, ике күзен талдырып көткән бердәнбер улын каршына утыртып, туйганчы карар һәм:

– Я, улым, сөйлә, ниләр күрдең, ничек сугыштың? – дигәч, Бәхетгәрәй шушы гади татар егетенә багышланган шатлыклы кичә турында да сөйләр.

**Зәкәрия АХМЕРОВ.**
*«Совет әдәбияты», 1944 ел, №10.*

## Укучы фикере

«Казан утлары» журналын мин үзем инде бик күптәннән укыйм. Гомер буе фермада сыер саудым, эшләгәндә дә, хәзер ялга чыккач та журналдан аерылганым булмады. Беркайчан да бәясеннән куркып тормыйм, ул бит елга унике китап булып килеп тора! Һәр санын җыеп барам, күп кеше миннән алып укый. Ике улым хәзер Казанда яши, авылга кайткач, алар да кич, бала чактагы кебек, идәнгә ятып, аерыла алмыйча укыйлар. Үзләре, көлеп: «Карале, әни, Интернетсыз да торып була икән бит, искә дә керми», – диешәләр.

Менә журналның соңгы, 7нче санын да бик яраттык. Наилә Харисованың «Эссе җәйнең ун көне» дигән әсәрен бер утыруда диярлек укып чыктым. Корылык бик куркыныч нәрсә, үзебездә дә үләннәр саргаеп беткән иде. Ярый әле соңгы араларда бераз яңгыр яуды. Бу әсәр йөрәктән чыгып язылган, андагы проблемалар авыл кешесенә бик таныш.

Әхтәм Зариповның «Әманәт» дигән повесте да бик әсәрләндерде. Хаҗда мин бер генә проблема да булмый торгандыр дип уйлый идем... Әсәрне укыганда, үземне шунда йөргәндәй хис иттем, бик мавыктыргыч язылган.

Журналны бер хәрефен, бер өтерен төшереп калдырмыйча укыйм, соңгы елларда һәр саны берсеннән-берсе матуррак, баерак булып чыга, шигырьләрне дә бик яратам. «Яңа килгән журналның исләренә тиклем тәмле бит аның», дим мин. Ай саен күрешеп торырга язсын!

**Люция ӘХМӘТГАЛИЕВА.**
*Актаныш районы Усы авылы*

# БӘЛӘКӘЙ МӘСГУТ*

Миңа бүген – 86. Байтак гомер яшәлгән. Үткәннәрне уйлап утырам.

Мин туган ягыма бөтен җаным-тәнем, сулышым белән береккәнмен икән. Озак кайтмыйча торсам, кайтасым килеп интегәм, кайтсам – китәсем килми йөрим. Күңелемдә гел җыр, гел моң. Андагы таулар мине һаман хәтерлиләр кебек; инешләре, чишмәләре мине күргәч челтерәбрәк агалар төсле; җилләре дә шаярыбрак, назлабрак исәләр сыман; урманнары да шаулабрак куялар – шулай сәламлиләр микән әллә үземне?.. Еш кайтам туган якка, кайтмыйча һич түзә алмыйм. Малай чакта йөгереп узган сукмаклардан атлыйм, тыкрыкларга керәм, картайган таныш каеннарны кочаклап торам: иркәлим, иркәләнәм. Киткәндә моңсуланып, инде кабат күрешмәбез дигән сыман озаталар бит алар.

*Туган ягым каеннары калалар инде,*
*Озатыша баралар инде.*
*Йөрәгемдә яфраклар яралар инде.*
*Сагышларга салалар инде...*

Зиратларда йөрим. Әнием янында утырам. Картәти, картәни белән сөйләшәм. Алар күптән бакыйлыкта булсалар да, минем менә монда – күкрәк эчемдә... Йөрәгем әрни... Их, кешечә яшәтеп булмады үзләрен!.. Бала идем бит, малай гына идем... Гомер буе рәхәт күрмәделәр, дөресрәге, күрсәтмәде аларга ул вакыттагы тормыш дигән нәрсә. Картәтинең дә башы сөргендә черегән иде, ярый әле әти, үзенең тормышын куркыныч астына куеп, бабакаемның гаепсез икәнлеген исбатлап, коткарып калган. Ә үзенең, әүзенең башы таш ватудан арынмаган. Мин аны хәтерләмим дә. Әни, бәгырькәем, мине берүзе үстереп азапланды, җәфаланды. Ләкин мин аның беркайчан да зарланганын ишетмәдем. Күз яшьләрен дә бер генә мәртәбә күрдем, бәлки, башка вакыттагысын күрсәтмәгәндер.

Тормышыбызның авырлыгы еламаслык түгел иде...

## Кием урлату

Миңа ул вакытта алты яшь чамасы булгандыр. Әни миңа базарданмы, кибеттәнме шунда, моряк киеме алып кайтты. Якалары да бар, башка кияргә бескозыркасы да. Әй, сөенгәнемне белсәгез! Тизрәк киеп чыктым да барак буйлап йөрим, күрсеннәр, янәмәсе. Яныма малайлар җыелды. Мине тотып карыйлар, әйләндерәләр, чеметәләр. Күзләремдә горурлык чаткысы, ә аларныкында – көнчелек. Әһә, күрдегезме инде, мин, сез уйлаганча, бик үк ярлы баласы түгел. Беләмме-белмимме, моряк булып йөреп күрсәтәм боларга. Байтак шулай малайларны кызыктырып маташканнан соң, Мулянка елгасына барып су коенырга булдык. Җәй. Барыбыз да чишендек тә әй чумабыз, әй йөзәбез, әй су чәчрәтешәбез. Шулай итеп, дөньябызны онытып, рәхәтләнеп коендык. Мин арттырыбрак та коендым әле. Инде кайбер малайлар күптән судан чыгып, киенеп, кайсы кайда югалдылар, ә мин һаман суда. Ахыр чиктә, җитәр дип, мин дә чыктым. Эзлим, киемнәрем юк. Кемнән сорарга белмим, малайлар да күренми. Аңладым,

* Мәсгут Габдрахман улы Имашев – мәдәният эшлеклесе, педагог, күренекле татар композиторы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. 1930 елның 5 июлендә Пермь өлкәсе Барда районының Каенавыл дигән авылында дөньяга килгән. «Саубуллашу вальсы», «Кыр казлары артыннан», «Туган ягым каеннары», «Кукмара» кебек музыка әсәрләре татар җыр сәнгатенең алтын фондына кергән. Казанда яши.

кемдер чәлдергән! Күлмәксез, ыштансыз кайтып киттем. Баракка кермәдем, койма артына постым, оят бит, ничек кеше күзенә күренәсең?.. Чүгәләп, кычыткан арасында утырам. Эштән кайткач, әни белән күршеләребез барак тирәсендә кычкырып, мине эзләп йөри башладылар. Эшдәшмим. Гел шулай утырып булмый бит инде... Беткән баш беткән, чыктым мин кычыткан арасыннан. Шуннан соң өйгә алып кереп кыйнаган иде әни. Гомерендә бер мәртәбә елый-елый кул салды миңа әнием, бәгърем. Аңа бу киемне табу бик авыр булгандыр, күрәсең. Ә мин шул көнне үк югалтып кайттым!

## Әни, абый, картәти

Миңа тугыз яшь тулган көннәр иде, ягъни июльдә бу. Әнине хастаханәгә салдылар. Табиблар картәтигә: «Мондый авыруга медицинаның көче җитми. Кызыгызны авылыгызга алып кайтыгыз, анда һава килешер», – дип әйткәннәр. Без, картәти, әнинең сеңлесе Фәридә апа һәм мин әнине пароход белән алып кайттык. Август аенда әни җан бирде.

Авылда әниемнең энесе Тәүфикъ абый бар иде. Ул мине тәрбиягә алды. Моның өчен документлар тутырдылар. Аның кул астында рәхәт яшәдек, мул тормышта дисәк тә була. Чөнки ул колхозда тракторчы булып эшләде. Аннан соң ул елларда иген дә әйбәт уңды. Мин икенче класска, без яшәгән Чириз авылыннан ике чакрымдагы Иске Чат мәктәбенә укырга йөри башладым. Безнең авылда ун гына йорт булу сәбәпле, анда мәктәп юк, ә Иске Чат зуррак авыл, шуңа күрә дүртьеллык мәктәбе дә, авыл советы да бар иде. Без менә икенче, өченче, дүртенче классларны шул ике араны көн саен йөреп, өч-дүрт бала укыдык.

Ике елдан соң Тәүфикъ абыемны армиягә алдылар. Май ае иде. Хаты килде. Пермь өлкәсенең төньягындагы Кудымкар дигән җирдә хезмәт итә икән. Агач кисәбез, дигән. Трудармия инде. Аның бер күзенә ак төшкән иде. Бераз зәгыйфьрәк кешеләрне шундый армиягә алалар бит.

Картәтием:

– Бәтәч, бу бит безне сөргән җиргә барган, шунда интегеп кайттык бит без, мин беләм ул төшләрне, улымны күрергә барам, – диде.

– Минем яраткан абыем бит ул, әти-әни урынына калган абый, картәти, мин дә барам, – дим.

Бездән кырык чакрым баргач, Кама елгасы янында Оса дигән шәһәр бар. Анда пристань. Барда районының зур дөнья белән элемтәсе – Пермь, Казан, Мәскәүләргә бару өчен шул бердәнбер юл иде ул елларда.

Картәти көне буе юлга ризык әзерләп йөрде. Иртән иртүк менә шул Осага киттек картәти белән. Кайда атка утырып, кайда җәяү, кайда ничек... Осага барып җиткәндә, кояш байый иде инде. Туп-туры кассага бардык. Кассир:

– Бүген бөтен пароходлар китеп бетте югарыга, иртәгә килерсез, билет та булыр, китәрсез дә, – ди.

Картәти:

– Улым, бүген өлгереп булмады, моннан өч кенә километр ераклыкта, шәһәрдә, Александр исемле таныш дустым яши, әйдә, шунда кереп куныйк та иртән пристаньга төшәрбез, – диде.

Киттек. Тиз таптык аларны. Үзләре янында зур, җиткән кызлары да бар икән. Кич буе кунак булдык. Ике бабай сөйләшеп туя алмыйлар, ә мин әлеге апа белән уйныйм.

Иртүк торасы бар – йокларга яттык. Урынны картәти белән миңа идәнгә җәеп бирделәр. Арылгандыр инде, тиз йоклап киттек, яткач ук.

Нәрсәдәндер борчылып уянып китсәм, таң аткан, картәти, Александр бабай, аның хатыны, кызлары почмактагы кара тәлинкә радионы тыңлыйлар.

«Вероломное нападение на Советский Союз...»

Менә шунда ишеттем: сугыш башланган! Мин, сикереп торып, картәтине барып кочакладым да тыңлап торам. Русча аңлыйм. Радиодан: «Приказ Главнокомандования... призыв всех запасников...» Армиягә алалар инде. Туган елларын әйтеп баралар. Картәти бармагын бөкләп тора... «Бәйрәмхуҗам китте, ди, Мөхлисем китте, ди, – аннан

соң миңа борылды да... – Тәуфигыбыз сугыштадыр инде. Ул бит армиядә. Бүген үк сугыштадыр, балам, янына барып йөрмәбез, әйдә, кире кайтып китик, улым», – ди.

Ничек кайтканыбызны хәтерләмим. Шуннан сугыш мәшәкатьләре башланды.

Тәүфикъ абый сугышның беренче көннәреннән үк алгы сызыкка эләгеп, Мәскәү тирәсендә хәбәрсез югалды. Дөресрәге, үлгән инде. Аның соңгы хәбәре күршебез Шәрифулла абыйдан килде. Шәрифулла абый Тәүфикъ абыйның Смоленск ягына таба атакага барганын күргән. Ул чакта аның үзенең аягына ядрә тиеп, үкчәсен алып киткән була. Санитарлар яралыны кирегә өстериләр икән. Шулчак, дулкын сыман, икенче атака күтәрелә. Күрә, Тәүфикъ абый йөгерә. Ул: «Шәрифулла, исән кайтсаң, безнекеләргә сәлам әйт», – дип кычкырып үтә. Тәүфикъ абыйның соңгы сүзләре бу.

## Бүреләр



Без ике чакрым ераклыктагы авылга йөреп укыдык дип әйткән идем бит. Кышын юлыбызга бүреләр чыга торган иде. Ул елларда алар бик аздылар. Хәтта авылга килеп сарыкларны буып киткән чаклары күп булды. Бездә сарыкларны берәү дә утарга япмый, ишектә куналар, урамда да калгалыйлар. Бер мәртәбә бүре көтүе килеп 20ләп сарыкны харап итеп киткән иде. Ашамаганнар, бугазларын чәйнәгәннәр...

Безнең авылда юкәдән кап сугалар. Менә шул кап сугудан юкә кабыгы коела, шуннан, җыелышып, аркан сыман әйбер ишәбез. Аркан дип тә әйтеп булмый аны, чөнки ул начар сыйфатлы юкәдән эшләнә – жгут ясыйбыз. Аны өчәр, дүртәр метрлы итеп эшлиләр, шуның башына ут төртәбез дә янарга ирек бирмибез, көйрәтеп кенә тотып барабыз. Уттан бүре бик курка. Кайчагында юлда безне көтеп өчәр бүре утыра, ачлар, тешләрен ыржайтып торалар. Утны уйнатып барабыз, күрүгә бүреләр кирегә чабалар, ә без мәктәпкә баруыбызны дәвам итәбез. Куркыныч, ләкин яшәргә кирәк бит.

Кайбер балаларның әни-әниләре, безне озатып йөрү өчен, тавышланып колхоздан ат сорыйлар иде. Алай да, күп вакытны йә ат авырый, йә йөртүчесе юк, йә чанасы ватык. Без тагын җәяү. Бүреләр күбесенчә безне дәрескә барганда, иртәнге якта көтеп торалар иде.

Аюлар очрамады. Безгә сөйләделәр генә. Өйләрендә аю тиресен идәнгә, яки стенага элгән кешеләр күргәнем булды. Әйтүләренчә, аю кешене интектереп үтерә икән. Берәү шулай аюга очраган. Галәмәт зур аю ди. Әлеге кеше моның астында калган. Тәпәли дә тәпәли икән чатан тәпи моны. Инде үлгәндер дип уйлаганда, теге кеше каяндыр көч табып, шактый озын җәпле пычагын чыгарып, аюның корсагын ярып җибәрә һәм үзе тиз генә астыннан кырыйга чыгып баса. Шулай итеп, исән кала.


## Туңдырылган аш

Үскәч кемдер булу хыялы юк иде миндә. Картәни генә гел кабатлап торды: «Балам, әниең укытырга кушты, укысаң, инженер булырсың, кәтлит ашарсың, укы, яме!» – ди торган иде. Бишенче класска күчкәч, инде үземнең туган авыл – Каенавылдагы җидееллык мәктәпкә бардым. Картәти шунда җибәрде. Шунда квартир сөйләштеләр, шунда укыдым. Әлеге дә баягы һаман сугыш еллары бу.

Җәй буе урман җимешләре җыеп, азык запасын тулыландыра идем. Кайчагында колхоз эшенә барып тыгылырга туры килгәли иде: көлтә җыю, печән әзерләүләр... Черек бәрәңгедән пешергән көлчәләрне дә күп ашадык. Аннан соң безнең басуларда чеберкәй дигән үсемлек үсә, аның җир астындагы бәрәңге сыман әйберен бик яратып ашашлы иде. Без аны берәр чиләк җыйган чаклар булды. Чеберкәйне чи килеш тә, ашка салып та кулланалар. Кыш көне картәни

чеберкәйне турый, торна борчагы оны сибә, шомырт оны да куша, бераз бәрәңге дә, тегенди онны да бутап аш пешерә. Менә шул ашны картәни алты тәлинкәгә бүлә, ул туңа. Мин алты туң ашны биштәргә тутырам да Каенавылга укырга китәм. Көн саен бер тәлинкәне (ул тәлинкәләр табак хәтле инде) өчкә бүлеп, иртән, көндез, кич ашап яшим. Һәм ялга авылга кайтып китәм. Картәни тагын туңган ашларны хәзерләп куя.

Әле һаман үскәч кем булу турында уйлаган юк. Мин әле картәтинең авыз эчендә генә сызгырып йөргүен тыңлыйм. Үзе генә белә торган бер көе бар иде аның, гел шуны сызгыра, дөресрәге, өреп йөри. Картәнинең җырлаганын ишеткәнем булмады, ә менә әнинең сеңлесе Фәридә апада андый талант бар иде. Ул сыер сауганда җырлап җибәрә, минсиңайтим, сыеры да рәхәтләнеп тыңлап тора, селкенми дә, койрыгын да болгамый хәтта. Сыерыбыз җыр тыңларга яраткан, күрәсең. Мин дә шунда таң калып янәшәсендә утырам. Нигә кушылып җырламадым икән? Оялганмындыр инде...



Икенче класста укыганда, ата-аналар җыелышында сөйләргә миңа бер шигырь бирделәр. Тәүфикъ абый әле армиядә түгел, өйдә иде. Мәктәпкә Тәүфикъ абый белән икәү барабыз. Ике чакрым юл тәпилисебез бар бит инде. Абый мине юл буе, барып җиткәнче, сөйләтте бирелгән шигырьне. Оятка каласы килми бит. Мәктәптә сәхнә-фәлән юк, зуррак бер класс. Менә шунда сөйләргә кирәк. Минем бөтен максатым – ничек кенә булса да ялгышмаска! Сөйләдем инде. Әйбәт килеп чыккан, күрәсең, шуннан соң миңа гел шигырь бирә башладылар. Мәктәп концертларында чыгыш ясап алгалый идем. Мактап, нәрсә булса да бирәләр иде: сабыннар, бер вакытны чалбар да бүләк иттеләр. Белмим, ятим булгангамы, әллә яхшы укыгангамы?

## Иң бәхетле көн

Каенавылда радио ике кешедә бар иде: мәктәп директорында һәм тагын бер укытучыда. Мин мәктәпкә йөри торган юл уңаендагы директор Мәхмүт абыйның өендәгесе урамга ишетелерлек итеп кычкырып сөйли. Иртән дәрескә барганда, алар тирәсенә җиткәч туктыйм, шул тирәгә кар өя, көрт артына посам да совинформны тыңлап утырам. Минем нәрсә беләсем килә: беренчедән, сугыш кайда бара, нинди шәһәрне алган безнекеләр, нинди шәһәрне дошманга калдырганнар; икенчедән, ишетеп булмас микән Тәүфикъ абыйның хәбәрен. Йә үлгән дип әйтерләр сугышта, йә булмаса герой булган дип әйтерләр кебек. Имашев Тәүфикъ дигән сүзне көттем мин радиодан сугышның башыннан ахырына чаклы. Үлгән дигән хәбәре юк иде әле ул вакытта. Мин шуны көрткә чумып тыңлыйм. Янәшәдә генә авыл советы, шуннан бер тапкыр җыештыручы Оркыя апа чыкты да:

– Син, малай актыгы, директор тәрәзәсе төбендә нишлисең? – ди.

Бик шикле күренгәнмендер инде мин моңа – шпион булып.

– Оркыя апа, сугыш хәбәрләрен тыңлыйсым килә, абыем турында ишетеп булмас микән дим.

– Алай булгач, туктале, син бит болай салкын тидерәсең, менә мин авыл советында җыештыручы булып эшлим, иртән гел шунда, телефонны алып тыңласаң, ул стенада эленеп тора – агач телефон, аннан шул ук радио сөйли. Бар әле, кереп тыңла, – ди.

Мин кердем дә, трубканы алып тыңласам, чыннан да, радио сөйләп ята.

– Менә шулай иртүк кил дә тыңла, яме!

– Ярар.

Оркыя апага рәхмәттән башка сүзем юк.

Һәм беркөнне трубканы алуым булды:«Капитуляция... Подписан договор. Война кончилась!..» Бик матур хәбәр бит бу. Трубканы ташладым да тәрәзәне ачып җибәрдем.

«Сугыш беткән, сугыш беткән!» – дип акыра башладым. Сугыштан яраланып кайткан бригадир Сәфәр абый атына атланып эшкә нәрәт биреп йөри.

– Нәрсә акырасың? – ди.

– Сәфәр абый, сугыш беткән бит...

Сикереп төште дә атыннан, телефоннан ике генә сүз тыңлады да, яңадан атланып, авыл буйлап чапты:

– Сугыш беткән, сугыш беткән!..

Бу минем иң бәхетле көнем иде. Чөнки авылдашларыма алар зарыгып көткән сөенечле хәбәр җиткердем.

## Тәкый абый җыры

Һаман шул сугыш вакыты.

Укытучылар спектакльләр куялар. Безне дә шунда уйнарга чакыралар. Кайда колхозчы баласы, кайда солдат малае, кемдер әсир, разведчиклар... Йөрибез инде укытучылар арасында уйнаган булып. «Кайту» дигәнне дә куйдылар. Ныграк истә калганы «Ак калфак» спектакле булды. Монда көтүче егет хуҗабикәсенең кызы Хәмдиягә гашыйк була. Шәрәф исемле бай егете дә йөри ул кыз артыннан. Ярлы көтүче егетнең исеме – Бакый. Бу спектакльдә без көтүче малайлар булып катнашабыз. Бакый роленә безнең яшь укытучы Тәкый абыйны билгеләделәр. Үзе дә мәктәпне яңа гына бетергән ять-яшь егет. Хәмдиянең ярдәмче иптәш кызлары бар. Бер дусты – авылда медсестра булып эшләүче марҗа апаның кызы Аня. Репетициядә дә, спектакльдә дә бер тапкыр да «Бакый» дип әйтә алмады. «Тәкый» ди дә «Тәкый», ди. Спектакльнең бер кызыгына әйләнде аның шулай дип әйтүе. «Тәкый», дигән саен халык егылып көлә.

Тәкый абыйның беркайчан да җырлаганы юк. Теге көтүче Бакый җырларга тиеш. Репетициядә аңа, җырла, диләр, ул, юк, спектакльдә генә җырлыйм, ди. Спектакль башланды, тегенең тавышы килә, үзе күренми, җыр ишетелә. Укытучылар һәм без калтырап торабыз инде нәрсә булыр дип. Җыр булмаса, спектакльнең эчтәлеге ачылып бетми бит инде. Бакый җырлап килеп чыкты, малай! Шундый моңлы тавыш! «Хәмдия» көен безнең якта берәү дә белми ул вакытта. «Нурия» дигән җыр бар бит әле: «Башымдагы эшләпәмне элеп куйдым киртәгә...» Шул көйгә җырлый бу «Хәмдияне». Шигырь юллары ята «Хәмдия»гә моның. Әй, кул чаба шунда халык, әй, чаба!..

Ул җыр халыкка бик зур бүләк булды, мин чын җырчыны беренче мәртәбә шунда ишеттем.

Кич белән премьера булды. Кесәсендә сугышка китәргә килгән повесткасын тотып җырлаган икән ул Бакый абыебыз. Китеп озак та тормады,«батырларча һәлак булды» дигән похоронкасы килде.

## Сабантуйда

Менә җиденче классны да тәмамладык. Чыгарылыш кичәсе дә узды. 17 июнь – көндезге сәгать бердә Сабан туе. Сугыш еллары бит әле. Шундый дәһшәтле елларда да бер елны да Сабан туе булмый калмады. Шул Сабантуйда беренче мәртәбә йөгерештә катнаштым. Унлап малайны бер абзый километр чамасы ераклыкка алып китте. Шуннан старт бирергә барыбызны да тезеп бастырды да «Внимание!» диюе булды, малайлар тоттылар да чаптылар. Нәрсә карап торасың, ди теге абзый миңа, бар йөгер, ди. Мин әйтәм, «Марш» дигән команда булмады бит. Кем туктата инде аларны хәзер, бар, артларыннан йөгер, ди. Ярышта беренче стартым шундый булды минем. Йөгердем. Куып җиттем тегеләрне. Алтысын уздым, дүртенче килдем. Сөлге бирделәр. Чигүле. Тукыган. Иң тәүге ярыш бүләгем шул иде.

## Секретарь булдым

Алга таба укырга кирәк миңа. Картәти белән сөйләштем дә сигезенче класска район үзәге Бардага киттем. Миңа танышлык буенча квартир таптылар. Картәти:

– Әйбәтләп укырга тырыш, улым! – диде.

Бер айлап укыгач, күзгә арпа чыкты. Мәктәп директоры Галиева дигән апага:

– Менә, күрәсезме, күземә арпа чыкты. Мин авылга кайтам, – дидем.

Ул:

– Бар, кайт, картәтиең белән күзеңне дәвала, килерсең, укырсың, – дип әйбәтләп озатты.

Кайтып киттем. Эшнең нәрсәдә икәнен аңлаттым. Картәти әйтә:

– Ярар. Монда әле авыл советы председателе Нәҗмехан абыең килгән иде – Иске Чатныкы, ул: «Биш авылым бар, ләкин секретарь булырлык бер кешем юк. Җиде класс белемле берәү – ул синең малаең, миңа Мәсгут кирәк», – ди. – Үзең беләсең, улым, мин бит хәзер эшләмим, сине чакырып торалар эшкә, бар, үз көнеңне үзең күрә башла!

Бардым Чатка, әйттем:

– Нәҗмехан абый, чакырдыңмыни?

– Абый, мин бер эш тә белмим, җиде класс кына бетергән, мәктәптән генә.

Үзен дә яңа гына председатель итеп куйганнар:

– Өйрәтермен! – ди.

Авыл советы секретаре булып Чат авылында хезмәт юлым башланды. Миңа нәрсәләргә генә өйрәнеп бетәргә туры килмәде: авыл халкына меңтөрле справка кирәк. Көнбагыш үстерәләр безнең якта, аны шәһәргә илтеп сатарга рөхсәт сорыйлар, урлаганга түгел, үзең үстергәнгә. Колхоз идарәсе белән бер бинада авыл советы. Нәҗмехан абыйны чакыралар да сыйлыйлар солдатка хатыннар. Эчә дә эчә бу. Өч ай чамасы эшләдем, мине өйрәтү юк, үзем нәрсә уйлап табам, шуны эшләп утырам. Көтмәгәндә райисполком секретаре килеп керде.

– Имашев, председателегезне тыеп булмый, алыштырабыз. Менә, яңа председатель алып килдек, Рәшит Бәширов, – ди.

Мин нәрсә әйтим инде. Ярар. Эшли башладык Рәшит абый белән. Ул чыннан да аек, эчми, документларны ничек дөрес тутырырга өйрәтә.

Бераз эшләгәч, ул минем фамилиягә игътибар итте.

– Имашев, син кайсы авылдан? – дип сорады.

Мин әйтәм:

– Каенавылдан...

Ул безне тәяп сөргенгә озаткан кешеләрнең берсе булып чыкты. Минем мондагы эшләр кирегә китә башлады: кычкыра, төрттереп сөйләшә, эшкә өйрәтми. Кеше саны алу кампаниясендә: «Тегендә бар, кайда йөрисең, нишләп алай итәсең?»– дип бәйләнергә тотынды. Мин кайтып картәтигә сөйләдем: шундый-шундый хәлләр, Рәшит абый минем белән усал кылана.

Картәти әйтеп куйды:

– Ә-ә, Бәшировмыни әле...

Исенә төште аның да.

– Түз, улым, түз, әзрәк хезмәт хакың бара, аннан соң ашау-эчү карточкага бит. Аз булса да карточка белән бирәләр сиңа, – дип тынычландыргандай итте картәтием.

Ләкин минем күңелгә «ычкынырга кирәк!» дигән фикер ныклап кереп калды.

## Кыз булып уйнадым

Шулай күңел төшенкелеге белән йөргәндә, авыл яшьләре спектакль куярга маташалар. «Үги кыз» дигән пьесаны сайлап алганнар. Уйныйсы килә. Уйнаганым да бар бит инде. Репетициягә килдем, спектакльдә үги кызны уйнарга кыз юк. Ул кыз спектакльдә җырларга тиеш.

– Синең җырлаганың бармы? – дип сорыйлар миннән. – Җырлап күрсәт әле!

Мин җырладым. Хәйран әйбәт килеп чыккандыр инде. Болар әйтә:

– Бүтән кешене эзләмибез, бетте! Давай, син уйныйсың үги кызны!.. Тавышың да нечкә, нәкъ кызлар тавышы.

Ул яшьтә тавышым кызларныкы кебек нечкә иде шул. Ризалаштым инде.

Ярар, спектакльне чыгарыр вакыт җитте. Клуб юк, кызыл почмак кына, шунда сәхнә ясаганнар. Чаршау корылган, шуннан чыгабыз инде. Спектакль башланып

китте. Мин сәхнәдә күрендем. Халык борын төбендә генә утыра бит инде. Апаларның берсе кычкырып:

– Сөбханалла! – дип карап тора миңа. – Бу малайдан матур гына кыз чыгасы булган икән, борыны гына мишәйт итә! – ди.

Авыл советы секретарен халык таный бит инде, зал тәгәри. Спектакль кайгысы бетте халыкта. Ничек үзем дә көлми түзгәнмендер мин анда уйнаганда? Юк, бирешмәдем.

Ярый, бу өлеш бетте, мин җырлый башладым. «Каз канаты». Шул көйгә пьесадагы сүзләрне җырлыйм. Барсы да тып-тын булды. Сулыш та алмый тыңлап утыралар. Җыр тәмамлангач, алкышларның чиге-чамасы булмады. Алга таба спектакльнең эчтәлегенә кереп тын калдылар. Ананың усаллыгын, атаның явызлыгын, кызның юашлыгын күреп хәйран аптыраштылар. Елаткан җирләре дә, көлдергән урыннары да булды ул тамашаның.

Мин, шул алъяпкычлы кыз булып, авылым кешеләре күңелендә калдым.

## Икенче мәртәбә секретарь

Бервакыт район үзәгендә авыл советы секретарьларының семинары булды. Егермеләп секретарь җыелган иде анда. Минем туган авылдан да Гарифә исемле секретарь килгән. Ул миңа:

– Мәсгут, син нишләп Иске Чатта секретарь булып эшләп йөрисең? Әйдә, туган авылыңа кайт! – диде.

Мин:

– Анда син эшлисең бит, – дим.

– Хәзер эшләмим инде. Председатель итеп Камил абыйны сайладылар, ул сугыштан кайтты, мин аңа кияүгә чыктым, – ди бу. – Председатель белән секретарьга бер гаиләдән булырга ярамый. Мин эштән китәм. Син Каенавылга секретарь булып кайт.

Чатка кайттым да гариза бирдем. «Прошу уволить!»

Секретарьга кеше юк бит. Бәширов:

– Никакуй... Эшлисең! – ди.

Хәзер мин картәти белән киңәш итәм. Башка кешеләр белән дә... Ничек ычкынырга?..

Кайсыдыр акыллы кеше әйтте: «Укырга китәм, дип әйт. Укырга китүгә каршы килә алмый ул. Шундый закон бар!»

Әһә!.. Мин моңа шундый эчтәлектәге гариза яздым. «Укырга барырга ният!»

Тешен кысып риза булды Рәшит абый.

– Ярар, китәрсең инде, – дип усал гына карап калды.

Каенавылга бардым. Эшли башладык. Председательнең бернинди белеме юк. Рәшит абый кебек түгел, кәгазьгә кулын куйганда, Мостаев дигән фамилиясенең «М» хәрефен генә ясый да койрыгын дулкынлатып куя. Кәгазьләрне укып тормый, нәрсә язылганын сорый да теге «М»ын сырлый. Справкаларны мин язам. Эшли башлагач, аңлап алган бу минем Имашев нәселеннән икәнне. Ул да, теге вакытларда, комсомол булып, халыктан дошман ясап йөрүчеләрнең берсе икән. Җитмәсә, әле безнең картәтинең өлкән улы Бәйрәмхуҗа белән алар яшь чакта икесе бер кызны яратып йөргәннәрме, сугышып та алганнармы шунда – бер сүз белән әйткәндә, бер-берсен күрә алмаганнар. Нишләргә? Укырга китәргә кирәк. Шулвакыт авыл советына повестка килеп төште – минем туган елгыларны ФЗОга алалар. Мин китәсе кешеләрнең исемлеген яздым, шул исәптән үземне дә. Кәгазьне алды да сорый:

– Үзеңне яздыңмы?

Мин әйтәм:

– Яздым.

Миңа усал итеп карап тора.

– Яздым, – дим кабатлап.

Иртәгесен ике арбага төялдек тә җыелышып районга китеп бардык. Армиягә алынган күк медкомиссия үтәсе бар икән. Мәдәният йортының залында бара бу эш. Дусларымны берәм-берәм кертеп җибәрдем дә иң ахырдан чишенеп үзем кереп киләм. Сәхнәдә зур өстәл. Өстәл артында дүрт-биш кеше утыра – комиссия. Вербовщиклар инде болар. Райисполком секретаре Гайнуллин да шунда. Мине күреп сикереп торды бу.

– Син кая барасың?
– ФЗОга! – дим.
– Кем кушты сиңа?
– Минем елгыларны алалар.
– Бар, кайт, йөрмә монда!
Утырып торучыларның берсе өстәл артыннан сикереп торды да моңа каршы:
– Враг народа вы, самый рабочий человек пришёл, а вы не хотите его отдавать! – дип кычкырды.
Бу тегеләргә:
– В районе я выращиваю одного грамотного секретаря, у меня не хватает кадров, не с кем работать, я вам его не отдам! – ди.
Мин чыктым да киттем. Начальнигым әйтеп тора бит. Шулай итеп, миңа кайтып китәргә туры килде.
Кайткач, Камил абый сорый:
– Кемнәр китә?
– Башкалар барысы да китә.
– Ә син нигә китмисең?
– Гайнуллин абый җибәрми.
Миңа барыбер китәргә кирәк иде – укырга. Укырга, укырга, укырга... Инде бер ел эшләдем бит секретарь булып. Киттем Пермьгә.

## Уңышсыз омтылыш

Минем картәтинең өлкән улы Бәйрәмхуҗа абый, ул да заманында авылдан куылган кеше, авылга кайтмыйча, Пермьдә заводта эшләп калган. Өйләнгән, ике кызы, бер улы белән шунда яшиләр – зурлар инде миннән. Аларга барып төшәм, туган абый бит. Мин әйтәм:
– Укырга керергә килдем.
– Үзең кара, үзең кара инде... – ди абый.
Менә шунда мин документларымны тимер юл техникумына бирергә бардым, ләкин анда керү имтиханнары тәмамланган булып чыкты, әмма елга техникумына өлгердем. «Капитан-штурман дальнего плавания» дигән бүлеккә алдылар һәм «жди вызова», диделәр.
Кич белән Пермь шәһәренең ерак Сталин районындагы бер Мәдәният сараенда үзешчәннәр спектакль куя икән. Мин әйтәм, барып кайтыйм әле. Бардым. «Балыкчы кызы» дигән спектакль карадым. Бик әйбәт уйнадылар, чын артистлар кебек, суфлёрсыз-нисез. Абыйларга кайттым. Йокладым. Иртә белән уянсам, температурам – 39. Костыра, эч тә китә. Миңа «Ашыгыч ярдәм» чакырттылар. Табиблар килделәр дә сораштыра башладылар, кем ул, кайдан? Менә авылдан укырга килгән иде, диләр. Табиб әйтә: «Немедленно обратно в деревню, Пермьская атмосфера не для него», – ди. Абыйлар тора торган җирнең күршесендә генә хәрби завод, мартен цехлары, янәшәсендә генә тагын кислота заводы икән. Алардан җитмеш төрле төтен чыга. Кеше гомере өчен куркыныч яный икән монда. Ничек яшиләр соң абыйлар? Аптырарсың...
Пароходка утырып яңадан авылга кайтып киттем. Укый башларга җай чыкмады.

## Тагын авылга кайттым

Авыл советына керсәм, минем урынга бер өлкән яшьтәге абыйны секретарь итеп алганнар. Ул өч ел буе, ни сәбәпледер, төрмәдә утырып чыккан икән. Камил абыйга кердем дә:
– Миңа берәр төрле эш табалмассыңмы? – дип сорадым.
– Хәзер бит инде менә Әхәт абыең эшли синең урында, – дигән җавап алдым. – Әнә колхозның клубы хуҗасыз – шуны ал. Клубны да, кызыл почмакны да, агитбригаданы да җитәкләрсең. Давай!
Шулай итеп, мин, малай-шалай, клуб мөдире булып эшли башладым! Укытучы агитаторларның башлыгы итеп тә билгеләделәр әле. Концертлар куюны җәелдереп

җибәрдек. Спектакльләр әзерлибез. Тик менә пьесалар табып булмый. Һич безгә ошаганы юк. Бар алар, ләкин 20шәр артист уйный торган. Ә бит авылда аның хәтле уйнарлык кеше табып булмый.

Өйгә кайтып, баш ваттым-ваттым да, туктале, мәйтәм, бигрәк ошады бит миңа Пермьдә караган теге «Балыкчы кызы». Утырдым да яздым хәтерләгәнчә – иртәнгә пьеса әзер! Яшьләрне җыйдым. Менә шундый пьеса бар дип укып бирдем. Булган бу, диделәр. Бөтен образлар каршымда утыра. Балыкчы да монда, гаскәр башлыгы да... Давай, куябыз! Шуны куеп, унлап авылны йөреп чыктык. Халык яратып карады.

## Тәмәке тартучыларга комсомол ярдәме

Шуннан, ярый, бер ел тагын клубта эшлим, агитатор да мин. Мәҗбүр итәләр, завклуб булгач. Чәчүчеләр бригадасына барам, русча булса да гәҗит укыйм. Тыңлыйлар, киткәндә, рәхмәт, рәхмәт,диләр. Сорыйлар:

– Карале, син бу гәҗитләрне тагын берәр җиргә барып укыйсыңмы?

– Бүген сез – соңгысы.

– Кара, гәҗитеңне биреп калдыр әле, тәмәке төрергә кирәк, – диләр.

– Мәгез.

Укылган гәҗитне кулларына тоттырам.

Бу хәл минем күңелдә калды. Тәмәке тартырга өйләрендә гәҗитләре юк икән бит. Монысы – бер. Икенчесе, гәҗит ертып маташып, тәмәкесен төреп, кадерле вакытларын әрәм итәләр бит болар. Мин – комсомол! Туктале, боларга ярдәм йөзеннән ни эшли алам икән?

Кызыл почмак тулы подшивкалар ята. Кайчы алам да гәҗитне папирус озынлыгы итеп кисеп чыгам, бөтерәм дә шуны тәмәке төрергә җайлыйм.

Берничә көннән тагын шул бригадага эләктем. Сөйләшеп алулар тәмамлангач, мин боларга әйтәм:

– Менә сез тәмәке төрергә гәҗитебез юк, дисез, мин сезгә гәҗитне уңайлы итеп кисеп, папирос төсле ясап килдем. Махоркагызны гына саласы, төкерегегезне генә җәлләмисе.

Таратып та чыктым. Шунда үземнең туганым Әүхәт абый:

– Ну малай, карагыз әле, шулкадәр саран булыр икән бу, – дип әйтеп куймасынмы?

Әйләндереп салды мине, рәхмәт ишетәсе урында.

## Ниһаять, ФЗОга эләктем

Тагын бер ел үтте. Укырга китәргә кирәк барыбер. Мин бу хыяллар белән йөргәндә, классташларым район үзәгендә унны бетерделәр. Бер партада утырган дусларымның берсе Мидхәт тә белгән минем укырга китәргә җыенганны. Килгән бу миңа.

– Ал әле мине дә, үзем генә барырга шикләнәм, укыйсы килә, – ди.

– Әйдә! – мәйтәм.

Киттек Пермьгә. Тагын Бәйрәмхуҗа абыйларга кердек. Аның улы Салих абый да өйдә иде

– Салих абый, менә укырга килдек.

– Бик әйбәт! Мин механическийны тәмамладым, хәзер заводта инженер булып эшлим, шунда ук әниең ягыннан туган Нәгыйм абыең да укыды. Ул конструктор булып эшли. Керегез шул техникумга, укып чыгыгыз да безнең белән бер заводта эшләрсез, – диде. – Техниклар булырсыз, – дип тә өстәп куйды.

Ярар, Салих абый белми әйтми инде. Сугыштан кайткан абый ул. Документларны икебез дә шунда бирдек.

Без имтиханга иртәрәк килгәнбез икән. Мидхәт әйтә:

– Әйдә, берәр җирдә эшләп торыйк, – ди.

Аның да әти-әнисе ярлы гына кешеләр инде. Ярдәм итәр кешесе дә юк. Шул техникумга кердек, анда ремонт бара. Бригадирларыннан:

– Сезгә ремонт эшләренә эшчеләр кирәкмиме? – дип сорадык.

– Кирәк. Нәрсә эшли беләсез? – ди бу.

– Ни кушсагыз, шуны эшлибез, – дидек.

Әзрәк акчасы булса, шул җитә безгә. Шулай итеп, үзебез керәсе техникумны ремонтлый башладык. Безгә буяу эше куштылар. Тәрәзәнең эчләрен буйыйбыз. Мидхәт әйтә:

– Әйдә, кичке эшләр дә карыйк әле, – ди.

Техникумнан ерак түгел яшелчә саклый торган урын бар. Инде көз якынлаша. Бәрәңге китерә башларлар. Бардык. Сорыйбыз:

– Сезгә бәрәңге сортировать итүчеләр кирәк түгелме?

– Кирәк. Түлке төнге сменага, – диләр.

Безгә шул гына кирәк инде.

Көндез – ремонт, төнлә бәрәңге чүплибез.

Шулай бер айга якын эшләдек, аннары кабул итү имтиханнары башланды. Бирдек. Икебез дә кердек. Мидхәт унны бетереп килде бит, ә мин җидене генә. Язма эштән минем хаталар киткән, шуңа күрә миңа «өчле» куйганнар. Ләкин, шуңа карамастан, алдылар тагын. Утыз беренче август көнне спортзалда беренче курска керүчеләр өчен җыелыш үткәрделәр. Басып торабыз. Директор чыкты да укый башлады: «Новое постановление Советского правительства на новый учебный год». Китте, китте укып... «С этого года с тройками стипендия отменяется». Бәтәч, стипендия булмагач, мин ничек укыйм ди.

– Болай булгач, Мидхәт, мин документларны алып бүтән җиргә укырга китәм инде.

– Син укымагач, мин дә укымыйм монда, синең белән бергә йөрим, документларымны алам, – диде Мидхәт.

Чыгып киттек. Шәһәр буйлап белдерүләр карап йөрибез. Өстен карамыйбыз белдерүләрнең, астын гына карыйбыз. Кайда тулай торак бар, кайда безнең өчен җай туры килә – шуларны гына эзлибез. Бер җиргә килеп эләктек бит. «Обеспечиваются общежитием, рабочей, парадной одеждой, трёхразовое бесплатное питание».

– Мидхәт, карале, безгә бит бу!

– Безгә!

Башны күтәреп караган идек – «ФЗО-43 металлургов».

– Мидхәт, – мәйтәм, – бу безнеке! Әйдә, киттек.

Бардык. Директор:

– Вы, молодой человек, будете кузнецом-штамповщиком, – ди миңа, а вы – печником доменно-мартеновских печей, – дип Мидхәткә төртеп күрсәтте. – Согласны?

– Согласны.

– Идите в общежитие. Устраивайтесь. Получите обмундирование и в столовую.

Шулай ФЗОда укып йөрдек. Алты сәгать эшлибез заводта, ике сәгать теория укыталар.

Миңа эшләү, уку гына җитми – бер клубны эзләп таптым. Татар түгәрәге бар икән. Кердем, ни эшләтәләр икән монда дип. Спектакльләр куябыз, җырлыйбыз, биибез, сөйлибез, концертлар белән йөрибез, диләр.

– Килергә мөмкинме соң?

– Ә нәрсә эшли беләсең? – диләр.

– Җырлап та, биеп тә, сөйләп тә караганым бар, – дим.

– Давай, җырлап күрсәт әле! – диләр.

Җыелган халык байтак, барысы да түгәрәккә йөрүчеләр. Җитәкчеләре – Гариф абый Дашкин.

Җырлап күрсәттем.

Гариф абый әйтә:

– Күрдегезме инде, куялмыйбыз да куялмыйбыз, дисез, иртәгә үк башлыйбыз репетицияне «Галиябану»га. Менә Хәлил килгән!

Шулай итеп, сәнгатькә кереп киттем...

**Мәсгут ИМАШЕВ**



Ак җилкән

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнең сәхифә!

# ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

## Тәңрем ташламасын

**– Әгәр дә әбиләр кебек яулык бөркәнеп, төренеп йөри башлыйсың икән – мин сине ташлыйм! – диде Азат каты гына итеп. – Әнә, дөньяда ниләр бара! Сиңа да берәр сылтау табып бәйләнсәләр? – Кыз икеләнеп, юк, икеләнеп түгел, уйланып калды.** Егеткә зур зәңгәр күзләре белән карап алгач, болай диде:

– Ә син якламас идең дә мәллә? Сине ныклы таянычым дип йөри идем…

– Син минем белән йокларга да теләмисең. Ничек мин сине яклыйм ди?

– Аңа килгәндә, минем уемны беләсең. Бары никахлашканнан соң гына.

– Магазинда итек алганда да киеп карап алалар. Син никах та, никах, дисең. Әнә башкалар никахсыз да яшәп яталар.

– Мин – итек, тормыш кибет түгел, – диде Рауза, егет белән ачуланышырга теләмичә, әйткәләшүне уенга борып.

– Ташлыйм дигәч, ташлыйм. Ябалак кебек бөркәнеп йөрисең, – диде дә егет борылып китә дә башлады.

– Аллага шөкер! Ташларга мин ватык чынаяк түгелмен. Ходаем үз мәрхәмәтеннән ташламасын! – диде кыз, тамагына төелгән яшен йота-йота.

– Во… во, шул Аллаң свиданиегә чакырыр. Ходаең белән җитәкләшеп йөрерсез. Ха… ха… ха! Ходай, имеш! Мәчеткә йөри, Ходай янына. Ха-ха!!!

Азат шулай шаркылдап көлә-көлә китеп барды. Кыз, зиһене буталып, кая барганын белмичә, урамның икенче ягына чыгарга теләде. Урамда җыелып яткан күлләвеккә аягы белән килеп баскач кына һушына килде. Тик соң иде: зур тизлектәге бер машина аны баштанаяк пычрак су белән коендырды. Ярый асфальттагы суга басып туктап калды. Юкса, машина астында калачак иде. Үтеп киткән машина, артка чигеп, елап басып торган кыз кырына килеп туктады. Аннан озын буйлы, киң күкрәкле егет чыгып, кызның тетмәсен тетеп әрли башлады:

– Син нәрсә? Тилекәй! Машина астына ташланасың? Үләсең килә…

Егет кызның хәлен чамалап, аннан да бигрәк аның чибәрлеген күреп туктап калды. Суланып кыз тәненә сылашкан күлмәге аның зифа буен тагы да ныграк бизәп, тагы да сылурак итеп күрсәтә иде. Егет:

– Әйдә, утыр! Хәзер ипкә китерербез, – дип, Раузаны җитәкләп машинага утыртты. Үзе хуҗа булган супермаркет магазинына алып килде.

Алар Салих белән менә шулай танышып киттеләр…

Бер атна үтәр-үтмәстән, Азат, Рауза яшәгән фатирга килеп, кыз белән сөйләшеп аңлашырга, гафу үтенергә теләгән иде дә барып чыкмады. Анда Раузаның күчеп китүен әйттеләр. Һәм бу вакыйгаларга бер ел үткәч, Азат аны көтмәгәндә очратты һәм бу хәл бөтенләй башкачарак килеп чыкты. Кызның мәчеттә әби-апаларга гарәп теле һәм дин дәресләре өйрәткәнен белә иде ул. Мөгаен, адресын беләләрдер дип кергән иде. Рауза исә мәчет ишек төбендәге аяк киемнәрен тәртипкә китереп, төшкән чүп-чарны себереп булаша иде. Азат, елмаеп:

– Нәрсә, һаман әби-сәби карап, мәчет себереп йөрисеңме? – диде.

Рауза, тураеп, аңа бер күз сирпеп алды да, берни дәшми капка төбендәге “Лексус” машинасына утырып китеп барды. Кыз бармагындагы алтын балдак елтыравы егетнең йөрәгенә утлы уклар булып кадалды.

Раузаның түгәрәкләнгән билен чамалап, егетнең тамагына төен утырды. Күзләренә яшь тулган егет мәчет бусагасында берүзе серәеп басып калды...

## Хәерче

**Әлеге вакыйга инде онытыла да башлаган иде. Тик менә бүгенге хәл аны барсының да янәдән исенә төшерде.** Таныды ул аны. Менә бүген аның алдында нәкъ ул басып тора. Ә бит күпме эзләде ул аны. Кибет төбендә, яргаланып беткән кулын сузып, калтыранып басып тора. Сакал баскан битендәге ярасы да урынында. Карлыккан тавыш белән, кергән-чыкканга:

– Әпәйлек булса да бирегез әле, рәхим итеп, – ди.

Тәүдә ул аңа бер иллелек бирергә уйлады, таныгач, бу уеннан кире кайтты. Кайбер нәрсәләрне ачыклыйсы бар! Каршыда торган кафены күреп:

– Икмәклек бирмим. Әйдә, үзеңне бер сыйлыйм, – дип, кафега башы белән ымлады. Хәерче танымады. Аны сыйларга теләгән ир бүтәнчә сүз катмый гына кафега таба атлады. Хәерче дә тыйтаклап аңа иярде.

Бик тә сәер иде: зал түрендә кыйммәтле ризыклар тулы өстәл артында икәү утыра. Берсе – урамдагы бомж, карарга җирәнгеч. Икенчесе – олпат гәүдәле, бик яхшы киемгалстуктан, түгәрәк йөзле, әйтерсең лә берәр завод директоры. Чынлап та, ир бер зур гына оешманың җитәкчесе иде. Бомж гына ашыга-ашыга ризыкларны авызына озата. Менә ул туя башлады, ахры, ашавы сүлпәнләнде. Ир, бокалга кыйммәтле вино коеп, бомжгарак этәрде дә:

– Сөйлә!!! – диде.

– Нәрсә сөйлим?

– Ничек бу көнгә төштең?

Бомж виного үрелде. Тик түрәгә охшаган ир бокалны кулыннан ычкындырмаган иде. Ул виноны кире үзенәрәк тартты:

– Башла! Монысы дөресен сөйләсәң генә.

Бомж озак кына үзенең тормышын барлады. Гаиләсе турында, ничек төрмәдә утыруын – барсын да сөйләде. Директор дәшми генә тыңлап, каралтылган күзлеге аша хәерчене күзәтте. Теге ашап туйды шикелле, тагын бокалга сузылды. Дәшми генә тыңлап утырган кара күзлек тамагындагы төердән карлыккан тавыш белән әкрен генә:

– Хәлимә кайда? – дип сорады.

Сорау бомж өчен аяз көнне күк күкрәгәндәге кебек көтмәгәндә яңгырады. Аның йөзе аклы-күкле булып китте. Бокалга сузылган кулын кара елан токтандай кинәт тартып алды. Йөзендә әллә нинди үзгәрешләр чагылып, куллары гына түгел, ияге дә калтырарга тотынды. Хәтта тешләренең бер-берсенә бәрелеп шыкылдавына чаклы ишетелде. Һәм ул, чак ишетелерлек итеп:

– Хәлимә үлде, – диде һәм, бераз дәшми торгач: – Үч алырга уйлыйсыңмы? – дип куйды.

Каршысында утырган кара күзлекне хәзер бомж да таныды.

– Юк, Хәлимә хөрмәтенә сиңа тимим. Бу кадәр шакшы бәндәгә кулымны пычратасым килми. Тик кисәтеп куям: кайдан кайттың, шунда олак! Югыйсә сине бетерәчәкмен. Башкача районда күренәсе булма!..

Ир озак кына уйланып утырды. Ул армиядә чакта шушы шакшы ничек итеп аның сөйгәне Хәлимәне җиләк җыйганда көчләп, аңа өйләнүен дә, аннан соң кайдадыр чит якларга чыгып качуын да белә иде. Ярый юньле-рәтле яшәгән булса, юк, гаиләсенә һич игелек күрсәтмәде. Хәлимәне имгәтеп, мине карамыйлар дип, балалары белән судлашып та йөрде әле...

## Күзле бүкән

**...Ир дигәне җай гына үз көненә яшәп, бернинди наз, ярату хисләрен тойдырмаганга илереп әйтте ул бу сүзләрне.** Әйе, әйе, шулай диде. Тик ирнең моңа бик исе китмәде. Гадәтенчә бер тутырып карап алды да елмаеп кына куйды. Хатынның моңардан җен ачулары килеп, тәмам ярсып:

– Син... Син кеше ирләре кебек әрләшә-сугыша да белмисең бит. Түмәр син, түмәр! Хет яратып кына булса да бер яңакка чабып җибәрер идең. Сугып егар идең, тартып торгызып яратыр идең!

Күрәсең, ирнең тәмам ачуы кабарды. Ул, елмаюын яшерергә тырышып, хатыны кырына шәп-шәп атлап килде дә, көрәктәй учларын җәеп, кулын өскә күтәрде. Моны көтмәгән Гүзәл чытырдатып күзен йомды һәм җир ярып кычкырып җибәрде.

– Ай... ай... Үтерәләр!

Тик ир дигәнең тәүдә хатынының ансыз да бәләкәй генә гәүдәсенә, аннан үзенең өскә күтәргән килбәтсез зур кулына карап алды. Һәм, гадәтенчә кулбашын сикертеп, кире үз эшенә барып тотынды. Ә хатын, һаман чәрелдәвен белеп:

– Сугып кына кара, сугып кына кара! Бармагың белән чиртсәң дә, иманыңны укытып, унбиш тәүлеккә утырттырам. Бүкән син! Күзле бүкән!

Хатын пыр тузып әниләренә чыгып китте. Ул тагын әнисенә барып ирен яманларга уйлады. Әнисе дә кызының холкын белә. Киявенә сүз тидерми. Тик Гүзәл әниләренә барып җитә алмады. Юлдан шәп итеп килгән машина астына эләкте. Хатынны больницага озаттылар. Ничәмә-ничә операция ясап, аны яңадан җыйдылар дисәң дә була. Бүтәнчә ярдәм итә алмыйбыз диеп, өлкә больницасыннан кире кайтардылар. Насыйп булса, берәр елдан аягына басар, язган булса, сөйләшә дә башлар, диделәр.

Менә шул насыйпны, Ходай язганын көтеп, унбиш ел үтеп тә китте. Балалар да башлы-күзле булып, аерым торалар. Ярый олы кызлары урам аша гына яши. Көнаралаш килеп, әнисен юындырышып караша. Бер килгәнендә әтисенә, инде ничәнче тапкыр дигәндәй:

– Әти, әллә безнең күршедә торган Минзифа апаны алып килеп торасыңмы? – диде. – Әнине үзебезгә алып кайтып, үзем карыйм. Әле бит сиңа илле дә тулмаган. Үзеңә дә җиңелрәк булыр. Минзифа апа риза, – дигәч, әтиләре:

– Юк, кызым, булмас инде. Әниегездән башка кеше белән яшәүне күз алдыма да китерә алмыйм. Яраттым мин аны, нык яраттым. Әле дә яратам.

Шул чакны кыз белән әти кешене аптыратып, менә инде ничәмә еллар сүзсез яткан Гүзәл:

– И-и, күзле бүкәнем! Тискәренең тискәресе бит ул, – диеп ыңгырашып куйды.

Һәм, ни могҗиза, шул көннән башлап әниләре күзгә күренеп арулана башлады. Алты ай дигәндә аягына басты. Чир белән Гүзәлнең иренә шар-бар килеп кычкырыну гадәте дә китте. Тик кайчакларны гына иренә сыенып, кулларыннан тотып сырпаланып:

– Ичмасам, менә болайрак итеп кочакла, – дип, иреннән үзен кочаклатып яраттыра иде...

## Күрше кызы

**– Әни, мин күрше кызы Сәлимәгә өйләнәм! – диде Дамир.**

**– Юк! Юк! Юк! – диде әнисе.**

Авыл сәхнәсеннән әлеге сүзләр ничектер үтә җитди яңгырап, бик тә табигый килеп чыкты. Ә бит бу спектакльдә әни ролен башкаручы Рәмилә алай дип әйтергә тиеш түгел иде. Әни кеше: «И балам, без бу мизгелләрне күптән көтеп йөри идек. Бик тә тәүфыйклы бала. Үзебезнең күз алдыбызда үсте», – дияргә тиеш иде. Менә сиңа мә! Буталды Рәмилә, буталды. Ни уйлап шулай дип әйтте соң ул? Әллә сүзләрен онытты мы? Үзенең ялгыш зур хата җибәргәнен аңлап, берчә куркудан, берчә аптыраудан Дамирга карап, нәрсә эшләргә дә белми, сәхнәнең уң ягында торган караватка барып утырды.

Барысына да капылт тамаша залына килеп кергән ире Ринат гаепле иде. Спектакль куярга барырга әзерләнеп йөргәндә генә, әлеге шул сыер турында сүз кузгатудан килеп чыкты бу. Имеш, быел печән әзерләү кыен, сыерны бетерергә кирәк дип, шул бер балык башын чәйнәргә тотынды. Авылда яшәп, сыер да асрамагач, ничек була инде ул? Ире эш ягына авыррак кузгала иде шул. Сыер да асрамагач, балаларга сөт-катыгын каян аласың ди? Үзең дә каймаклап чәй эчәргә яратасың лабаса! Юк, юк, сыерны бетермибез, дип ишекне каты гына ябып, клубка, үзе эшләгән урынга төшеп киткән иде. Менә бит ничек килеп чыкты. Нәкъ Дамир үз ролендәге сүзләрне әйтә башлауга, залга Ринат килеп керде. Рәмиләнең башыннан, вәт җен алыштырган нәрсә, казларны да ябып тормый килеп җиткән, сыерны да эләктермәгән инде бу, дигән уй яшен тизлегендә йөгереп үтте.  Ул гына да түгел, сыер турындагы бер сәгать элек кенә әйтешкәннәре исенә төшеп, авызыннан шушы сүзләр чыгып очты:

– Юк, юк, юк! – диде.

Менә хәзер сәхнәдә, ярга чыгарып ташлаган балык кебек, авызын бер ачып, бер ябып зиһенен җыя алмый утыра. Ул гына җитмәгән, алдагы әйтәсе сүзләрен дә онытты.

Бу ялгышу, бу буталудан егет ролен уйнаучы Дамир да югалып калды. Тагын бераз шулай торсалар, спектакльдән, давылда печән чүмәләсе тузгыгандагыдай, теткәләнгән күбә генә торып калачак. Авылдашлар алдында мәсхәрә булачаклар. Районнан килгән жюри әгъзалары ни әйтер тагын?!

Ярый әле сәхнәгә чыгарга үз вакытын көтеп торган әти кеше ролен башкаручы тракторист Вәли хәлне аңлап алды. Сәхнә уртасына чыгып басуга ук:

– Нәрсә булды? Балтасы суга төшкән татар кебек утырасыз? – диде ул.

Бу сүзләр дә пьесада юк иде. Шулай да әти кеше улы Дамирга карап сүзен дәвам итте:

– Нәрсә булды, улым? Нигә әниеңнең төсе качкан?

Шуны гына көткән диярсең, әни кеше дә спектакльдә буталганын бетерергә тырышып телгә килде. Тик баягы сыер турындагы, ире белән әйтешкән хәлләрдән аерыла алмый һаман шул «сыер» сүзе телендә буталды буталуын:

– Сыер, сыер Сәмиясенә өйләнәм ди бит. Ничәмә ирдән кайткан, ике баласын балалар йортына озаткан Сәмия ди бит.

Бу хәл, бу сүзләрдән телсез калып, әти кеше дә аптыраулы карашын улы Дамирга күчерде. Дамир, чая, яшь егет, тиз генә башын эшләтеп:

– Сыер Сәмиясенә түгел, күрше Сәлимәгә өйләнәм! – диде.

Бу килеп туган хәлдән чыгу юлын тапкан Вәлигә, аннан да бигрәк авылга практикага кайткан булачак ветврач һәм спектакльдә Дамир ролен башкаручы Илдарга рәхмәтле иде Рәмилә. Шатланып урыныннан ук сикереп торды да өзелгән диалогын дәвам итәргә чамалады. Залга карап алды. Ишек төбендә хатынының ничекләр оста итеп уйнаганына сокланып авызын ерып торган ирен күреп:

– Якын киләсе булма сыерга! Сыер сыер инде ул, – дип, иренә йодрык күрсәтеп алды. Аннан пьесада ничек язылган, шулай дәвам итте: – Ай, улым! Бик тә дөрес ниятләгәнсең. Без каршы түгел. Үзебезнең күршедә, күз алдыбызда үскән бик тә уңган инсафлы бала. Бу мизгелләрне күптән көтә идек, – дип, улының аркасыннан да кагып алды. Ә үзе эчтән генә: «Бу бик үткер һәм уңган егет азаккы курста укый. Ишетүенчә, Илдар Рәмиләнең кызын ныклап озатып йөри шикелле. Иншаллаһ, шушы бала гына кияү булырга насыйп булсын»,  дип уйлап куйды. Тик спектакльдә тагы да ялгышудан куркып, бу турыда уйламаска тырышты.

Шушы өлеше халыкка бигрәк тә нык ошап китте. Зал дәррәү озак кына алкышлап алды. Спектакль шәп килеп чыкты. Хәтта жюри әгъзаларына да шәп тәэсир итте. Һәм алар бу спектакльне район сәхнәсендә күрсәтергә дә лаеклы дип таптылар.

**Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ.**
*Башкортстанның Эстәрлебаш районы Турмай авылы*

# СЕРЛЕ КУНАКЛАР

ХИКӘЯ

Барча тереклеккә хәерле иртә теләп, Кояш киң итеп елмайды, болытлар арасыннан Җиргә күз салды. Авыл читендәге чәчәккә күмелгән гүзәл йортның киң тәрәзәләреннән Кояш малайлары кереп, ятакта аунап ятучы кызның битеннән, чәчләреннән иркәләделәр. Кыз, уянасы килмичә, иркәләнеп киерелде, кояшның җылы, рәхәт нурларында коенды.

Иркә уянганда, Кояш шактый югары күтәрелгән иде инде. Бүлмәгә җиләк исе таралган. Димәк, әниләре җиләктән кайтканнар. Аякларына йомшак башмакларын киеп, йокы бүлмәсеннән чыгып барганда, өстәл уртасында кукраеп утырган ак тартмага күзе төште. Ни өчен кабат өстәлгә менеп кунаклаган соң әле бу? Бу ак тартма дигәнебез ишегалдында чирәм чүпләп, йөгереп йөргән каз-үрдәкләрнең «әнкәсе» иде. Үткән атнада гына, үз вазифаларын җиренә җиткереп үтәгәч, тәртипкә китереп, Иркә аны үзе келәткә чыгарып куйган иде ләбаса. Кыз, кызыксынып, тартма капкачын күтәрде һәм «аһ!» итте: тартма эчендә ниндидер серле кошчыкның чуп-чуар нәни генә йомыркалары!

***

...Кояш, җир тирәли сәяхәтен дәвам итеп, Кушкаен үскән аланга тукталды. Нәрсә булган аланга? Танымаслык булып үзгәргән, гүя аланның күлмәген умырып төшергәннәр. Йомшак җилгә иркәләнеп, җай гына тирбәлеп утырган аллы-гөлле чәчәкләр дә, шул чәчәк таҗларына кунып, чык тамчылары суыручы күбәләкләр дә күренми. Шәрәләнгән аланны үрсәләнеп кычкырган кош тавышы ярып узды. Чү! Нәрсә бу? Кушкаен янында тузып яткан кош каурыйларын күреп, Кояшның йөзе караңгыланды. Һәркөн аны каршылаучы, нәсел дәвамчыларының борын төрткәнен көтеп ояда утыручы ана кош канга баткан. Нарасыйларын саклап калырга теләгәндәй, сыңар канатын ояга салган кошның үле гәүдәсе ята. И кошкаем, Кушкаен төбенә оялаган булсаң, бәлки, исән дә калган булыр идең. Юк шул, кечкенәләрең көн дә кояш күрсен, җылыда булсын дип, агач күләгәсеннән качып, ачыклыкка оя кордың. Ә Кеше дигәннәрең табигать балаларын бер дә аямый шул, үзенә буйсындырырга теләп вата, кыра, җимерә. Менә бит син дә йомырка эченнән борын төртергә дә өлгермәгән кошчыкларыңны ятим калдырып китеп бардың.

***

Тормыш дәвам итте. Һәр иртәдә Кояш барчасына: көчле-көчсезгә, явыз-яхшыга тигез итеп җылысын, яктысын өләште.

Бүген дә Кояш яшь киленнәрнең каккалап, суккалап кабартылган мендәрләре кебек болытларны куып таратты да үз биләмәләрен барларга чыкты. Кушкаен аланында бытбылдыкның сөенечле тавышын ишетеп хәйран калды. Әткә кошны чуар, мамык кебек йомшак йомгаклар сырып алганнар. Бу шатлык әткә кошка Иркәнең әти-әнисеннән бүләк иде.

***

Теге көнне, көтүләрне озаткач, Иркәнең әтисе белән әнисе, көн суыгында җиләк җыеп кайтырга дип, аланга килгәннәр иде. Аланның печәнен күптән түгел генә чаптырып киткәннәр икән. Җиләкне чиләккә түгел, тәлгәшләп кенә җыя алдылар. Аланга килгәч, һәрвакыттагыча, икесе бергә үрелеп үскән гашыйк каеннарның хәлен белергә дип, бер-ике адым гына атладылар да җан тетрәндергеч күренешкә тап булып катып калдылар: яшәү өчен көрәшеп яткан кош һәм чуар нәни генә йомыркалар иде анда... Әнкә кошка берничек тә ярдәм итеп булмый, ә менә кошчыкларны коткарырга өмет бар. Шамил абзый әле суынып та өлгермәгән йомыркаларны түбәтәенә тутырды да күкрәгенә яшерде.

***

...Көн кичкә авышты. Әткә кош кошчыкларын канат астына җыйнады. Кушкаен аланында бытбылдыклар тавышы тынмаячак, аның нәсел җепләре өзелмәгән, исән, яшиләр.

**Илүзә КАШАПОВА,**
*Мөслим гимназиясенең 9нчы сыйныф укучысы*

# ҖИҢҮЧЕ КЕМ?

## Беренче вакыйга

Безнең «Казан утлары» журналы редакциясе урнашкан бинадан ерак түгел бер күл бар. Юлны метро туннеленнән чыгып Энергетика университетын гына узасы. Беркөнне төш вакытында шул күлгә барып килергә булдым. Үзем генә киттем. Хезмәттәшләремнең күбесе чираттагы ялда. Киттем күлгә. Ни хәле бар икән? Шәһәр үзәгендә тончыгып, җан биреп ятмыймы? Әнә Идел белән Казансуны көн саен күреп торабыз. Безнең редакция тәрәзәсеннән уч төбендәге кебек күренеп тора алар. Суларының муллыгы, ярларының матурлыгы белән күңелгә ямь, эшкә дәрт бирәләр.

Аллага шөкер, күл исән, кипмәгән дә, беркая да китмәгән. Бер як ярына брусчатка җәеп, эскәмияләр куйганнар. Суга кереп торган тимер басма да бар. Басып торам шул басмада күл белән хозурланып. Әнә теге ярдан бер оя үрдәк бәбкәләре йөзеп килә. Уч төбенә сыярлык йомры-йомшак, җанга ятышлы йомгаклар. Тын гына шуып килделәр. Ана үрдәк, җим эзләп булса кирәк, камышлар арасына кереп югалды. Бәбкәләр үзләре генә калды. Шул мизгелдә, көтмәгәндә, алар янында күлдән күтәрелгән албасты, матурлыкның ямен алган гыйфрит кебек, су күсесе пәйда булды һәм бәбкәләргә ташланды. Тын күлдә мәхшәр башланды: бәбкәләр як-якка сибелде, тирә-якка су чәчрәде, дулкыннар кузгалды. Күр әле бу ана үрдәкне, камышлар арасыннан ни арада чыгып өлгергән? Аның яссы томшыклары ялтырап-ялтырап, кыска муены сузылып-сузылып алды. Су күсесенең иманын киде ул.

Тасма койрыкка читкә таба йөзеп китүдән башка чара калмады. Ул хурлыгыннан нишләргә белмәде. Аптырашта калды. Аннары яр буена йөзеп килеп, үткен тешләре белән черт иттереп камыш кисеп алган булды. Үрдәккә бирешкәч тә, ул алай ук беткән җан түгел әле, янәсе.

Бәбкәләр пипелдәштеләр, елтыр-йомры, шомырт күзләре белән әнкәләренә карадылар, үзләрен коткарып калган газиз җанга олы рәхмәт, яннарында шундый терәк булганга тыелгысыз куану, чиксез ярату хисен тоярга була иде бу карашлардан.

Су күсесе камышны колга кебек өскә күтәрде дә теге як ярга таба йөзеп китте. Яшел әләмнән илаһи яктылык, төрле төсләргә кереп балкыган нур сибелеп калды, гәрчә аны су күсесе күтәргән булса да.

## Икенче вакыйга

Безнең ишегалдында бер кара мәче яши. Дөресрәге, җан асрый. Хуҗасы үлеп ялгыз калганмы? Ташлап киткәннәрме? Кайчандыр кемнеңдер кадерлесе булгандыр инде ул. Бүген кайда ышык урын тапса, шунда йоклап, кайдан ни юнәтсә, шуны ашап йөрергә мәҗбүр. Кешеләргә зыяны тими. Бирсәләр – ашый, бирмәсәләр – комсызланмый. Шуңа күрә аңа әйбер әйткән кеше юк. Этләр генә яратмый үзен. Аны гел талап торалар. Кайчан карама, яралы бу песи. Йә битләре тырналып беткән була, йә сыртыннан кан тибеп тора, йә аягына басалмый.

Беркөнне безнең йортта яшәүче күрше егете Фәрит белән дүртенче катта подъезд балконында басып торабыз. Песи кибет почмагында утыра. Агачлар арасыннан (безнең Имәнлек урамының бер ягы – урман), алагаем зур этен ияртеп, өстенә спорт костюмы кигән, чәчен баш түбәсенә күпертеп өеп куйган бер хатын чыгып бара. Бозау кадәр овчарка ярсып өрергә тотынды. Каян, ничек күреп алган диген, теге мәчегә өрә икән. Йоннары ялык-йолык ялтырап торган бу затлы эт тә йолкыш мәченең, пычрак хәшәрәтнең үз территориясендә йөргәнен яратмады.

Бу этне күрүгә үк җаның табан астына төшәрлек. Менә ул хатын кулыннан ычкынып китте дә абалап өрә-өрә мәчегә таба чаба башлады. Без дүртенче каттан йөгереп төшеп җиткәнче ул мәхлук мәчене ботарлап ташлаячак. Мин кычкырам:

– Мәче, югал тизрәк!

Фәрит кычкыра:

– Мацы, кац!

Безнең кычкыруларны песиебез койрык астына да элмәде. Алай гына түгел, песи песиләнеп тормады. Овчарканы ул сыртын кабартып каршы алды. Башта сыртын кабартты, аннары дугага әверелде. Басып тора шулай эт каршында, дәһшәт каршында кара дуга булып. Күзләрендәге утлы нәфрәтне әйтеп-аңлатып бетерерлек кенә түгел. Эт – песигә, песи эткә караган. Коточкыч киеренкелек! Мондый хәлне көтмәгән овчарка каушап калды. Күзен читкә алды. Аннары акрын гына чигенде дә хуҗасы янына шылды. Ул киткәч тә, ачулы песи байтак вакыт шулай дуга булып басып торды әле.

Ну, песи, эт икәнсең, җиңдең бит!

## Өченче вакыйга

Майның кояшлы, җылы бер көне иде. Быел беренче тапкыр Биектау районындагы бакчама килдем. Минем белән Рифкать Хуҗи да килде. Казан технология университеты доценты ул. Хикәяләр дә яза. «Казан утлары»нда, «Идел»дә басылганы бар. Без кечкенәдән таныш. Пионер булып йөргән чакларда бергә Бөтенроссия лагере «Орлёнок»та булдык. Рифкать бакча эшен шәп белә. Үзенең дә бакчасы бар. Ул үстергән йөземнәр Ташкент йөземнәре белән янәшә куярлык. Башкасын әйтеп тә тормыйм. Дустым бакчада миңа да булыша. Сезонны бергә ачабыз, бергә ябабыз.

Рифкать килүгә гадәттәгечә эшкә ябышты. Кулына әле көрәк, әле пычкы, әле балта ала. Казый, тырмалый, кисә. Мин исә утын, су кертеп мунча миченә ут салдым. Шулвакыт алмагач ботагына кунган бер кош өзелеп-өзелеп кычкыра башлады. Очы аска кәкрәеп торган озын томшыклы урман күгәрчене иде бу. Канатлары күгелҗем-коңгырт, аксыл түшендә тимгел-тимгел таплар. Нигә шулай ярсып кычкыра соң ул? Нигә безне ошатмады? Һәрхәлдә монда килеп эшләп йөрүебезне мәгъкуль күрмәде бит инде.

Бераздан кошкай алмагачның очына ук менеп утырды һәм «разбой» сала башлады. Аннары тынды. Юкка чыкты. Юк, әллә кая китмәгән. Урман күгәрчененең тәрәзә йөзлеге өстендә оясы бар икән бит. Ул шул ояга кереп чүмәшкән. Анда йомыркаларыдыр, күрәсең. Димәк, тиздән балалары чыгачак. Без килгәнче тыныч кына, матур гына утырган инде ул. Хуҗа булып утырган. Бүген исә көтмәгәндә-уйламаганда ниндидер адәм затлары килеп керде дә, кулларына көрәк-балталар алып, тыз-быз йөри башлады. Хәтәр кешеләр болар. Кош үзе өчен борчылмый, балалары өчен борчыла. Тиздән дөньяга аваз салачак газиздән-газиз, кадерледән-кадерле җан ияләренең иминлегенә куркыныч яный! Юк, бәгырь җимешләрен саклап-коткарып калырга тиеш ул. Адәм затларын моннан куарга кирәк! Йөрмәсеннәр әле әллә кем булып.

Күгәрчен һөҗүмгә күчте.

Беренче атакага Рифкать Хуҗи дучар ителде. Дөресрәге, маңгае дучар ителде. Кош очып та килде һәм... Беренче һөҗүм уңышсыз булды. Шулай да пырхылдап өстенә килгән кошны күреп, Рифкать сискәнеп китте, башын артка ташлап чалкан төшә язды. Урман күгәрчененең икенче омтылышыннан соң дустымның маңгае кызарып чыкты.

Оя тирәсенә бүтән бармаска, кошны борчымаска булдык. Мунча кереп чыккач, онытылып китеп, оя янына барып басканмын бит. Урман чибәре канаты белән колагыма кундырды.

Бакчадан тизрәк китү ягын карадык.

***

Көчле җиңә. Бу – табигать кануны. Мин сезгә сөйләгән өч вакыйгада исә көчсезләр җиңде. Үрдәк – су күсесен, песи – этне җиңде. Урман күгәрчене безне кыйнап җибәрде. Үрдәкнең суда йөзәргә, песинең урамда йөрергә, кошның тынычлап (бу бакчаның минеке икәнен белми бит ул) бала чыгарырга хакы бармы? Бар!

Димәк, табигатьтә гаделлек тә җиңә!

**Вакыйф НУРИЕВ**

***Редакциядән:***

*Кадерле авторларыбыз һәм укучыларыбыз! Бу сәхифәгә язмаларны сездән дә көтәбез.*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Ашыкма!

М.Горький исемендәге ял паркы янында троллейбуска утырдым. Алгы рәтләрне чегән хатыннары сырып алган. Шулар янына барып бастым. Телләрен аңламасам да, аларның үзара сөйләшкәнен тыңларга яратам. Шау-гөр киләләр.

Троллейбус Татар академия театры янына җиткәндә, урамга карадым. Театрның афишалар элә торган тактасында «Премьера. Туфан Миңнуллин. «Адәм баласына ял кирәк» дип зур хәрефләр белән язылган белдерү тора. Күңелдә рәхәтлек. Масаю да бар, әлбәттә. Чөнки мин инде премияләр алгалап, тәнкыйтьчеләр тарафыннан шактый ук иркәләнеп, бераз гына бозыла башлаган кеше. Җае туры килгән саен, «мин» дигән сүзне дә кулланам. Бу юлы да, мине күрәләр микән, дип кукраеп, як-ягыма карангалап алдым. Тәрәзәдән карап баручылар минем исем-фамилияне укыр өчен генә тәрәзәгә караганнардыр кебек тоелды.

Рәхәт! Валлаһи, дип әйтәм, рәхәт! Купләрнең күз карашы афишага ябышып калды. Хәтта чегән хатыннары да татарча язылган афишаны укып үттеләр. Әйе, әйе, укып үтүләренә әз генә дә шигем юк иде. Ник дигәндә, тәрәзәгә төбәлгән чегән хатыннарының берсе, тәрәзәдән күзен алып, миңа карап куйган сыман итте дә, драматург, диде. Кирәк бит, ә? Татары белә дә белә инде мине, анысына печтик тә шикләнгән юк. Керфек буйый, күз төбе каралта, каш сыза торган карандаш сатып табыш итүче чегәннәр дә мине таныйлар икән ләбаса. Әнә үз телләрендә кызып-кызып сөйләшәләр, драматург, драматург, дип туктаусыз кабатлыйлар. Билгеле инде, сүз минем турыда бара. Троллейбуста драматург мин генә, афишада минем исем.

Шунысы гаҗәп: исемемне, фамилиямне ни өчендер телгә алмыйлар. Югыйсә афишадан укыдылар ич инде.

Колакларны тагын да сагайтыбрак тыңлыйм: бәлки, әйтәләрдер минем исемне, мин генә ишетеп өлгерми каламдыр! Тыңлый торгач, чегәннәр сөйләшүендә «Армавир», «Константиновка» дигән сүзләр ешрак чыга башлады. Туктале, Армавир, Константиновканың драматургка, ягъни мәсәлән, миңа ни катнашы бар? Әллә минем пьесалар Армавир шәһәрендә, Константиновка авылында куелып, бу чегәннәр шунда спектакль караганнармы?

Троллейбус базарга якынлашканда, ниһаять, барысы да ачыкланды. Чегән хатыннары, драматург, димиләр икән ич, Краматорск, диләр икән. Ялгышмасам, шундый шәһәрме, станцияме бар.

Пырхылдап көлеп җибәргәнемне үзем дә сизми калдым. Чегән хатыннары базарда төшеп калгач та, вокзал тукталышында үзем төшкәч тә көлдем. Үткән-сүткәннәрне гаҗәпләндереп, эчемне уа-уа көлдем. Шушы вакыйганы дусларга сөйләп тә көлдем.

Ә язганда көлмичә генә язам. Чөнки бик гыйбрәтле вакыйга бит. Масаюның куркыныч чир икәнен янә бер кат исбатлаучы вакыйга. Масаю чире колакны томалаган, Краматорскины драматург дип ишеттергән.

Димәк, хәтта күзеңә карап, кабат-кабат исемеңне әйтеп мактаган очракта да, күккә сикерергә ашыкма. Бәлки, сине мактаучы, Краматорск, дип әйтәдер?!

**Хәсән ТУФАН**

## Түбән Кама түбән түгел

*– Без, – диде ул, – яшьлек шәһәре*
*салабыз ич... Ә исеме... иске,*
*шигъри түгел. Бигрәк тә «түбән»*
*дигәне...*

Г.Әпсәләмов

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре юк әле.
Синең хәл дә, Түбән Кама,
Нәкъ шулай ук шул әле.

Билләһидер, суга салам
Йөзегемнең кашларын,
Түбән дигән кушаматтан
Котылмаса башларым!

Түбән дигән сүзегезне
Бүтән әйтмәсәгезче,
Безнең бөек эшебезне
Түбәнәйтмәсәгезче!

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре юк әле,
Бездә, җаный, мондый хәлләр,
Исемсезләр күп әле.

**Айдар ХӘЛИМ**

## Марсель Галинең «Талисман» дигән китабы чыгу уңаеннан

Нишләргә, аңлап булмый, юк кесәмдә
киредән укый белгән күзлегем дә!
«Талисман» дигән сүз күренми бит әле
татарның академик сүзлегендә!

Бер карасаң, «тылсымлы билге» инде ул,
ягъни мәсәлән, бөти!
«Халык шагыйре»нә әйт әле шуны син,
Габделҗаббаретдин түти!..

## Зөфәр Фәтхетдин афоризмнары

Әй, бу безнең үткән гомерләр
үткәч тә үтә бит бушка:
Тач Зөфәр Фәтхетдин афоризмы:
сүз – озын, акыл – кыска.

***

Бер дошманым минем өстән
Президентка шундый жалу яза:
«Үтерергә кирәк. Айдарның исән булуы
безнең өчен иң каты җәза».

**Шәүкәт ГАЛИЕВ**

## Үзеңнеке

Капка асларыннан чыгып, ырылдаган этләр балакны йолыккан-тарткалаган сыман, күңелне талаган борчулы уйлар була. «Пошёл!» дип куып кына булмый. Үз «этең» бит.

## Вагонда сөйләшеп кайталар

– Минем әти авыз ачып иснәгән иде, ияге салынды да төште. «Скорый» чакыртырга туры килде.

– И-ии, анысы нәрсә! Минем хатын әнә шундый каты итеп төчкереп җибәрде – соңыннан врач әйтте, мие селкенгән, диде. Баш мие инде!

## Дачада

– Кара миләштән эчемлек ясагач, бакчада калдырасыңмы? – дип сорый күршесе.

– Менә син, унсигез яшьлек кызга өйләнсәң, читтә тотар идеңме, әллә кочактамы?

## Баштан башлый

Песи баласы белеп туа – балыкның койрыгына тәпие белән басып, иң элек башын чәйни. «Башыңны ашармын!» дип тикмәгә әйтмиләр икән. Баштан башлаучы бүтән ерткычлар да бар. Бигрәк тә ике аяклылар.

## Лимон

Миллионны бер шаяны «лимон» дип атаган. Киткән шуннан телдән-телгә тәгәрәп. Берзаман чын лимон бер «лимон» булмагае.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Җөмләләр

***

Җырчы: «Бу җырның көен үзем яздым», – дип игълан итсә, җырның җыртыгы җырылып китә.

***

Минминлеген мәнле тота белгән милләтнең миллек бәйләү алымында да милли чалым була.

***

Президентның төчкерүе халыкка ютәл булып төшә.

***

Тигәнәк – керпе уйнаштан тудырган гөл.

***

Ярлы кесәсендә – шымытыр, бай иңсәсендә шом ятыр.

***

Арзанлы хәмер эчте-эчте дә кыйммәтле даруга күчте.

Сәхифәне **Марсель ГАЛИЕВ** әзерләде.

# Ictimaği-mədəni tormışıbızdan

# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

## САЙЛАУ

18 сентябрьдә булачак Россия Федерациясендә VII чакырылыш Дәүләт Думасына сайлауга «Бердәм Россия» федераль съездында партия исемлегенең Татарстан Республикасы территориаль төркеменә 14 кандидат кертелде. 6 кандидат бермандатлы округлар буенча тәкъдим ителде. «Бердәм Россия» партиясе исемлегендә республика төркемен ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкли. Президент фикеренчә, Татарстанны тәкъдим итәчәк бердәм төркемдә үз эшенең осталары, тәҗрибә туплаган, яхшы мәктәп узган абруйлы кешеләр булырга тиеш.

## ФОРУМ

Иннополис шәһәрендә V Халыкара «Президент академиясе җәйге кампусы – 2016» форумы үткәрелде. Аңа бөтен Россиядән иң сәләтле студентлар җыелды. Сөйләшү заманча һәм нәтиҗәле белем бирү технологияләре турында барды. Форумда чыгыш ясаган ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов кампусның мөһим роль уйнавын әйтте, яшьләрне республикадагы инновацион проектлар белән танышырга чакырды. Форумда Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе урынбасары Аркадий Дворкович, РФ элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министры Николай Никифоров, РФ Халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе ректоры Владимир Мау катнашты.

«Президент академиясенең җәйге кампусы – 2016» мәгариф проектында катнашучылар РФ Федераль Җыены Дәүләт Думасы Рәисе Сергей Нарышкин һәм ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин белән дә очраштылар.

## БЮСТЛАР АЧЫЛДЫ

Түбән Новгород өлкәсенең Кызыл Октябрь районы Уразовка район үзәгендә шушы якта туып үскән, гомерләрен татар җыр сәнгатенә багышлаган Рәшит Ваһапов һәм Хәйдәр Бигичевка бюст (авторы – сынчы Мәхмүт Гасыймов, архитекторы – Герман Бакулин) ачу тантанасы булды. Шушында ук мәшһүр татар җырчылары турында мәгълүмат язылган стела да бар.

Тантанада ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Валерий Шанцев катнашты һәм чыгыш ясадылар. Рөстәм Миңнеханов Рәшит Ваһапов һәм Хәйдәр Бигичевларның истәлекләрен мәңгеләштерүгә турыдан-туры катнашучыларга Рәхмәт хатлары тапшырды.

## XVI ФЕДЕРАЛЬ САБАНТУЙ

Быел XVI федераль Сабантуй Түбән Новгород шәһәрендә узды. Ул бер көн алдан кичен М.Л.Растропович исемендәге Дәүләт филармониясе концерт залында ТР сәнгать осталары концерты белән башланып китте. Анда тамашачыларны ТР Премьер-министр урынбасары Васил Шайхразиев һәм Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Валерий Шанцев сәламләде.

Сабантуй 1 Май аттракционнар паркында һәм аның янәшәсендәге «Локомотив» стадионында үтте. Бәйрәмдә Россиянең 47 төбәгеннән 442 делегат катнашты. Бәйрәм котлавын ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм Түбән Новгород өлкәсе губернаторы Валерий Шанцев ирештерделәр. Р.Миңнеханов өлкәнең татар милли-мәдәни мохтәриятенә «Форд-транзит» микроавтобусын бүләк итте. Төрле ярышларның үзәгендә, әлбәттә, татарча көрәш иде. Ул кызу барды һәм бәхәсле булды. Бәхәс Татарстан көрәшчеләре белән Түбән Новгород спортчыларының – икесенең ике төрле алым куллануы аркасында килеп чыкты. Нәтиҗәдә федераль Сабантуйның баш батыры булып Түбән Новгородтан Рөстәм Садыйков калды һәм «Фольксваген-Поло» автомобиленә ия булды.

Федераль Сабантуйның күчмә символы – «Тулпар ат» Әстерхан өлкәсе Думасы Рәисе урынбасары, «Дуслык» татар җәмгыяте рәисе Әнвәр Алмаевка тапшырылды. Димәк, Россиянең төп Сабан туе киләсе елда Әстерхан каласында узачак.

## ДЕРЖАВИННЫ ИСКӘ АЛУ

Җәмәгатьчелек шагыйрь, дәүләт эшлеклесе Гавриил Романович Державинның туган көнен һәм вафатына 200 ел тулуны билгеләп үтте.

Бу көнне Казанда аның һәйкәленә чәчәкләр салынды. Олуг шәхеснең туган ягында – Лаешта, үзәк мәйданда театральләштерелгән тамаша күрсәтелде, шигырь бәйрәме үткәрелде. Шушында ук Державин исемендәге республика премиясенең (ТР Президенты Указы белән бу бүләк шушындый статус алды, аның күләме 200 мең сумга җиткерелде) быелгы лауреатлары игълан ителде. Алар – шагыйрь Ренат Харис, әдәбият галимәсе Әлфия Галимуллина, шагыйрә, тәрҗемәче Алёна Кәримова. Лауреатларны котлыйбыз!

***

Мәскәү һәм Бөтенрусь патриархы Кирилл да Татарстанга сәфәрен Лаеш районы Каип авылында шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесе Гавриил Державинга һәйкәл ачу тантанасында катнашудан башлады. Бу һәйкәлне «Россия даны аллеясе» федераль проекты кысаларында Бөтенроссия дәүләт юстиция университеты (ректоры – Ольга Александрова) эшләтте. Патриарх Державинга һәйкәл ачуны Татарстанда гына түгел, бөтен Россия күләмендә зур вакыйга булуын әйтте. Тантанада РФ Президентының Идел буе федераль округындагы тулы вәкаләтле вәкиле Михаил Бабич, ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов катнашты һәм чыгыш ясадылар.

## ЖУРНАЛИСТЛАР КАЗАНГА КИЛДЕ

Казанда милли һәм төбәк массакүләм мәгълүмат чараларының VI форумы булып узды. Аны ТР «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы оештырды. Ул ТР Хөкүмәте ярдәмендә үткәрелә. 2014 елдан ук «2014–2020 елларга Татарстанда дәүләт милли сәясәтен тормышка ашыру» дәүләт программасына да кертелде.

Форумда Россиянең 25 төбәгеннән 230 вәкил катнашты. Әлеге чарада матбугатның бүгенге хәле, проблемалары, киләчәге, үсеш перспективалары турында сөйләштеләр. Этникара журналистика гильдиясе рәисе Маргарита Лянге катнашында «Этникара журналистика һәм кризис» дигән темага семинар да булды.

## «СӘЛӘТ»ЛӘР ҖЫЕЛДЫ

Биләр тарихи-археологик музей-тыюлыгында V Халыкара «Сәләт» форумының рәсми ачылу тантанасы булды. Форум ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән уздырыла. Монда Татарстанның барлык районнарыннан, Россиянең дистәләрчә төбәгеннән һәм чит илләрдән җыелган 5 меңнән артык сәләтле бала һәм яшьләр катнашты. Форумда катнашучыларны ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде. «Сәләт»ләр алдында РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов, Казан дәүләт энергетика университеты ректоры Эдвард Абдуллаҗанов, спортчы Ирек Зиннуров һ.б. чыгыш ясады.

## КӘРИМУЛЛИН УКУЛАРЫ

ТР Милли китапханәсендә китапчы-галим, филология фәннәре докторы, академик Әбрар Кәримуллин укулары узды. Ике елга бер үткәрелә торган бу чарага татар галимнәре белән бергә Белоруссия, Литва, Казакъстан, Төркия, Дагыстан һәм Кырымнан да кунаклар чакырылган иде. Кәримуллин укуларында катнашучыларны ТР Дәүләт Советының мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев сәламләде. Чыгыш ясаучылардан һәркем китапчы-галимнең титаник хезмәтенә сокlануын белдерде, аның милли мәдәниятебез тарихында зур роль уйнавын әйтте.

## «БЕЗ – ТУКАЙ ОНЫКЛАРЫ»

Арча районы Яңа Кырлай авылында шундый исемдәге чатырлы лагерь эшләде. Аны ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы Татарстан мәгарифне үстерү институты, Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе, Арча педагогия көллияте бергәләп оештырды. Анда Татарстанның барлык районнарыннан, шулай ук Удмуртия, Марий Эл республикаларыннан, Саратов өлкәсеннән, хәтта Казакъстаннан 150ләп малай һәм кыз килгән иде. Алар ял итү белән бергә әдәби чараларда катнаштылар, Тукай турында белемнәрен баеттылар, язучылар, фән эшлеклеләре, журналистлар белән очраштылар. Лагерьда төрле түгәрәкләр, мастер-класслар эшләде.

## ИСТӘЛЕК ТАКТАСЫ КУЕЛДЫ

Троицк шәһәренең Октябрь урамындагы 1912 елда кымыз белән дәваланырга килгән Г.Тукай тукталган сәүдәгәр Абдулла Яушев йортына мемориаль такта куелды. Бөек шагыйрь монда шәһәр җәмәгатьчелеге, иҗат белән шөгыльләнүче яшьләр белән очраша. Гранит тактаны ачу тантанасында Зәйнулла Рәсүлев укуларына җыелган кунаклар да катнашты. Тантанада Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь Ирек Сабиров такта куелган йортның бай тарихы белән таныштырды, Тукайның шигырьләрен укыды.

Уфада 92нче яшендә Башкортстанның халык язучысы, Татарстан һәм Башкортстан республикаларының атказанган фән эшлеклесе, Бөек Ватан сугышында катнашкан **Суфиян Шәмсетдин улы Поварисов** вафат булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть А.ЗАРИПОВА «Завещание», рассказ С.ЯКУПОВОЙ; стихи Р.МИННУЛЛИНА, Л.ЛЕРОНА, Г.БАЙРАМОВОЙ, Б.ИБРАГИМОВА.*
*«Новые имена»: рассказ А.ГАРАЕВОЙ «Ни һоу! Или как поживаешь?»*
*«Литературная критика»: статья Р.СВЕРИГИНА о творчестве Камиля Каримова».*
*«100-ая страница»: Ф.УРАЗАЙ. «Нация живёт памятью и духом».*
*«Тукай и татарская литература»: рубрику ведёт Р.Рахман.*
*Наши юбиляры: Ф.ГАЛИЕВА. «Жизнь, как одно мгновение»;*
*«70 лет со дня рождения Харраса Аюпа»: Ф.ХАСАНОВА. «Он был мастером поэтической молитвы»; стихи Х.АЮПА.*
*«Искусство»: Ю.САФИУЛЛИН. «Она просто блистала на сцене».*
*«Театр — это волшебство». Беседа И.ИБРАГИМОВА с главным режиссёром Оренбургского русского драматического театра Р.ИСРАФИЛОВЫМ.*
*«История»: статья Ф.БАЙРАМОВОЙ, посвящённая 140 летию со дня рождения Хади Атласи.*
*«Встречая юбилей»: очерк З.АХМЕРОВА «АБ-225».*
*«Маленькие»: М.ИМАШЕВ. «Маленький Масгут».*
*« Природа и я»: В.НУРИЕВ.«Чья победа?»*
*«Белый парус»: рассказы Х.ИСМАГИЛОВА, И.КАШАПОВОЙ.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Из фотоархива журнала.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Казань моя, Казань...; Голубое озеро.*

# IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: novel by A.ZARIPOV «Testament», story by S.YAKUPOVA; poems by R.MINNULLIN, L.LERON, G.BAYRAMOVA, B.IBRAGIMOV.
«New names»: story by A.Garayeva «Ни hoy! Or how are you?»
«Literary criticism»: article by R.SVERIGIN about creativity by Kamil Karimov».
«100th page»: F.URAZAY. «Nation lives with memory and spirit».
«Tukay and Tatar literature»: section is led by R.Rahman.
Our anniversaries: F.GALIEVA. «Life is like an instant»;
«70th anniversary of Harras Ayup»: F.HASANOVA. «He was a master of poetic prayer»; poems by H.AYUP.
«Art»: YU.SAFIULLIN. «She's just so brilliant on stage».
«Theatre is magic». Conversation by I.Ibrahimov with the director of the Orenburg Russian Drama Theatre R.ISRAFILOV.
«History»: article by F.BAYRAMOVA dedicated to 140th anniversary of Hadi Atlasi.
«The small»: M.IMASHEV. «Little Masgut».
«Meeting the anniversary»: an essay by Z.AHMEROV «AB-225».
«Nature and me»: V.NURIEV «Whose victory is it?»
«White Sail»: stories by H.ISMAGILOV, I.KASHAPOVA.
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
From the photo archive of the magazine.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: My Kazan, Kazan...; the Blue Lake.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казаным, Казаным...

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Зәңгәр күл.